# КАЗАН УТЛАРЫ

10
ОКТЯБРЬ
1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**

ОКТЯБРЬ
1978

## Бу санда

Г. РӘХИМ. Туган илем, Татарстан... Шигырь . . . 3
Ф. САФИН. Игенчегә. Шигырьләр . . . . . . 4
К. СИБГАТУЛЛИН. Кар шыгырдый. Шигырьләр . 7
Р. КӘРАМИ. Очар кошлар белән янәшә. Повесть 12
Р. ГАТАУЛЛИН. Йолдыз җавап язмый. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 64
Г. САДӘ. Мәхәббәт елы. Шигырьләр . . . . . 68

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

М. ХУҖИН. Ике бөртек күз яше. Хикәя . . . . 72

И. ЮЗЕЕВ. Кыр казлары артыннан... Драма . . 77

ОЧЕРКЛАР

Җ. РӘХИМОВ. Күпер . . . . . . . . . . . 113
Ш. РӘКЫЙПОВ. Кайту . . . . . . . . . . 120

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ХӘСӘНОВ. Бөтен халык эше . . . . . . 132
М. ГОСМАНОВ. Саклап каласы иде . . . . . 135
Г. БӘШИРОВ. Әле соң түгел . . . . . . . . 137

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ш. АБИЛОВ. Поэзиябез тарихына яңа исем . . 141

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Әгәр син язмасаң, әгәр без язмасак . . . . . . . . . . . . . . . 148
Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Әдәби тәнкыйть һәм эстетик тәрбия . . . . . . . . . . . . . 157

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ШИРИЯЗДАНОВ. Аның дәрте, дәрманы белән 162

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## КИТАП КҮЗӘТҮ

М. АБДУЛЛИН. Ниятләре яхшыдан түгел . . . 171
Х. МАКСУДОВ. Муса Җәлилгә багышланган китап . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ф. ВӘЛИЕВА. Сон суларын эчкән ул . . . . . 176
Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Җиң сызганып эшләр чак. . 178

## МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Түребездә: айсорлар . . . . . . . . . . . . 181

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

К. МОСТАФИН. Пародияләр . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 189

А. МОНАСЫЙПОВ музыкасы, З. НАСЫЙБУЛЛИН шигыре. Кеше булсаң. Җыр . . . . . . . 192

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 21/VI-1978 ел. Басарга кул куелды 23/VIII-1978 ел. ПФ 07121. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91.000 экз. Заказ В-211. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Гәрәй Рәхим

### Туган илем, Татарстан...

Синең тарих — минем гомер башым,
Киләчәгең — минем киләчәк.
Син көрексез булсаң — мин көрексез,
Һәм син чәчәк булсаң — мин чәчәк.

Мин дошманга синең җавап белән
Җавап бирдем — кайтты үчләрем.
Тик сүземне үлчәп сөйләдем мин —
Синең үлчәм белән үлчәдем.

Синең үсеш белән мин зур үстем,
Синең дәртең белән дәртләндем.
Канатларың белән канатландым,
Шатлыкларың белән шатландым.

Синең яшьлек белән яшәрдем мин,
Синең яшен белән яшьнәдем...
Синең көнең белән көн күргәнгә,
Синең гомер белән яшәрмен.

Син бит мине шундый көчле иттең,
Өстәп бирдең тагын изгелек.
Рәхмәт, илем! Инде үзем сине
Күтәрергә көчем бар кебек.

## Фәннур Сафин

### Игенчегә

Күңелеңдә җиргә кадер-хөрмәт.
Кырны сыйдыралган олы йөрәк:
яңгыр яумый торса, кырлар түгел,
синең йөрәк яна дөрләп-дөрләп.

Офыкларга кадәр уйнап-уйнап
йөгерәдер алтын дулкыннарың.
Төннәрен дә шулай пышылдашып
үзенә дәшә сине мул кырларың.

Читкә китсәң, чит кырларга ятып,
син тыңлыйсың ерак кырлар шавын...
Үз күңелең тулы ут булса да,
кырга карап син көтәсең явым!

### Сөембикә манарасы янында

...Хезмәт сөйгән халкым борынгыдан,
йөрәгеннән барын үткәргән...
Җилкәсенә кайгы белән бергә
биек манаралар күтәргән!

Риваятьләр тыңлый монда халык...
Манарага аңа соң нәрсә,
ишетми ул, гүя көндезен дә
ак йолдызлар белән серләшә.

«Сөембикә» горур карап тора,
эндәшергә дип баш игәндәй.
«Мин халыкның хыялый бала чагы,
мин гаепле түгел, — дигәндәй. —

Сез тыңлагыз, сезнең җан бутамас,
аерыр бит чынын-ялганын?
Мин уйлыйм бер ерак бала чакны,
сез уйлагыз үзегез калганын...»

## Хаклык турында

Җирдә күпме сер бар, моңдаш туган,
бер серләшик, бәлки, тын гына,
гасырларны кичеп, бу заманга
килеп җиткән хаклык турында.

Чал тарихта шушы көнгә кадәр
җанга газиз күпме хаклар бар?!
Һәрбер мизгел — гомер кебек озын,
Җир шарыдай авыр чаклар бар...

Гел чынбарлык булыр кебек иде
кояшларга җиткән теләкләр.
Бу дөньяның кайсы почмагында
саркып калды алар йөрәктән?..

Килмәдеңме, Кеше, бу җир йөзен
тоташ хаклык итәр өчен син?!
Мин тезләнәм: изге еллар безне
буш мизгелләр өчен кичерсен!..

Вәгъдәдәге ак юлларны сузып
үтәр өчен туган җирләрдән,
уйга талган Кеше, хаклык өчен
яна, димәк, төптән, тирәннән!..

## Кайту

Тагын өйгә! Туган якка!
— Мин сине көттем, көт-те-ем! —
дигән кебек, өй өстендә
бии күгелҗем төтен!..

## Курай турында баллада

Син сазыңда уйна бу тынлыкны,
оркестрда уйнат — теләсәң! —
шулай дияр идем, әгәр, туган,
курай моңы барын белмәсәм.

Ак пәрдәне ярсу җилфердәтеп
җанга тула — язгы җилмени? —
Шундый давыллы моң дулкыннарын
күңел дигән якты ил тели!..

Моң сыярмы күңел ярларына? —
Бәргәләнә уйлар ташкыны.
Яна шулай Җирнең билгесез бер
бик күптәнге һәм бик яшь моңы.

Ул моңнарны беркөн пьедесталдан
бөек Тукай үзе тыңлады.
Болытларга кадәр күтәрелде
Җирнең асыл курай моңнары.

Ә бер агай шунда ник үкседе,
тезләренә салып чал башын?
Юаталсак аны юатыр идек,
күрер идек берәр чарасын.

— Ник елыйсың, агай, ник үксисең,
тезләреңә салып чал башың?
— Моң кагылды күңел болытына, —
дигән кебек булды Тукай кинәт, —
кагылмагыз аңа! Еласын...

Ник кагылыйк аңа! Өзгәләнсен,
шуның өчен дә бит ул — Кеше.
Кешелекнең шатлык-кайгыларын
ялкын итеп җанда йөртүче.

Җирдә азмы андый бәхетлеләр
бу мизгелдә, шушы минутта?!
Бер бушанып нигә үксемәскә
күңел тулы дөнья булып та,
йөрәкләргә ялкын тулып та?!

Күңел тулу — мең рәхмәтле булу,
күңел тулу — мәрхәмәтле булу,
Күңел тулу — җәрәхәтле булу,
Күңел тулу — мәхәббәтле булу...

Һәм без киттек уйчан урамнардан,
уйнамадың бүтән нигәдер...
Елатырмын диеп уйладыңмы
әңгер сарган Казан өйләрен.

Җанда курай моңы чыңлый һаман,
олы тынлык үзен тыңлый сыман...

Син сазыңда уйна бу тынлыкны,
оркестрда уйнат — теләсәң! —
Шулай дияр идем, Ифрат туган,
курай моңы барын белмәсәм...

## Кадыйр Сибгатуллин

### Кар шыгырдый

1

Көмеш тоякларын
тугайларга
сузып яткан ап-ак тай кебек,
бишегендә — күктә кырын ята
кичә генә туган Ай көлеп.
Күктә үзе,
тәрәзәдә күзе:
өйләрендә нишли кешеләр?

...Өйдә җылы.
Тышта һава чатный,
каеннардан карлар ишелә.

Өйдә яхшы, якты, тыныч, җылы.
Һавасында бала тыны бар.
Ике бармак тарта каба йонын —
безнең өйдә лира моңы бар.

Кабасыннан кулын алмый гына
бер күз ташлап ала ишеккә.
Орчыклары туктап торган чакта
тәрәзәгә карый — бишеккә.
Тәрәзәгә нигә карый икән,
тәрәз артларында кемнәр бар?
Ник ишеккә карый икән әни?
Ник шыгырдый икән тышта кар?

2

Берәм-берәм
елдан-елга керәм,
узганнарны үтәм сүткәләп...
И елаган идек үксеп-үксеп,
ник кайтмыйсың диеп, үпкәләп.
Язмышларның мәрхәмәтсез чагы.
Уйларымнан китми ул һич тә.
Бик сагышлы иде һәм бик салкын,
без бик мескен идек ул кичтә.

Иске табак кебек изелгән Ай —
бозлы тәрәзәдә шәүләсе..
Уйлап арган башын түбән игән,
Сәке почмагында гәүдәсе.

Салкын өйдә ике ач бәндә без,
икебез дә елап арыган.
Караңгыда иске шәлен капшап,
иңнәренә барып сарылам.

Кайсы йортлар инде көтеп алды.
Үлем белән тормыш килешә.
Яки кайтып, яки гүргә ятып
өзде ирләр алыш-бирешне.

Вафат дигән хәбәр җиңел түгел,
күнәсеңдер күнгән кадәре.
Өметеңне өзми ялгап тора
«Хәбәрсез юк» дигән хәбәре.

Әллә кайда сузып-сузып елый —
әллә бүре, әллә эт улый.
Ватык капкаларны кага-кага,
әллә язмыш, әллә җил дулый.

Тышта дөнья тынып торган чакта
әллә нәрсә әни ишетә.
Сискәндереп сикереп кузгала да,
йөгерә-йөгерә бара ишеккә.
Тәрәзәгә килә. Тыңлап тора.
Тагын ишек биген күтәрә.
Яңа кертеп япкан тоткын сыман,
үз өендә үзе үртәлә.
Язмыш шулай алдамакчы була.
Ышаныр да, барыбер чыгар, ди.

Өй артында, ахры, этләр йөри.
Кар шыгырдый, һаман шыгырдый...

## 3

Мылтык тавышы дисәң, кемнәр атсын?
Агач шартлый торган суык чак.
Күмерен әни мичтән яңа тартты,
җылы бөркеп җемелди учак.

Орчыклары тынып торган чакта
оныгына карый — бишеккә.

Моңлы, серле, шомлы шыгырдый кар.
...Ике күзе күчә ишеккә.
Ике күзе һаман ишектә.

Әллә йөрәк, әллә кар шыгырдый,
әллә тышта аяк тавышы.

Бишеклəрдə — кече оныклары.
Гомерлəрнең — үтеп барышы.

Вафат дигəн хəбəр җиңел түгел,
күнəсеңдер күнгəн кадəре.
Өметлəрне өзми ялгап тора
«Хəбəрсез юк» дигəн хəбəре.

Кичə генə туган Ай елмая.
Бишек уйный, уйный җаныбыз.
Тышта салкын... Булса юрганыгыз,
яңа туган Айга ябыгыз.

## Авыл урыны

Урамнары əле беленеп тора,
нигез саен — чокыр, багана.
Шау чəчəкле алмагачын күреп
килеп кердем үтеп барганда.

Арба эзен күмгəн яшел чирəм.
Бака тавышлары сазлыкта.
Киртəлəрен баскан алабута.
Авып ята черек казыклар.

Инде быел буылмаган инеш.
Чишмəлəре кипкəн, саеккан.
Буш нигезнең каены ботагында
йорт җиткереп кергəн саескан.

Сүтсəң, бəлки тузан гына калыр,
исəн килеш əле йорт əрəм.
Тəрəзен дə каплап маташмаган,
ташлап киткəн икəн бу адəм.

Соңгы йортның инде хуҗасы юк.
Кошлар торыр — алар талымсыз...
Бу авылда туып-үскəн кеше
Калмас микəн туган авылсыз?

Бабалары ята шушы җирдə,
кайтыр əле — карар, кадерлəр.
... Китə алмый ияреп кеше артыннан
туган нигез белəн каберлəр.

Туган җирдə урын иркен безнең,
кая барсаң — шунда хуҗа син.
Бəхетенə таба китə кеше,
ияреп бармый арттан нужасы.

Бик кирəккə күрə китəлəрдер,
ялгыз язмышлардан котылып.
Китккəннəрнең үткəннəре генə
югалмасын инде онытылып.

Ни әйтсәң дә, бераз ямансурак
нигезенә хуҗа калмагач.
...Ак чәчәген коеп елый кебек
авыл урынында алмагач.

## Картлар

Җиңел чагы туры килмәгәнгә,
онытылмаган әле авыр чаклар.
Зарланмыйча гына дәшми йөри,
хәтер бетте диеп, тыйнак картлар.

Үз гомере белән үлчәп карый,
сынап карый: болар нинди затлар?
Нәрсә бөркәнсәк тә, безне таный,
замананы таный сизгер картлар.

Төскә түгел, алар төпкә карый.
Нигә сүзләр, нигә ялган антлар?!
Эшебезне, үзебезне аңлый
үзебездән элек зирәк картлар.

Үзләренә әле без түлисе
онытылмый торган олы хак бар.
Үзләреннән туган изгелеккә
рәхмәт укып йөри сабый картлар.

Кер булганга түгел, сер булганга
гүргә кадәр бәлки әйтми саклар.
Оланнарга зыян килмәсен дип,
кирәк булса әгәр — сабыр картлар.

Карап кына, санап, барлап кына
бу тормышның гел алдыннан атлар.
Әйтерсең лә әле яшәмәгән,
бер дә картаймаган даһи картлар.

## Эскәмиядәге карт

Йоклый алмый чыкты микән?
Чал сакалын бер сыпырды.
Түбәтәен кырынайтып,
моңсу гына уйлап торды.

Иреннәре көлеп куя,
тере очкын — карашында.
Бүлдермәгез! Карт утырды
яшьлегенең канатына.

...Сәер генә карап алды
утыргычның уң ягына.
Гаҗәпләнде, күрә алмагач
сөйгән кызын үз янында.

•

Нинди генә булсын, мәхәббәтне
тиңли алмам әрнер ярага.
Бер генә көн чынлап яратсам да,
әллә нигә җитә янарга.

Сагышлары арттан килсә килер,
илаһидыр әле бу чагым.
Әле һаман дөрли йөрәгемдә
унсигездә яккан учагым.

Һәр минутта, һәр сәгатьтә, һәр көн
мәхәббәтем тота имтихан.
Еллар белән юллар сынап тора.
Арта гына бара ул илһам.

Яратуның күгенә менгәндә дә
әле тагын калыр хыялым.
Кешенең бит мәхәббәте икәү:
берсе — чыны, берсе — идеалы.

## Атыла йолдыз

Баш түбәмдә генә, бер үземә
янып тора күпме йолдызлар!
Уйлы-моңлыларга ялгыз чакта,
әле ярый, күктә йолдыз бар.

Бу төнем дә әнә шундый чагым.
Барыбер миңа — җирдә, күктәме,
сердәш кирәк миңа сөйләшергә,
киңәшергә азга, күпкәме.

Саубуллаштым йөрәгемнән йолкып.
Хисләр аерылышу чатында.
Мәңгелеккә, гомерлеккә микән?
...Җавап булып йолдыз атыла.

Атылсын, дим, бетмәс, бетмәс әле.
Берсе сүнсә, берсе кабыныр.
... Кабынганы янда яна торыр,
ә сүнгәнен күңел сагыныр.

Атыла йолдыз. Миллионнардан бердер.
Сизелми дә бит ул күкләргә.
Минем менә бердәнбер йолдызым
Атылды әле бүген... Үткәнгә.

Рәфкать Кәрами

# ОЧАР КОШЛАР БЕЛӘН ЯНӘШӘ

ПОВЕСТЬ

## IX



Участок башлыгы Әхмәтов үзенең кабинетында телефоннан сөйләшеп утыра иде, КМУС мастеры керде.

— Яхшы, аңладым. Урыны бу түгел, соңыннан, — дип, ул каты гына эндәште дә, трубканы куйды һәм, аягүрә басып, мастер белән исәнләште.

— Эшләр ничек? Кайчан бетерәсең?

Ул, гадәтенчә, ике кулын кесәсенә тыгып, идәнгә карап йөренә башлады.

— Начар, — диде мастер.

— Нишләп?

— Тишекләр дөрес калдырылмаган, аптырадым.

Сүз эстакада буенча килүче торбалар турында бара иде. Өлкән прорабның кашлары гына түгел, калын кара мыегы да күтәрелеп киткәндәй булды. Ул әрле-бирле йөрүеннән туктап:

— Ничек? — дип сорады. Аннары күрше бүлмәгә дәште. — Петр Ефимович, син андамы? Кер әле бире.

Олы яшьләрдәге прораб Телегин керде. Монтажчылар мастерына баш какты.

— Җылылык трассасында будканы син ничек эшләргә куштың?

— Проект буенча.

— Тишекләр кайда?

Телегин кәгазьгә сызып күрсәтте.

— Дөрес, — диде участок начальнигы сызымга карап. — Әйдә барыйк әле.

Алар төп объекттан әллә ни ерак булмаган җылылык трассасына киттеләр. Монда ташчылар бригадасы будканың түбәсен ябып, соңгы эшләрне төгәлләп килә иде. Сызым буенча тикшереп карыйсы да юк,

Ахыры. Башы 9 санда.

өлкән прораб тишекләрнең дөрес түгеллеген шунда ук аңлады. Ул бригадирны чакырып китерде.

Озын буйлы, юан корсаклы бригадир Пашков, мыш-мыш килеп, аның каршына басты.

— Син нишләп субподрядчыларга тишекләрне дөрес калдырмадың?

— Ничек куштылар, шулай эшләдем.

— Кем кушты?

— Башта Телегин, — диде бригадир, тир агып торучы йөзен прорабка борып. — Аннан Самойлов.

Әхмәтов кызарып-бүртенеп аны сүгәргә тотынды.

— Синең прорабың кем? Телегинмы? Тыңла шуның сүзен. Бәлки сиңа иртәгә берәрсе СУ-3 тән килеп болай эшләмә, тегеләй эшлә дияр. Вообще, үз башың белән эшли белмәгәч, нинди бригадир син? Син сызымны су кебек эчәргә тиеш. Бездельник. Петр Ефимович, зинһар өчен, сүтеп эшләргә кирәк.

— Самойлов үзе эшләсен, — диде Телегин киреләнеп. — Минем бүген кызның туган көне дә...

— Ярар инде, үтенеп сорыйм. Эшне көйләгәч, кайтып китәрсең.

Телегин сүгенеп алды да, читкә борылып ачу белән җиргә төкерде.

— Бетермичә кайту юк инде болай булгач. Җиһангир Шәмсиевич, җиде-сигез кеше кирәк булачак. Конторга барып кил, алайса, бишәр сум эшлә инде.

Әхмәтов кесәсеннән бумажнигын чыгарып, прорабка кырык сум санап бирде дә, машинага утырып конторга китте.

Петр Ефимович әле һаман нишләргә белмичә аптырап, аның күзенә карап торган бригадирга ике ташчы һәм ярдәмче эшчеләр белән эштән соң калырга кушты. Прораб будкасына барып, измә китерүләрен сорап, бетон заводына шалтыратты. Тагын бер балта остасын һәм сылаучыны кисәтеп куйды. Кирпеч җитәрлек иде.

Үзе дә эшчеләр белән бертигез эшләгәч, тиз тоттылар.

Шулай да алар химкомбинат капкасыннан чыгып киткәндә сәгать ун тулып килә иде.

— Кыз ачуланыр инде. Үпкәләгәндер, — диде ул бригадир Пашковка трамвайга утырышлый.— Бүләк алырга да өлгермәдем. Ә-ә, эштә онытып калдырганмын диярмен.

— Яхшы түгел, Петр Ефимович, — диде бригадир иренеп кенә һәм авызын зур ачып иснәде.

Бераздан Телегин үз хәйләсеннән үзе куанып, елмайды.

— Складта иде, табельщица миңа әйтмичә бикләп киткән диярмен. Ә иртәгә төш турында берәр магазинга барып килермен. Шулай бит?

Пашков йомшак урындыкта йокымсырый башлаган иде инде.

— Монысы ярый, — диде күзен ачмыйча гына.

— Ваня, әйдә безгә киттек. Анда хәзер мәҗлеснең иң кызган чагы.

— Рәхмәт, Петр Ефимович, — диде Пашков, прорабның тәкъдиме бик кызыктыргыч булса да баш тартып.

Икенче көнне Әхмәтов үзенең бригадирларын, прораб-мастерларын планеркага җыйды. Узган көнгә анализ ясап, алда торган эшләрне, һәр объектның иң мөһим дип саналган, кичекмәстән төгәлләнәсе «тар» урыннарын билгеләде. Бригадаларга гына түгел, аларның звеноларына кадәр бер атнага конкрет эш бүлеп бирде.

— Август-сентябрь — менә безгә соңгы срок. Чигенергә урын юк, арттта... план. Шуннан ары безне монда тотмаячаклар. Ике, өч сменага бүленеп эшләргә, әмма бетереп китәргә...

Ул сүзен бетерер-бетермәс, прораб будкасына идарә башлыгы Мәхмүтов керде. Ул әкрен генә исәнләште һәм өлкән прорабка сүзен дәвам итәргә кушты. Кемдер ишек янынарак шуышып аңа урын бирде.

Әхмәтов:

— Мин бетердем, — диде. — Ләкин дисциплина турында бер-ике сүз әйтеп үтмичә булмый. Участокта хезмәт дисциплинасы турында аерым сөйләшү булыр, аны партбюро белән берлектә уздырачакбыз. Ә бүген инженер-техник работниклар арасындагы дисциплина турында. Иптәш Самойлов, син кайсы объектта эшлисең?

Бу сорау шундый көтелмәгәндә яңгырады, бер мәл бригадирлар, мастер-прораблар гына түгел, Мәхмүтов та аптырап калды. «Ничек инде участок начальнигы үзенең мастеры нинди объектта эшләгәнен белми?» дигән сорау бирә язды. Ләкин ул, өлкән прорабның тавышына карап, тел төбендә нидер ятканын бик тиз аңлап алды.

Мастер Самойлов бурлаттай кызарып, колгадай сураеп басты. Авыз эченнән нидер мыгырданды.

— Ачык ишетелмәсә дә, аңлашылды, — диде Әхмәтов. — Ә ташчыларга будкадагы торба тишекләрен билгеләдеңме?

— Әйе, — диде мастер. Ул, эшнең нәрсәдә икәнен төшенеп, башын түбән иде, сары чәче йөзенә үк төште.

— Яңадан кеше эшенә тыгылма. Үзеңне күрсәтәсең килсә, күрсәт, ләкин Телегинны юкка чыгарырга тырышма. Ул үз эшен синнән башка да бик яхшы белә, егерме ел төзелештә. Сиңа да шуны ук телим.

Әхмәтовтан соң идарә башлыгы да бер-ике генә җөмлә белән эш, дисциплина, документ кәгазьләре тутыру, объектларны төгәлләү турында әйтеп үтте. Ишектән керә-керешкә аның борынынаниндидер ят ис бәрелгән иде, утыра торгач ул моның хәмер исе икәнен һәм аның кемнән килүен дә абайлады.

— Җиһангир Шәмсиевичның баягы сүзләренә ялгап, һәр ИТРның үз-үзен тотышы, шәхси үрнәге турында әйтеп үтәсе килә, — диде ул һәм Петр Ефимовичка карап алды.— Эш вакытында бригадирның, я мастер-прорабның аракы эчүен белсәм, икенче көнне үк куам да чыгарам. Соңыннан үпкәләштән булмасын! Кем булуына карап тормыйм, колагыгызга нык киртләп куегыз.

Идарә башлыгы сүзен бетергәч, Әхмәтов планерканы япты. Кешеләр тарала башлады. Мыштым гына чыгып баручы Телегинны Мәхмүтовның көр тавышы туктатты.

— Петр Ефимович, сез калыгыз әле.

Прораб башын бер яккарак борып, борын сөрткән булып авызын каплабрак идарә башлыгы каршына килеп басты.

— Кем бакчасына таш атканны сизгәнсездер, шәт, — диде Мәхмүтов урыныннан күтәрелеп. Аның янында прорабның юка гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай булды. Җыерчыклар белән сыргаланган какча йөзенә сизелер-сизелмәс кызыллык йөгерде. Яшьләре бер чама булса да, Телегин идарә башлыгы янында үзен бала сымак итеп тойды.

— Аңладым, Ислам Бакирович. Минем кичәгедән ул,— диде прораб, сүзне уенга бормакчы булып.

— Анысы мине кызыксындырмый. Сезнең кул астында мастерлар, бригадирлар һәм берничә дистә эшче... Икенче мондый хәлдә күрмим. Барыгыз.

Петр Ефимович башын түбән иеп, ишеккә юнәлде.

Мәхмүтов өлкән прорабка, әйдә, күрсәт хуҗалыгыңны, дип аны урамга алып чыгып китте.

— Ислам абый, — диде Әхмәтов, икәве генә корпуска таба атлаганда, — Телегинга юкка алай каты бәрелдегез. Ул Самойлов ясаган бракны рәтләп кичә төнгә калды. Шуның өстенә кызының туган көне иде. Әле йокламагандыр да... Ничек аягында йөри торгандыр, белмим.

— Андый хәл булгач, бөтенләй килмәскә иде.

— Юк, кешесе ул түгел. Эш аңа, солдатка строй кебек — изге нәрсә.

— Әйт үзенә, бер-ике сәгать йоклап алсын. Я кайтарып җибәр.

— Әйтеп карармын.

— Эти-әниең ни хәлдә?
— Исән-саулар. Нишләп бу арада килеп чыкмыйсыз?
— Кая вакыт? Ял көне дә эш кәгазьләре белән утырам. Аннары... апаң кешегә бару түгел, ишек төбенә чыгып утырырга да читенсенә. Җайлы булмады...
— Кем уйлаган шулай булыр дип.
— Да-а, әйтмә... Язмыштыр. Үзеңдә ничек? Туеңны күрәсе килә, егет. Ә туй синең уеңда да юкмы? Утыз яшь...
— Ислам абый, онытмагыз, егерме тугыз гына,— диде Әхмәтов елмаеп.
— Барыбер инде... Билгеле, кем шул рәхәтне калдырып, камыт кисен. Аерым фатир, машина... Артына тибеп яшисең инде дөньяның.
— Ислам абый, энекәшнең хаты киләме?— дип сорады Җиһангир Шәмсиевич, сүзне икенчегә борып. Мәхмүтовның быел гына институт бетергән малаен күптән армиягә озатканнар иде.
— Бер хаты килде. Урта Азиядән.
— Бик ерак киткән икән.
— Исән йөрсен. Сугыш вакыты түгел... Җиһангир, мин беркөн баш бухгалтерга участокларга анализ ясарга кушкан идем. Картина шәптән түгел: күләмсез, акланмаган эшләр бик күп. Форма ике буенча акча түләүче юк, ә нәрәтләр буенча без түләгәнбез. Монысы гомуми күренеш. Конкрет синең участок буенча: Телегин кирпеч стена сүтүне икеөч тапкыр язган. Бу — чын мәгънәсендә приписка. Аннан синдә вакытлы эшчеләр күп очрый. Кара аны, мин сиңа кунакта абый, ә эштә каты торачакмын.
— Бала-чага түгел лә, аңлыйм.
...Петр Ефимович яңадан әйләнеп килгәндә, Мәхмүтов белән Әхмәтов прораб будкасы янында тыныч кына сөйләшеп торалар иде. Телегин дәшми-тынмый узып китмәкче иде, начальник аны дәшеп алды.
— Петр Ефимович, килегез әле бире. Катырак бәрелдем, ахры, ләкин үзегез гаепле.
Телегинның да керпе энәләре шиңде.
— Юк, мин бүген эчмәдем. Кичә кызның туган көне иде.
— Беләм. Ишеттем. Җиһангир Шәмсиевич әйтте. Гафу ит.— Аннан начальник теманы үзгәртте.— Петр Ефимович, кайчан ауга чыгабыз? Сезне баш инженер бик һәвәс аучы дип мактады.
— Мин әзер. Хет иртәгә. Сез дә яхшы аучыдыр, борыныгыз ис сизә,— диде Телегин көлеп.— Су-4 нең элекке начальнигы шулай иде. Ул әле хәтта иснәп тә чыга торган иде. Бервакыт мин аңа, миндә йогышлы авыру, якын килмәгез, дидем. Шуннан бирле иснәмәс булды.
Көлешеп алдылар.
— Мин андыйга ук барып җитмәм,— диде Мәхмүтов,— әгәр мәҗбүр итмәсәгез. Минем ауга һәвәслек юк, сирәк-мирәк балыкка гына йөргәлим. Петр Ефимович, сез монда килгәнче дүртенчедә идегез бит?— дип сорады.
— Әйе.
— Ә болай үзегез кайсы яклардан? Әле ныклап белеп җиткермим. Техникумны читтән торып бетергәнсез бугай.
— Шулай туры килде,— диде Телегин.— Сугыш башланганда дүртенче курска җиткән идем. Сугышта булырга туры килде. Ә соңыннан укый алмадым. Эти-әни карт, сеңелләр бар иде. Заманасы авыр — карточка. Безнең Пенза ягында гына түгел, бөтен җирдә шул булды инде.
— Да-а, ул вакытлар баллы булмады.
— Илле алты-алтмыш җиденче еллар минем Красноярь краенда узды. Совхозда столяр, бригадир булып эшләдем. Прораб киткәч, мине аның урынына куйдылар. Бер егет минем элек укыганны әйткән дә...
— Син шул еллардан бирле прорабмыни?

— Ну, анда кечкенә объектлар, кеше әз иде. Эшләргә була иде, билгеле, тик хатын авырды, бөер белән. Су ярамады. Киттек Казан ягына...
— Бала-чага ишләме?
— Бер кыз да бер малай. Кыз КИСИ [1] да укый, ә егет әле тугызда гына. Үзем Мәскәүнең заочный техникумын бетердем, Шабловкада.
— Күптәнме?
— Биш ел элек.
... Бераздан идарә башлыгы үз эшләре белән китеп барды, ә Әхмәтов белән Телегин прораб будкасына юнәлделәр.

## X

Кара күзлек кигән, кулына калын гына китап тоткан Әзһәм автобустан төште. Көн эссе, кояшлы һәм автобуста да бөркү булганга аның тамагы кипкән иде. Тукталыш янындагы киоск ябык, квас мичкәләре дә бикле. Ул урамның икенче ягындагы яңа ачылган кибеткә юнәлде.

Ял көне булгангамы, урам тулы халык — каядыр баручылар, кайтучылар, яшьләр-кызлар... Урам аркылы чыкканда, Әзһәм хатыны белән каяндыр кайтып килүче, яшь бала күтәргән бер танышын очратты.
— Кая чаптың? Килеп тә чыкмыйсың.
Байтак вакыт сөйләшеп тордылар.
— Вакыт юк бит, кем әйтмешли, кыл да сыймый. Менә бүген дә бер егетнең өенә килеш иде. Бюродан тагын бер кыз булырга тиеш, сәгать җидедә очрашырга сөйләшкән идек.
— Ул егет нишләгән соң? Кем ул? Мин беләмме?
— Юк, белмисең. Прогул ясаган.
— Аларны әзрәк авызлыклап тоту ярый, азмасыннар. Ну, хәлләр ничек?
Дусты Әзһәмнең укуы, төзелеш идарәсендәге хәлләр белән кызыксынды. Чөнки үзе дә, Донбасстан Казанга кайткач, шунда балта остасы булып эшләгән иде, хәзер шофер. Аннан ул Әзһәмне үзенә кунакка кыстый башлады.
— Әйдә, эт мөгезе, безгә, чәйләп утырырбыз, — диде ул серле елмаеп. — Чәй куәтләре житмәсә... Әйеме, карчык!..
— Бер килеп чыгармын әле.
Алардан аерылгач, Әзһәм азык-төлек кибетенә керде. Тоташ пыяладан эшләнгән якты кибетнең бер башында сок саталар иде. Газлы су юк микән дип, Әзһәм икенче башка барып килде. Анда да су юк икән. Кире килгәндә бер сатучы кыз аннан вакыт сорады. Егет башта кызга, аннан сәгатенә карады.
— Җиденче ун минут.
— Рәхмәт.
Үзе дә абайламастан, аның карашы кызга озаграк тукталды. Кыз коңгырт күзләрен түбән төшерде. Әзһәм дә үз юлына китте. Чиратка басты. Әлеге сатучы кызны искә төшереп елмайды. Бер стакан слива согы эчте. Сәгатенә карады. Әле шактый вакыт бар икән. Ул баягы кибетче кыз янына килде.
Кыз кәгазь тартмалар өстенә утырган иде. Прилавка каршында кеше пәйда булуга җәһәт кенә торды.
— Арыдыгызмы әллә? — дип сорады Әзһәм.
— Әйе шул. Көнозын аяк өстендә бит.
— Сезнең бүлектә кеше бик аз икән.

---

[1] КИСИ — Казан төзүче-инженерлар институты.

— Бүген ял көне бит. Миндә, гомумән, кеше аз була, анда да карчык-корчык кына.

Бу бүлектә чәй, каплы печенье, шикәр, варенье, повидло ише әйберләр сатыла иде. Стенада бер рәсем: түбәтәйле, ак сакаллы татар карты аякларын бөкләп зур самавар янында чәй эчеп утыра.

Кыз егетнең күз карашын сизеп:

— Ул минем иптәшем, — диде.

— Бик карт бит. Элек кенә кызларны шундый картларга икенче хатынлыкка көчләп биргәннәр.

— Сез инде бигрәк. Мин болай гына, бергә эшли торган иптәш дип әйттем.

Ак яулыклы бер карчык килеп чәй сорады. Ике кап чәй алгач, ул:

— Кызым, теге катысын да бир әле, — диде һәм такта чәй дә алды. Карчык китеп баргач, Әзһәм баягы сүзгә кайтып:

— Ә сезнең иптәшегез булырга иртәдер әле? — диде.

— Минем инде кызым бар.

— Ышанмыйм, — диде егет.

Сатучы прилавка астыннан ридикюлен алды һәм аннан бер карточка алып Әзһәмгә сузды. Карточкадан сатучы һәм йөз чалымнары белән бераз аңа охшаган бер-ике яшьләр чамасындагы бала карап тора иде. Егет артык гаҗәпләнмәде һәм тагын кибетчегә карап куйды.

— Ә этисе кайда?

Шул чак прилавка янына бер кыз килде һәм Әзһәм белән янәшә басты.

— Халидә, нихәлләр? Авылга кайтканың юкмы? — диде ул.

— Юк әле, Сания. Үзең нишләп йөрисең?

— Менә вак-төяк алдым,— диде кыз, сумкасына ишарәләп.— Син хәзер кайда торасың? Ә Вагыйз кайда? Абыйларында калдымыни? Кызың кая соң?

— Авылда, әни янында.

— Кайчан кайтасың соң?

— Киләсе атнада.

— Ярый, сау бул, китим әле, — дип, сатучының иптәш кызы китеп барды.

Әзһәм беравык дәшми торды. Берничә минут вакыт өчен артык күп иде бу яңалыклар. Бу кадәр төгәл мәгълүматны кайбер кешедән берничә көндә дә алып булмый бит.

— Тамагыгыз кипмәдеме? Сок алып килимме? — дип сорады Әзһәм, үзе дә сизмәстән.

— Юк, рәхмәт.

— Чыннан да.

— Юк, юк.

— Мин боларны монда калдырып торыйммы? — дип сорады егет, китабы белән күзлеген витрина өстенә куеп.

— Калдырыгыз. Китабыгызны карыйммы?

— Әлбәттә. Ә минем исемем — Әзһәм.

Әйберләрен елмаеп торучы Халидәгә биреп, Әзһәм тагын соклар бүлегенә чиратка басты. Ул кулъяулыгы белән тирләгән маңгаен сыпырып алды. Башын чайкап куйды. «Кызык бит. Ә нинди сөйкемле, яныннан китәсе килми».

Халидә дә бу минутта егет турында уйлап алды. Белмәгән-күрмәгән кеше белән үзенең шулай җиңел генә сөйләшеп китүенә гаҗәпләнде. Хәер, ул аны яңадан әллә күрә, әллә юк, болай гына, эч пошканнан гына сөйләште бит ул. Артык бәйләнми, күп төпченми, сөйләшсә ни булган

Әзһәм стакан белән алма согы алып килгәндә, Халидә янында төсе

унган зәңгәр халат кигән бер ир басып тора иде. Ул егеткә сөзеп кенә карап алды да китеп барды.

— Мәгез, бераз хәл керер, югыйсә бик бөркү, — диде Әзһәм, Халидәгә стакан сузып.

— Рәхмәт.

Халидә, стаканны үзем илтермен, дип янына куйды. Сумка тоткан бер ир килеп варенье сорады.

— Кайсысын?

— Менә монысын, — диде ул, витринага бармак очы белән төртеп. — Ә юк, тегесен бирегез, алтмыш биш кенә тиен икән.

Халидә белән Әзһәмнең елмаюын күреп сатып алучы үзе дә көлеп җибәрде.

— Берәр пиволык булса да янга калдырыйм әле.

Ул киткәч, Әзһәм сәгатенә карап алды.

— Менә шулай, егет, — диде Халидә, — барасы җиренә бар. Минем инде сиңа бирерлек кызым үсеп килә.

Бераз икеләнеп торганнан соң, Әзһәм тәвәккәлләп сорады.

— Гафу итегез тыйнаксызлыгым өчен, Вагыйз кем ул? Ирегезме?

— Әйе, ирем иде.

— Кайда эшли?

— АТХ да.

— Кем булып?

— Шофер. Сорау алу төгәлләндеме, иптәш прокурор? — диде Халидә елмаеп һәм үзе дә сорап куйды. — Аны беләсезме әллә?

— Юк, мин белгән Вагыйз химкомбинатта аппаратчы булып эшли, — диде егет уңайсызланып.

Хатын ридикюленнән карточка алып Әзһәмгә сузды. Уртачадан бераз озынрак буйлы, ябык гәүдәле бер егет сурәте иде анда. Ул спорт киеменнән, күкрәгендә номер да бар, кросс йөгергән, ахры.

Тик бу Әзһәм белгән Вагыйз түгел иде. Егет карточканы кире бирде. Ләкин күңелендәге шик бетмәде. Бәлки Халидә дөресен әйтмәгәндер? Алай булса ул икенче Вагыйз булып чыга. Ә Әзһәм аны яхшы белә. Алар тулай торакта бергә яшәделәр, бүлмә аша гына. Аларның бүлмәсе бакча ягындагы почмакта иде, бер егет белән бәйләнешкәне дә хәтерендә. Әзһәм, тагын бер егетне ияртеп чыгып, аларны аерып җибәргән иде. Тегеләр соңыннан аңа кырын күз белән карап йөрделәр. Руслар әйтмешли, рубаха парень иде ул. Хәзер Әзһәмнәр бүлмәсенә бер егет янына килеп йөри, алай телгә килгәннәре юк. Менә шуңа күрә егеткә бу хатын белән сөйләшеп тору, гомумән, танышу ничектер уңайсыз булып китте. Дөрес, алар аерылышканнар, ләкин нәрсәдер, ниндидер күзгә күренми торган җеп Әзһәмне бу хатын янына якын җибәрмәскә теләгәндәй тартып тора, күңел түрендә ниндидер аңлатып бирә алмаслык тойгы, юшкын бар иде. Башта Халидәнең Вагыйз хатыны икәнен белсә, бәлки алай булмас та иде. Чөнки ул аңа Вагыйз хатыны итеп кенә карар иде. Ә хәзер... нигәдер ул аның күңеленә якын, аның янында рәхәт, бер-берен күптән белгән кешедәй, алар иркенләп сөйләшәләр. Бәлки Халидә Әзһәм кебек уйламыйдыр да, ул бит сатучы, көн буена күпме кеше аның яныннан уза. Сүз катучылар да юк түгелдер. Башта бәлки ул оялгандыр, теләсә кем белән болай иркенләп сөйләшмәгәндер, тора-бара күнеккәндер, кергән, үзенә эндәшкән һәр кешегә каш җыерып тора алмый бит инде ул. Хатын булгач, кызлар кебек әйткән бер сүзгә кызармас бит инде, әрсезләнәләр бит алар, бигрәк тә ирдән дә аерылган булгач. Аңа да бит яшәргә кирәк. Ир кирәктән генә түгел, ә тормыш иптәше дә кирәк бит кешегә.

Әзһәм уйларыннан арынып Халидәгә үзе белгән Вагыйзне тасвирлап бирде. Халидәнең торган саен йөзе үзгәрә баруын егет сизде, әлбәт-

тә. Егет бәлки әле ул түгелдер, икенче кешедер дип уйлаган иде һәм шул уенын чынга ашуын теләгән иде, юк булмады. Димәк, дөрес.

Халидә үзен тиз кулга алды. Ирен белгән, житмәсә, егет кеше белән сөйләшү аңа бик үк күңелле түгел иде. Ул кулына рәсемле катыргы кәгазь алды да:

— Сезгә бер әйбер биримме? — диде һәм рәсемнәрне кисеп алып Әзһәмнең китап арасына салды. Кечкенә рәсемнәрдә аю, куян балалары һәм бер чеби. Аннары Халидә тагын берне кисеп бирде. Анысы конфет өләшүче матрешка иде. Әзһәм рәсемнәрне китап арасына кире салып куйды да сәгатенә карады.

— Ярый, мин киттем. Сезнең эшегез сигездә бетәме? Мин килимме?

— Нигә?

«Чыннан да нигә?» дип уйлады Әзһәм. Бу хатын белән аның арасында нинди уртаклык бар? Нигә кирәк ул аңа? Ул ир хатыны. Дөрес, хәзер ире юк. Бәлки юри әйткәндер.

— Минем турыда тулырак мәгълүматлар аласыгыз килсә, килегез.

— Гафу итегез, мин анкета тутырырга җыенмыйм.

— Ихтыярыгыз.

Әзһәмнең вакыты бетте һәм ул саубуллашып чыгып китте. Ишек төбендә төсе уңган зәңгәр халатлы ир, кибеттә йөк бушатучы булса кирәк, тора иде. Әзһәм аның аягына чак кына абынып егылмады. Ул аңа күтәрелеп карагач, аның бая Халидә янында басып торган кеше икәнен таныды.

— Чамалабрак йөр, егет, — диде зәңгәр халатлы. — Көпә-көндез абынасың, караңгыда бөтенләй башсыз калуың бар.

— Үзең өчен кайгыр, — дип, Әзһәм китеп барды.

Ул кызлар тулай торагына кереп, үзе белән барасы бюро членын иртте дә, прогул ясаган егетнең өенә — Каравайга таба китте. Ләкин егетне очрата алмадылар. Әнисе: «Иптәшләре белән чыгып китте. Татын кайда йөри торгандыр инде? И әнем, ичмаса сез шуны бераз кысар идегез, һич кенә баш бирми», — дип зарланып калды.

Әзһәм үзләре шефлык итә торган тулай торакка кереп, тәрбияче кыз белән шушы арада бергәләп үткәрәчәк кичә турында сөйләшеп чыкты.

— Бүләкләр өчен акча хакында начальник белән сөйләштем, — диде ул тәрбияче кызга. — ышаныч язуы алып, иртәгә идарәгә кил, икәү бергә бухгалтериягә керербез.

## XI

Әзһәм кибет янына җиткәндә Халидә ишектән чыгып килә иде. Үзе дә сизмәстән, аның йөзе яктырып китте һәм ул туктап калды.

— Киттекме? — диде егет.

— Кая?

— Белмим, монда сез хуҗа.

— Миңа өйгә кирәк.

— Әйдәгез.

Алар кибет почмагыннан борылдылар да тротуар буйлап киттеләр. Урам тулы яшьләр-кызлар. Бер якта — биш катлы, эре панельле, икенче якта өч катлы таш йортлар тезелеп киткән.

Сөйләшү башта, очы-очка ялганмыйча, вак-төяк турында барды. Аннан Әзһәм үзенең бүген ике шигырь китабы алуы турында әйтте һәм Халидәгә:

— Сезнең тавышыгыз бер яшь шагыйрәнекенә охшаган, — диде. — Минем иптәш егет әз-мәз язгалый, шигырьләре ике дәфтәр булган инде. Беркая да бирми генә. Без аның белән әдәби җомгаларга йөрибез.

— Беләм, — диде Халидә һәм үз тавышының кемнекенә охшавын әйтте. — Мин дә поэзия белән даими танышып барам.

Аннары сүз гел поэзия тирәсендә булды. Халидәнең ул өлкәдәге яңалыклар белән танышып баруы һәм төпле фикер йөртүе Әзһәм өчен көтелмәгән ачыш һәм шатлык иде. Кибетче хатыннар, гомумән, андый нәрсәләр белән кызыксынмыйлар дип белә иде егет. Хатыннар түгел кызларның да кругозоры шул прилавка артыннан әллә ни ерак китми, китсә дә, кино-театрга, танцы мәйданчыгына барып җиткәч туктала иде. Бәлки шуңадыр, аның Халидәгә булган ихтирамы артты, Әзһәм күз алдында бу хатын бер карышка үсеп киткәндәй булды.

— Хәзер поэзия үсте, фикер күп,— диде Халидә.— Шулай да нигәдер Тукайлар, Такташлар күренми.

— Андый кешеләр берничә дистә елга, хәтта, мин әйтер идем, гасырга бер генә булалар.

— Моңысы белән килешмим, Тукай, Такташ, Җәлил — алар бит барысы да бер гасыр кешеләре.

— Сезнеңчә фикер йөрткәндә, әле тагын шундый бер-ике талантны көтәргә була, — диде Әзһәм. — Беләсезме нәрсә, бер әһәмиятле моментны истән чыгармаска кирәк, ул — тарихи момент.

— Анысы да дөрес. Ә тулаем алганда, талантлы шагыйрьләр аз түгел.

Тулай торак яныннан узганда бер кыз Әзһәм белән исәнләште.

Халидә әйтә куйды:

— Минә сезне күрделәр дә инде, сезне балалы хатын белән йөри диярләр.

— Бүредән курыксам, урманга бармас идем.

— Әйдәгез өйгә таба борылыйк, химфармзавод яныннан әйләнеп кайтыйк.

Алар беркадәр вакыт дәшми бардылар.

— Минә шулай, егет, минем кызым бар.

— Өч көн торгач, исәнме, кодагый, дип әйткән ди бераү дә.

Әзһәм уң кул яктагы спорт мәйданчыгына карады. Кызлар-егетләр волейбол суга, баскетбол, футбол уйнаучылар да бар. Сулда чайкалып торучы арыш басуы, юл буенча өрәңге, юкә агачлары тезелеп киткән, сирәк-мирәк машиналар уза, кочаклашып янсә култыклашып баручы парлылар очрый. Каршыда химкомбинатның факеллары төтенләп утыра, төтене ерактагы урман, Аккош күле ягына агыла.

Химфармзаводның озын корпусларына җитәрәк Халидә туктады.

— Бая сез сурәтләгән Вагыйз минем ирем иде. Ә карточкада — ул түгел.

Әзһәм күптәннән көткән һәм шул ук вакытта ишетәсе килмәгән сүзләр иде бу. Ул аның шулай икәненә төшенде, ләкин алай түгелдер, ул икенче кешедер дип үз-үзенә ышандырырга, алдарга теләгән иде. Шулшул, элек Савиново поселогында торганнар, хәзер монда. Аннары абыйлары... Әзһәмнең ишеткәне бар иде.

— Минем сүзләрем сезгә бәлки кызык түгелдер. Минә шулай, без аның белән бергә тормыйбыз. Сез әйткәнчә, элек кенә икешәр-өчәр хатын белән торганнар. Ә хәзер... Аның кибеттә дә ике хатыны булган.

Халидә, аскы иренен тешләп, елап җибәрүдән үз-үзен көчкә генә тыеп торды да, бөтен көчен туплап, бар ачуын бергә җыеп, тагын сөйли башлады.

— Монда килеп эшли башлавымның беренче көнендә үк җыештыручы бер апа әйтте. Халидә, кем ул синең янында басып торды, ди. Нигә, апа, дим. Бик азган-тузган егет ул, сак бул, башыңны әйләндермәсен, ди. Шуннан сөйләде... Үз ирем турында сөйләгәнен белми иде бит ул апа. Сөйләмәгән булса... Белсәгез иде шул чактагы хәлләремне! Җир ярылса, бер минут тормый кереп киткән булыр идем... Гарьлек... Хурлыгы ни тора... Башта берсе янына килеп йөргән, аннары икенчесе... Хәзер генә сөйләве җиңел... Юк, әллә нәрсәләрне кичереп була, ләкин

моны түгел. Сезгә ничә яшь? Егерме биш. Алайса, сез аңларга тиеш. Аңа бит инде егерме сигез. Алай йөреп туймагач, өйләнмәскә иде...

Халидә сөйләгән саен дулкынлана бара, иреннәре калтырап куя, ияге дерелдәп, менә-менә елап җибәрер кебек иде. Аңа сөйләве дә авыр иде, күрәсең. Ләкин эчке пошыну белән, гаҗизләнеп сөйләгәч, ул бушанып киткәндәй булды. Кеше һәр вакыт шулай бит. Аның фикерен уртаклашучы яисә моң-зарын бирелеп тыңлаучы, йөрәгенә якын кабул итүче булса, ул түкми-чәчми, берни яшерми сөйли дә сөйли һәм кайчак үз-үзенә аптырап та куя, минме соң бу, нигә боларны аңа сөйлим дип гаҗәпләнеп тора. Халидә алары турында уйланмый иде әле. Ул Әзһәмдә үзенә фикердәш тапты һәм шуңа куана иде. Ир-атлардан аның җаны бизгән, аларның барысын да бер калыптан сөрергә тормыш аны үзе өйрәтте. Чөнки иреннән башка да бик күп кешеләрне белә иде ул, һәрберсенең уенда бер нәрсә... Һәрберсе аңа ирдән аерылып кайткан хатын итеп кенә карарга телиләр иде. Күрәсең, ирсез хатын — йөгәнсез ат, дип уйлауларыдыр инде. Таныш кызлары кияүгә чыкты, кибетче хатыннар ирләре турында, башкалар турында сөйлиләр иде. Үз ире дә шундый булгач, Халидә, гомумән, бар кеше дә шундыйдыр дип уйлый башлаган иде. Менә шуңа күрә Әзһәмнең аның һәр сүзен дикъкать белән тыңлап, күңеленә салып баруы, борчылуы аны ачыктан-ачык булырга этәрә һәм сөйләгән саен сөйлисен китерә иде. Әйе, монда гаҗәпләнерлек берни дә юк бит. Күпме күз яше түккән, ә күпмесен эчкә йоткан бу яшь хатынның моң-зарлары күбәйгән, йөрәге өзлексез ялкынланып тора иде. Шул ялкынны сүндерүче, ашкынган күңелен басучы, тынычландыручы кирәк иде Халидәгә. Һәм Әзһәм, үзе дә белмәстән, шул кешегә әйләнде. Халидәнең, билгеле, шик-шөбһәсе дә юк түгел иде, ләкин ничек кенә булмасын, ул үзен алдап булса да Әзһәмдә дус, киңәшче, һич югында, үгет-нәсихәт бирүчене табарга тели иде. Тормышта төрлесе була бит, берәүләр синең йөрәгеңне бер күрүдә үк билэп ала, аның я йөз-бите, я килеш-килбәте, я булмаса кием-салымы сине, бигрәк тә яшьләрне кинәт билэп ала, аның бары матур сыйфатларын гына күрәсең, аның матурлыгын мәдхия кыласың, ә тискәре яклары синең карашыңча гел булмый. Кайвакыт исә кешеләр бер-берендәге күркәм сыйфатларны тора-бара ачалар, бер-беренә якынаялар. Озынча буйлы, юка гәүдәле, аксыл йөзле бу хатынның тормышы Әзһәмне торган саен ныграк били барды. Аның акыллы, базык сөйләшүләре, салмак хәрәкәтләре ирексездән игътибарны тарта иде.

— Бер кызымны тәрбияли алмаммы әллә.

Әзһәм дәшмәде. Уйларына чумып барды да барды. Ләкин аның уйлары чуалды. Бу хатын аңа якын да, ерак та. Ул аның үзен яңа гына белде. Ә ирен? Белгән кешенең хатыны булуы аны җинаять эшләгән кеше хәлендә калдыра. Әзһәм үзен җинаять өстендә тотылган кешедәй сизә иде. Ул үзенең ник килүенә үкенә башлады. Ә дөресен әйткәндә, бу мөлаем хатын турында артык күп белүенә эче поша иде. Әгәр Халидәнең иптәш кызы кибеткә кермәгән булса, ул аларны белмәс иде. Ләкин инде соң. Әйтәсе сүз әйтелгән, беләсе беленгән. Хәзер аңа ниндидер бер төпле фикергә киләсе кала иде. Бәлки ул бу халәттә чын дөрес юл да булмас, ләкин ни дә булса эшләргә, бу башваткычны чишәргә кирәк иде.

Шулай әкрен генә сөйләшеп алар химфармзавод почмагыннан сулга борылып куаклыклар, яшел чирәм арасыннан салынган бормалы-сырмалы тар сукмактан «Яшьлек» шәһәрчегенә кайттылар. Әзһәм Халидәнең куе кара чәчләренә карый һәм алар нигәдер бик йомшактыр шикелле тоела.

Ут алынган. Караңгы төшеп килә. Чикләвек куагында сандугач сайрый, якында гына бакалар бакылдаганы ишетелә. Алда тар гына канау аркылы чыгасы иде. Әзһәм Халидәгә чыгарга булышты.

— Минем кулга тотын.
— Юк, мин үзем. Сез барып йөрмәгез инде, хәзер үзем кайтып җитәм. Әнә улым каршы ала, — диде Халидә һәм биш катлы эре панельле йортның ян стенасына төшерелгән малай рәсеменә күрсәтте.
Икесе дә көлеп җибәрделәр.
— Бай яшисең икән үзең, кызың да бар, малаең да.
Тирә-юньдә җыр-музыка тавышы. Кая карама парлылар. Волейбол, домино сугучылар. Әзһәмнең бер танышы — балта остасы очрады. Исәнләшеп китте. Бер йорт каршында эскәмиядә бухгалтериядә эшләүче бер хатын утыра иде. Аның белән дә исәнләшеп киткәч, Халидә Әзһәмгә:
— Мәнә сезне тагын күрделәр, — диде.
— Зыян юк.
Халидә белән саубуллашып, Әзһәм китеп барды.

## XII

Будкага Валя килеп керүгә, бөтенесе тынып калды. Ул бу тынлыкка гаҗәпләнеп:
— Исәнмесез, кызлар, — диде дә ишек төбендә тукталды.
Миләүшә исемле кыз түзмәде, дөнья яңгыратып:
— Валя апа, сөенчегә нәрсә бирәсең? Бие! — дип кычкырды.
— Ай, кызлар! — диде Валя һәм елап җибәрде. — Әллә булганмы?
— Әйе. Сөенче, сөенче!
Куллары белән битен каплап, Валя сүз әйтү түгел, башын да күтәрә алмыйча елады. Моннан өч ел элек кияүгә чыккан бу хатын әле һаман кеше өстендә яши иде. Кечкенәләре булгач, балагыз елак дип, беренче хуҗалары куып чыгарды. Ике ел эчендә берничә хосусый фатир алыштырдылар. Бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, я хуҗаларның туганнары каяндыр кайтып төшә дә, бүлмә кирәк була, я әти-әниләрен алып киләләр дә боларга урын тарая, я башка сәбәп килеп чыга. Валя авылга кайтып китү турында да уйлый башлаган иде инде. Ире, түзик, бер җае чыгар, дип туктатты. Шуңа күрә бу хатынның куанычы бригада членнарына аңлашыла иде. Аны кызлар сырып алды.
— Я инде, җитәр.
— Юләркәй, шатлан!
— И-и, кызлар, белсәгез иде! Шатлыктан бит ул, шатлыктан! Нәрсә генә әйтим сезгә? Ничек рәхмәтләр укыйм мине сөендергән өчен?! Балакаемның бәхете бардыр, шуның бәхетенә биргәннәрдер!
Ул берәм-берәм барысын да кочаклап чыкты. Үзенең бите буйлап күз яшьләре ага, үзе лышык-лышык борын тарта. Иң соңыннан Валя бригадир янына килде дә аның күкрәгенә капланды.
— Зоя апа, җаным, мәңге онытмам!
— Я, я, — диде бригадир, аның да күңеле тулган иде. — Юкса мин дә елап җибәрәм. Мин нәрсә, постройкомга рәхмәт әйт. Анда да кешеләр утыра бит, кеше хәлен аңлыйлар.
Буяучылар бригадиры Зөһрә Кәбирова кырыкны яңа гына тутырган,. нык карашлы, киңчә яңаклы, биек маңгайлы, урта буйлы татар хатыны иде. Эштә аңа кайвакыт Зоя дип дәшкәлиләр. Кайберәүләрнең исем бозуга әллә ни исләре китми, беришеләре исә авыр кичерә. Әлбәттә, Зөһрәнең дә башта моңа ачуы килә иде, тора-бара ияләнде. Мәнә шулай үз әнисенә сыенгандай якын итеп дәшкән чакларда ул моңа артык әһәмият бирми. Валяның чәченнән сыйпап, Зөһрә төзелеш комитеты утырышының җил-давыллы булуын, үзенең иң яхшы эшчесенә бүлмә бирдертү өчен бөтен ораторлык осталыгын тупларга, бик күп дәлилләр китерергә туры килүен исенә төшерде. Әйе, Валя дүрт кенә ел эшли. Ләкин ничек эшли?!. Бу да бит мәсьәләнең бик игътибарга лаеклы ягы.

Берәүләр гомер буе, әледән-әле герен күтәреп җибәргән сәгать теле кебек, янмый да, көйми дә салмак кына эшлиләр, көн үтсенгә йөриләр, ә икенчеләр эштә ут уйната, кулы-кулга йокмый, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Зөһрә Кәбировага да Валяның сылау эшләрен башкарганда измәне бетермичә, эш сәгате чыкты дип, бервакытта да кайтып китмәвен, икенче сменага яисә озайтылган көнгә дә сукранмыйча калуын, эшенең сыйфаты яхшы булуын һәм, ниһаять, узган ел ирен дә үз янына шушы идарәгә эшкә урнаштыруын төзелеш комитеты членнарына кат-кат искәртергә туры килде. Бригаданың профгрупоргы, үзенең уң кулы икәнен дә әйтергә онытмады. Боларны — утырышның ничек узуын бригада членнары белми, билгеле. Кайбер өлкәнрәк хатыннар чамалый гына булса кирәк.

Кызлар кием алыштырып, әкренләп кузгала башладылар. Яулыклар чөелде, кечкенә көзгеләр чалбар кесәсенә шуды. Чиләкләр, терка-полутеркалар, пумалалар, валиклар идәннән кызлар кулына күчте.

— Зөһрә апа, миңа путевка юк микән? — дип сорады еш кына авыручы күзлекле хатын Гөлфия.

— Председатель булыр сымак әйтте, тик бу кварталда түгел, — диде бригадир һәм кечкенә гәүдәле Ганҗә исемле хатынга дәште. — Ганҗә, онытып торам икән, син эштән соң постройкомга кереп чык әле, Пустые Морквашка путевка бар дигән иде. Берочтан ялыңны да оформить итәрсең.

— Ярар, Зөһрә апа. Рәхмәт.

Кызлары чыгып китәр алдыннан бригадир звеноларга эш бүлеп бирде.

— Валя, сез икенче этажда коридор...

— Беләм, Зоя апа, беләм, — диде хатын аны бүлдереп һәм елмаеп әйтте. — Бүген бөтенесе өчен берүзем эшләргә риза.

— Синнән анысы да булыр. Бик көчәнмә тагын.

Аннары бригадир икенче звено башлыгына дәште.

— Ак буяу китерергә тиешләр, өске катның классларын бүген төгәлләргә кирәк.

— Пумалаларның да рәте юк, флейцылар алып киләләрме? — дип сорады үз чиратында звено җитәкчесе.

— Килерләр, әйттем. Төшкелеккә иртә китмәгез, аннан миңа әләгә.

Мәктәп Идел буенда гына иде. Кызларның күбесе ашханәгә йөрми, кибеттән катык-сөт, булка ише коры-сары гына алып капкалыйлар да, тизрәк суга чумалар, комда кызыналар. Монысына бригадирның сүзе юк, әлбәттә. Нигә форсаттан файдаланып калмаска. Төзүче халкы күпчелек көндез эшли бит, фәкать ял көннәрендә генә кызына ала. Заводта сменалы эштәгеләрнең рәхәт ичмаса, җәй узганчы кара чутырга әйләнәләр. Зөһрә үзе дә кызлар белән рәхәтләнеп су коена, бәбкәләрен уйнатучы ана каз кебек, алар арасында чуала. Кисәтүе дә урынсыз түгел, чөнки кайберләре алдан ычкынырга чамалый. Быел җәй бик шәп килде. «Мондагы рәхәтлек Кавказ, Кырымга бирешерлек түгел», — диләр кызлар, күбесенең ул якларны күргәне булмаса да.

Зөһрә башка звено җитәкчеләренә дә нинди эшләр башкарачакларын әйтте. Хәер, кичтән ул аларга задание биргән иде инде, исләренә генә төшерде. Гадәттә, ул алдагы көн өчен эшләрне кичтән бирeп куя. Чөнки иртән конторда тоткарланган чаклары була, бригада төрле җирдә эшләгәндә башка объектларны да йөреп чыгарга туры килә. Бу арада бигрәк тә күңеле алгысып йөргән вакыт.

Нишләптер участок начальнигы белән тыныша алмыйлар. Бригада ару гына бер урында эшли башлый, начальник тота да икенче төшкә җибәрә. Кайчагында звеноларны бригадирга әйтмичә дә күчергәли. Аннары килеп, мастер, прораблары арасында да килешүчәнлек юк, уң кул нишләгәнне сулы белми. Зөһрә кемгә барып сүз катарга да аптыра-

ды. Чөнки эшкә төпле тотынган идарә башлыгы юк иде, баш инженер да нишләптер аның сүзенә колак салмады. Әллә Зөһрәнең үзендә дә гаеп бар инде, характеры кырысрак, картлар әйтмешли, талканы корырак бугай шул. Нишләсен, кырыкка житкәч, кеше үзгәрми торгандыр инде. Эш өчен янып-көеп йөри бит — үз мәнфәгатен кайгыртмый. Менә шуңа күрә участок башлыклары да, прораб-мастерлар да бригадир Кәбирова белән телгә килмәүне кулайрак күрәләр иде. Ә бу өлкән прораб аны санга сукмыйчарак йөри. Әгәр һаман да тыныша алмасалар, башка идарәгә күчү идѐ Зөһрәнең теләге. Элек бергә эшләгән кешеләр чакырып тора, үзләренә алырга дүрт куллап риза. Ләкин менә нәрсәдер аны тотып, тыеп тора. Бер иялэнгэн кешеләрне, сине чолгап алган мохитны эчендә жаны булган кешегә алай тиз генә ташлап киту жиңел түгел шул. Бригада өчен ул борчылмый, таркалмас, үз урынына калырдай кеше дә табылыр, ләкин менә тиктомалдан китеп бару — бригада члennарына хыянәт булыр кебек. Чөнки алар Зөһрәгә күнеккәннәр, кайвакыт катырак дәшә торган гадәте булса да, авыз турсайтмыйлар, чөнки бригадир апалары юкка орышмый, алар да үз әниләренә ышангандай ышаналар, ни әйтсә шуны тыңлыйлар.

Әнә беркөн ике кыз Дусяны тотып кыйныйбыз дип ажгырып торалар иде. Көлсәң көл, еласаң ела, дигәндәй, менә хәзер яшьләр нинди. Егетләрмени?! Шуннан бригадир икесен дә чакырып алды да: «Әгәр дә мәгәр аңа тырнак белән генә чиертсәгез дә, миннән рәхим-шәфкать көтмәгез», — диде. Әлегә ул-бу ишетелми. Күрәсең, үзара килешкәннәрдер. Әнә Гөлфия белән Ганжә эшлиләр бит, сүз әйтерлек түгел. Ә бит аларның да арасы эт белән мәченеке кебек иде. Ир-ат аркасында низаг килеп чыкты. Хәер, әле һаман да сөйләшкәннәре юк бугай.

— Тагын тартасыңмы? — дип сорады бригадир, Дусяның яшереп кенә чалбар кесәсенә шырпы салуын күреп.

Кыз дерт итеп китте. Аннан ничектер гаепле елмаеп:

— Ачуланма инде, Зоя апа, жаным,— диде.— Берне генә, иртәгә ташлыйм.

— Тукран тәүбәсе, — диде Ганжә тышкы яктан. — Әйтмә ичмаса, Зөһрә апа, шуңа теләңне әрәм итеп.

Бригадир дәшми-тынмый гына ишектән чыгып баручы Миләүшәне күз карашы белән озатып калды. Акыллы, тыйнак кына кыз дип йөри иде, бу арада монысы да сәеррәк күренә башлады. Я моңаеп, уйланып утыра, я кирәгеннән артык шаяра. Әллә гыйшык утына эләкте инде.

Зөһрә дежур кызга будкада тәртип ясарга кушып, үзе иң соңыннан чыкты. «Менә бит, — дип уйлады ул, — шул балаларны (әйе, балаларны, чөнки алар бит кемнеңдер балалары, әниләре минем кызым фәлән жирдә, фәлән кешеләр кулы астында эшли дип уйлый торгандыр), менә шушыларны ни жаның белән ташлап китәсең? Күбесе әле аягына ныклап басмаган. Тормыш сукмагы тайгак бит ул, буының сыек булса, егылуыңны көт тә тор. Ярый ла, таеп киткәндә иңбашын куючы булса. Ә булмаса?» Бригадирлыгының беренче елларында шулай булгалады да. Хәтта бер кызы төрмәгә дә эләкте. Менә шул хәл Зөһрәне күп уйланырга мәжбүр итте. Бигрәк тә кызның әнисе әйткән сүзләр. «Мин аны сезгә ышанып тапшырдым. Сезгә хөкүмәт эш өчен генә түгел, ә аларны тәрбия иткән өчен дә акча түли». Дөрес, бераз гади, тупасрак әйтелгән, ләкин аны киңрәк, артында нинди мәгънә ятканын аңларга кирәк иде. Ул вакытта Зөһрәнең үзенә дә егерме алты яшь кенә иде. Шулай да Зөһрә һәр кызның әнисе дә булырга тиеш икәнен аңлады. Менә хәзер шул кызларны, балалар йортында үскән Дусяларны ничек ташлап китәсең? Утызлап кеше — һәрберсе туганыңдай якын... «Идарәгә яңа начальник килде, бәлки эшләрне бераз рәткә салыр», — дип уйлады Зөһрә Кәбирова, киенү-чишенү бүлмәсеннән чыгып барышлый.

... Прораб төшке аштан килүгә Зөһрә җилтерәтеп дигәндәй аннан сорау ала башлады.

— Фаяз Гомәрович, кая буяулар? Пумала да юк.

Озын буйлы, ябык чырайлы Фәхретдиновның аксыл кашлары җыерылды. Ул:

— Белмим, — диде һәм будкасына кереп китте.

Бригадир аның артыннан калмады һәм каршына килеп басты да тегенең озын бармаклары белән нәфис папирос тотып, тәмәке кабызганын көтеп торды. Фәхретдинов иркенләп бер суырды да, утырып, урындыгында бераз янтаеп әйтте:

— Белмим, Зөһрә, белмим.

Аның бу кыланышына Кәбированың җен ачулары чыкты. Ул кулларын бутап сөйләргә кереште, чөнки бирешергә исәбе юк иде.

— Сезгә рәхәт, билгеле, белмәгәннең беләге авыртмый.

— Мин нишли алам? Китермиләр бит.

— Ничек инде нишли аласың? Син бит прораб, сора, шалтырат, таләп ит. Манка малай шикелле мәлҗерәп утырасың.

Фәхретдинов корт чаккандай урыныннан сикереп торды. Зөһрәнең күзләренә чекерәеп карады.

— Син нәрсә мине мыскыл итәсең?

— Ә син нигә минем каршыда киерелә-сузыла тәмәке төтәтеп утырасың? Кыланышың кырга сыймый.

— Зөһрә, шуны аңла: давай, давай дип эшли торган заман үгел хәзер. Һәр нәрсә фәнни нигездә, алдан билгеләнгән план буенча эшләнергә тиеш, центрозавоз бар...

— Алайса, бигрәк тә әйбәт. Безгә буяу кирәге әллә кайчан билгеле бит, мәктәпне беренче сентябрьгә өлгертергә кирәге дә көн кебек ачык.

— Ну, нишли алам соң мин? Китермиләр бит.

— Синең кулыңда машина бар.

— Миндә юк.

— Соң участокта, водозаборда бар. Сора.

Фәхретдинов кул селтәп:

— Әй, чәнчелеп китегез лә, — диде һәм ишеккә юнәлде. — Әнә телефон, шалтырат та сора. Табарсың микән...

— Алайса, кешеләрне җыям да монда алып керәм. Тик утырсыннар.

Шул вакыт прораб каршында иелеп ишектән кереп килүче Мәхмүтов пәйда булды. Ул йонлач дәү кулын сузды.

— Исәнме.

Аннары бригадирга дәште.

— Зөһрә, исәнмесез.

Төксе генә исәнләшүеннән, урамга ук ишетелгән тавыштан идарә башлыгы бераз төшенгән иде, шулай да эш нәрсәдә икәнен үзләреннән сорады.

Фәхретдинов, акланып-нитеп тормыйча, эшнең асылын, гауганың нидән килеп чыкканын әйтеп бирде.

Мәхмүтов тирләгән муенын кулъяулыгы белән сөртеп алды. Өстәл янына килеп, телефон трубкасын күтәрде, көчкә-көчкә номер җыйды: чөнки номер чокырына бармагы керми, дискы ычкынып китә иде.

— Диспетчермы? Мәхмүтов бу. Мин мәктәптән. Замга әйт, кичекмәстән буяу һәм пумалалар җибәрсен. Тап. Булмаса, үзең йөгер. Бетте.

— Нинди эштер инде бу? Һаман бер балык башы...

— Ярар, Зөһрә, тынычлан. Алып килерләр.

— Килерләр... Ә мин утыз кеше эшсез утырганда тыныч кына карап торыйммы? Аларга бит җитмеш-сиксән тиеннән дә ким ябып булмый.

Мәхмүтов елмаеп, прорабка ымлады.

— Менә бит янында миллионер, ач тотмас.

— Ислам Бакирович, эш бит акчада гына түгел, эшсез утырдылармы, алар хәзер кыбырсый башлыйлар: берсенә кибеткә чабарга кирәк, икенчесенә ательега, өченчесенә поликлиникага... Хәзер таркала башлыйлар.

— Ярар. Әйдәгез әле объектка.

Алар өчәүләп ике катлы мәктәпнең һәр бүлмәсен йөреп чыктылар. Мәхмүтов кызларның эшеннән кәнәгать иде. Эленке-салынкы йөргән бер генә кеше дә күренмәде, эшләгән эшләре дә күнелгә хуш килерлек.

— Зөһрә, бөтен кеше эштә, ә син эшсез утыралар дисең.

— Бүгенгә бар. Ә иртәгә, берсекөнгә...

— Фаяз Гомәрович, ишеттеңме? — диде идарә башлыгы хәйләкәр елмаеп. — Да, болай барса, вакытында бетерәчәкбез.

Мәхмүтовның кәефе күтәрелеп китте. Житәкче органнарның күзәтүе астында булган, ике башыннан да урам якка үстереп, янкорма салынган мәктәп үзенә шактый көч таләп иткән иде. Монтажчылар, ташчылар инде китеп барды. Столярлар да тиз тотарга чамалый. Бояу-сылау эшләре генә калачак иде.

— Ярар, Зөһрә, темпны киметмә. Материал булыр. Үзем контрольдә тотармын, — диде Мәхмүтов. — Ә без Идел буеннан әйләнеп килик әле.

Хәзер китеп барачак, дип уйлап кына торганда начальникның бу тәкъдиме прорабны шөбһәгә төшерде.

— Фаяз Гомәрович, сез дүртенче ел эшлисезме инде?

— Әйе, — диде Фәхретдинов һәм бераздан өстәп куйды, — прораб булып.

— Анысын беләм, — диде Мәхмүтов, ләкин соңыннан гына сүзнең ничек әйтелүенә игътибар итте, асылына төшенде. — Һаман прораб булып дип әйтәсе килүегезме?

— Дөрес аңлагансыз.

— Ләкин миндә хәзергә вакансия юк. Аннары... — Мәхмүтов фикерен әйтеп бетермәде. — Сезнең эленке-салынкы эшләвегезнең сәбәбе шул гынамы?

— Житмәгәнмени?

Мәхмүтов су кырына житәр-житмәс туктап калды. Фаяз да адымын акрынайтты. Алар кара-каршы басып торалар иде. Берсе — чалара башлаган кара чәчле, күпне күргән, тормыш тәҗрибәсе туплаган, икенчесе — яшь, төз гәүдәле, үз-үзенә нык ышанган, үзен яхшы белгеч дип санаучы, ләкин белгәннәренә эштә куллану таба алмыйча, барысына битараф караучы.

— Әгәр мин сезгә иртәгә участок бирсәм? Йөкне тарта алырсызмы?

— Алырмын.

— Ә мин ышанмыйм. Хет үтер — ышанмыйм. Синдә ниндидер меланхолия бар. Неужели син шул бияуны үзең юллап алалмый идең?

— Ала идем.

— Эш нәрсәдә?

— Теләмәдем.

— Циник! Да мин сине иртәгә үк эштән куып чыгарам!

Идарә башлыгының кызара-бүртенә ярсуына каршы, Фәхретдинов түш кесәсеннән кәгазь алып, тыныч кына аңа сузды.

— Менә гариза. Күптән әзер. Кул куегыз.

Мәхмүтовның әйтерсең башына таяк белән суктылар. Ул, үз-үзен белештермичә, кәгазьне прораб кулыннан тартып алды да ачу белән ерткалап атты.

— Син нәрсә? Бирермен мин сиңа! Гариза, имеш.

Аннан ул тынычлана төште.

— Ә мин кем белән эшләрмен? Синең урынга дүрт класс белемле бригадирны прораб итеп куйыйммы? Хәлеңне аңлыйм. Синең түштә

институт ромбигы, ә участок начальнигы техникум гына бетергән. Аңлыйм. Үземнең дә баштан узган. Ләкин синең әле барысы да алда. Өлкән прораб, баш инженер да булырсың, идарә житәкчесе дә...

— Беләсезме, Мопассан булса кирәк, болай дигән: «Кешегә бәхет ул инде аңа лаек булмый башлагач килә». Ә мин алай булуын теләмим. Картаеп, бөкрем чыккач, комым коелып беткәч, миңа берни дә кирәкми! Миңа барысы да хәзер булсын.

Мәхмүтов аның җилкәсенә кулын куйды.

— Сиңа ничә яшь?

— Егерме алты.

— Булыр, Фаяз, булыр... Әле... Әйдә без болай итик, башта мин сине кеше итим, Горький бабаң әйткәнчә, ә аннан начальник... Синең җитешсез якларың шактый...

— Алар һәркемдә бар.

— Берәүләр үзенең җитешсезлеген бетерергә тырыша, ә икенчеләргә ярдәм кирәк була. Синең гаилә барып чыкмаган дип ишеттем. Дөресме?

— Булды, — диде Фәхретдинов авыр сулап.

Ике ир, инне иңгә куеп дигәндәй, Идел ярында торалар. Якында гына бала-чага чыр-чуы: мәш килеп су коеналар, чумалар, йөзәләр, су сибешәләр. Идел өстендә көймәләр чаба, теплоход, баржалар әкрен генә уза. Һәр җирдә тормыш кайный. Һәр кайда кешеләр, йөзләгән, меңләгән, миллионлаган... Ләкин һәрберсе үзе өчен дә, бүтәннәр өчен дә бер генә. Һәркайсының үзенә генә һәм якыннары, танышларына гына билгеле булган катлаулы, сикәлтәле юлларга юлыгучы, башка беркемдә дә кабатланмас тормышы бар. Ничек башлана ул тормыш, ничек дәвам итә һәм ничек бетә — беркем дә әйтә алмый. Бу — язмыш. Ләкин ул югарыдагыниндидер илаһи көчкә түгел, ә җирдәге тормышка, сине чолгап алган тирәлеккә, якыннарыңа, танышларыңа бәйләнгән. Ничек башлап җибәрәсең ул тормышны, ничек дәвам итәсең һәм ничек тәгәллисең — ул сиңа бәйләнгән. Ләкин күп вакытта ул синең әйләнә-тирәңә дә нык үрелеп бара. Шуңа күрә берәүләр тормыш баскычыннан гел югары үрмәли, зур мәртәбәләргә ирешә, югары постлар били, ә икенчеләр бер урында таптанып тора бирә, аста кала, баскычтан менәргә аларның көчләре җитми, ә авыр чакта баскычны тотып торырга дуслары, якыннары булмый.

Мәхмүтов та үзен хәзер шул баскычны каты куллары белән тотып, бу яшь белгечне югары күтәрергә бурычлы кеше сыман тойды.

Идел өстендә кояш нурлары уйный. Аңа карасаң, күзләр чагыла, күңелгә аңлатып бирә алмаслык рәхәтлек килә, тәндә сихәтлек, үз-үзеңә, кешеләргә ышаныч арта. Бу минутларда шушы ук тойгыны прораб Фәхретдинов та бик ачык кичерә иде.

Фәхретдиновтан аерылгач, җиңел машинада тирбәлеп кайтканда Мәхмүтов кәефе күтәрелүен тойды. Эшләргә кеше бар, эш бар. Бу идарә ул кадәр үк өметсез түгел икән. Тырышканда яңадан кеше рәтенә чыгарырга була. Дөрес, күп көч сарыф итүне сораячак, күпме сәламәтлек китәчәк. Ә бит соңгы вакытта анысы да бик шәптән түгел, йөрәге шаяра башлады. Табибларга күренергә, дәваланырга иде дә, кая ул... Кайта-кайта үзенең соңгы көннәрдә кылган эшләренә анализ ясый башлагач, Мәхмүтовның яңадан кәефе кырылды. Нәрсәдер аның күңелен бимазалый, ул үзенең җаяне катырак бөгеп ташлавын сизде. Эш нәрсәдә икәнен белер-белмәс, Телегинга карчыга кебек ябырылды, бу егетне куып чыгару белән янады. Ә прораб шуны гына көткәндәй синең бәбәгеңә терәп, шартлатып гаризасын да китереп салды. Нигә салмасын? Аның болай да күңеле төшенке, җитмәсә, килеп бер атна эшләгән «яңа себерке» куып чыгарам дип яный. Ә аңа нәрсә? Дипломы

кесәсендә. СУ-5 тә эшләсә ни дә, СУ-1 дә эшләсә ни, барыбер түгелмени? Бүген ул китсә, үзе әйтмешли, иртәгә Мәхмүтов җиде-сигез класс белемле берәр практикны Фәхретдиновлар урынына тотып куярга мәҗбүр булачак. «Тәртәгә типмәскә кирәк, сабыр булырга, нинди генә хәлдә дә башны югалтмаска кирәк», — дип уйлады идарә башлыгы. Алай дип әйтүе генә җинел шул.

## XIII

Гөлүсләр яшәгән тулай торакка өченче төзү-монтаж идарәсенең конторасы урнашачак, диделәр һәм аларны башка урынга күчерделәр. Бу тулай торак та шул ук «Яшьлек» шәһәрчегендә, биш катлы озын бинада. Иң өске катта егетләр, беренче этажда китапханә, комендант, тәрбияче бүлмәләре, ашханә, ә калганнарында кызлар хуҗа иде.

Ял көне.

Бүлмәдәш егетләр кайсы кая чыгып киттеләр. Гөлүс берүзе калды. Форточка ачык булса да, бүлмәдә эссе иде, шуңа күрә ул тәрәзәне бөтенләй ачып куйды. Бүлмәгә августның җиләс һавасы кереп тулды. Егет тәрәзә тупсасына күкрәге белән ятып, урамга карады.

Спорт мәйданчыгында волейбол ярышы, икенче тулай торактан егетләр килгәннәр. Кичә аягын авырттырган Гөлүс аларга кызыгып карап торды. Ундa күптән түгел салынып беткән биш катлы йортка бүген хуҗалары күчеп киләләр икән. Бераздан егетнең игътибары шунда юнәлде.

Тулай торак кызлары да тәрәзәләреннән яңа йортка күченеп килүчеләрне карап торалар. Гөлүскә аларның башлары гына күренә. Ул үрелеп, үзләре турысына аска карады. Дүртенче каттагы тәрәзәдән кара чәчле бер кызның башы күренә иде. Кыз әллә үзенә текәлгән күз карашын тоеп, әллә болай гына өскә күтәрелеп карады. Аның кулында нindидер китап. Ул бераз елмаеп, кара кашларын күтәреп, егеткә сораулы караш ташлады.

Гөлүс никтер уңайсызланып китте. Кызның күзенә туры карарга кыймыйча, аның иңенә яткан, сумаладай чем-кара чәченә, кояшта янган беләкләренә күз салды. Кызның кашлары, очарга әзерләнгән кош канатлары кебек, бераз дугайланып, як-якка сузылганнар. Аның күзләрендә нindидер сихри көч бар иде булса кирәк, Гөлүс үзенең кызга таба тартылып куйганын тойды.

Алар шулай берничә секунд ни әйтергә белмичә бер-беренә карашып тордылар. Ниһаять, Гөлүс үзен кулга алып, кызга сорау бирде.

— Сез нәрсә укыйсыз?

Кыз көлемсерәп куйды. Билгеле, Гөлүс үзе дә бу сорауның мәзәк килеп чыкканын аңлады. Ләкин соң иде инде. Кызый калын китабын күтәреп, исемен Гөлүскә күрсәтте. Бу Джек Лондонның «Мартин Иден» исемле романы иде.

— Сез Лондонны бик яратасызмы? — дип сорады Гөлүс, тагын ни әйтим икән дип аптырап торгач.

— Мин Парижны да бик хөрмәт итәм, — диде кыз көлеп. — Ә яхшы язучыларның барысын да.

Кызның җавабы, көр тавышы Гөлүскә җан өргәндәй булды.

— Ә мин Шолоховны һәм Галимҗан Ибраһимовны гына яратам. Әлбәттә, башка язучыларны да укыйм.

— Мин язучыларны укымыйм, ә аларның китапларын, — диде кыз тагын елмаеп. — Әнә, карагыз, безнең егетләр нинди әйбәт уйныйлар. Исәп тугызга дүрт инде. Монысын отсалар, тагын бер генә партия уйныйсылары кала.

Гөлүс спорт мәйданчыгында волейбол уйнаучы егетләргә карады. Туп әле бер, әле икенче уенчының кулына эләгә, аннан ул сетка өстенә күтәрелгәч, берәрсе югарыга сикереп, бөтен көченә аны каршы якка суга. Сул яктан өченче тулай торак егетләре, ә уңда кунаклар — Восстание урамындагы икенче тулай торакта яшәүчеләр. Гөлүс үз егетләренең оста уйнавын күреп, горурланып куйды.

Дүртенче этаждан:

— Ә сез нигә чыкмадыгыз? — дигән тавыш ишетелде.

— Ә, минме, мин... болай гына, — диде Гөлүс гаепле кеше сыман.

— Ә сез бик яхшы уйныйсыз, — дип, кызый Гөлүскә тиз генә карап алды. Аның тулы йөзе бераз кызарып киткәндәй булды.

— Ничек яхшы уйныйм? — диде Гөлүс аптырап. — Сез мине беләсезмени?

— Бер тапкыр күргән идем.

Гөлүс башта кызның бу сүзләренә артык игътибар итмәде. Ләкин бераз вакыттан соң аның уйлары, җитез йөгерешчеләр кебек, бер-берен куа башладылар. Ул аны бер генә күргән. Тик ничек исендә тоткан? Гөлүс моны яхшыга да, яманга да юрый алмады. Волейбол уйнаганда ул бик еш егыла. Мәктәптә укыганда физкультура укытучысы аны шулай өйрәткән иде. Шуңа күрә, кызның исендә калуына үзенең күп егылуы сәбәп булгандыр, дип уйлады.

— Кулыгыз суелып канаган иде, бик нык авыртмадымы соң?

— Юк, — диде Гөлүс, үзе дә искәрмичә.

Бары бераздан гына кызның бу сүзләренең мәгънәсенә төшенде. «Кул, кул, әйе, беркөнне ул бик каты егылган иде. Терсәген бинт белән бәйләгәч тә уйнавын дәвам итте. Кыз аны хәтерли, димәк. Тик... бу кызый әллә Гөлүстән көлә инде?»

Шул вакыт спорт мәйданчыгында карап торучылар да, тулай торак тәрәзәләреннән күзәтүчеләр дә:

— Мо-лод-цы! Мо-лод-цы! — дип, үз егетләренең җиңүен тәбрикләделәр.

Гөлүс үзе дә сизмәстән аларга кушылды. Аскы каттагы кыз да шатлыгыннан нишләргә белмичә, сабый бала кебек, кулларын чәбәкли иде.

Алкышлар тынып, егетләр тагын уйный башлагач, кыз башын күтәреп, Гөлүскә күзләрен тутырып карады да, әкрен генә:

— Сезнең исемегез ничек? — дип сорады.

Егет үз исемен әйткәч, ул:

— Ә минеке — Миләүшә, — диде.

— Чәчәк исеме икән,— дип куйды Гөлүс.

Алар беркавым бер-берсенә сүзсез генә карап тордылар.

— Миләүшә, миндә бер бик яхшы китап бар. Укыйсызмы?

Ул моны Миләүшәгә бу китапны укытасы килгәннән түгел, ә бары аның белән озаграк сөйләшәсе килүдән әйтте, ахры.

— Нинди китап?

— «Карт һәм диңгез».

— Укыганым юк әле, ишетә беләм.

— Хәзер үк биримме? Мин әкрен генә төшереп җибәрермен, ә сез тотып алырсыз.

— Юк, мин тота алмам, Гөлүс. Я китабыгыз ертылыр. Сез аны алып, аска төшегез, мин дә төшәм.

Тәрәзә яныннан китеп, Гөлүс теге китапны эзли башлады. Кулына төрле брошюралар, газеталардан кисеп алынган спорт темасына язылган мәкаләләр, Стендальнең бер романы эләкте. Ә Хэмингуэйның китабы юк иде. «Эх, шайтан, хәтер диген инде!» Егет башына сугып куйды. Кичә ул китапны Альберт алып торган иде бит. Гөлүс тиз генә күр-

шесенең тумбочкасына ташланды. Менә ул, тумбочка өстендә генә икән.

Гөлүс титаклый-титаклый баскычтан йөгереп төште һәм ишегалдына чыкты. Тулай торак бинасын урап (чөнки бишенче катта торучы егетләрнең ишеге аерым иде), аксаклаганын белдертмәскә тырышып, экрен генә китапханә тәрәзәсе каршында торучы кыз янына килде. Миләүшәнең өстендә кыска җиңле буйлы күлмәк, аягында ак туфли.

Кыз да Гөлүсне күзеннән кичерде. Егет киңчә балаклы кара чалбар, ак нейлон күлмәк кигән. Күлмәгенең җиңнәрен пөхтә итеп сызганып куйган. Куе кара чәчләрен яхшылап тараган.

Алар икесе дә сүзсез калдылар. Гөлүс, китабын ике куллап тоткан килеш, карашын Миләүшәнең нур сибеп торучы зәңгәр күзләреннән алалмый иде. Аның күзләрендә әйтерсең лә күк йөзе баткан. Ул анда үз шәүләсен күрде. Миләүшәнең күзләрендә якты очкын, саф дәрт сизелә иде.

— Менә, — диде егет бөтен көченә һәм җиңел сулап куйды.

Миләүшә китапны алды һәм Гөлүскә карады. Аларның күзләре тагын очрашты. Кыз башын иде. Ул бу кыяфәтендә тагын да матур иде. Аның күпереп торган иреннәрендә бәхетле елмаю иде. Кап-кара чәчләре иңенә ишелеп төшкән. Шундый табигый һәм бер үк вакытта бик килешле таралып ятучы шул чәчләрне Гөлүснең сыйпыйсы, иркәлисе килде. Шул юләр уеннан ул үзен чак кына тыеп калды.

— Рәхмәт, — диде кыз һәм башын күтәрмичә генә кырт борылды да йөгереп китеп барды.

Шушы очрашудан соң бер атна узды. Ул көннәр Гөлүс өчен тиз дә, озак та тоелды. Аңа эшләве рәхәт, җиңел иде. Соңгы вакыттагы кебек, эшнең ваклыгына да игътибар итмәде, нәрсә кушсалар шуны бик теләп башкарды. Звено җитәкчесе Зиннәт моңа хәтта аптырабрак та калды, ләкин шулай да егетнең үзеннән бернәрсә дә сорашмады. Ул моңа куанды гына.

Шул ук вакытта Гөлүс өчен көннәр озынга да сузылды. Чөнки ул бер тапкыр да Миләүшәне күреп сөйләшә алмады. Ә сөйләшәсе бик килә иде. Кыз аның йөрәген җилкендереп, әле моңарчы билгеле булмаган ялкын кабызып калдырган иде. Кичләрен эштән соң, тулай торак янында волейбол уйнаганда Гөлүс Миләүшәләрнең тәрәзәсенә карап-карап ала. Әгәр озаграк карап торса, кыз я аска карый, я читкә борыла. Нигә алай итте икән ул? Гөлүс бүлмәдә чагында берничә мәртәбә тәрәзә тупсасына ятып аска да карап алгалады, ләкин Миләүшә анда күренмәде. Егет өчен бөтен тормыш, табигать, яшәеш шул дүртенче каттагы, үзләре турысындагы тәрәзә, бүлмә һәм Миләүшә белән бәйләнгәндәй булды. Хәтта бүлмәдәш егетләр дә моны сизә башладылар, ахры. Ләкин аларның берсе дә бу турыда тел тибрәтмәде.

Кызның да йөрәге тыныч түгел иде. Ул үзе еактан Гөлүскә карый һәм шул ук вакытта егетнең карашы белән очрашудан курка, ояла иде. Хәзер алар арасында беренче тапкыр очрашкандагы кебек самимилек, гадилек юк иде. Нидер булды. Ләкин нәрсә бу? Каян килгән ул? Ни өчен? Нигә килгән? Бу сорауга тәгаен генә алар җавап бирә алмаслар иде. Алар бер-беренең уйларын, йокысыз төннәр кичерүләрен белмиләр иде. Бу төннәр нинди татлы, нинди рәхәт! Аларның аралары да ерак түгел, бер-береңне күрү өчен әллә кайларга барасы, бик күп михнәтләр, газаплар да чигәсе юк. Ә шулай да күрешмәгәннәренә бер атна булды?

Менә тагын ял көне килеп җитте. Альберт күпме кыстаса да, Гөлүс шәһәргә чыкмады. Спорт киемнәрен киде дә волейбол уйнарга төшеп китте. Ул бүген нигәдер канатлы аттай ашкына, баскычның дүртбиш басмасын бер генә сикерә иде. Шул ашкынуы белән ул төшкә кадәр туп сукты. Каралып, кул-аяклары сыдырылып бетте. Ләкин во-

лейбол уйнавы нинди рәхәт иде! Тирә-яктагы эскәмияләрдә халык, тулай торак тәрәзәләреннән дә кызлар карап тора, бик күбесе үзләре дә егетләр белән уйный. Миләүшә дә беркөнге кебек кулына китап тотып тәрәзә төбендә утыра. Гөлүс аңа бүген озак-озак карап торды, кызның карашын туры китереп, кул да болгады. Миләүшә елмайды һәм уң кулын чак кына күтәреп куйды.

Егет коштай очып, өч-дүрт басма аркылы сикереп, баскычтан менде. Чишенеп юынды, өстен алышты, ашханәгә кереп чыкты. Тәрәзәдән үрелеп аскы этажга карады һәм кызны күрде.

— Миләүшә, исәнмесез?!

— Исәнмесез.

— Мин биргән китап ошыймы?

— Бик яхшы. Мин аны укып бетердем инде.

— Шулай тизме?

— Әйе.

— Ә хәзер нишлисез?

— Тик утырам.

Кыз иңбашы аркылы оялып кына егеткә карады. Очрашкач әллә ниләр әйтер кебек иде, менә хәзер Гөлүснең сүзе юк.

— Миләүшә, сезнең вакытыгыз бармы?

Кыз аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлады.

— Йөреп керергәме? Әйдәгез. Әле минем бүген урамга чыкканым юк. Китабыгызны алыйммы?

— Юк, кайткач.

Алар гадәттәгечә тулай торак тирәсенә җыелган егетләргә дә, бераз ялындырып, тәрәзә аша гына сөйләшүче кызларга да игътибар итмичә, күптән түгел утыртылган өрәңге аллеясы буйлап киттеләр. Аллеяның уң ягында ачык кыр: ерак та түгел химфармзаводның берничә йөз метрлы үзәк корпусы, кечерәк корылмалар, күтәрү краны, ә алар артында химкомбинат күренә.

Тулай торак белән беррәттән салынган йортның аскы катында кибетме, яисә парикмахерскаямы булачак. Идәннән түшәмгә кадәр сузылган зур тәрәзәләр, тоташ пыяла. Тәрәзә пыялалары акка буялган. Кемнәрдер кара тимер ишеккә акбур белән «Валя, я тебя люблю!» «Нина + Миша = любовь». «Кайчан парикмахерская ачыла?» дип язып куйганнар.

— Бу соңгысы кызлар эшедер, — диде Гөлүс.

— Ник алай уйлыйсыз? Егетләр дә чәч алдыру өчен автобус белән ярты сәгать барырга мәҗбүр булалар бит.

— Анысы да дөрес.

Алар булачак трамвай юлы белән химкомбинатка таба киттеләр.

— Миләүшә, сез кайда эшлисез? — дип сорады Гөлүс.

— Без бит бер идарәдә, — диде кыз, елмаеп. — Мин — буяучы. Әле бу арада мәктәптә.

— Яңа мәктәпме?

— Юк, искене зурайтканнар. Шуны яңа уку елына өлгертергә кирәк.

Бераз баргач, Миләүшә юл читендәге кечкенә күлгә борылды. Аның әйләнә-тирәсендә чикләвек куаклары, нәзек тал агачлары үсеп утыра. Суы мул булмаганлыктан, аның ярлары текә булып күренә. Бу күл тирәсендә һәр вакыт яшьләр-кызларны очратырга була иде.

Миләүшә егетнең беләгенә таянып аска төште һәм иелеп суга кулын тыкты да:

— Ай, нинди салкын! Гөлүс, кара әле! — диде, үзе дә сизмәстән сиңгә кучеп.

Гөлүс тә кулын суга тидереп алды. Чыннан да, су боз кебек салкын иде. Чишмәсе көчле, ахры.

— Күл астында бик куәтле берничә суыткыч бардыр,— диде егет көлеп.

Су күргәч, Миләүшә ничектер тынычлыгын югалтты. Менә-менә суга чумар шикелле. Ул, туфлиен салып, аягын да суга чылатып алды. Аннан яшел чирәм өстенә барып утырды. Гөлүсне дә үз янына чакырды.

Миләүшә күзләрен зур ачып, көзгедәй су өстенә караган. Вакыт-вакыт кечкенә балыкларны чирткәли, әллә вак бөҗәкләрме уйный, су өстендә түгәрәк дулкыннар хасил була. Алар Миләүшәнең уйларын тибрәлдереп, аны туган ягына — Ык буйларына алып китәләр.

Аларның өе Ык буенда гына иде. Җәй көннәрендә иртән йокыдан тору белән Миләүшә юынырга төшеп китә иде. Елга эрәмәлекләр, печәнлекләр арасыннан салмак кына ага. Су тып-тыныч, чиста, вак балыкларга кадәр күренә...

Соңгы вакытта Миләүшә нигәдер күңеле белән Ык буйларында, әти-әнисе янында еш була. Сагына иде ул аларны!

Аның әтисе урта мәктәптә немец теле укыта иде. Семьяда бер генә кыз булса да, әтисе Миләүшәне дә ике абыйсы кебек үк иртә торырга, дәресләрен хәзерләп бетергәч кенә ятарга, кыскасы, көннең һәр минутын файдалы үткәрергә өйрәтте. Үзе һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга, башлаган эшне ташламаска гадәтләнгәнгә, балаларыннан да шуларны ук таләп итте.

Сугыштан соңгы елларда күпчелек ата-аналар, без күргәнне алар күрмәсен, дип балаларын артык иркәли, ни теләсәләр шуны эшләргә ирек куя башладылар. Әмма Миләүшәнең әтисе моның яхшыга алып бармавын бик яхшы аңлый иде. Ул да сугышта булды, әсирлеккә эләкте. Андагы михнәт-газапны бер нәрсә белән дә чагыштырып булмый. Ләкин аңа карап ул бала тәрбияләүдә йомшаклык күрсәтмәде. Аннары Миләүшә бервакытта да әтисенең өйдә тавыш кубарып, юкка-барга ачуланып, яисә эчеп-исереп кайтканын күрмәде.

Әнисе ана теленнән укыта иде. Классташлары беркайчан да Миләүшәгә, әниең сине яклый, димәделәр. Алай әйтергә берсенең дә теле бармас иде. Чөнки әнисе кызыннан даими сорап торды, билгене дә белемгә карап, хәтта кирәгеннән артык саранлык күрсәтеп куя иде. «Алар хәзер еракта», — дип куйды кыз үзалдына.

Әнисенең Миләүшәне үз яныннан җибәрәсе килмәгән иде. Мәктәптә өлкән пионервожатый урыны буш, кызына институтта читтән торып укырга була иде. Ул ирен дә үз ягына авыштырырга тели иде. Ләкин әтисе кызы белән икәү генә калгач: «Кызым, тормышны китапларда яхшы сурәтлиләр, без дә барысын да ал да гөл итеп кенә күрсәтәбез булса кирәк, ләкин бераз үзең аның казанында кайнасаң, киләчәктә җиңелгәрәк туры килер. Хәтерлисеңме, мин сине ничек йөзәргә өйрәткән идем? Бер-ике тапкыр шулай тормыш дулкыннары уртасында калсаң, аннан үзең йөзеп чыга башларсың», — дигән иде.

Уйларыннан арынып, Миләүшә янында утырган Гөлүскә карады. Егетнең йөзе җитди. Ул хәтта үз яшеннән олырак та күренә. Маңгае биек, кара кашлары җыерылган. Аның карашында бераз үзсүзлелек сизелә.

— Нәрсә турында уйлыйсың?

— Үзебезнең бригадир турында,— диде егет кызның соравына.— Аңламыйм мин аны: бер караганда үзе яхшы кеше кебек, ә икенче караганда үтә начар сыман.

— Бригадир барысы өчен дә яхшы булмас инде. Кеше саен төрле характер бит.

— Юк, Миләүшә, син мине аңламадың. Мин аның безгә карашы, мөгамәләсе турында әйтмим. Ә үзе турында. Ул икейөзле Янус кебек.

Миләүшә бервакытта да ашыгыч нәтиҗә ясауны яратмый иде. Шуңа күрә егетне кисәтте.

— Гөлүс, син бит әле аны яхшы белмисең. Бәлки ул алай ук начар түгелдер. Ни дисәң дә бригадир итеп ни житте кешене куймыйлар. Гөлүс, әйдә химкомбинат ягына барабыз.

Кыз чәчләрен сыпырып куйды да, йөгереп яр башына менеп китте. «Нәкъ кыр кәҗәсе!» — диде Гөлүс, аның житезлегенә сокланып. Ул бер-ике атлауда Миләүшәне куып житте. Кыз егетнең кулын алды да аны селтәп бара башлады. Аның кулы шундый йомшак, шундый җылы иде, Гөлүс бу рәхәтлек бик озакка баруын теләгән иде. Ләкин бераз баргач, кыз кулын ычкындырды да, трамвай йөриячәк рельс өстеннән китте. Аның әледән-әле әллә аягы таеп китә, әллә тигезлеген саклый алмый, ул як-ягына чайкалып тора да, инде егылдым дигәндә Гөлүснең җилкәсенә таянып кала.

— Тот инде, егылам бит.

— Ике колагыңа ябыш, — ди егет, аны юри егарга тырышып.

Шулай шаяра-шаяра барып, алар химкомбинат каршына килеп житкәннәрен сизми дә калдылар.

Автобус тукталышында бүген берәү дә күренми. Төзүчеләр ял итә, ә химикларның смена алмашыр вакыты җитмәгән. Проходной алдындагы асфальт мәйданда тату күгәрченнәр генә гөрләшә. Ленин һәйкәле тирәсендә кечкенә куаклар — гөлҗимеш һәм карагай агачлары, төрле төстәге чәчәкләр утыртылган, аллеялар ясалган, эскәмияләр куелган. Гөлүс белән Миләүшә дә буш эскәмия табып килеп утырдылар. Беркадәр вакыт сөйләшеп утыргач, Миләүшә:

— Әйдә, урман буена төшәбез, — диде.

— Киттек, — диде егет һәм алар химкомбинат коймасы буйлап түбәнгә, урманга таба юнәлделәр.

Бераздан эстакада астыннан, тимер юл аркылы чыгып, ике ягына да бәбкә үләне түшәлгән йомшак ком юлдан урманга якынлаштылар.

Юлда корзин белән гөмбә күтәргән карт-коры, малай-шалай, күңел ачарга чыккан яшь-җилбәзәк, ял итеп кайтучы семьялылар очрый.

Арттан искән салкынча җилдә селкенеп, лепердәшеп утыручы тополь, каен агачлары арасыннан фыр-фыр килеп сары түш, тагын әллә нинди кошлар очып китә. Миләүшә белән Гөлүс аларны күздән югалганчы озатып калалар. Баш очында, тирә-юньдә берөзлексез кигәвен, шөпшә, чебеннәр оча, химкомбинат ягыннан репродуктордан җыр тавышы ишетелә. Ул ерак-еракларга агыла, тирә-юньне яңгырата. Җил искәндә җыр я көчәеп, я әкренәеп китә һәм моңлы көй йөрәкләргә тагын да ныграк үтеп керә, бөтен барлыгыңны биләп ала, хисләр дулкынында йөздерә.

— Әлфия апа җырлый, — диде Миләүшә, җырга колак салып, — безнең якташ.

— Сезнең Зифа апагыз бар инде, оста икәнсең, барысын да үзеңеке итмәкче. Ул бит Актаныштан.

Билгеле, кызның бу сүзләргә ачуы килмәде. Егетнең шаяртып әйткәнен аңлый бит ул.

Урман эченнән борыннарны ярып яшь нарат исе аңкый. Сулыш алуы ук җиңеләя. Шәлләрен алыштыра башлаган ак каеннарда кошлар сайрый. Табигать кочагына чумып, урман эченә кереп китә яшьләрнең күңелләре.

Аяк астында коелган сары яфраклар кыштырдый, тирә-юньдә биек нарат агачлары да, зифа каеннар да күренә.

— Мин урманда яз көне умырзая җыярга яратам, — диде Миләүшә.

Ул күбәләк кебек очып кына йөри. Тар сукмактан читкә чыга да, ботак-сатакларны шытырдатып, урман эченә йөгереп китә. Гөлүс аны куа башлый. Янына килеп җитә дә, менә тоттым ди, ә үзе аңа кагы-

лырга кыенсына. Сөйләшүләренең дә рәте юк. Әле генә караган киноларҗ укыган китаплар турында сөйләшәләр, аннан кисәк кенә тагын икенче темага күчәләр. Туган якларын искә алалар. Текә яр буена килеп чыккач, икесе дә туктадылар һәм җиргә утырдылар.

— Миләүшә, беләсеңме, — диде Гөлүс, карашын еракка төбәп, минем Себергә китәсе килә, я Төмәнгә.

— Нигә? — дип сорады кыз йомшак кына. Аның тавышында каушау, курку бар сыман иде.

— Үзем дә белмим. Әллә монда ошамый башлады, әллә ил гизәсе килә.

— Өлгерерсең әле.

— Кайчан?

— Белмим. Соңыннан.

Дөресен дә, Миләүшә аның кайчан икәнен белми иде.

— Әйдә бергә китәбез, — диде егет. — Анда бәлки тагын да кызыграктыр.

Кыз да күңеле белән әллә кайларга ашкына иде. Ул үзе дә менә хәзер торыр иде дә җәяүләп ил гизәргә чыгып китәр иде. Ләкин йөрәге белән ул икенче төрлерәк тоя иде. Реаль тормыш бар бит. Ил гизү күңелледер дә бәлки, ә алай бер җирдән икенче җиргә йөри башласаң, эштән дә тәм тапмый башлавың бар. Аннары...

— Гөлүс, — диде кыз, — безнең бит әле кулда һөнәр дә юк. Башта берәр эшне ныклап өйрәнергә кирәк. Монда ике ай, тегендә ике ай эшләп, без юньле һөнәр дә ала алмыйбыз. Минемчә, әле киту иртәрәк. Укырга кирәсебез бар.

— Минем нәрсәдер эшлисе килә, үзем дә белмим. Менә шушы агачларның берсен аударыйммы? Көләсең. Миңа да көлке. Ә менә шуны эшлисе килә. Я тормышта нинди дер батырлык эшлисе килә. Павка Корчагиннарны ал. Заманасы бүтән, беләм, ә күпме файдалы эш эшләгәннәр, күпме авырлыклар...

— Менә тиле, — диде Миләүшә көлеп. — Син бит комсомолның удар төзелешендә эшлисең. Беләсеңме шуны, удар төзелештә! Бу бит инде үзе синең иң алгы сафта булуың. Корчагиннар шикелле батырлыклар эшләвең турында сөйли.

— Ә мин аны күрмим.

— Күрмәсәң дә гаеп түгел. Беркем дә батырлык эшләгәндә мин фәлән эшлим, мин төгән эшлим, дими, ахыры турында уйламый. Менә син әле бая гына Тойма елгасында бер малайны судан тартып чыгардым дидең. Син аны ни өчен тартып чыгардың соң?

— Бәй, бата иде бит.

— Ә син үзеңнең батырлык эшләгәнеңне беләсеңме соң?

— И-и, көлмә инде, нинди батырлык булсын ди ул.

— Менә тагын тиле дими ни дисең инде сиңа. Соң аның өчен кешеләргә хәтта медаль бирәләр.

— Ну, анысы башка. Я берничә кеше булганда, я бүтән ситуациядә бирәләрдер аны.

— Син үҗәтрәк икәнсең, — диде кыз елмаеп, — сүзеңне бирмисең. Әллә юри мине үчекләп утырасың?

— Мин чынлап әйтәм.

— Алайса, дөресе шул инде: тормышта һәрчак батырлыкка урын бар. Менә безнең монда эшләвебезне дә батырлык дип сана. Китмик, Гөлүс, син дә китмә, мин дә китмим. Химкомбинатны төзеп бетерик әле, аннан күз күрер.

— Ярар, — диде егет килешеп.

Миләүшә белән Гөлүс тулай торакка кайтканда электр утлары белән ерактан ук балкып торучы химкомбинат ягыннан салкынча җил исә иде. Юл буендагы кечкенә куаклыклар гәпләшеп алгалыйлар.

Еракта-еракта түгәрәк кызыл шарның инде яртысы гына горизонтта күренеп тора. Әмма Гөлүскә ул һаман якты биреп, үзенең нурларын сибеп, төне буе Миләүшәнең йөзен яктыртып торыр шикелле. Күк йөзе сихри бер күренеш кебек зәңгәр, алсу, кызыл төскә кергән. Кояш нурлары, көчле прожекторлар кебек, болытларны тишеп үтеп бөтен офыкны яктырталар. Хәтта тулай торак бинасы һәм йортлар да алсу төскә буялган кебек, тәрәзәләрендә кызыл шәүләләр уйный.

Гөлүс белән Миләүшә икесе дә дәшмиләр. Чөнки бу минутта аларның нәрсә әйтергә теләгәнен елмаюлы йөзләре, бер-беренә сокланып караучы күзләре әйтә иде. Аларның әйтер сүзен моңлы да, дәртле дә итеп сайраучы, чикләвек куагының бер ботагына кунган сандугач әйтә иде. Хәер, бәлки ул сандугач та түгелдер, азмыни табигатьтә аның кебек матур итеп сайраучы моңлы кошлар, ләкин ул кош яз көнендә генә була торган иркенлек, шатлык һәм дәрт белән сайрый иде.

Бу минутларда сүзләр урынсыз булыр иде. Унҗиде яшьлек ике йөрәкнең бер-берен табышканга шатланып, бер-беренең җылысын, якынлыгын тоеп тибүен нинди генә сүзләр тулы итеп аңлатып бирә алыр иде икән?! Аларның яшь йөрәкләре күкрәкне тишеп чыгардай булып җилкенеп тибә иде. Бу бернинди сихри дә, фантастик көч тә түгел. Бу — иң якты хисләр белән сугарылган ике яшь йөрәкнең, вакыты җитеп канат чыккач очарга талпынган кош баласыдай, очсыз-кырыйсыз киңлекләргә ашкынуы иде.

Бу — ургып-ургылып агучы язгы ташкын иде. Ул ташкын үз юлында бернинди киртә алдында да туктап калмый. Ул сулар, таулар аша уза, урманнардан үтә. Аны бернинди көч тә туктата алмый. Аны хәтта меңләгән чакрым аралар да тыя алмый. Бу ташкын яшь йөрәкләргә бер генә мәртәбә килә һәм мәңгегә йөрәкнең соңгы тибешенә кадәр саклана. Бу — иң изге, сабый бала елмаюыдай самими, чишмә суыдай саф ташкын.

Ләкин ул кояштан көчлерәк яндыра, көйдерә. Бу ташкынның куәтен, яндыру көчен үзе татып караган йөрәк кенә әйтеп, тасвирлап бирә ала. Андый йөрәк мең мәртәбә бәхетле! Бу ташкынга эләккән йөрәкнең бер минуты давылсыз, утсыз пыскып янган йөрәкнең гомеренә тора. Күпме шигырь язылып, күпме җырларда җырланып та, әле һаман да тасвирланып бетмәгән һәм бетмәячәк сихри көч белән тулы иде бу унҗиде яшьлек ике йөрәк шушы минутларда.

## XIV

Миләүшәне озатып куйгач, Гөлүс тулай торакка тиз генә кереп китмәде. Бүген аның күңеле канатланган, йөрәге дәртләнеп тибә, менә-менә күкрәген тишеп чыгар төсле иде. Ул, үз-үзен белештермичә, байтак вакыт тулай торак тирәсендә йөрде. Аннан бер эскәмиягә килеп утырды. Вакыт соң иде инде. Тулай торакның берничә бүлмәсендә генә ут яна, күрше йортларның да тәрәзәләре караңгы. Кешеләр дә сирәк: эштән кайтучылар ашыга, кызларын озаткан егетләр соңгы автобуска йөгерә.

Гөлүс эскәмиягә чалкан ятты. Нәкъ аның баш очында йолдызлар җемелди, тулган ай йөзә. Әллә болытлар зур тизлек белән акканга, ай зур йомгакны хәтерләтеп тәгәри дә тәгәри. Алабуга өстендә дә шул ук ай, йолдызлардыр. Тик кешеләр генә башка. Анда Гөлүснең әнисе. Әле ул да йокларга ятмагандыр. Бу минутларда әнисе ниләр уйлый икән? Бәлки улы турындадыр. Хәзер бит ул берүзе. Гөлүснең моңарчы бу турыда бер дә уйлаганы юк иде. Әнисенә хәзер җиңел түгелдер. Гөлүс хәзер генә әнисенең аны ни өчен үз яныннан җибәрәсе килмәвен аңлады. Пристаньга килгәч тә әнисе нәрсәләр әйтергә теләде, ләкин

сүзне тагын икенчегә борды. Ул чагында Гөлүс моны аңларлык түгел иде, аның бөтен теләге үзе кебек үк кызлар, егетләр белән бергә комсомолның удар төзелешендә эшләү иде. «Метеор» кузгалып киткәч тә, әнисе бик озак пристаньда басып торды, улына яулык болгап калды.

Гөлүс карасу болытлар арасыннан әнисен күргәндәй булды. Аның белән янәшә Миләүшә басып тора. Элек егет өчен дөньяда бер генә иң якын кеше бар иде. Хәзер алар икәү. Кызык, бер белмәгән, күрмәгән кеше синең йөрәгеңдәге иң кадерле урынны биләп ала. Син аның өчен теләсә нишләргә — утка да, суга да керергә — барысына да риза. Нигә алай икән ул? Гөлүс ирексездән көлеп куйды һәм кинәт аягына басты. Чалбарын каккалап, тулай торакка кереп китте.

Егетләр йокларга яткан иде инде. Гөлүс туфлиен салып, караваты янына узды да, тавыш-тын чыгармаска тырышып, чишенә башлады. Шул чак өч карават та җанланды һәм егетләр торып утырдылар.

— Шула-ай, мәхәббәт шаукымы Гөлүскә дә кагылды, — диде Илфир авыр сулап. — Әй, дөнья, әле кайчан гына төпсез ыштан киеп, өстәл астында күмер ашап йөргән бала, хәзер кызлар куенында назлана.

— Без картаябыз, яшьләр үсә, тормыш алга бара. Эх, бу яшьлек, әллә төштә, әллә өндә булды, күрми дә калдым.

Моны бу бүлмәдәге дүртенче кеше Насих әйтте. Безнең егетләр элекке тулай торактан монда күчкән арада Николай тагын дөнья гизәргә китеп барды һәм алар өчесе бергә Насих яшәгән бүлмәгә керделәр. Ә элек монда торган бер яшь егетне башка бүлмәгә күчерделәр.

— Хәзер үк яшьлегеңне сагынасың. Ә үзең өйләнергә йөрисең.

— Яшең өч дистәне түгәрәкли башлагач, өйләнми булмас шул инде, Илфир.

Альберт та сүзгә кушылды.

— Гөлүс, кайсы читлектәге кошны эләктердең? Ничәнче этаждан?

— Алтынчыдан, — диде Гөлүс елмаеп.

— Оһо, менә монысы — да! Шулай инде, беренче мәхәббәт серле була. Бәлки әле кешегә белдермәскә дип сүз дә куешкансыздыр?

— Әйе шул, шулай иттек.

Илфир тәрәзә янына килеп тәмәке кабызды һәм:

— Син, Альберт, кешедән көләргә генә торасың. Аның яшендә үзең дә шулай булгансыңдыр әле. Барыбызның да баштан үткән бит, — диде Гөлүсне яклап.

— Ярар инде, теге кем әйтмешли, авыл мәхәббәтендә нәрсә аңлыйсың соң син. Армиядән кайтканыңа ике ел инде, әле кызлар озатканыңны күргәнем юк. Синең внешность белән... Үзең спортсмен, ә үзең...

— Мин укыйм, аның өше вак-төяк белән шөгыльләнергә вакытым юк, — диде Илфир, кызларга бик исе китмәгәнне аңлатып.

— Вак-төяк димә. Кызлар үзеңә дә кырын карый башларлар. Өйләнә алмый аптырарсың. Сакалың биләңә җитәр.

— Юк инде, Насих дус, анысы өчен кайгырма. Сакал билгә түгел, теге Бельгия әдәмене кебек ике метрга җитсә дә, Галя миңа кырын карамас.

— Галя, Галя дип, авыз суларың корыды инде. Шул бала-чага белән нәрсә турында язышасыздыр, белмим.

Альбертның бу сүзләре Илфирның ачуын китерде. Ул папиросын тәрәзә төбенә куйды да ут кабызды. Аннары, тумбочкасын ачып, нәрсәдер актара башлады. Кулына бер кап хатлар тотып Альбертның борын төбенә китерде.

— Мә, укы! Мондый хатлар язучы булса, син ул кызның үкчәсен үбәр идең! Хәер, синңамы соң андый нечкә хисләрне аңлау.

— Мин аңламыйммы, минме? Мин андыйларны йөзне табам! — диде Альберт кабарып-бүртенеп. — Укып күрсәт сер булмаса. Ишетик

бала-чаганың нәрсә язганын. Атна саен килгән хатларның барысы да бердер инде.

Гөлүс боларның бәхәсен тыныч кына тыңлап ятканнан соң:

— Андый хатларны кешегә укымыйлар инде, юкны сөйләмәгез,— диде.

— Нигә укымаска? Менә тыңлагыз.

Илфир караватына утырды. Хатларны одеал өстенә таратып салды. Беренче туры килгәнен кулына алып, әкрен генә, ниндидер бер көтәренкелек, тантана һәм ягымлы әчке хис белән укый башлады.

«Исәнме, Илфир!

Хәзер генә синең хатыңны алдым һәм җавап язам.

Үзем турында бер-ике сүз. Бүгеннән икенче ярты еллык башланды. Беренчесен бик үк яхшы тәгәлли алмадым, дүртлеләрем күп.

Яңа ел бәйрәмен мин дә матур каршыладым. Утызы көнне безнең мәктәптә кичә булды. Ә калган көннәрне без клубта үткәрдек. Анда бик күңелле булды.

Илфир, синең бәйрәмне әйбәт уздырганыңны белгәч, бик шатландым. Мин синең хәлләрең яхшы икәнен белсәм, гомумән, һәр вакыт куанам.

Илфир, ягымлым, хат яз. Түземсезлек белән көтәм. Сау бул. Кызлардан сәлам. Яз, көтәм... Галя. 20 январь».

— Һи әйттем бит, бала-чаганың бала-чагача инде,— диде Альберт кычкырып көлеп.

— Ашыкма, ашка пешәрсең. Менә икенчесен тыңла.

«Исәнме, Илфир!

Синнән хат алгач, шатлыгымның чиге булмады. Син бик аз язсаң да, мине ул да бик куандырды. Мин хәзер үзем дә белмим минем белән нәрсә булганын. Син киткәндә мин барысы да үтәр, онытылыр дип уйлаган идем. Синең белән бергә без бик аз булдык бит. Анда да башта безнең мөнәсәбәтләр бик үк яхшы булмады, бары соңга таба гына яхшырды. Барысы да үтәр дигән идем, юк, үтми икән... Син, сагынасыңмы, дип сорагансың. Әйе, бик сагынам. Шулай да, язып узганнан күренгәнчә, ничектер вакытны уздырам. Мин сине һәр көн искә алам, син һәр вакыт минем күз алдымда. Мин сине соңгы вакытта бигрәк тә еш искә төшерәм. Клубтан башка беркая да йөрмим.

Укуым яхшы гына бара. Бик күңелсез дәресләрдә гел сине искә алам, җәй көннәрен... Әйе, мин ул вакытта нәрсәнедер аңлап җиткермәгәнмен икән, хәзер генә мин барысын да аңладым. Ә ни өчен? Чөнки миңа озакламый уңҗиде яшь була бит. Күп түгел, шулай да җитәрлек.

Менә мин сиңа бөтенесен ачып салдым. Ә син, син мине искә аласыңмы? Әллә хат килгәч кенә минем турыда уйлыйсыңмы? Бу хатны укыгач, син бәлки көләрсең. Ә миңа бер дә көлке түгел. Миңа...,

Сау бул. Синең Галяң».

— Имәндә икән чикләвек. Менә сиңа бала-чага. Ничек матур язган, ә?!

— Җитәрме, әллә тагын укыйммы?

— Укы, укы.

— Җитәр, майлы ботка күп булмый ул,— диде Илфир.

Ул, гадәте буенча, хат укыганда да бернигә тапкыр чәчен сыпырып куйды. Аның кызгылт йөзе тагын да нурланып китте, карашы хәзер тагын да ягымлырак иде. Ул хатларын берәмтекләп җыеп тагын тумбочкасына салып куйды һәм караватына килеп утырды.

Гөлүс Альбертны үчекләп:

— Бу синең модницаларың яза торган записка түгел, агайне. «Ах, Альбертик, мольбертик, миленький...» — дип куйды...

— Без тебя тошно, — диде Альберт коры гына.

— Их, егетләр, белсәгез иде... — Илфир караватына сузылып ятты.— Безнең старшинаның буй җитеп килә торган кызы бар иде. Галяны беренче тапкыр мин аның янына килгәч күрдем. Тәбәнәгрәк, юантык кына гәүдәле кыз. Бер толым итеп үргән саргылт чәчле, битендә сипкеле дә бар, шулар өстенә зәп-зәңгәр күзләр... Беренче күрүдә үк текәлебрәк караганмын, күрәсең, икенчесендә мине күрү белән кыр кәҗәсе кебек кача бу миннән. Шулай ерактан гына карашып йөреп шактый күп вакыт узды. Яз житкәч, алар безнең белән туп суга башлады, көрәш ярышларын карарга килгәләделәр. Менә шунда әз-мәз сөйләшә башладык.

— Үбешмәдегез дәме? — дип сорады Альберт.

— Юк.

— И мәми авызлар. Сөйли, житмәсә...

— Үбешүдә генәмени хикмәт! Без аның белән Иделне, Кремльне, Знаменскийлар капкасын карарга ярата идек. Ике тапкыр Федор Волков театрына бардык. Монысы инде соңрак булды.

— Нигә алып китмәдең соң?

— Кая, әле яшь иде бит. Мин кайтып киткәндә ул апасы белән вокзалга килгән иде. Юньләп сөйләшеп тә, саубуллашып та булмады. Әле дә күз алдымда кул болгап калулары. Житмәсә, болай да өзгәләнгән үзәкне телгәләп паровоз кычкырта...

— Да, егетләр, әллә миңа да чын-чынлап гашыйк булырга инде, — диде Альберт, уенын-чынын бергә кушып. — Әллә нәрсә шунда. Пустота, егетләр, эчтә безвоздушное пространство! Әллә безгә нечкә хисләрсез дә ярап торырмы? Буталмыйча төгәл исәбен алып барсаң, шул житәрме? Илфир, ә, Илфир, давай чакыр син аны. Эшкә урнаштырырсың, шаулатып туй итәрбез. Көнләшәм мин синнән, дускай, көнләшәм... Их, кабер тактасын тибеп сындырасы, мин дә яшим...

Альберт одеалын башыннан ук бөркәнеп ятты да башкача сүз дәшмәде. Нигәдер ямансу булып китте. Илфир баш кагып кына Гөлүскә утны сүндерергә кушты. Бераз шыгырдап алгач, караватларның дүртесе дә тынып калды. Аларның хуҗалары әллә татлы йокыга талды, әллә тирән уйга чумды, тәгаен генә әйтүе кыен иде.

## XV

Президиумга сайлангач, Семагин башта бераз дулкынланган иде. Дөрес, кызыл постаулы өстәл артына беренче генә утыруы түгел, элеккә эшендә еш туры килгәләде. Ә монда ул әле яңа кеше, барысына да таныш түгел, ул да бик әзен генә белә. Ләкин комсомол оешмасы секретаре Әзһәм Шәрипов доклад укырга керешкәч, Семагинның беренче минутларындагы каушавы бетте. Ул иркенрәк итеп, докладчыга карап, дикъкать белән тыңлап утырды.

Шәрипов трибуна өстендәге стаканнан бер йотым су кабып, докладның соңгы өлешенә күчте.

Залдагылар кул чабып, докладчы кәгазьләрен җыештырган арада, җыелышны алып баручы Мәхмүтов президиум өстәле артыннан күтәрелде. Аның өстендә өр-яңа кара костюм иде. Ак нейлон күлмәгенең өске сәдәфен ычкындырып, ул гастугын бераз бушайтып куйды.

— Иптәшләр, сораулар бармы?

— Юк. Булса язма рәвештә бирерләр,— диде урта рәттән берәү.

— Яхшы, килештек. Кемнәр сөйләргә тели?

Кызыл почмак беравык тын торды. Аннары, идарәнең баш механигы «мин» дип күтәрелгән иде, аңа залдан берьюлы берничә тавыш каршы чыкты.

— Ашыкма, башта участок начальниклары сөйләгәнне тыңлап утыр, аннан соң сүз сорарсың.

Халык көлешеп алды. Мәхмүтов үзе дә елмайды.

— Җыелышка буйсынырга туры килә.

— Дисциплина, — дип, кулларын җәйде баш механик һәм, киң елмаеп, кире урынына утырды.

— Алайса, сүз иптәш Танеевка бирелә.

Йомгак кебек тәгәрәп, кечкенә юантык гәүдә трибуна янына чыкты. Тулы йөзле, сап-сары чәчле Танеев трибуна артына түгел, ә президиум өстәле кырыена килеп басты. Бер кулы белән өстәлгә, икенчесе белән бөеренә таянып:

— Бәлки бу җыелышны кичектерергә һәм тугыз айга йомгак ясарга иде, — диде. — Башка идарәләрдә әйбер табалар, ә бездә юк.

Идарәнең баш бухгалтеры реплика ташлады.

— Конкрет сөйлә.

Өстенә шакмаклы пиджак, җылы күлмәк кигән Танеев кызу-кызу, селкенә-селкенә сөйли башлады. Кулындагы кәгазе дерелди. Чәчен сыпырып алды.

— Ну, әгәр конкрет икән, пенобетон юк... Белмибез нишләргә. Дежур кием кирәк. Мичләр кирәк...

Идарә башлыгы аның чыгышын ошатмыйча торып басты. Залга карады. Карасу-коңгырт йөзе тагын да караңгыланды. Күзлеген өстәлгә бәргәләп:

— Иптәшләр, мондый чыгыш кемгә кирәк? — диде. — Нигә син безне Совет власте өчен кул күтәрергә өндисең? Участок начальнигы — ул зур объектның, коллективның житәкчесе. Ничек эшләргә, нәрсә эшләргә җыенасыз — сез менә шул турыда сөйләргә тиеш.

— Ул турыда минем сөйлисем дә килми. Бу — сүз боткасы куерту.

— Без ул турыда әйтергә тиешбез. Монда партия җыелышы, — диде калын тавышлы Мәхмүтов, көрәктәй кулы белән залга ишарәләп.

— Яхшы,— диде Танеев теләр-теләмәс кенә, ул тирләп чыкты, тотлыга башлады, — сөйлим. Әйбәт күрсәткечләр турында тыңлавы күңелле булыр иде, ләкин быел мактанырлык эшебез юк. Мәсәлән, механика заводында заказчы эшләнеп бетмәгән эшләр ведомостен әзерләмәде. Без дефектларны бетерә алыр идек. Трест базасында саф техник сораулар, очы-очка ялганмаган нәрсәләр күп. Механизмнар белән тулысынча тәэмин иттеләр: уналты һәм егерме тонналы краннар, ә алар тик тора. Безнең коллектив эшкә атлыгып тора, ләкин УПТК тарафыннан ярдәм юк. Югыйсә, үзебезнең база.

Ул трибунадан төшешли борынын сөртеп, сары чәчен сыпырып куйды. Семагин өченче участокның башлыгы Михайлов турында шактый күп ишеткән иде. Ул яше белән дә, эш тәҗрибәсе белән дә өлкән прораблар арасында иң өлкәне. Озын, таза гәүдәле, күз кабаклары шешебрәк торган кызгылт йөзле, карап торуга кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге бу кеше турында аңа төрле каршылыклы фикерләр дә ишетергә туры килгәләде.

Өстенә шакмаклы көрән пиджак кигән Михайлов трибунага менеп тормады. Җыелыш алдына чыгып, җир асты коммуникацияләре кору һәм гомумтөзелеш эшләре башкаручы участоктагы хәлләргә тулы һәм конкрет анализ ясады. Сүзенең ахырында болай диде:

— Участок авыр хәлдә, эш юк иде. Ләкин хәзер ярыйсы. Шулай да баш механик бүлегенә зарыбыз зур. Күчмә электр станцияләре тиз сафтан чыга, бетон җылыту өчен дә, бигрәк тә металл опалубкаларны, хәзердән үк әзерләнергә кирәк.

Михайловның тулы чырае караңгыланып китте һәм ул президиумга яны белән борылып, сорау бирде.

— Безгә кайчан ял бирерләр икән?

Мәхмүтов урыныннан торып:
— Нинди мәгънәдә? — дип сорады.
Михайлов кинәт ярсып:
— Хәтта сугышта да ял иттерәләр иде. Ә монда ишәк кебек эшлисең дә эшлисең. Участок начальниклары, мастер-прорабларның икешәр-өчәр ел отпускада булганы юк, — диде һәм залга карамыйча гына урынына барып утырды.
— Мин моны беләм, Иван Алексеевич, — диде Мәхмүтов, залга карап. — Түзәтербез, Иван Алексеевич, төзәтербез бу хәлне, ял бирербез.
Михайлов белән янәшә утырган баш инженер көлеп:
— Компенсация алырсың, Иван Алексеевич, — диде.
— Үзегез алыгыз. Минем акчам җитәрлек, — дип Михайлов йөзен читкә борды.
Мәхмүтов каләм белән графинга бәргәләп, дилбегәне тагын үз кулына алды.
Начальник урынбасары Белыйның чыгышы Семагин карашынча җыелышта әллә ни яңгыраш тапмады. Чөнки ул бер балык башын чәйнәүдән гыйбарәт иде — тегесе юк, монысы юк, база гаепле, трест гаепле. Ә үзе ни караган? Нинди чара күргән? Җыелыш моны ишетмәде.
Семагинга бу җыелыш мөһим бер вакыйга булып, идарә һәм үз тормышында ниндидер әһәмиятле бер эз калдырыр сыман иде. Трест управляющие килү дә моңа сәбәпче иде булса кирәк. Бу хәл җыелышның әһәмиятен төзү идарәсе тормышында бермә-бер арттырырга тиеш иде. Җыелышта утыручы башка кешеләр дә моны шулай кабул иттеләр. Алар уенча да бу җыелыш коллектив тормышында әһәмиятле бер этап булырга тиеш иде.
Белыйдан соң чыгыш ясаган Зиннәтнең бер генә сүзе дә, бер генә җөмләсе дә артык та, ким дә түгел иде. Бу өлкәдә тәҗрибәсе зур булган Семагин моны бик тиз аңлады. Һәр сүзе уйланган, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дип сөйләнгән нотык түгел иде бу, ә шартлатып маңгаена бәрә торганы.
Партбюро исеменә тәнкыйть сүзләре шактый элакте.
— Әле бригадалардагы прогул ясау, эшкә соңга калу кебек җитешсезлекләр белән көрәш тә партбюро эшендә тиешле чагылыш тапмады. Әлбәттә, беркадәр эш эшләнә, ләкин җитәрлек түгел, халык контроле, комсомол прожекторы рейдларын да ешлатасы бар, — диде Зиннәт. — Билгеле, партбюроның мөмкинлекләрдән түбән эшләве кайбер объектив сәбәпләр белән дә аңлатыла. Соңгы вакытта секретарь Иннокентий Федорович авырды, Шәриповка ике йөкне бергә тартырга туры килде. Ләкин бу аклану була алмый...
Начальник урынбасары Зиннәт чыгышыннан соң урындыкка ингәндәй булды. Эшченең һәр сүзе Белыйның тамак төбенә кылчык булып кадалды. Чөнки материал булмады, булган кадәресенең дә начар сыйфатлы икәне конкрет мисалларда күрсәтелгән иде. Бияләй, эш киеме, газ кискечләре, эретеп ябыштыру агрегатларында кабель җитмәү — болар бер Зиннәтне генә борчыган сораулар түгел иде. Ләкин яхшы гына башланган чыгыш аның көлкегә калуы белән тәгәлләнде.
— Монтаж пояслары сынау үтмәгән. Берәр җиргә менәрсең дә...— дип, Зиннәт егылып төшүне русчалатып, гап-гади, ләкин кәгазьгә язылмастай сүз белән әйтте дә куйды.
Зал егыла-егыла көлде, президиумдагылар да, ике-өч бөртек хатын-кыз да елмаеп утырдылар. Әле ярый, трибуна артында түгел иде, Зиннәт кып-кызыл булып, ялт кына урынына утырды. Шулай да көлеш, шау-шу тынгач, торып җыелыштан гафу үтенде. Монысы тагын бер елмаеп алырга сәбәп булды.
Тагын бер-ике кеше чыгыш ясаганнан соң, Мәхмүтов сәгатенә карап алды. Беренче участок башлыгыннан:

— Жиһангир Шәмсиевич, сезнең әйтер сүз юкмыни? — дип сорады.
— Минем эшләр хәзергә көйле бара. Ул турыда сөйләсәм — мактану булыр. Ә вак-төякне эш барышында да хәл итәрбез, — диде Әхмәтов урыныннан кузгалмыйча гына.

— Яхшы. Ул чагында миңа бер-ике сүз әйтергә рөхсәт итегез, — дип, идарә башлыгы өстәл арасыннан трибуна артына күчте. — Иптәшләр, монда ИТРлар тарафыннан инженерларча фикерләү әз булды. Сез бит үз эшегезнең профессорлары. Ә сез зәңгәр читле алтын тәлинкәдә алып килеп биргәннәрен көтәсез. Башмакның кайсы төштә кысасын алдан ук белеп торырга кирәк. Сентябрьгә үз көчләребез буенча план йөз егерме мең, ә безгә ике йөз мең кирәк. Тәэмин итү яхшы куелганда без өч йөз мең дә бирә алабыз бирүен...
Управляющий әйтеп ташлады:
— Узганында йөз алтмыш мең бирдегез.
— Әйе, ләкин без өч йөзне бирә алабыз.
Кабышев үзалдына көлеп, башын чайкады. Ислам Бакировичның тулы йөзе тыныч, ышанычлы иде. Ул житди төстә дәвам итте.

— Менә сез көләсез, ә без юк. Монда утыручылардан берәү дә көлми. Расчетлар буенча... шулай бирә алабыз дигән фикергә килдек. Ярдәм итегез безгә, Василий Георгиевич. Без үз казаныбызда үзебез кайныйбыз. Аннары, Василий Георгиевич, безгә тагын егерме-утыз гыпытыушник бирә алмассызмы? Безнең алда торган бурычлар зур, ачык. Кем әйтмешли, ыштаннан чыксак чыгарбыз, ләкин эшләрбез. Без әле үз хуҗалыгыбызны да тәртипкә китерергә уйлыйбыз. Конторны зурайтасы, тагын бер склад саласы булыр. Ә баш механик чыгышына карата шуны әйтәм: безгә әле тагын унлап будка кирәк. Һәр бригада саен бер генә түгел, ә икешәр булсын...

Семагин идарә башлыгының чыгышын дикъкать белән тыңлап, аның ышандыра белә торган сөйләм осталыгына сокланып утырды. Мәхмүтов трибунада терсәкләренә таянып, әкрен, тыныч сөйли, вакыт-вакыт бармакларын аралаштырып куя. Идарә коммунистлары, гомумән, коллектив аны үз арасына кабул иткән. Моны залда тынлык булудан, чебен очкан тавыш та ишетелерлек тынлыктан да шәйләп була иде. Семагинга бу әллә ни гаҗәп тоелмады, чөнки ул Мәхмүтовны бик күптәннән белә иде. Аның кеше белән аралашучан икәнлеге дә хәтерендә яхшы сакланган. Дөрес, ул чагында Мәхмүтов әле Ислам гына иде, яшь иде, төз гәүдәле, чибәр, чем-кара чәчле яшь егет иде. Хәзер аның гәүдәсе авырайган, борыны да зурайган кебек, иреннәре элеккечә калын, йөзе карасу-кызгылт, ләкин тупасланган — җыерчыклар күренгәли. Элек ул күзлек кими иде, хәзер ансыз укый алмый. Шулай да трибунада аны да салып куйган иде.

... Кабышев зур, таза гәүдәсен артка ташлап, кашларын җыера төшеп, залга карап утырды. Аның йөзе һәр вакыт житди, хәтта бераз кырысрак та иде. Күзләре усал һәм беренче карашка ул үзе дә усал кешедер кебек тоела. Күрәсең, Себер ягының кырыс табигате аңа тугач та үзенең тамгасын салып калдырган. Трибунага чыккач, аның йөзе ачылып киткәндәй булды. Ләкин бу бер генә мәлгә шулай күренде: ул агарган чәчен уч төбе белән сыпырып, түшенә депутат значогы таккан аксыл пиджак кесәсеннән күзлеген алып киде һәм залга карап сөйли башлады:
— СУ-5 коллективы яңадан трестта әйдәп баручыларның берсенә әверелергә тиеш, иң мөһим эшләрне тапшырырга була. Кешеләр килде... Менә идарә начальнигы яңа, энергияле иптәш, күрәсезме, нинди дәү ул, аның энергиясе өч кешегә житәрлек.
Залда көлешеп алдылар. Мәхмүтов үзе дә елмаеп куйды.
Кабышев күзлеген салып, маңгаен сөртеп алды. Трибунага таянып,

идарә эшендәге чатаклыклар турында сөйләде, аларны тиз көндә бетерү юлларын аңлатты. Ахырда ул сүзен болай тәмамлады:

— Ә сезнең тәкъдимне, Ислам Бакирович, тикшерербез. Ике участок булмас булуын, әмма фәкать җир асты коммуникацияләре һәм эстакадалар гына коручы аерым участок оештырырга кирәк булыр. Аны Михайлов участогы базасында оештырганда начар булмас дип уйлыйм.

Трест управляющиеның бу сүзләреннән соң Мәхмүтовның канәгать булуы йөзенә үк чыкты. Ул баш инженер Коновка карап алды. Аларның күзләре очрашты. Моны алар икәве генә белә һәм бу алдан уйланылган иде. Чөнки торба салу һәм тимер-бетон эстакада монтажлау кебек күләмле эш һәр вакыт булып торганда идарә планының яртысын булмаса да, өчтән берен бу участок бирүзе биреп барачак иде. Дөрес, бу эшләр пычрак, юеш, һәр вакыт ачык һавада башкарыла торган мәшәкатьле эшләр иде, ләкин шул ук вакытта алар төшемле дә иде. Мәхмүтов та үзенә: «Җайлап кына башка идарәләрдән эретеп ябыштыручылар һәм монтажчылар да сорарга кирәк»,— дип куйды. Чөнки моның табигый хәл, үзеннән-үзе килеп чыгарга тиешле нәтиҗә дип уйлый иде ул.

Кабышев сәгатенә карап алды һәм үзен җыелыштан җибәрүләрен сорады. Кырык минуттан химкомбинат директоры белән горкомда булырга тиеш икәнен әйтте.

...Семагинны яңа партбюро составы исемлегенә кертергә тәкъдим булгач, арттагы рәтләрдән берәү каршы чыкты. «Без аны белмибез, ул әле яңа кеше», — диде. Билгеле, коммунист хаклы иде, моны беркем дә инкарь итмәде.

Председательлек итүче Мәхмүтов торып басты.

— Иптәшләр Александр Вениаминовичны мин яхшы беләм. Ул фронтовик, моряк. Торпеда катерлары дивизионында без бергә хезмәт иттек. Әгәр теләсәгез, мин сезгә аның нинди батырлыклар эшләгәнен дә сөйли алам... Ә соңгы тапкыр аларның катеры үтә мөһим сугышчан задание үтәгәндә минага эләгеп шартлады. Семагин үлеп терелгән кеше... Сугыштан соң күп еллар балалар укыткан, колхозда, мәктәптә партоешма секретаре вазифасын башкарган, гаиләсе белән дә таныш, ике баласы бар. Тагын нинди мәгълүматлар кирәк?

— Җитәр! Исемлектә калдырырга, — диде баягы тавыш.

... Бер Семагин өчен генә түгел, ә Мәхмүтов өчен дә бу җыелышның әһәмияте бик зур иде. Чөнки аңа гомуми картина, идарәнең сулышы тагын да ныграк ачыла төште: кешеләрне танып белүдә дә җыелышның файдасы тиде. Кем нәрсәгә сәләтле, кем ни уйлап яши, авыр чакта кемнәргә таянырга була — болар хәзер Мәхмүтов өчен зурайткыч пыяла аша караган әйбер кебек ап-ачык бер хакыйкать иде.

## XVI

Беркөнне иртән сәгать җиделәрдә әле дүртесе дә рәхәтләнеп йоклый иде, күрше егете кереп Илфирне төрткәләп уятты.

— Илфир, Илфир, тор әле.

— Нәрсә бар?

— Анда берәү сине сорый.

— Кем ул? Таң тишегеннән йөрмәсә.

— Каян белим. Вахтер янында.

Егет чыгып киткәч, Илфир спорт костюмы гына киеп сукрана-сукрана аска төшеп китте. Дүрт-биш минут үттеме-юкмы, ул артына ут капкандай бүлмәгә атылып керде һәм егетләрнең одеялларын чөеп атты.

— Егетләр, тизрәк, тизрәк, торыгыз! Килде!

— Кем? Нәрсә?
— Үзе килде, үзе, егетләр!
Ул тиз-тиз урынын җыештыра башлады.
— Ял көне дә рәхәтләнеп йоклатмыйлар,— дип шыңшыды Альберт. — Юньләп әйтергә булмыймыни? Кем килде?
— Галя дим бит, ничә мәртәбә әйтергә була!
— Ә?!
Башланды ыгы-зыгы, шау-шу. Тагын берничә минуттан урын-җир ялт иткән, егетләр чын ясау киенгән иде инде. Илфир тагын аска төшеп китте һәм бераздан бүлмә ишеген шакыдылар.
Ул оялып кына килеп керде. Исәнләште. Егетләр аны таныдылар, әлбәттә, карточкасын күргәннәре бар иде. Ләкин бу Илфир сөйләгән, егетләр хыялында туган юантык гәүдәле, кечкенә буйлы Галя түгел иде. Бер толым итеп үрелгән чәч урынына матур прическа ясалган, сипкелләре дә беленер-беленмәс кенә, зифа гәүдә. Кыз-кыркынны шактый күп күргән Альберт та аның килешле буй-сынына сокланып карап куйды.
Ул оялып кына егетләр куйган урындыкка утырды. Итәген тартып, аякларын бер якка авыштырыбрак куйды.
Илфир үзе дә аннан ким каушамаган иде, ахры, бары бераз торгач кына:
— Егетләр, таныш булыгыз — Галя, — диде ул. Аннары берәм-берәм аларның исемнәрен әйтеп чыкты.
Бүлмәгә әйтерсең зур чәчәк бәйләме кертеп утырттылар. Һәркемнең карашы анда. Ул бөтен дөньяны нурга чумдырды, ямьләп җибәрде. Илфир Гөлүскә ымлап өстәлдәге чәйнеккә күрсәтте, ә Альбертка баш какты. Аяк очларына гына басып, егетләр чыгып сыздылар. Насих Илфиргә:
— Әйберләрен урнаштыр, — диде. — Галя, ничек килеп җиттегез? Юлда читен булмадымы?
— Юк, бик рәхәт булды. Рәхмәт.
Шулай хәл-әхвәл сорашкалап, вак-төяк сөйләшкән арада табын әзерләделәр. Үзләрендә стаканнан һәм чәй пешерә торган калай кружкадан башка савыт-саба заты юк иде. Альберт йөгереп кенә вахтер хатыннан бер пар чынаяк алып менде, ашханәдән ризык, тәлинкәдер, кашык-чәнечкедер юнәттеләр. Шулай итеп, кадерле кунакны иртәнге чәй белән сыйладылар.
Бераздан егетләрнең дә телләре ачылды. Галя үзе дә телгә бик юмарт икән, оялу-тартыну бетеп җитмәсә дә, сөйләшеп утырды.
Аннары Илфирдән кала өчесенең дә бик мөһим йомышлары, кичектергесез эшләре булуы беленде. Билгеле инде, кунакны калдырып китү гаеп саналса да, кунак килде дип барасы җиренә бармыйча калу килешмәс диделәр һәм, Галядан гафу үтенеп, чыгып киттеләр. Бары Илфирнең генә барыр урыны да, таныш-фәләне дә юк икән. Нишләсен, бахыр, ул өйдә утырып калды. «Молодцы минем егетләр!» дип куйды ул эченнән генә.
— Галя, синме соң бу?! — диде ул, кыз каршына утырып. — Таныйм да, танымыйм да.
Кыз башын иде. Аның да йөрәге урынында түгел иде... Күпме хыялланып йөри торгач, менә, ниһаять, тагын Илфирне күрде. Ирексездән күзләре яшьләнде. Ул мөлдерәмә күзләрен тутырып егеткә карады. Илфир урыныннан торды да Галяның каршына тезләнде, кулларыннан тотты һәм күзләренә карады. Я ходай, күпме шатлык, бәхет иде аның зәп-зәңгәр күзләрендә. Илфир кызның куллары белән битен каплады һәм аларны йомшак кына үбеп алды. Галяның кайнар куллары егетнең муенына сарылды. Ул әле аннан ояла, тартына, бөтен тәне ут яна иде, шулай да бөтен көчен җыеп, Илфирнең иреннәренә үрелде. Аның

күзләре йомык иде. Кызның кайнар иреннәрен кат-кат суырып, бөтен сагынуларын берьюлы белдерергә, аны өзелеп яратуын аңлатырга теләде егет. Әйе, кыз аны аңлый, үз хәле дә егетнекеннән ким түгел иде.

— Илфир! — диде ул йокы аралаш эндәшкән сыман.

— Галя! Кадерлем!

Бераздан икесе дә аңнарына килеп, айнып, тагын кара-каршы утырдылар. Ләкин әле күзләре күреп, куллары иркәләп туймаган иде. Илфир кызны җиңел генә урыныннан торгызды да тагын кочып алды. Бөтен дөньяның назын, җылысын, бөтен гомеренең яшәү шатлыгын җыйган йомшак иреннәрен эзләде. Үзләре дә назга, сөюгә сусаган иреннәрне табу читен түгел иде. Ниһаять, алар күктән җиргә төштеләр.

— Бик арымадыңмы? Ял итәсеңме?

— Юк, — диде Галя.

— Алайса, мин сиңа безнең башкаланы күрсәтәм. Чыгасыңмы?

— Алып чыксаң, билгеле, чыгам.

— Мин бая сораган идем бугай, апаң, әти-әниләрең ни хәлдә?

— Барысы да исән-сау. Апа курсын яхшы бетерде. Әти дә, әни дә сиңа сәлам әйтергә куштылар.

— Рәхмәт, Галя, әгәр сине монда калдыруларын сорап язсам, нәрсә диярсең?

— Белмим шул, — диде Галя серле генә елмаеп. — Мин монда нишләрмен соң?

— Эшкә урнашырсың, укырга керерсең. Тик менә документларыңны да соратырга туры килер.

— Ә мин паспорт белән аттестатны да ялгыш үзем белән алып килгәнмен.

— Чынмы? Галя, кадерлем, чын әйтәсеңме?

Егет көчле куллары белән кызның биленнән кочып алды да, бүлмә буйлап бөтерелеп йөри башлады.

— Илфирем, төшер инде, куркам, — диде Галя, аны муеныннан кочаклап.

Бераздан алар шәһәр карарга дип урамга чыгып киттеләр. Чөнки аларның шатлыгы, бәхете, куанычы тулай торакның бер бүлмәсенә генә сыярлык түгел иде. Аларның сөенече шәһәр кебек зур, урам кебек киң, күңел шатлыклары Иделдәй тирән һәм тулы иде.

## XVII

Бик еш булмаса да, Әзһәм Халидәне озаткалый иде. Күпчелек вакыт ул кибет ябылуга килә дә, аны өенә кадәр озатып куя. Әле алар үзләренең хисләре, киләчәк турында берни дә сөйләшмиләр иде. Ике таныш кеше арасында була торган гадәти сөйләшү генә була, бер-беренә хәерле төн теләп аерылышалар иде. Бүген дә Әзһәм кибет ябылуга килде, һәм Халидә эшен бетереп чыккач, алар урам аркылы чыгып, кайту уңаена юл тоттылар.

Халидә, гадәттәгечә, подъезд янында туктамады, әйдәгез, өйгә керик, диде һәм эчкә узды.

Икенче катка күтәрелгәч, ридикюленнән ачкыч алып, каршыдагы фатирның ишеген ачты. Керделәр. Халидә ут яндырды, аяк киемнәрен салды.

— Узыгыз инде.

Туфлиен коридорда калдырып, Әзһәм эчкә узды.

Халидә аңа диваннан урын күрсәтте.

— Рәхмәт, — диде егет һәм үзе кыяр-кыймас басып торуында булды.

Ике бүлмәле квартира. Шифоньер янында кечкенә карават. Комод

өстендә зур карточка. Аның астына Халидәнең рәсеме кыстырылган. Комод пыяласы арасына аның кызы белән төшкән рәсеме куелган.

— Утырыгыз инде.

Әзһәм диванга утырды да, бераз иелебрәк, кулларын тез арасына куеп, Халидәгә карап тора башлады. Ул аңа үз итеп, якын итеп карый иде. Хатын моны сизде дә оялып башын түбән иде.

— Монда сез үзегез генәме?

— Абыйлар отпускада, ә кызым авылда.

— Сагынасызмы?

— Сагынмаган кая ул. Кибеткә берәрсе бала күтәреп керсә, дөньямны онытып карап торам, көнләшәм. Ул хәзер белә бит инде. Кайтсам, башта ятсынып тора, аннан иялəшә, әбисе чакырса да бармый. Быел аны яслегә урнаштырасы бар. Әгәр укырга керсәң, алырбыз, диделәр.

— Сез элек укымадыгызмы?

— Педагогическийда ике ел. Тагын ике ел бар иде. Әгәр укыган булсам, минем балам булмый иде.

Әзһәм яшь хатынның кияүгә чыгуына да, баласы булуына да үкенмәве, гомумән, язмышыннан зарланмавын сизде һәм ул балконнан керләр алып кергәч, сорап куйды.

— Кайберәүләр баланы җәфа дилəр бит, бигрәк тә сезнең хәлдә.

— Мин моңа ышанмый идем, бервакыт «Азат хатын»да бер язма укыгач, йөрәкләрем әллә нишләп китте.

Әзһәм диваннан торды һәм бүлмә буйлап йөри башлады.

— Алар бит безнең җәмгыятьнең калдыклары. Һәр җәмгыятьнең, ул нинди генә алдынгы булмасын, бозык кешеләре була.

— Вагыйз, кыз тапкан дип, беренче көнне янга килмәде. Алырга такси белән килгән иде. Шофер, кем белән котларга була, ди. Ә ул күзен-кашын җимереп, кул селтәде. Шофер беренчесе кыз булуы яхшы аның дигәч, кыз — кеше хатыны ул, диде. Җир тишегенә керердәй булдым шул чагында. Ә ул шундый матур иде, түгәрәк битле, әтисенә охшаган, минем кебек каз түгел. Миңа энем шулай дия иде. Ник син әнигә охшамагансың, каз шикелле дия иде. Ә аның чәчләре оп-озын, врачлар прическа белән туган дип көлəләр иде. Кайткач, Вагыйзга, кара әле кызыңа, дигән идем, йөзенә җирәнү чыкты. Кулымны этеп җибәрде дә чыгып китте. Хәтта аю да үз баласын аппагым, керпе дә йомшагым ди. Ә ул... гарьлегемнән утырып еладым. Үз баласы бит, әйтерсең лә мин аны ияртә килгән.

Әзһәм байтак вакыт дәшмәде. Халидәнең кызы белән төшкән карточкасына карап торды. Бала чыннан да матур иде. Башында ак шапка, килешле кием... Аннары егет балкон каршына килде. Урамнан музыка тавышы ишетелә. Бала-чага чыр-чу килә. Каршыдагы бакчада кечкенә кызлар, малайлар качышлы уйныйлар. Арырак, агачлар артында башнялы кран. Анда йорт төзиләр.

— Күрәсең, — диде ул Халидәгә таба борылып, — малай булачагы аның күңеленә береккәндер. Ул бит авылдан. Ә элек авылда кемне көтүләрен үзең беләсең. Дөрес, хәзер җир бирмиләр, ләкин борын-борыннан килгән гадәт бит ул. Аннан, кеше күңеленә берәр нәрсә берексә, аны ул уйдан кире кайтаруы бик авыр. Миңа минем белән бергә торучы бер энекәш тә укуын ташлыйм дигән иде. Мин аңа ике сәгать аңлаттым, барыбер аңламады.

— Аңа ничә яшь иде соң?

— Егерме. Күрәсең, сондыр. Янсә аның үз фикере куәтледер. Ә икенчесен үз фикереннән кайтардым. Ул яшь егет, унҗидедә, ун класс бетергән. Физика, химия, математиканы яхшы белә. Фантастик китаплар ярата. Эрудициясе бик көчле, үз иптәшләреннән күп алга киткән. Аның үзенең фәлсәфи фикерләре бар. Беркөн шулай матдә турында

сүз чыкты. Мин аны идеалист дип уйлаган идем. Ә ул метафизик булып чыкты. Мин аңа ялгышып әйттем һәм аны исбатлап бирдем. Мине әле бәхәстә җиңүче кеше юк иде, ди.

— Димәк, сез акыллы.

Әзһәм елмаеп:

— Мин андый комплимент өмет итмәгән идем, — диде. — Эш монда икенче нәрсәдә: кешене үз фикереннән кайтару кыен, ләкин була. Аңларга теләсә. Бәлки әле ул да аңлар, килер.

— Юк, әйтмәгез аның турында. Мин аны кичерә алмыйм. Узган ел берәүләрдә фатирда тора идек. Беркөн килә бер хатын. Мин кер юа идем. Вагыйз монда торамы? ди. Әйе, дидем. Урын бирдем. Утырды. Ул кайда соң? ди. Чыгып китте каядыр, кайтыр, дим. Ә бу аның кеме, кызымы әллә? ди аптырап. Ә сез аның кеме буласыз? дим, үз чиратымда мин дә шикләнеп. Ул аптырап карап торды-торды да, ашыгып чыгып китте. Вагыйз элек тә шул авылда командировкада булган икән, шул хатын белән торган.

Халидә кечкенә кулъяулыгы чыгарып күз яшьләрен сөртте. Борын тартып алды да сөйләвен дәвам итте.

— Кибеттә хатыннар, син аны судка бир, алиментка, ди. Кирәк түгел, минем аны берни белән дә борчыйсым килми. Аңа типтерергә дә акча күп кирәк бит.

Халидә торып үзенең фоторәсемнәрен алып комодка салды. Әзһәм аның янына килеп, кулына үрелде.

— Калдырыгыз. Урынында торсыннар, кире куегыз, — диде һәм нишләргә белмичә торган Халидәнең кулыннан карточкаларны алып кире урынына куйды.

— Тормышны аны үзең әз-мәз яшәп карагач кына беләсең икән. Мин элек беркатлы, шул кадәр ышанучан идем. Частныйда торганда сәгать ничәдә кайтса да, аның әйткәненә ышана идем. Ә хәзер... үз-үземә аптырыйм. Утырыгыз, нигә басып торасыз?..

— Болай фикерләү сәләте яхшы, баш әйбәтрәк эшли. Утыргач, йокыга тарта, кеше гамьсезләнә.

Халидә көлә.

— Мин әллә шулай укып карыйм микән. Сез — философ.

Әзһәм:

— Һәркем үзенчә философ, — диде. — Уйлый, фикер йөртә, нәтиҗә ясый. Менә аю баласына бик рәхәт. Гомумән, адәм баласына яшәве бик үк рәхәт түгел. Чөнки ул уйлый, кайгыра, сөенә, шатлана, хафалана!.. Менә тагын фәлсәфәгә бирелде диярсең.

Өстенә яшел күлмәк, кара йон кофта кигән Халидә кулына радио һәм телевидение программасын алды да бераз күз йөртеп чыккач:

— Сез миңа ничә яшь бирәсез? — дип сорап куйды.

— Сезгәме? — диде Әзһәм уйланып. — Егерме ике-егерме дүрт.

— Менә күрәсез, ә миңа унҗиде көннән егерме бер генә тула.

Әзһәм башта Халидәгә текәлеп, ышанмыйчарак карады. Аннары бу караш соклануга күчеп, ул аңа яратып карап тора башлады. Менә шул коңгырт чәчләрен сыйпыйсы, күкрәгенә кысасы, иркәлисе килә аның тормышта бәхетсезлеккә тарган бу яшь хатынны.

Халидәнең дә егеткә булган карашы үзгәрде. Барысын да бер калыпка салып, барлык ир-атны да үз кирәген генә кайгыртучылар дигән уе әкренләп югала барды һәм моңа, әлбәттә, Әзһәмнең тыйнаклыгы, төпле фикер йөртүе, сагызланмавы сәбәпче иде. Аның ачык күз карашы, гомумән, Вагыйз белән чагыштырганда күп уңай яклары булуы Халидәне бу егеткә икенче төрле карарга мәҗбүр итә иде. Ул бу егетнең үз тормышына минут саен ныграк керә баруын, менә ул хәзер саубуллашып чыгып китсә дә, уйларының аның турында булачагын сизә иде. Әйе, ул шулай булачак. Яхшылык җирдә ятмаган кебек, ке-

шенең яхшы уйлары да башкаларда да якты уйлар, тирән хисләр уята. Кеше хыяллана, уйлана башлый һәм аның уңай сыйфатлары тагын да калкурак күренә, хәтта булмаганнары да күренә башлый. Менә шуңа күрә Халидә үзен мәҗбүр итеп булса да икенче төрле дә уйлый иде. Әйе, егет аңлаган сурәттә дә ул аны үзенә бәйләргә җыенмый. Моны аңа хәзер үк әйтү, һич булмаса искәртеп, сиздереп кую хәерле. Соңыннан икесе дә газапланырлар... Вагыйз кебек каты бәгырьле булса иде, ләкин Әзһәм бит андый түгел, ул да уйланыр, борчылыр...

— Әзһәм, гафу итегез, безгә чыгарга кирәк.

— Димәк, куасыз.

— Сезгә кайтырга кирәк. Автобуслар йөрми башлар.

— Бөтен кайгыгыз, борчылуыгыз шул гынамы? Юкка. Бәлки сез кеше сүзеннән куркасыздыр? Подъезд төбендә безнең кереп киткәнне күрделәр бит.

— Юк, алар мине беләләр. Мин анысыннан курыкмыйм.

— Ә нәрсәдән?

Халидә дәшмәде. Нәрсәдән? Дөресен генә әйткәндә, нәрсәдән икәнен ул үзе дә белми. Ул инде бу егетне якын күрә башлады, аның үз янында, янәшәсендә булуын тели. Ләкин шул ук вакытта менә шуннан курка иде ул. Әйе, бәрәүләр дә яшьтән үк үзе белгән, күргән кешене генә яратмыйлар. Киресенчә, күпчелек очракта күз күрмәгән, белмәгән кеше соңыннан иң якын кешегә әверелә. Халидә елмаеп куйды, авылда бер кыз елый икән, әнине этигә биргәннәр, мине чит кешегә бирәләр, дип. Халидә, үзенчә батыраеп, дөресе, үз-үзен батыраерга мәҗбүр итеп, Әзһәм каршына килде.

— Әйдәгез, чыгабыз.

Егет аның иңбашыннан тотты да күзләренә карап тора башлады. Халидәнең бөтен уйлары күзендә һәм йөзендә чагыла иде, шуңа күрә Әзһәмгә аның эчке халәтен аңлау кыен түгел. Әйе, шик тә юк, бу хатын Әзһәмнән курыкмый, аны тиң күрә, аның һәр сүзенә ышана, әйткән бер сүзен күңеленә сеңдереп бара, егет ни генә әйтсә дә, ул аны чын күңелдән кабул итәчәк. Әйе, Әзһәмнең моңа шиге юк иде. Әнә аның күзләрендә, ирен читләрендә елмаюы сизелә, күпме газаплардан соң эссе чүлдә кое күргән юлчы кебек, аның бөтен барлыгы хәзер шатлык белән тулып ташырга тора иде. Аның бу минутта шатлыктан елап, я җырлап җибәрүе дә бик мөмкин. Озак вакытлар явым көткән үләннәр дә шифалы яңгырдан соң шулай тулып, яшәреп китәләр. Халидә дә бу минутларда шул хәлдә булгандыр. Егет ни әйтсә дә, ни эшләсә дә, Халидә аңа сүз әйтәчәк түгел иде. Әзһәм моны яхшы аңлады. Ләкин... ул аны күкрәгенә кысып бер кочты да:

— Әйдә, чыгабыз, — диде һәм ишеккә юнәлде.

Урамда караңгы. Йолдызлар җемелди. Ай йөзә. Электр лампочкалары яна. Подъезд ишеге төбендә эскәмиядә яшьләр утыра.

— Сезне автобуска кадәр озатып куйыйммы?

— Юк, рәхмәт, — диде Әзһәм, йорт башында туктап. — Менә шушында әзрәк сөйләшеп торыйк та, китәрмен.

— Нәрсә турында сөйләшик соң? Үзең уйлап кара, Әзһәм, минем кызым бар. Син яшь егет, синең йөрәгеңдә беркайчан да миңа урын булмаячак.

— Ә синең йөрәгеңдә миңа урын булырмы? — диде Әзһәм, Халидәнең караңгыда тагын да озая төшкән аксыл йөзенә карап.

Халидәнең юка иреннәре дереләп китте. Аннан соң да әле алар вакыт-вакыт кыймылдап куя иде.

— Нигә дәшмисең? — диде Әзһәм, Халидә җавап бирмәгәч.

— Сорамагыз ул турыда, әйтә алмыйм... Белмим.

Урамда этләр өрә, кешеләр берөзлексез йөреп тора. Озынча буйлы бер егет үтеп китте. Әзһәм аны Вагыйзга ошатты. Аннан егетнең кү-

ңелен ниндидер аңлатып бирә алмаслык тойгы биләп алды. Ул үзен җинаять өстендә тотылгандай хис итте. Аның акылы белән йөрәге тартыша башлады. Йөрәк хисләр агышы белән яши, акыл вакыйгаларга аек күз белән карарга киңәш итә. Әзһәм Вагыйз белән очрашканда нәрсә дияр? Бәлки әле алар тагын аңлашырлар, кавышырлар... Һәм егет китәргә булды.

— Ярый, мин китим, алайса.

Әзһәмнең бу сүзләрен ишетеп, Халидә кинәт каушап калды. Бу каушау аның күзләрендә чагылды һәм ул аларны мөлдерәмә тутырып егеткә карады.

— Әйе, китәм. Мин сезгә комачауларга теләмим. Мин аны яхшы беләм, ул безгә килеп йөри, элек бергә тордык. Кешедә намус, оят дигән нәрсә дә бар бит әле. Әлбәттә, төрле кеше бар: дусты янына килеп, эчеп, аның хатыны белән йоклап китүчеләр дә була, ләкин мин... просто не могу. Дөрес аңла! Миңа аның күзенә күренү ничектер уңайсыз булачак. Син, әлбәттә, бу егет куркак икән дип тә уйлый аласың, ихтыярың. Юк, эш анда түгел. Төкерәм мин анысына. Ләкин мин йөрәгемне түгел, акылымны тыңларга телим. Йөрәгем белән мин синең янында калам. Ләкин баш белән уйлаганда... Дзержинскийның бер сүзе бар: чекист кайнар йөрәкле, салкын башлы һәм чиста намуслы булырга тиеш, дигән. Мин моны чекистлар өчен генә кулланма димәс идем. Шулай, Халидә, сез әле бәлки кавышырсыз да. Син ул өметеңне дә өзмә әле.

Халидә нәрсәдер әйтергә теләп авыз ачкан иде, Әзһәм аны бүлдерде:

— Беләм, сез, бер киселгән икмәк кире ябышмый, дип әйтергә телисез. Ләкин кешеләрдә өмет дигән нәрсә бар. Ансыз шайтан гына. Ә бәлки... Менә шул нәрсә кешеләрне күп вакыт тотып, үзенә биләп тора. Ә бәлки... Монда киресен дә уйларга була. Ләкин оптимист булырга кирәк.

— Эх, сез, — диде Халидә әрнү белән.

Ул бу сүзләрне әйтмәгән булса, Әзһәм бәлки китеп тә барган булыр иде. Ә хәзер... Юк, юк, ул чыннан да китә алмый. Халидә дә китмәсен. Әзһәм инде китеп барырга җыенган Халидәне кулыннан тотып, кире борды.

— Әйдәгез, әзрәк йөреп киләбез.

Асфальт сукмак. Караңгы. Уңда балалар бакчасы. Сулда агач койма, аның артында кран кукыраеп утыра. Алда йортлар. Тәрәзәләрдә утлар сирәк. Парлылар йөри. Урак кебек ай саргылт төстә, йолдызлар җемелди. Күк йөзе куе зәңгәр, караңгы. Бераз вакыт алар юлдан бардылар. Ә аннан балалар бакчасы янында уңга борылдылар, тагын янәшә сөйләшеп бардылар. Бакча янында тукталдылар. Әзһәм койма башына кулын куеп, уйланып торды. Халидә дә дәшми — ул агач ботагы сындырып ала, әкрен генә аны кулында бөтерә. Аннан тәбәнәк койма өстендә башын тотып уйлана. Әзһәм аңа карый. Халидә аның карашын сизеп, егетнең артына чыга һәм коймага сөялә. Ялгыш терсәгенә кагылып китә.

— Син минем китүне телисеңме?

— Әйе.

— Моны бит синең йөрәгең әйтми.

— Сез бит үзегез, йөрәк белән түгел, ә акыл белән эш итәргә кирәк, дидегез.

— Мин аңлыйм, барысын да аңлыйм. Ләкин... Ярар, ул турыда калдырып торыйк. Кайчан килим? Иртәгә килимме?

— Белмим. Мин иртәгә ял итәм. Аннан бер атна эшлим, икенче атнаны авылга китәм. Юк, сез килмәгез.

— Мин кибеткә килермен.

— Белмим. Кайтасызмы?

— Әйе. Киттек.
Бакчаның икенче башына барып җиткәч, Әзһәм туктады:
— Ышанасызмы, китәсе килми.
— Сезгә минем янда кызык түгел бит, минем моң-зарымны тыңлап торуы.
— Мин сезне төне буе тыңлар идем.
— Ярый, китегез инде, — диде Халидә, Әзһәмнең уң кул терсәгеннән тотып, аннары каршысына чыгып басты. — Китегез.
— Иртәгә килимме?
— Белмим, әгәр мәҗбүри булса, килмәгез.
Әзһәм көлеп куйды.
— Ул бит суд тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри эш түгел.
Халидә дә көлде.
— Алайса, килегез.
— Кайчан?
— Мин көне буе өйдә.
— Кич сәгать сигезгә килермен.
Халидә китеп барды. Аннан яңадан килеп, егетнең каршысына басты. Һәм аңа кулын сузды.
— Сау булыгыз.
— Хәерле төн.
Әзһәм аның йомшак, салкынча кулын кысты да тиз-тиз атлап китеп барды.

## XVIII

Сәгать дүрт тулып килгәндә Яббаров Гөлүс янына килде дә:
— Бүген төнгә калырсың, битум казанына ягарга кирәк,— диде.
Егет карышып тормады, ярар, диде дә китеп барды. Ләкин нидер исенә төшепме, кире килде.
— Низами абый, ә рөхсәт бармы?
— Нинди?
— Янгын сүндерүчеләрдән.
— Ну, юмор син, Гөлүс. Сиңа нигә кирәк ул?
— Пропуск алганда инструктажда әйттеләр бит: рөхсәт язуы булмаса, ут якмаска, әгәр берәрсе мәҗбүри куша икән, килеп әйтергә дип.
— Бар, барып әйт, — диде Альберт көлеп.
— Я, бетте, әзрәк шаярдык, житте. Мастерда була ул, бездә түгел.
Яббаровның сүзләреннән соң Гөлүс үзе дә беркатлылыгы өчен уңайсызланып куйды. Билгеле, мастер да, бригадир да ул белгәнне генә белә торганнардыр. Алар өстенә төшкән җаваплылык Гөлүснеке кше генә түгел бит.
Төзүчеләр кайтып киткәч, участок бушап, тынып калды. Прораб будкасында каравылчы белән аның эте генә иде.
Гөлүс кичтән бик күп итеп утын әзерләде, төне буе битум казанын якты. Ул төнлә бер-ике мәртәбә каравылчы янына кереп сөйләшеп утырды, төзелеш мәйданындагы алтмыш метрлы торбага менеп химкомбинатны, шәһәрне күзәтте. Дистәләгән озын-озын цехлары, алар тирәсендә сузылган эстакадалары һәм меңләгән утлары белән җемелдәп торучы химкомбинат төнлә тагын да матур икән. Ә аңда березлексез җилфердәп торучы факел утлары үзенә бер хозурлык белән тирәякны бизәп, күңелгә якын булып тора. «Ә шулай да ул факел матурлык өчен генә, ә матди яктан караганда шактый күп акчалар җилгә очадыр», — дип уйлады Гөлүс. Төнге шәһәр гаҗәеп матур икән. Төрле

төстәге реклама утлары ерак-ераклардан балкып, шәһәрне тагын да бизиләр, ямь өстенә ямь өстиләр.

Гөлүс шәһәр, үзе төзи торган химкомбинат, гомумән, кешеләр турында да шактый вакыт уйланып утырды. Көндез я эш, я уен белән андый уйларга бирелергә вакыт юк. Ә монда төрледән-төрле уйлар башка килә. Әнисе белән Миләүшәне дә бәлки очкылык тоткандыр. Алар турында да егет шактый вакыт уйланып утырды.

Иртән кешеләр килгәндә казанда битум быгыр-быгыр кайный иде инде. Бригадир аны хәтта мактап куйды. Чөнки элегрәк төнгә калучыларның өендә йоклап, иртән генә килеп ягуларын белә иде ул.

Гөлүс кайтырга җыенган иде инде. Бригада членнары будкадан чыгып таралышырга торганда прорабскидан табельчы кыз чыгып халыкка мөрәҗәгать итте.

— Иптәшләр, бер генә минутка игътибарыгызны сорыйм. Әле генә контордан шалтыраттылар: безнең бер егет больницада ята икән, малокровие белән. Менә шул егетнең хәле бик мөшкел, ашыгыч рәвештә кан кирәк. Кемнәр бирергә тели?

Бераз вакытка тынлык урнашты. Аннары Зиннәт кулын күтәрде дә:

— Мин, — диде.

Аның артыннан Яббаров, Гөлүс һәм тагын берничә кеше кан бирергә ризалыкларын белдерделәр. Гөлүс белән янәшә генә торган Альберт: «Үземә дә җитми әле, әнә патриотлар бирсен», — дип, халык артынарак шуышты. Гөлүс үз колакларына үзе ышанмыйча артына борылып карады. Әйе, Альберт, чыннан да, аның яныннан китеп барган иде. «Әгәр үзе больницада ятканда башкалар шулай эшләсә?» — дип уйлады Гөлүс һәм беренче мәртәбә аның күңелендә Альбертка карата ризасызлык уянды.

Кан бирергә теләүчеләр тиз генә будкага кереп, инструментларын куйдылар, кием алыштырдылар. Аннары, төзелеш идарәсеннән килгән автобуска төялеп, шәһәргә юл алдылар.

Гөлүснең колак төбендә Альбертның: «... патриотлар бирсен», дигән сүзләре чыңлап торды һәм ул беренче мәртәбә тирә-юненә, аны әйләндереп алган мохиткә, кешеләргә ышаныч һәм соклану белән генә түгел, ә тәнкыйть күзлегеннән дә карарга кирәк икәнен төшенде. Ә октябрь башларында аларның шеф колхозга баруы һәм анда булган җәнҗал Гөлүс белән Альберт арасында башланган әчке бәрелешнең тышка чыгуына ук китерде.

## XIX

Колхозга баручыларны бер автобус төзү идарәсе янында көтеп тора иде, ә икенчесе трест каршында, диделәр. Сәгать җидедән үк ташчы, монтажчы, бетончы, балта остасы егетләр һәм буяучы-сылаучы кызлар берәм-берәм, күмәкләшеп конторга җыела башладылар.

Гөлүс Миләүшәне кичәгенәк күрә алмады, шуңа көенеп, ләкин әчке бер сиземләү белән конторга килүче кызларны ерактан ук күзәтә иде. Муенына аскан гитара кылларын чирткәләп, янында Альберт басып тора. Кемдер транзистор акырта. Конторга керәләр, чыгалар, тыз-быз киләләр, кайберәүләр, алдан килгән урын өчен дип, автобуска да утыра башладылар.

Шул вакыт механика мастерское артыннан бер кыз белән Миләүшә килеп чыкты. Ул өстенә җылы свитер, куртка һәм резин итек белән чалбар киеп алган, кулында җылы перчатка.

Башына ак фуражка, өстенә замоклы куртка һәм резин итек кигән Гөлүс Миләүшә каршысына атлады.

— Исәнмесез, кызлар.
— Исәнмесез.
— Миләүшә, син дә безнең беләнме?
— Нигә, әллә алып бармас идеңме? — диде кыз шаяртып.
Егет куанычыннан нишләргә белмәде.
— Менә әйбәт булган!
Ул арада Әзһәм Шәриповның:
— Яшьләр, автобуска! — дигән яңгыравык командасы ишетелде.
Альберт авызын кыйшайтып һәм сул күзен кыса төшеп:
— Сәлам, килен, — дип куйды һәм, сорау билгесе кебек бөгелеп, Миләүшәнең кулына үрелде.
Кыз аңа «кыланчык» диде дә автобуска кереп, артка барып утырды һәм үз янына Гөлүсне дә чакырды. Егет Миләүшә белән аның иптәш кызы арасына кысылды.
Автобус кузгалып китүгә комсомол оешмасы секретаре кая һәм ни өчен баруларын, үз-үзләрен ничек тотарга кирәген яшьләрнең исенә төшерде. Аннан ул шофер янына аягүрә басты да, кулларын дирижер кебек як-якка җәебрәк алга сузды, тынычлануларын көтә башлады.
— Әйдәгез, безнең көйне.
Уртадагы урыннарның берсендә кызлар белән янәшә утырган Зиннәт баянын сызып җибәрде. Шәрипов үзе үк җыр башлады.

Забота у нас простая,
Забота наша такая...

Җырның кушымтасын дәррәү күтәреп алдылар.

И снег, и ветер,
И звезд ночной полет...
Меня мое сердце
В тревожную даль зовет.

Бертуктаусыз һаман алга омтылучы, берниндн авырлыкларга да карамыйча гел алга баручы яшьләр җыры автобусның ачык тәрәзәләреннән шәһәрнең киң урамнарына таралды.
Шәһәр читенә чыккач, икенче автобусны куып җиттеләр. Юлның бер ягында текә яр, аның артында саргылт төскә кергән урман, ә икенче ягында калкулыклар. Юл урман эченә кереп бераз баргач, кинәт кемдер шатланып кычкырып җибәрде.
— Куян! Куян!
Барысы да ул күрсәткән якка, тәрәзәләргә ябырылдылар. Соры куян, җитез, озын аякларына нык ышанып, терек-терек чаба. Яхшы йөгерешче аны куып та җитәр кебек. Шул вакыт Альберт, тиз генә тәрәзәне төшереп, авызына ике бармагын тыгып, әче итеп сызгырып җибәрде. Куянның кечкенә койрыгы гына күренеп калды. Кызлар, үзенең бу кыланышыннан канәгать булып, авызын ерып утыручы Альбертка ташландылар.
— Нигә куркыттың инде?
— Сызгыра беләсеңмени?
Альберт берни булмагандай:
— Мадемуазельләр, мин бит сезгә куянның нинди тизлек белән чабарга сәләтле икәнен генә күрсәттем, — диде. — Хәтерем ялгышмаса, ул сәгатенә илле километрга кадәр бирә ала. Кәефегезне кырган булсам, гафу үтенәм, түбәнчелек белән гафу үтенәм. Пардон.
Аннан ул озын бармаклары белән сакалын төзәткәләде дә, муенына аскан гитарасын җайлап куеп, карлыккан тавыш белән җырлап җибәрде.

Эх, бар иде яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар.
Саламнан тәртә каерып,
Чикерткә җиккән чаклар.

Яшьләр автобусны күтәрердәй булып көлеп җибәрделәр. Бу көлү Альбертны бермә-бер дәртләндерде. Ул гитара кылларына тагын да катырак суккалап, тамак төбеннән гыжлап чыккан тавыш белән джаз мотивына икенчене җырлый башлады.

Җиһаншин буги, Җиһаншин рок,
Җиһаншин кебек берәү дә юк.
Сау бул намус, сау бул кайгы,
Америкада Җиһаншин калды.
Сау бул кәләшем, Татарстан,
Негр кызына өйләнәм...

Ләкин ул җырлап бетерә алмады, Шәрипов аны шып туктатты.

— Әллә җырларга да ярамыймы? — диде Альберт, аңа ачуланып.

— Ярый, тик авызың ни сөйләгәнне колагың ишетсен.

— Блатной җырларны аңлыйсызмыни сез? Кая барсаң да — активистлар, шаярганны да аңламыйлар.

Кечкенә гәүдәле бер кыз:

— Зиннәт, «Яшь иманнәр»не уйна әле, — диде дә баянга кушылып җырлап та җибәрде.

Колхозга барып җиткәнче җырладылар, уен-көлке, шигырь, анекдот сөйләделәр. Алдагы автобустан да вакыт-вакыт җыр тавышы ишетелеп китә иде.

Сәгать тугызда «Ватан» колхозы идарәсе каршына килеп туктадылар. Болдырга брезент кожан, аягына кирза итек, башына күн бүрек кигән тәбәнәгрәк буйлы, юантык бер кеше чыкты. Колхоз рәисе булса кирәк.

— О, шефлар, килеп тә җиттегезмени? Исәнмесез, — диде ул, кулларын җәеп, трестның комсомол комитеты секретаре һәм тагын берничә егет белән исәнләште. — Машинадан төшеп маташмагыз, туп-туры кырга китәбез.

Кайсыларыдыр аны чеметтереп алырга да өлгерде.

— Арышыгыз да калмадымы? Без музейдан урак та алып килгән идек.

— Бәрәңге Яңа ел бәйрәме алдыннан алсаң бик тәмле була, диләр. Сез моңа ничек карыйсыз, иптәш председатель?

Колхоз рәисе кызарып, алдагы автобуска кереп утырды һәм шоферга юл күрсәтеп барды.

Тар гына елга аркылы салынган такта күперне чыгып, бер урамлы кечкенә авылны үттеләр, тау башына менделәр. Аннан төшеп бераз баргач, бәрәңге басуына килеп чыктылар.

Егетләр, кызлар шау-гөр килеп автобуслардан төштеләр, оеган аякларын язар өчен йөгерешеп, төрткәләшеп алдылар.

Күк йөзе карасу болытлар белән капланган. Октябрь ае икәнен сиздереп әче җил сызгыра. Ул телогрейка эченә дә керә, җылы свитерларны да капшап карый. Өске төймәләрне каптырып, шәльяулыкларны тыгызрак бәйләргә, фуражкаларны батырыбрак киярга мәҗбүр итә. Кырны шаулатып биш тәрәнле сабан таккан ике-өч трактор бер-бер артлы килә. Алар артыннан кулларына чиләк тоткан колхозчы хатыннар иелеп бәрәңге чүплиләр. Чиләкләре тулгач, алар бәрәңгене әкрен генә килүче атлы арбаларга бушаталар.

Арбасына чиләкләр төягән колхоз бригадиры да килеп җитте. Яшьләр йөгереп барып чиләкләргә ябырылдылар. Кайсыларына җитми дә калды.

Гөлүс бер чиләк эләктерде дә Миләүшә янына килде.

— Икебезгә бирәү житәрме?

— Житә, — диде резин итек кигән аякларын бер-беренә бәргәләп торучы Миләүшә.

— Туңамы?

— Печтик кенә. Әйдә чүпли башлыйк, эшләсәк җылынырбыз.

Бер читтә Галя белән Илфир дә бәрәңге чүпләргә керешкәннәр иде. Илфир Гөлүскә:

— Ну, держитесь, кем күпме җыяр икән! — дип кычкырды.

— Карап карарбыз! Миләүшә, борыннарына чиртәбезме?

— Билгеле, — диде кыз һәм Галяга кул болгады.

Телогрейка якасын күтәргән, зур козыреклы фуражкасын батырып кигән Альберт күшегүдән сорау билгесенә охшап калган.

— Мин өйләнгәч, төн кыскарды, дип әйтте ди бер егет тә. Тырышып кына эшләп, колхозга файда китерим дигән идем, чиләк житми калды.

— Йоклап йөрмәссең. Ашарга соңга калмассың әле, — диде аңа Миләүшә.

— Нигә инде шулай каты бәреләсең. Минем сүз күтәрмәвемне беләсең бит. Ярый инде, мин сиңа ачуланмыйм. Әйдә, өчәү бергә эшләрбез. Уңайлы да булыр, җиңелгә дә туры килер.

— Юк инде, егет булсаң, әнә берәр кызның чиләген ал да, күтәреп йөр, — дип, Миләүшә аны куып җибәргәндәй кызлар ягына китәргә мәҗбүр итте.

Менә эреле-ваклы бәрәңгеләр даң-доң чиләк төбенә төшә башлады. Гөлүс чиләк күтәреп бара, ә Миләүшә җәһәт-җәһәт иелеп бәрәңге чүпли. Вакыт-вакыт Гөлүс үзе дә үрелгәли.

Алар янәшәсендә Альберт бара. Егет ник кенә бер иелсен. Моны күреп, Миләүшәнең ачуы чыкты.

— Альберт әллә уклау йоткан инде, — диде ул юри кычкырып.

— Ай, телең дә телең, Миләүшә. Үзең чибәр генә...

— Анысында синең эшең юк.

— Гөлүс, тый инде кызыңны, — диде Альберт аптырагач. — Борынгылар, ир — баш, хатын — муен, дигәннәр бит.

— Ахмак,— диде Миләүшә, Гөлүскә карады.— Нигә шуңа бер сүз дә әйтмисең?

— Сөйләнсен әйдә, — диде Гөлүс кул селтәп.

Кырның икенче башыннан кулына фотоаппарат тоткан Әзһәм Шәрипов килеп чыкты.

— Егетләр, кызлар, бер-ике кадрны корбан итим әле үзегезгә. Миңа табарак карагыз.

— Була ул, оныкларыбызга житмешенче еллар комсомолларының истәлеге булыр, — дип, Альберт чиләген югары күтәрде.

Комсомол секретаре ике-өч тапкыр аппаратын чыртлатып алды.

— Кайткач, һәрберегезгә ясап бирермен.

Әзһәм фотоаппаратын япты да йөгереп барып, бер тракторга менеп утырды. Тракторчының колагына нәрсәдер әйтте. Тегесе бераз урын күчкәч, ул рычагларны үз кулына алды.

— Карагыз, безнең секретарьның эшләмәгән эше юк. Әллә трактор да йөртә инде? — диде Галя сокланып.

Илфир аңа:

— Белмәскә, элекке танкист бит ул, — диде. — Галя, туңдыңмы?

— Юк.

— Ә нишләп иреннәрең күк-күмгәк булган? Җылытыймммы?

— Кирәкми, — диде кыз оялып. — Мә, кулымны җылыт.

— Әем, — диде Илфир татарча.

— Нәрсә соң ул?

— Не буду дигәнне аңлата. Понятномы? — Ул көлеп җибәрде дә Галяның перчаткаларын салдырып кулларын учына алды.

— Жылынамы?
— Юк, — диде Галя, юри иренен турсайтып.
Егет аның кулларын башта битенә тидерде, аннан муенына шудырып төшерде.
— Ә хәзер?
— Ой, сина салкын бит!
— Алма инде, әзрәк жылынсыннар. Галя, мин кичә синең ике мәсьәләнне чишкән идем. Сездә дә безнең электротехническидагы кебек каты икән. Мин төзелеш техникумында уку чүп кенә дип йөри идем.
— Каты булмаган кая. Кышын дүрт экзамен бирәсе.
— Әле аңа кадәр контроль эшләреңне эшләп тапшыр.
— Тырышырбыз инде, — диде кыз көлеп. — Электротехникадан син булышсаң, сызымнан Гөлүс ярдәм итәм диде.
— Ә-ә, син миңа шуңа күрә Миләүшә мәсьәләләрен дә бирдеңмени?
— Әйе, билгеле. Ә математика белән төзү материаллары үзебезгә кала инде.
Алар икесе дә рәхәтләнеп көлделәр. Аннан Галя:
— Гөлүс бик башлы егет икән, — диде. — Белмим, үзе ничек институтка керә алмагандыр?
— Керер иде, — диде Илфир көрсенеп, — физикадан сынау биргәндә янындагы бер кызга булышып, үзенекен эшләп өлгерә алмаган. Мин аңа шул билгеләрең белән техникумга бар, бер елың бушка уза бит дигән идем, тыңламады. Институтка гына, ди. Әнә, әле ничек кирәк алай хәзерлек курсларына йөрергә күндердем...
Сәгать унберләрдә бәрәңге кырына салам, утын һәм вак такта кисәкләре төягән колхоз машинасы килеп туктады.
Аларны ике урынга бушатып, учаклар ягып җибәрделәр. Кызлар учак ягына караштыра башлады. Җир салкыны аякларга гына түгел, бияләй, перчатка аркылы кулларга да күчә иде. Миләүшәнең күгәрчен тәпие кебек кызарган бармакларын Гөлүс берничә тапкыр тыны белән өреп жылытты. Тагын берникадәр вакыт эшләгәч кенә Әзһәм Шәрипов яшьләрне учак янына чакыра башлады.
Борыннарга көлдә пешкән чикмәнле бәрәңге исе килеп бәрелде. Салам өстенә клеенка җәеп табын да хәстәрләгәннәр. Анда булары чыгып торган ак бодай күмәчләре, консерва банкалары, берничә кап шикәр, тоз, калай кружкалар тезелгән. Читтәрәк ике бидон тора, берсендә салкын су, икенчесендә кайнар чәй.
Альберт тиз-тиз генә кулларын юды да, кесәсеннән пәке чыгарып ипи кисә башлады, Зиннәт, Гөлүс һәм тагын берничә егет консерва банкаларын ачып куйдылар. Аннары, көл арасыннан чүпләп, пешкән бәрәңгеләрне чиләкләргә салдылар. Яшьләр түгәрәкләнеп утырды да яңак мускулларын эшләтергә керештеләр. Кулларында әвәли-әвәли бәрәңге чистарттылар. Ярмалы бәрәңге шундый тәмле, йомшак булып пешкән, дөньяда аннан да тәмле ризык юктыр кебек. Әзһәм сиздерми генә торды да бер-ике тапкыр карточкага төшереп алды. Кызлар чырчу килеп яулыкларын төзәткәли башладылар. Ләкин соң иде инде. Әзһәм аппаратын тоткан килеш икенче табынга китеп барды.
— Секретарь, аша инде, аннан төшерерсең, — диде бер кыз, ул кире килгәч.
— Мин үземне алдатмам, — диде егет.
Өреп суыта-суыта, зур кружкалардан кайнар чәй эчтеләр. Егетләр, после вкусного обеда, по закону Архимеда, дигән булып, көйрәтеп җибәрделәр. Кызлар учак тирәсендә аяк жылытты.
Төштән соң һава бөтенләй үзгәрде. Каралы-аклы болытлар бөтен күк йөзен томалап алдылар һәм, озак та үтмәде, җилләп-давыллап кар яварга тотынды. Куллар күшегә, аяклар туңа, әле генә жылы чәй эч-

сәләр дә, тәнгә суык үтә башлады. Ләкин яшьләр салкын көчәйгән саен бәрәңгене тизрәк җыйдылар. Атлар килеп өлгермәсә, өемнәргә өйделәр, кыскасы, йөгереп кенә йөрделәр. Комсомол секретаре әле берәүләр, әле икенчеләр янына килеп, уен-көлке сөйләп яшьләрнең күңелен күтәреп торды.

Трестта инженер булып эшләүче бер егет өс-башын салып атты да, кар белән тәнен ышкый башлады.

Аңа карагач, Альбертның тәне эсселе-суыклы булып китте. Каз ите чыкты. Ул чиләген калдырып, Гөлүс янына килде дә колагына:

— Әйдә, рәтлибезме? — дип дәште.

Гөлүс аңламады һәм Миләүшәгә чиләген биреп, туктады.

— Нәрсәне?

— Мин бәрәңге ташучы авыл малайлары белән сөйләштем. Кибетләре эшләми икән, сатучы авырый, ди. Моннан өч чакрымда бер татар авылы бар, диләр, шунда барып киләм. Анда булмаса, ары китәрмен.

— Берүзең, сорамыйчамы? — диде Гөлүс.

— Менә юләр, сорап кем җибәрсен. Эштән соң җылынмасак, үпкәгә салкын тидерүебез бар. Әнә бит нинди зәһәр җилли, үзәкләргә үтә. Кая, рәтең бармы?

Гөлүс як-ягына карап алды да кесәсеннән өчлек чыгарып Альбертның учына төртте.

— Фатирга бергә керербез. Мин тагын бер-ике егет белән сөйләшәм.

... Кич белән яшьләр машиналарга төялеп авылга кайттылар. Карангыда бригадир аларны берничә төркемгә бүлеп фатирга урнаштырып йөрде.

Гөлүс, Альберт һәм тагын берничә егет ялгызы гына торучы бер марҗа әбигә туры килделәр. Әбинең кәбестә ашы пешкәнче кәрт уйнап алдылар. Ниһаять, аш өлгерде. Аш алдыннан бераз кабып та куйгач, көне буе эшләп арган, туңган яшь тәннәр язылып китте, тагын көч-куәт өстәлде. Киенеп клубка юл тоттылар. Бакыр чәчле бер үсмер генә ярты стаканнан мәлҗерәп, өйдә калды.

Гөлүс Миләүшәләрнең кайсы йортка тукталганын шәйләп калган иде, алар урыннан узганда:

— Альберт, кызлар чыгар микән? — дип сорады.

— Чыкмыймы соң! Клубта утыралардыр инде, — диде Альберт һәм Гөлүсне җиңеннән тартып колагына әйтте. — Син аны бүген чамала.

— Ничек?

— Ну, кысып кара.

Бергә эшләгән, бергә яшәгән дусты булса да, Гөлүснең егеткә ачуы чыкты.

— Мин аны яратам...

— Яратсаң ни... Ул да сине яратса, тагын да җиңелрәк булыр.

Гөлүс Альбертка ташланудан үз-үзен көчкә генә тыеп калды. Бая Миләүшә, нигә килгән ул, дигәч, ялганларга туры килүе дә, комсомол секретаре Альбертның кайда икәнен сорагач, белмим, дию дә — барысы да, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, җыелган иде. Гөлүснең «шеше» тулып, менә-менә тишелергә тора иде. Аннары үзен батыррак тотарга аракы да ярдәм итә, ахры.

— Миләүшә әйбәт кыз...

Альберт аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, урам яңгыратып көлеп җибәрде.

— һа-һа-һа, әйбәт кыз! — Тавышын бераз акрынайтып өстәде.— Баксаң, бәлки кыз да түгелдер инде.

Гөлүс кинәт борылды да сул кулы белән Альбертны якасыннан әләктереп, уңы белән янагына сугып та җибәрде. Аның бу хәрәкәте егетләргә генә түгел, үзенә дә көтелмәгәндә булды һәм ул бермәлгә каушап

калды. Альберт моннан файдаланып җавапсыз калмады. Яннарында барган егетләр араламаса, бу хәл нәрсә белән бетәр иде, әйтүе кыен. Клубка барырга чыккан трест комсомол комитеты секретаре Әзһәм, Зиннәт белән башка егетләр дә килеп җиттеләр. Шәрипов артык сүз куертып тормады.

— Кайтыйк әле, мин сезнең белән икенче төрлерәк сөйләшермен. Тапканнар урынын, шефлар бит, «үрнәк күрсәтәләр».

*

* *

Җыелыш бишенче яртыга билгеләнгән иде. Шулай да барлык участоклардан да яшьләр килеп җиткәнче сәгать биш тулды.

Озын корпусның икенче катында беренче участокның кызыл почмагы урнашкан иде. Өстәлдәге газета-журналларны җыеп бер читкә куйдылар. Эскәмия һәм урындыклар җитмәгәч, кайберәүләр тәрәзә төпләренә утырды, идәнгә чүгәләде.

Әзһәм Шәрипов башта сәгатенә, аннан ишеккә карап алды да, участок комсоргларыннан исемлек барлаткач, җыелышны ачып җибәрде.

Көн тәртибен барысы да белә иде инде. Шәрипов аңлатмасыннан соң ук Гөлүсне бастырдылар.

— Мин үз гаебемне таныйм, әйе, булды андый хәл, — диде егет. — Моннан соң кабатламам.

— Булдырды ичмасам! Конкрет һәм ачык итеп әйтте, вәгъдә дә бирде, — диде Миләүшә белән янәшә утырган бер кыз һәм Гөлүскә сорау бирде. — Ә ни өчен икәнен нигә әйтмисең?

— Булды инде.

Күпме генә тырышмасыннар, Гөлүстән авылда сугышуның сәбәбен әйттерә алмадылар. Альберт та алай бик җәелеп китмәде. Бик аптыраткач, ул бөтенләй икенче сәбәп уйлап чыгарды. Аңа ышандылар да, ышанмадылар да. Гөлүс Альберттан бик канәгать иде, чөнки ул аннан сәбәбен әйтмәүне үзе үтенгән иде.

Җыелышка махсус чакырылган Яббаров:

— Яшьләр белән була торган хәл, дүрт аяклы ат та сөртенә, — диде, маңгаеннан тирен сөртеп. — Ә алар әле яшьләр бит. Әлбәттә, мин аны җәзасыз калдырырга димим, шелтәме, кисәтүме, нәрсәдер бирергә кирәк. Ләкин кайбер яшь иптәшләр әйткәнчә комсомолдан ук куарга кирәк түгел. Әз-мәз якалашкан һәрберегезне комсомолдан куа башласагыз, иртәгә монда утырырга кеше дә калмас. Ну, монысын үзаралый гына әйтүем. Ул сезнең өчен дә, безнең өчен дә иң рәхәт юл. Ә бит безгә Гөлүс кебек яшь егетләрне, кызларны чын кеше итеп, Ватаныбызга турылыклы, киләчәктә коммунизмда яшәячәк кешеләр итеп тәрбияләргә кирәк. Коммунизм төзүченең мораль кодексы безгә шулай ди. Дөресме? Шулай, иптәшләр.

Гөлүс бригадирның чыгышын ике төрле мәгънәдә аңлады. Бер яктан тормыш тәҗрибәсе булган өлкән кеше чыгышы кебек тоелса, икенче яктан үзенең, агай-эне ак-мыек, бер-беребезне какмыек, дигән фикерен алга сөрүе иде шикелле.

Бригаданың башка членнары да егетләрне яклап чыктылар. Бары Зиннәтнең сүзе генә төпле һәм яшьләр турында чын кайгыртучанлык белән сугарылган иде. Ул бригадада хезмәт дисциплинасының түбән булуы, бригада членнары арасында татулык, үзара дуслык булмавы, бердәм коллективның әле оешып җитмәве һәм шуларның чагылышы булып яшьләрнең хәтта шеф колхозга баргач та сугышулары турында ачынып сөйләде. Аның чыгышы күпләрне уйга калдырды, бүгенге җыелыш Гөлүс белән Альберт тәртибен тикшерүдән битәр, гомумән, яшьләр тормышы турында уйланырга мәҗбүр итте.

Шактый бәхәсләр, сүз куертулар, очынып-очынып кунулардан соң, егетләрнең икесенә дә каты шелтә чәпеделәр.

Җыелыш беткәнче башын аска иеп, бер кызарып, бер агарып, хафаланып утырган Миләүшә урамда Гөлүсне куып җитте.

— Гөлүс, ни өчен сугыштыгыз? Миңа гына әйт инде.

— Болай гына, егетләр арасында ни булмас.

— Гөлүс, әйт инде, югыйсә...

— Сорама, Миләүшә, барыбер әйтмим.

— Үҗәт син. Әчкәнсең... сугышкансың... Сорагач, гаебеңне яшерәсең.

— Мин гаебемне таныдым,— диде Гөлүс коры гына.

— Мин сине яхшы егет дип йөри идем, ялгышканмын... Хуш.

Кыз еларга җитешеп йөгереп китеп барды. Ә Гөлүс үз уйларына чумган иде, моңа әллә ни әһәмият бирмәде.

Ә егетләр инде үзара килешкәннәр, берни булмагандай бергә сөйләшеп кайттылар. Альберт бүлмәгә керү белән үк әйбер-караларын җыештыра башлады.

— Китәм мин, Гөлүс. Син теләсәң нишлә. Миңа ирек кирәк, тыным кысыла башлады.

Гөлүс дәшмәде. Ул әле нәрсә эшләргә икәнен хәл итмәгән иде. Әллә ничек ке..э башланды аның тормыш юлы. Ул күз алдына китергәнчә түгел. Бәлки аңа мәктәптә, семьяда дөресен сөйләмәгәннәрдер, тормышта бөтенесе дә һәрчак ал да гөл генә була дип тукып килгәннәрдер, ул тәгаен генә әйтә алмас иде. Ләкин ничек кенә булмасын, хәзергә ул үз-үзеннән дә, эшеннән дә канәгать түгел иде.

Гөлүс төне буе уйланып ятты. Әллә китәргәме? Кая? Альберт беләнме? Төпле күренми. Тагын аның кул астында булу егетне Альберт белән китүдән тыеп тора иде. Эштә — Яббаров. Нәрсә соң бу? Чын тормышмы соң бу, әллә галлюцинацияме? Шайтан белсен. Кеше нигә яши соң ул вакытта? Элек гомер буе иза чигеп тә рәхәт күрә алмыйча үлеп киткәннәр. Корчагиннар ачлы-туклы яшәп бу яңа тормышның нигезен корганнар. Аларны моңа нәрсә этәргән? Әйе, заманы шундый булган. Ә соң хәзер кеше ничек яшәргә тиеш? Гөлүснең әтисе шикелле көне-төне эшләргә, эшләргә дә, көннәрдән беркөнне... Әллә Яббаров кебек үз кадерен үзе белеп кенә, тормышын уңайлы бер җайга салып кына яшәргә тиешме? Кайда дөреслек? Кайда бәхет? Кеше бәхетле дә булырга тиештер бит. Ә үлгәч нәрсә кала? Кем сине искә алыр? Нәрсәң кала синең киләчәк буыннарга? Гомумән, кирәкме ул? Син үлгәч, исемең калса ни дә, калмаса ни — барыбер түгелмени. Бәлки, чыннан да, идеаллар, романтика буш сүздер? Газета, китап сүзе генә бит болар. Ә чын бәхет үзүзең турында кайгырту, дөнья гизү. Эч, аша, йокла рәхәтләнеп, хатынкыз... Гөлүс гомерендә беренче мәртәбә әтисен малае буларак кына түгел, ә кеше буларак, аңлы рәвештә шул кадәр сагынып исенә төшерде. Дөрес, ул аның үлеме белән килешкән. Аны чынбарлык итеп күңеленә сеңдергән иде инде. Ә хәзер әтисе белән ул ирләрчә сөйләшер, киңәшер иде. Киңәшер кешеләр юк түгел түгелен. Ләкин ата кеше кебек каты һәм гадел дә, кырыс һәм ягымлы да, һәрчак туры юлга өндәүче, синең һәр адымыңны күзәтеп, кирәк чакта ярдәм кулын сузарга әзер торучы кем бар соң бу дөньяда?!. Әллә һич булмаса кайтып абыйсы, әнисе белән киңәшеп килергәме? Юк инде...

Бу кичне Миләүшә рәхәтләнеп, бер гамьсез, тәмле төшләр күреп йоклады дию дөреслеккә туры килмәс иде, билгеле. Кыз үзенең ялгышлык эшләп ташлаганын кайта-кайта сизде, ләкин соң иде инде. Гөлүс янына кире барырга, гафу үтенмәсә дә, янында гына булырга, болай да янган йөрәгенә тоз сипмәскә була иде. Ләкин әгәр боларның барысын да алдан уйлап эшләсә, ул Миләүшә булмас иде, аңа унҗиде яшь тә булмас иде, ә... Әйе, тиле, бәхетле, җил-давыллы, ут уйнатып, очкын

чәчрәтеп, абына-сөртенә, алдын-артын уйламыйча гел алга ашкынучы яшьлек булмас иде.

Икенче көнне Гөлүс эштән соң ук төзелеш идарәсенә китте. Секретарь-машинистка хатын аның йомышын сорады да кәтәргә кушты, начальник буш түгел икән. Егет кабул итү бүлмәсендәге буш урындыкларның берсенә түнде.

Начальникка да, баш инженер кабинетына да әледән-әле сызымнар, папка тоткан кешеләр кереп-чыгып йөри. Ә Гөлүс һаман утыра. Әнә җил-җил атлап Әзһәм Шәрипов килеп керде.

— Ә, Гөлүс, сәлам, — диде ул кулын сузып.

— Исәнмесез.

— Ни хәлләр бар? Кичәгедән соң кәеф шәптән түгелме әллә?

— Ярыйсы. Китәм мин.

— Нәрсә? Син нәрсә, Гөлүс, койрыкны сыртка салмакчы буласынмыни? Бик тиз бирешкәнсең, егет, тиз. Гаризаң да әзерме?

— Бар.

Комсомол секретаре бераз уйланып торды да, кинәт башын күтәреп:

— Әйдә, минем бүлмәгә керик әле, — диде. — Бераз уйлашыйк, бәлки ашыккансындыр.

— Кермим, — диде Гөлүс тыныч кына. — Башта начальниктан гаризама кул куйдыртам. Мин барысын да уйладым инде.

— Ярар, алайса.

Шәрипов өстәлдәге телефоннан каядыр шалтыратып сөйләште дә, секретарь-машинистканың колагына нәрсәдер әйтеп, чыгып китте.

Гөлүс сәгатенә карап алды. Алты тулып килә иде. Кызыл иренле секретарь хатын да башын күтәреп стенадагы сәгатькә күз төшереп алды һәм язу машинкасының төймәләрендә бармакларын тагын да җитезрәк биетә башлады.

Начальник кабинетына кереп киткән берәү ишеген ябып бетермәде һәм эчтән сөйләшкән авазлар ишетелде. Сүз ниндидер канализацияне төзеп бетерү турында бара иде. Аның срокларын билгеләделәр һәм папкалар кыстырган ике кеше кабинеттан чыгып китте. Гөлүс кермәкче булып башын тыккан иде, анда начальниктан башка тагын берәү калганын күреп кире утырды.

Начальникның калын тавышы ачык ишектән бу бүлмәгә дә аермачык ишетелә иде.

— Юрий Прокофьевич, корпусны ун көннән монтажчыларга тапшырырга тиешбез. Беләсезме?

— Беләм. Нигә алай сорыйсыз? — диде участок начальнигы Танеев сагаеп.

— Эшләр акрын бара, шуңа сорыйм. Нигә корпус янына вак таш бушаттыгыз?

— Башка урын булмады.

— Мин бит сезгә почмакка бушатырга куштым.

— Анда машиналар керә алмый, сазлык.

Начальник тавышы тагын да көчәя төште.

— Ә корпустан читкәрәк бушатырга була иде бит.

Кулына чиләк һәм себерке тоткан җыештыручы карчык кабул итү бүлмәсенә керде. Начальник кабинетына үрелеп карады да кире чыгып китте.

Секретарь-машинистка шакылдавыннан туктады. Яңа баскан кәгазендә бозгыч белән нәрсәдер бетерде. Бераз тынып торганнан соң кабинеттан кабат начальник тавышы ишетелде.

— Аннан, Юрий Прокофьевич, бер башлаган эшне ахырынача җиткерергә кирәк. Ә синең участокта бер эш тә тәгәлләнмәгән.

— Кешеләр җитми.

— Соң синдә бит болай да кеше артык. Аларны эш белән тәэмин итәргә кирәк, эшне дөрес оештырырга. Синнән бит хәзер кешеләр кача башлый. Борһанов бригадасы, зинһар, безне моннан алыгыз, ди.

— Алар эшләргә яратмый, — диде Танеев ышанычлы тавыш белән. Ләкин Мәхмүтов аңа каршы төште.

— Юк, ялгышасың. Кешеләрне эш белән тәэмин ит, эшләгән өчен түлә. Менә шул чагында алар эшләр. Борһановны яхшы беләм мин. Ул эштән курыкмый, элек минем кул астында эшләгән иде, ләкин бушка эшли торган кеше дә түгел. Чөнки әле заманы ул түгел. Аннан, син бер эшне биш эшләмә. Эшчеләргә ничек түләрсең? Синең нәрәтләреңне уздырмабыз бит. Ә кешеләр эшләгән.

— Мин биш тапкыр эшләмим.

— Ә тимер-бетон плитәләрне ничә тапкыр урыныннан күчердең?

— Өч.

— Житмәгәнмени?!

— Прораблар әйткән сүзне тыңламый, син аңа бер эш кушасың, ә ул икенче нәрсә эшли.

— Соң участокта син бит начальник, тыңлат. Әгәр дә син мин кушканны эшләмәсәң, миңа бит синең белән саубуллашырга туры киләчәк.

Идарә башлыгы бераз тынып торды, аннары, нәрсәдер исенә төшерергә теләгән булса кирәк, ишекле-түрле йөри башлады.

— Да, тагын бер нәрсә, кичә мин сезгә корпус янындагы плитәләрне алырга кушкан идем. Алдыгызмы?

— Алдык, Ислам Бакирович.

Начальник, үз-үзен белештермичә, бөтен кабинетны яңгыратып кычкырып җибәрде.

— Тукта!

Аның тавышыннан секретарь-машинистка сискәнеп китте һәм калын журналга нидер язуыннан туктады.

— Нигә алдашасың? Бүген үзем шунда булдым. Әле алынмаганнар иде.

— Ну, дүртәү калган иде.

— Менә бит, дүртәү. Ә син алдашасың? Син мине алдыйсың, мин трест управляющиен, ә ул югарыны. Соң министрга кадәр алдакчы булып чыга түгелме соң? Ә ул кемне алдый? Халыкны. Сине, мине... Без бит синең белән бала-чага уены уйнамыйбыз, байга да эшләмибез, ә дәүләт предприятиесе төзибез. Менә шулай, Юрий Прокофьевич, әйткәнне тыңларга, кушканны эшләргә кирәк. Үзеңә буйсынганнардан да шуны таләп итәргә кирәк. Миңа башка йомышың юкмы?

— Юк.

— Ярый алайса, хәзергә хуш.

Өстенә мех якалы кыска куртка кигән Танеев кабинеттан бурлаттай кызарып чыкты. Аның маңгаенда бөрчек-бөрчек тир бөртекләре, чырае караңгы иде.

Гөлүс начальник кабинетына атлады.

— Керергә ярыймы, Ислам Бакирович?

— Керегез, — диде ишек төбеннән түргә кадәр сузылган «Т» хәрефе формасындагы өстәл артында утырган таза гәүдәле, кара чәчле Мәхмүтов.

— Әйдә, әйдә, керегез.

Ул өстәлдәге бер кәгазьгә кызыл каләм белән тамга ясады да башын күтәрде.

— Ни йомыш?

Кабинетның, яшел постау белән капланган өстәлнең зурлыгыннан бермәл югалып калган Гөлүс кыяр-кыймас кына атлап начальникка үзенең гаризасын сузды.

Мәхмүтов тиз генә күз йөртеп чыкты да стенадагы кнопка төймәсенә басты. Ишектә секретарь-машинистка пәйда булды.

— Комсомол секретарен чакырыгызчы.

— Ул хәзер үзе кереп җитәчәк, Ислам Бакирович.

— Яхшы. Утырып тор, егет, — диде начальник.

Гөлүс урындык читенә генә утырды да кабинетка күз ташлады. Түрдә Ленин портреты, ян-як стеналарда сызымнар, графиклар, китаплар белән тулы пыяла ишекле шкаф. Ишек катында кара сейф, өстәл артында һәм стена тирәли каты урындыклар тезелеп киткән. Өстәлдәге тәлинкәгә сулы графин һәм стакан куелган. Начальник алдында язу приборы, төрле төстәге, яхшы итеп очланган каләмнәр салынган кызыл савыт, пресс-папье, ак телефон, өстәл календаре, юка тышлы берничә папка һәм төрле кәгазьләр ята.

Секретарь-машинистка ишектән башын тыгып, саубуллашып кайтып китте.

Бераздан кабинетка Шәрипов килеп керде.

— Тыңлыйм, Ислам Бакирович.

— Әзһәм, бу синең егетме?

— Әйе.

— Колхозда кәмит күрсәтеп кайтучымы?

Шәрипов уңайсызланып, әкрен генә:

— Әйе, Ислам Бакирович, берсе ул, — диде.

— Икенчесе иртән булган иде инде. Кул куеп җибәрдем. Ә моның нишләтик? Егет, ә, нишләтик сине? Сиңа да, бар, дүрт ягың кыйбла, дип әле ике генә җөмлә язылган хезмәт кенәгәңне тоттырып җибәрикме? Ә? Дәшмисең? Әле гел өметсез түгел икәнсең. Шулаймы, Әзһәм?

— Шулай, Ислам Бакирович, ул әле яшь бит.

— Күреп торам, яңагында әле бала йоннары гына күперәп тора, — диде Мәхмүтов һәм тәмәке кабызды.

Ул торып тәрәзә янына килде, беравык тын торды. Аннары борылды. Аның йөзендә елмаю чагыла иде.

— Килегез әле, егетләр.

Гөлүс аптырап тәрәзә янына килде. Шәрипов Мәхмүтовның икенче ягына басты.

— Күрәсезме химкомбинатны? Бөтен илдә тиңдәше булмаячак моның. Юк, сез уйлыйсызмы үзегезнең кайда эшләвегез, нәрсә төзүегез турында? Ә бит уйларга кирәк, уйларга, егетләр. Һәр чорның үз Комсомолкасы, Магниткасы, Днепрогэсы бар. Ул турыда уйларга гына кирәк. Егет, ә син беләсеңме монда әле нәрсәләр төзеләсен? Кызганыч. Монда бит тагын берничә комплекс төзеләчәк, ә һәр комплекс үзе завод эчендә завод дигән сүз. Бу бит гигант төзелеш. Күпме техника, механизм... Әнә сора Фатыйх абыеңнан, метроны ничек төзегәннәр икән. Күрәк, кәйлә, ат... Ә ул аларны ничек сагынып, горурланып искә ала. Чөнки аның яшьлеге ул.

Мәхмүтов шулай диде дә бераз тынып калды. Аның үзенең дә яшьлеге ерак Урал таулары буенда зур заводның мәһабәт корпуслары булып торып калды. Әйе, корпусларым дип авыз тутырып әйтергә аның хакы бар. Ул бит анда беренче адымнарын кара эшче булып башлады, аннары кулына кельма, балта, вибратор да алырга, хәтта түбә ябу һөнәрен дә үзләштерергә туры килде. Техникум, институт ишекләре аңа шактый соң ачылды.

— Нәрсә, егет, җыелышта катырак бәрелделәрме әллә? Син җинел генә узар дигән идеңмени? Сабак булыр.

— Мин хаклы идем, Ислам Бакирович.

— Бик яхшы. Ә нигә бер-береңә кул күтәрергә, — диде Мәхмүтов һәм сәгатенә карап алды. — Мин дә хаклы идем. Әле Уралга барып

эшли генә башлаган чак. Бервакыт мине бер егет җилтерәтеп тотып атты, караватаастына кереп киттем. Ни өчен диген, идән себермәгән өчен. Бүлмәдә алмашлап дежур тора идек. Беркөнне Вася исемле таза, усал егет, бар, Ислам, идән себер, ди. Ә мин алдагы көнне генә дежур торган идем. Шуны әйттем, чират синеке дим. Бу, тагын себер, ди. Шулай да тыңламадым. Бу тагын әйтте дә, тыңламагач, тотып атты. Үзем унбиштә генә, ябык булсам да, буйлы идем. Карават астыннан мүкәләп чыктым, сикереп торып тегеңә баш белән... Хаклы идем, шулай да җыелышта икебезгә дә бертигез эләкте.

— Ислам Бакирович, гаризага кул куегыз.

— Китәсеңмени?

— Әйе.

— Ну-ка, утыр әле, — диде Мәхмүтов һәм үзе дә өстәл артына барып утырды. Аның йөзе кызарып чыкты. — Син нигә монда килдең? Дурака валять итәргәме, әллә эшләргәме? Без сине эшкә алдык, тулай торактан урын бирдек, һөнәргә өйрәтәбез. Әзрәк кулың эшкә йога башлагач, син — таярга. Син бит моңарчы кемнеңдер урынын билэп тордың. Бәлки ул кеше синнән йөз мәртәбә яхшырак эшләр иде. Ә без аны эшкә алмадык, чөнки син бар идең. Хәзер ул да юк, син дә китәсең. Мин иртәгә тагын бер маңка малайны алып эшкә өйрәтиммени? Әгәр ул да синең шикелле өч-дүрт айдан табан ялтыратса? Мә гаризаңны, бераз эшлә, әгәр дә кабат уйласаң килерсең? Беттеме? Бар.

Гөлүс теләр-теләмәс кенә гаризасын кулына алып чыгып китте. Шәрипов начальникка мөрәҗәгать итте.

— Ислам Бакирович, иртәгә комсомол прожекторының рейды булачак. Бер-ике иптәшне эштән азат итеп булмасмы?

— Кемнәр ул һәм кайда эшлиләр?

— Монда язылган, — диде секретарь һәм аңа бер бит кәгазь сузды.

— Икәү генәме? — дип сорады начальник кәгазьгә карап.

— Калганнары икенче сменада эшлиләр, эштән азат итү кирәк түгел.

— Ярый, эшләрбез. Тагын нәрсә?

— Бетте.

— Алайса, минем бер-ике сүзем бар. Әлеге егет кебекләр киләчәктә безнең таяныч, чын төзүчеләр булачаклар. Шуңа күрә һәрберсе өчен көрәшергә кирәк. Төрле юллар, төрле ысуллар белән. Берсен дә югалтмаска кирәк. Разгильдяйларын куарга, ә боларын сакларга, үстерергә кирәк. Аңладыңмы? Әгәр берәр ярдәм кирәк булса, кил, тартынма.

— Ярый, Ислам Бакирович, аңладым. Сау булыгыз.

— Хуш.

## XXI

Төзүчеләр төялгән машина киң болынга килеп чыкты. Сулда, таш койма артында химкомбинат, ә алда һәм уңда болын, сазлык, әрем, алабута, чикләвек куаклары.

Митинг сәгать тугызда башланды. Калкурак урынга ышкыланмаган такталардан тиз-тиз генә трибуна әмәлләнгән, микрофон куелган иде. Берничә җиңел машина, самосваллар килеп туктаган. Халык сабан туендагы кебек мыж килә. Әле һаман агыла торалар. Химкомбинатта эшләрен бетергән төзүчеләр, машиналарга төяп, эш коралларын, киемсалымнарын алып киләләр, куәтле тракторлар тәгәрмәчле, чаналы күчмә будкаларны өстери. Якында гына берничә экскаватор, бульдозерлар тык-тык эшләп утыра, такта һәм арматура өемнәре калкып тора.

Мәнә трест, төзү-монтаж идарәләренең җитәкчеләре, партия, профсоюз, комсомол работниклары, заказчы һәм субподрядчылар вәкилләре, кунаклар трибунага якынрак җыелдылар. Трестның партком секретаре микрофон янына килеп, аңа бармаклары белән чирткәләп карады. Шак-

шок бәргән тавыш ишетелде. Ул микрофонны сул кулы белән тотып, җыелган халыкка мөрәҗәгать итте.

— Иптәшләр!

Шау-шу басылды. Ара-тирә көлешкән, сөйләшкән тавышлар да тынды. Хәрәкәтләнү бетте. Барысының да дикъкате алга, трибунага юнәлгән иде.

— Иптәшләр, — дип кабатлады Алексей Степанович, — без бүген истәлекле вакыйга алдында торабыз. Бүген полиэтилен комплексының яңа чиратын төзи башлыйбыз. Бу — мактаулы һәм бик тә әһәмиятле бурыч. Чөнки ул партия һәм хөкүмәтебезнең химия промышленностен тагын да үстерү турындагы карарларын тормышка ашыруда алга таба бер адым булачак. Полиэтилен комплексының яңа чиратын төзүгә багышланган тантаналы митингны ачык дип белдерәм.

Төзүчеләр дәррәү кул чабарга тотындылар, фотохәбәрчеләр, кино һәм телевидение хезмәткәрләре эшкә кереште. Җәен тургайлар, әрләнһәм йомраннар гына хуҗа булган киң болын тагын да җанланып китте.

Аннары Алексей Степанович трест управляющие Кабышевка сүз бирде.

Управляющий күп сөйләмәде. Ул монтажчылар һәм төзүчеләр алдында торган бурычлар, аларны үтәү юлларын әйтеп үтте.

— Бу производствода, — диде ул, — бер мең биш йөз эре җиһаз монтажланачак, эстакадаларда һәм җир астында бер йөз илле километрдан артык торба салыначак. Яңа комплексны сафка бастыру өчен алтмыш биш мең кубометр җыелма һәм егерме биш мең кубометрдан артык монолит тимер-бетон таләп ителә, ике йөз илле мең кубометр җир эшләре башкарасы бар.

Управляющийның кулында кәгазь-фәләне юк иде, шулай да ул күзлеген рәтләп куйды.

— Яңа комплекс сафка басканнан соң Татарстан башкаласы полиэтилен җитештерү буенча илдә иң зур үзәккә әвереләчәк. Бу бер-ике айда гына һәм бүрек атып кына эшләнә торган эш түгел, ләкин без үтәп чыкмаслык дип тә әйтеп булмый. Чөнки без сезнең белән ялан кырда химкомбинат кебек зур гигантны аякка бастырдык инде. Мин сезгә, комсомоллар һәм яшьләргә, үзебездә үсеп чыккан алдынгы төзелеш ветераннарына нык ышанам.

Кабышевка сүзен дәвам итәргә ирек бирмәделәр, көчле алкышлар яңгырады, ул үзе дә бер-ике мәртәбә кул чабып алды. Аннан күтәренке рух, көр тавыш белән сүзен тәмамлады.

— Без полиэтилен комплексының яңа чиратын төзүне һәм файдалануга тапшыруны үз вакытында башкарып чыгарбыз, чөнки ул бөтен илебезнең престижына бәйләнгән. Үзегезгә мәгълүм, җиһазлар чит илдән сатып алына. Сезгә хезмәтегездә яңа уңышлар телим!

Янә кул чабулар булып алды. Аннары кыска-кыска гына нотыклар белән тагын берничә кеше чыкты.

Төзүчеләр арасында буталып калган Гөлүс аларны белми дә, танымый да иде. Ә менә трест комсомол комитеты секретареннан соң... сүз бишенче төзү идарәсе буяучысы Миләүшә Галиевага бирелә дигәч, егет аптырап китте. Микрофон янына озын буйлы, зәңгәр куртка кигән кыз — ул чыгып басты. Каушау һәм дулкынланудан аның битләре тагын да алсуланган. Миләүшә кулларын кая куярга белмәгәндәй маңгаена төшкән чәчен төзәтте, аннан, ярдәм көткәндәй, янында торучыларга карап алды. Бөтен батырлыгын җыеп, кесәсеннән кәгазь чыгарды да укый башлады.

— Иптәшләр! Без бүген...

Ләкин ул әле яңа гына сөйләгән ораторлар кебек остармаган иде, бер-ике сүз әйтү белән тотлыгып калды, бөтен рәсмилеге юкка чыкты. Кәгазен бөтәрләп:

— Мин үземчә генә сөйлим. Гаепкә алмагыз, яме, — диде. Халык көлешеп алды. — Безнең хыялыбыз тормышка ашты, без төзүче булдык. Бу бик зур шатлык бит, әйеме? Ә бүген әйтеп бетергесез зур куаныч: без яңа комплексның беренче нигез ташларын салабыз. Шулай булгач, ул баш-аягы белән безнеке булачак. Комплекс дүрт елда төзелеп бетәргә тиеш икән. Без менә бригада һәм идарә комсомол-яшьләре белән киңәштек тә мондый карарга килдек: әйдәгез, бу комплексны срогыннан бер ел алда, өч елда төзеп бетерәбез. Бу...

Бераз суына башлап бер читтәрәк басып торучы хәбәрчеләр, операторлар тагын хәрәкәткә килделәр, әле кул чабучы төзүчеләргә, әле трибунага борылалар.

Гөлүснең артында гына кемдер сорап куйды.

— Бу безнең Миләүшәме соң?

— Әйе, үзе бит инде.

— Кара син чәтертәнне, ничек йөрәге җитеп чыккан.

Алкышлар тынгач, Миләүшә дәвам итте.

— Бу бит шундый яхшы булачак, иптәшләр. Полиэтиленнан клеенкалар да эшлиләр бит, безнең әниләребез ничек шатланырлар, безнең кызларыбыз, улларыбыз төзегән химкомбинатта эшләгәннәр бит моны диярләр, әйеме. Балаларга да күпме уенчык булыр, аннан бит уенчыклар да ясыйлар.

Кызның бу сүзләре митингтагыларны елмаерга мәҗбүр итте. Әллә дулкынланды, әллә каушады, Миләүшә тотлыгып калды, колакларына кадәр кызарды да трибунадан йөгереп төшеп иптәш кызлары янына басты.

... Эшләрне механизацияләү идарәсенең алдынгы машинисты кызыл әләмле экскаваторына менеп утырды. Экскаватор, яхшы ат кебек, берике мәртәбә пошкырып алды да, үткен тешләре белән умырып, чокыр казырга кереште. Берничә минуттан балта осталары бу кечкенә чокырга опалубка урнаштырдылар. Яңа гына килеп туктаган самосвал бетонын җиргә агызуга, бетончы кызлар аны опалубкага тутырдылар. Трестның комсомол комитеты секретаре һәм тагын берничә яшь төзүче ике-өч метр озынлыгындагы арматура тимеренә беркетелгән щитны шунда алып килделәр.

Гөлүс, үзе дә сизмәстән, алгарак омтылды. Чөнки яшь төзүчеләр арасында Миләүшә дә бар иде. Ләкин егет аны яхшылап күрә дә алмады, аның каршына озын буйлы бер төзүче баскан иде. Комсомоллар арматура тимеренең бер башын бетонга батырдылар. Хәзер щиттагы язуны да иркенләп укырга була, анда мондый сүзләр язылган иде:

## БУ УРЫНДА ПОЛИЭТИЛЕН КОМПЛЕКСЫНЫҢ ЯҢА ЧИРАТЫ ТӨЗЕЛӘЧӘК

Яшелгә буялган фанерга тигез, эре хәрефләр белән язылган бу сүзләрне йөзләрчә авазлар кабатлый. Йөзләрчә йөрәкләр моның хыял түгел, ә тормышка ашачак олы бер максат икәнен чын күңелдән ышана иде.

Митинг бетеп, халык тарала башлагач, Гөлүс үзеннән берничә адымда гына Миләүшәне күрде. Аны иптәш кызлары сырып алган иде. Кыз да егетне шәйләде, ахры, аңа карап елмайды. Әллә Гөлүскә генә шулай тоелды инде. Үзенең дулкынлануын сиздермәс өчен ул ашыгып бригада членнары янына китеп барды. Хәзер эшкә тотынырга кирәк иде.

Юлда Гөлүс Илфир белән Галяны очратты. Исәнләште. Тегеләрнең шатлык белән балкыган йөзләренә карап: «Болар нинди бәхетле!» дип уйлап куйды. Шулай да ул күңел төшенкелегенә бирелмәде. Чөнки гомуми ташкын, яңа төзелешкә керешүгә бәйле вакыйга аны да үзэченә бөтереп алды. Алда олы эшләр көтә иде.

## Рәдиф Гатауллин

# ЙОЛДЫЗ ҖАВАП ЯЗМЫЙ

●

Әллә җырлап, әллә елап, ләкин
Сөйләде чынлап Җил:
— Һичкайчан, ди, кавыша алмыйлар
Март белән Апрель.

Менә тагын быел Мартның соңгы
Көне бит каршыда.
Ул Апрельне күрә алмый китә —
Чара юк кавышуга.

Икесе дә шундый көләч айлар,
Ә гадәтләр — башка.
Март буранлап дулый (ирләр холкы!)
Апрель — елап, таша...

Мәңге кабатлана берсен-берсе
Эзләп Март һәм Апрель.
...Әллә җырлап, әллә елап, ләкин
Сөйләде чынлап Җил.

1976

### Шәрыкча бер шигырь

Гөнаһлы теләк-уемны
Син бүген, дөнья, кичер.
Картайгач, беркөн сорармын:
— Әй, сакый, шәраб китер!

Китер чын әрем ачысын,
Тормыш җамында китер.
Китер мәхәббәт агуын —
Минем җаныма күчер.

Әй, сакый, китер дан сүзен.
Мәдхия утын китер.
Китер — абелхәят суын,
Бер генә йотым китер.

Китер, әй, теләкләремнең
Соңгысын, чиген китер:
Ахырдан һушны китәрер
Бер садә шигырь китер!

Әй, сакый! Барсын кире ал,
(Кешеңне, дөнья, кичер!)
Яшәртсә яшәртер икән
Бу шигырь... Тагын эчер?!

1977

●

Ачы сагыш миндә,
Ничә көннәр — сагыш...

Ишетелсә иде
Җырдай синең тавыш:
— Күтәр әле башың,
Рухың тот югары.
Алдыңда бит — миңа
Илтәчәк юлларың.

Мин дә киңлекләргә
Карыйм гел ымсынып.
Мин дә бит яшимен
Сүзләрең юксынып.
Мин дә бит синең күк:
Уй-моң бар миндә дә.
Ышаныч та исән
Иң кыен көндә дә!
Курыкма, сүрелмәм.
Шикләнмә, үзгәрмәм.
... Кабынып идем мин
Синең шул сүзләрдән.

Син — ерак. Ялгыш та
Юатыр бер тавыш
Килми шул... Алда — җам,
Эчендә — моң, сагыш.

1977

●

— Алдыбызда алсу шәфәкъ,
Син «сүнү» димә аны!
Шәфәкъ артында төн агы,
Дәвамы — яңа таңы... —

Сокланып сөйләдең миңа:
— Яратам Август төнен.
Кара: йолдыз яңгырлары!
Таңгача йөрик бүген.

Тавышсыз яңгыр төн ката...
— Әй, яңгыр, әйдә чылат!
Яуса да йолдыз, чылатмый,

Йолдызлар түгел елак,
Нурында коендыралар тик,
Күңелдә — яктылары...
Син туган ай — Август төне,
Уртак — җыр, шатлыклары...

Таңгача, йолдызга ашып,
Тавышың яңгырады.
— Бәхетебезгә шаһит сез,
Әй, Август яңгырлары,
Сез йолдыз яңгырлары!

1977

●

Бел: мин ул сәгатьләрдә шашкан идем!
Шатлык башымнан ук ашкан иде,—
Бәхет капкаларын ачкан идек!

Мин үземдә тойдым йөрәк барын —
Нидер дәште миндә күкрәк ярып.
Сөенечтән онытылганнарым!

Табигатькә кушылды күк тавышым.
Мин канымда сиздем елга агышын,
Җил исүен, каен шавын — барсын!

Безне әллә көтеп торганнармы,
Әй, шаулады Мари урманнары! —
Мин әйтмәдем, гөлләр әйтте: ярың!

Бел, җанымда учак яккан идем.
Битләреңә уты капкан иде.
Бәхет капкаларын ачкан идек·

...Юлдаш булып бары кайткан идек.

1977

## Кыз җыры

Ах, булсаң икән абыем бер,
Күршем, дус-иптәшем бер.
Нишләргә миңа? Уйланам...
(Йөрәгем, киңәшең бир!)

Булсаңчы гамьсез сурәт бер,
Я хыял егете бер,
Йокысыз калмас идем бит...
(Йөрәгем, үгетең бир!)

Ах, булсаң син бәйсез зат бер,
Һавада очар кош бер,
Карар да онытыр идем...
(Йөрәгем, дәш, тавыш бир!)

Ах, килсен шундый болыт бер,
Телсен күкне яшен бер,
...Ник янам? Аңлата алмыйм.
Сөймим — ник оныта алмыйм?
(Йөрәгем, киңәшең бир!)

1977

## Йолдыз җавап язмый

Аңа барып җитми әллә хатым?
Өметемме — хата?
...Кызыгызга хатлар килми торса,
Кайгырыгыз хәтта,
Габдуллаҗан абзый,
Хөббениса апа!
Саф хисләрем хатта!

Хатым бәлки барган адресатка?
Бәлки җавап язмый?
Ата-аналарча, кызыгызны
Орышсагыз ярый,
Хөббениса апа,
Габдуллаҗан абзый!
Йолдызыгыз язмый!

Хат артында Кеше тора ласа!
Җаны тулы аның
Мәхәббәте, назы.
Кызыгызга шуны аңлатыгыз,
Сезгә әйтәм,
Хөббениса апа,
Габдуллаҗан абзый!

Беләм дә бит, сезнең гаеп түгел,
Аңа карап әллә миңа җиңел,
Хөббениса апа,
Габдуллаҗан абзый!
Җанда моңнар азмы?
...Мин йолдызга язам, җавап көтәм.
Ә ул көтми. Язмый.

1977

## Госман Садә

# МӘХӘББӘТ ЕЛЫ

●

Таш өстендә үскән чаган
Җирме җитмәгән,
Әллә аны дусларымы
Якын итмәгән?

Ник үзенә сайлаган ул
Шундый язмышны?
Ә асылда таш өстендә
Үсү ялгышмы?

Килер бер көн. Чаган, туфрак
Кавышыр бергә.
Тамырлары ташны ярып
Тоташыр җиргә.

## Түрдән узыгыз

Ишек ачыла,
Ишек ябыла.

Ишегем ачык —
Түрдән үтегез!
Кайчан булмасын —
Рәхим итегез!
Җиде ятны да
Чыгармам борып.
Куңел ачарбыз
Әңгәмә корып.

Ишек ачыла,
Ишек ябыла.

Кемнәр килсә дә —
Ишегем ачык.
Дус-ишләр килү —
Үзе бер шатлык.
Керегез миңа
Узган-барганда,
Учакта әле
Утлар янганда.

## Төнге урман

Төнге урман... Йоклый карагайлар.
Ылыс аша җиргә ай бага.
Менә-менә күзем йомылыр да,
Чәчәк атар сыман абага.

Нәрсә көтәм, нәрсә өмет итәм?
Әйтерсең лә мин бер дивана.
Төн үткәрәм урман кочагында,
Ә алдымда учак, ут яна.

Абагалар чәчәк атмыйдыр да,
Тик мин, тиле, көтәм могҗиза.
Ә бит кеше, могҗизалар эзләп,
Дөнья гизә, күпме юл уза.

Бөтәрләнеп яткан җәнлек төсле,
Йоклый урман куе тынлыкта.
Һич ышанмыйм урман ешлыгында
Могҗизалар, тылсым юклыкка.

Табиплары илнең юккамыни
Җыйган тамыр, кайры, аксыргак.
Җем-җем яна үлән арасында
Зәңгәр тылсым уты — шәмсыйрак[1].

Кинәт җиргә ботак сынып төшә,
Мине уйга салып, төн уза.
Ярый әле җирдә урманнар бар,
Урман булу үзе могҗиза.

## Ут

Адәм Кеше булыр өчен,
Асылда, баксаң уйлап,
Кармаланып менгән өскә
Үсеш агачы буйлап.

Табигатьтән өстен тылсым —
Яшәү сере эзләгән.
Таш-куыштан, курка-курка,
Ут-яшенне күзләгән.

Аңлаган ул уттан башка
Дөньясының тарлыгын,
Сары ялкын телләрендә
Тылсым көче барлыгын.

Кызыктырган гел үзенә
Сүнмәс яшен камчысы.
Ут — сихри сер! Ләкин кайда
Сернең серле ачкычы?

[1] Шәмсыйрак — яктырткыч корт исеме.

Шул ачкычны табар өчен
Уйланган көн-төн бәндә.
Күргән беркөн: очкын чыга
Ташка таш бәрелгәндә.

О! Ут уйлап тапкан кеше
Үткәннәргә алмашка.
Утнең сере күктә түгел,
Гап-гади чакматашта.

Бүген исә ут кемгә дә
Тоелмыйдыр сер булып.
Онытылган хәтер сыман
Ташлар ята сибелеп.

## Мәхәббәт елы

Быелны игълан итәм:
    — Мәхәббәт елы.
Мәхәббәт нуры кунса,
    Йөрәккә җылы.

Тасмалар, чәчәк белән
    Бизим Җир шарын.
Бәхеткә юлдаш булсын
    Сайрар кошларым.

Сөюләр кавышсын да,
    Гөрләп туй узсын.
Дөньяга килгән сабый
    Назга туенсын.

Онытсын бөтенләйгә
    Толлар сагышны,
Яман сүз җәрәхәтен,
    Рәнҗү, каргышны.

Һәр йөрәк янсын дөрләп,
    Сөйсен, сөелсен.
Парлылар үткән юлга
    Йолдыз сибелсен.

Һәркемгә җитә йолдыз —
    Күңел киң булсын.
Сөюгә илткән юллар
    Бары уң булсын.

Һәр елны игълан итәм:
    — Мәхәббәт елы!
Мәхәббәт нуры кунса,
    Йөрәккә җылы.

Җырларымда, сайрар кошлар кебек,
Мин кояшны телим кочарга.
Малай чакта ләкин гамьсез булып
Ташлар ата идем кошларга.

Ә бит халык сөйгән җырчыларын
Былбылларга бары тиңләгән.
Сөенәм мин шуңа, шул ташларым
Ул кошларга ярый тимәгән.

## Илбасар

Килде, ватты, кырды барсын,
Җир белән тигезләде.
Уйлады ул: «Мәңгелеккә
Юк иттем нигезләрен».

Тик белмәде шул нигезләр
Яңадан туачагын,
Шул нигездә үскән уллар
Муенын буачагын.

Өстән карап көлде бары:
«Җимердем нигезләрен».
Тик күрмәде
Шул нигездә аналарның
Сабыен имезгәнен.

## Җил канатым Җирән кашка

Куе ялың ялкынмыни —
Балкып китә чапкан чакта.
Тоягыңнан очкын чәчри
Чакматашка баскан чакта.

Оч син, әйдә, атым минем,
Җил канатым Җирән кашка...
Кемдер әйтер: «Атын данлый».
Хәзер, имеш, заман башка.

Әйтүчеләр әйтсен, әйдә.
Арттамыни без заманнан.
Шагыйрь һәрчак чорын данлап,
Атны сөеп җырлар язган.

Заман башка... Ләкин аны
Син бит алдан тартып бардың.
Яңа чорга чыгу өчен
Буразналар, мәйдан ярдың.

Заман башка... Әмма сине
Без тиешме онытырга?!
Табигатьнең нәфис заты,
Оч син, әйдә, күчеп җырга.

Мәгъсүм Хуҗин

# ИКЕ БӨРТЕК КҮЗ ЯШЕ

хикәя



Кышын йортта көнне Хәйдәр башлый, алгы якта чәчрәтмичә-шалтыратмыйча гына юына да, газ плитәсенә чәйнек һәм кичәдән калган ашны куйгач, эчке бүлмәгә кереп, Гөлбануның җилкәсенә кагыла.

— Тор, сиңа озак йокларга ярамый, ялкауланырсың, — дип пышылдый ул хатынына. Кайсы көнне: — Миңа кирәкми андый хатын,— дип тә өсти.

Гөлбануы торгач, Хәйдәр, майкасы өстеннән тунын киеп, кулына сулы чиләкләр күтәрә дә мал-туар карарга чыга. Аның әйләнеп керүенә, тәлинкәләргә аш бүленгән, алтынсу каймалы касәләргә чәй ясалган, Хәйдәрнең алдына бер стакан катык куелган була.

— Бигрәк озак мыштырдыйсың инде, — дип каршылый аны Гөлбану. — Эшне аны кызу тотарга кирәк. Солдат җәһәтлеген кайда җуйдың соң син?

Алар бер-берсен иртәдән үк шулай куалый башлыйлар һәм кичен дә, күзләре йомылганчы, сүз дөнья-гаилә мәшәкатьләре турында бара, әле дә ярый, көндезләрен очрашмыйлар, югыйсә тагын эш турында гына сөйләшерләр иде. Хәер, бу өйрәтү-куалауларда күңелгә тия торган кытыршылыклар юк, бер-береңә эш кушу, көнлек хезмәтең белән кызыксыну инде кайчандыр әйтелгән мәхәббәт сүзләренең табигый дәвамы булып тоела аларга. Авыл тормышы шулай күнектерде Хәйдәр белән Гөлбануны — адәм рәтеннән төшеп каласың килмәсә, син инде, кем булуыңа карамыйча, ут уйнатырга тиешсең. Ә Хәйдәр белән Гөлбану дәрәҗәне тота беләләр. Гөлбану кияүгә чыкканнан бирле колхозда сыер сава, балалары яшь чагында да фермасын ташламады, ел да алдынгылар рәтендә, әлеге касәләр — аның беренче алган бүләге. Хәйдәр исә армиягә киткәнче үк комбайнга укыды, армиядә шофер иде. Кайткач, тагын комбайнда

эшләде. Язны чәчүче булып башлый да урак өстен көне-төне басуда үткәрә, аннары колхоз мастерскоенда слесарьлык итә. Аларның еллары да, хезмәтләре дә әнә шулай сиздермичә генә бер-берсенә кушылып-ялганып бара да бара.

Гөлбану тиз-тиз генә капкалады да сыер саварга чыгып китте. Хәйдәргә ашыкмаса да ярый — Әнәс белән Әлфинурны мәктәпкә озаткач кына җыена әле ул.

...Гөлбану белән беренче очрашу-танышуларына әле кайчан гына иде, хәзер инде балалары үсеп җитте, Әлфинуры дүртенчедә, Әнәсе тугызынчыда укый. Эш дигәндә балалары да әти-әнисеннән калышмыйлар: Әлфинуры фермада әнисе янында чуала. Әнәсенә комбайн җене кагылган, бишенче классны бетергәннән бирле Хәйдәрнең үзе белән уракка төшә, быел комбайнны чиратлашып йөрттеләр. Әнәс бигрәк тә беренче урын өчен тырышты, чөнки авыл хуҗалыгы идарәсе район ярышында җиңүчегә бишекле «Иж» мотоциклы бүләк итәчәк иде. Мотоциклны булырга бик хыялланды инде Әнәс. Әмма урак беткәнгә әллә кайчан, яңа ел җитеп килә, ә ярышны һаман йомгакламыйлар. Яңа ел тантаналарына калдырганнар, күрәсең. Беренчелек Хәйдәрдә түгел, Кадыйрда, имеш, дигән хәбәрләр дә йөри, белмәссең тагын. Югыйсә алай була да алмый шикелле. Кадыйр да шушы колхозныкы, тәҗрибәсе зур, Хәйдәрдән алданрак комбайн йөрткән кеше, беркайчан да алдынгылар рәтеннән төшми. Былтыр да районда малае белән ул җиңеп чыкты, Хәйдәрләр дүртенче урында калды. Ләкин быелгы урак өстендә Хәйдәр белән Әнәс, урдырган мәйдан ягыннан да, суктырган ашлык күләме белән дә, Кадыйрларны бер генә көн дә алга уздырмадылар. Ә менә хәзер, урак бетеп ярыш сүрелгәч, Кадыйр суктырган ашлыкның центнер исәбе саллырак, урдырган гектар саны ишлерәк, имеш.

Беренчелекне Кадыйрга бирсеннәр дә ди инде, Хәйдәр үзе моңа бөлки офтанмас та иде, тиң җиңүчедән җиңелүче булып калуны Әнәскә ничек аңлатып бирергә менә? Беркөнне, кичке табын янында, Хәйдәр малаена икенче урынның да әйбәт икәнлеген төшендермәкче иде дә, әңгәмә күз яше белән очланды.

— Кадыйр абый озак эшләгән кеше, беренче урынны аңа бирсәләр дә карышыр хәл юк, улым, — дип сөйли башлаган иде Хәйдәр.

Әтисенең сүзе малайның күз алдын томанландырып җибәрде, бите комачтай кызарып, авызын турсайтты да, сүзен әйтә алмыйча катып калды ул. Бераздан гына, калын иреннәрен калтырата-калтырата:

— Дөреслек буламы соң инде ул алай, әти? — диде. — Ярыш шартларында, озак эшләгән комбайнчыга түгел, быел әйбәт урдырган кешегә бирелә, диелгән ич мотоцикл... Бер ышандыргач инде...

Әнәснең күзләренә яшь бөртекләре кунды, ахры, шуларның тәгәрәвен күрсәтмәс өчен, ул, ашавыннан бүленеп, өйалдына чыгып керде.

Ике бөртек яшь...

Теге чакта Гөлбануның күзләрендә дә ике бөртек яшь җемелдәп торган иде бит. Әмма алар Әнәс күзләрендәге яшь бөртекләре кебек җанга тимәгәннәр иде. Алар якты иде, Хәйдәрнең билгесезлек томаны каплаган күңелен яктыртып җибәргәннәр иде алар.

...Саратовта хезмәт итте Хәйдәр, Гөлбануны шунда очратты. Беркөнне яшелчәләр алырга базага барган иде ул. Частька кайтырга җыенганда гына машинасының алгы тәгәрмәче сызгыруын ишетте. Моны күреп үзе дә нечкә итеп сызгырып җибәрде, сытылган тәгәр-

мәчкә аяк очы белән типте һәм кешеләр узып йөрүенә игътибар итмәстән:

— Менә нинди була икән ул — шалкан кәлҗемәсе! Мәлҗерәеп күрсәтте, әй, — дип татарчалап әйтеп салды.

— Син үзең мәлҗерәмә, солдат егет! — дип тәрттереп узды аңа бер кыз.

Хәйдәр монда татарча эндәшүгә сөенсә дә, кызга җавап кайтармады. Икенче көнне килгәч кенә, шул кызны очратып:

— Чибәр туташ, миңа тиз генә яшелчә төятеп җибәр әле,— диде.

— Мин склад мөдире түгел шул, гади эшче генә. Аннары безнең складта шалкан да юк, сиңа шалкан гына кирәк бит, — дип шаяртты чая кыз.

— Исемеңне әйтсәң, үземне дөньядагы иң бәхетле кеше итеп санар идем, чибәр туташ.

— Исемемме? Гөлбану. Я, солдат егет, бәхетле булдыңмы?

...Шаяру сүзләре очрашкан саен артты. Дөресрәге, эшнең инде шаярудан узып барганын сизеп шаярышалар иде бугай алар.

— Өйләнәм мин сиңа, Гөлбану, валлаһи, өйләнәм!

— Сиңа ышанаммы соң? Солдат бүген — монда, иртәгә — тегендә.

— Мин сиңа солдат хезмәтен тутыргач өйләнәм дә үзем белән авылга алып кайтып китәм. Тик син шәһәр кызы шул, авылны ошатырсың микән менә?

— Үзең миңа ошарга тырыш син, үзең. Яратышып яшәсәң, авылга ни булган ди!

— Алайса, килештек, Гөлбану, безгә кайтып туй ясыйбыз!

— Килешми торыйк, Хәйдәр солдат. Үзең генә кайтырсың инде, яме, юлыңны беләсең. Мин кияүгә чыгарга ашыкмыйм әле. Бәлки гомер буе ялгызым гына да яшәрмен.

— Кызык туташ икән син, әй! Ничек инде бер ялгызың яшәмәк кирәк?

— Яшим ич әле менә. Кияүгә чыгып, аерылган исеме күтәрер ниятем юк. Хәзер бит алалар да аералар. Яратмыйм кимсетелүне.

— Сине аерсам, мине җир йотачак, Гөлбану!

Гөлбану рәхәтләнеп көлде.

— Күр син аны, инде өйләнгән кебек сөйли, хатыны дип белә, әхры!

Хәйдәр бераз уңайсызланып торды да:

— Шулай шаярып кына яшәсәң икән тормышта, Гөлбану, — диде. — Кем туры килер бит әле миңа, холкы синеке кебек булса ярый да. Мин чынлап әйтәм, Гөлбану.

— Якыныма да киләсе булма! Йөрерсең аннары синең авылыңны эзләп, бала күтәреп...

Бу сүзләр ярым шаярып әйтелсә дә, Хәйдәр аларны чынга алды, аннары Гөлбануга кабат-кабат ялынырга егетлек горурлыгы да ирек бирмәде бугай. Авылына үзе генә кайтып китте. Туган якта кызлар бетмәгән, хатынның яхшымы-яманмы буласын алдан кем белгән, өлешеңә тигән көмешең тагын, дип уйлады ул.

Әмма ике айдан Саратовка кабат әйләнеп килде Хәйдәр. Хат язып искәртмәде, туры Гөлбануларның өенә барды. Ишекне Гөлбану ачты. Кыз куе чия төсле халат кигән, кыска ак алъяпкыч япкан иде. Каршысында Хәйдәр басып торуга гаҗәпләнмәде шикелле, халат изүләрен рәтләп каплады да, әллә ничек бик җиңел генә итеп:

— Килдеңме, Хәйдәр? — диде.

Гөлбану моны шундый үз итеп әйтте, аның сүзләре, сораудан бигрәк, авылга бергә кайту турында Хәйдәрнең элеккеге тәкъдименә ризалык җавабы булып ишетелде.

— Килдем, Гөлбану.

Менә шул чакта инде шатлык яшьләре ялтыраган иде Гөлбануның күзләрендә. Ә Әнәс күзләрендәге яшьләр тонык та, боек та иде...

— Әле һаман ашап бетермәдеңмени? — дип, уйларыннан бүлде Хәйдәрне Гөлбану, сөтле чиләген сепарат беркетелгән кечкенә өстәлгә куеп. — Батарейларга җылы төшер.

— Үзең кара инде бүген, Гөлбану.

— Күрче син аны! Мин ничек өлгерим ди! Сөтне аертырга кирәк. Иртәнге савуга соңга калам ич аннары.

— Синең өлгермәгән эшең юк ла. Мин мастерскойга иртәрәк бармакчы идем, балалар үзләре җыенып китәрләр. Колхоз идарәсенә дә сугылырга исәп. Мотоцикл турында хәбәр юкмы икән? — Хәйдәр кинәт рухланып, тавышын көчәйтеп өстәде. — Мотоцикл безгә булса, илла чайкап та күрсәтәбез инде, Гөлбану! Барлык механизаторларны чакырып сыйлыйм. Илла сөенер инде Әнәс! Үз хезмәтенең нәтиҗәсе бит.

— Кайгырмагызчы шуның өчен. Инде сине икенче урынга калдырсалар, сөт савуда мин колхозда беренче урынга чыгам, бу биш көндә генә мине берәү дә куып җитә алмый. Үзең әйткәндәй, минем беренчелекне юабыз! Сыер савучыларның барысын да кунак итәбез.

— Сүз минем турыда гына бармый ла! Әнәс бар. Әнәс. Аның күңеле кителмәсен иде, дим. Хәер, нигә инде күрәләтә торып гаделсезлек кылырга тиешләр ди! Безнеке була, Әнәскә була мотоцикл!..

Иртәнге савудан соң колхоз канцеляриясе янынннан — авыл уртасыннан урап кайтырга булды Гөлбану. Хәйдәрне ул шунда күрде. Ике катлы кирпеч бинаның шома баскычында, әле ишек ягына, әле урамга борылып, таптанып тора иде ире.

— Ничек булган? Бармы берәр хәбәр?

Хәйдәр тире бияләйләре белән тезенә сугып алды, Гөлбануның баш өстеннән читкә карады.

— Кадыйр абыйны җинүче иткәннәр... — диде ул, Гөлбанудан башка кеше ишетүдән курыккандай пышылдап.

— Хәерле булсын, — диде Гөлбану, күңелсез хәбәрне ишетергә алдан ук әзерләнеп килгәндәй.

— Әллә авыл хуҗалыгы идарәсенә барыргамы икән? — дип аяк очларына карап торды Хәйдәр. — Мәгълүматларның колхоздан буталып бирелүен әйтсәң, андагы җитәкчеләр мәсьәләне ачыкламый калмаслар иде.

— Йөрмәсәнә, Хәйдәр, кирәкмәс.

— Бухгалтер янына керергәме дип тә уйлыйм. Ярыш күрсәткечләрен ялгыш бутадылар микән, әллә инде Кадыйр абыйны гел җинүче ясарга теләделәр микән?

— Ике аягыңның берсен дә атламыйсың. Бүләк артыннан йөрмиләр дә, сорап та алмыйлар аны. Бухгалтер ялгышса, председатель дә саный белә. Синең урак буе беренчелекне тотуың икесенә дә сер түгел аннары.

— Әнәскә ничек аңлатырга соң?

— Алдашмыйча, дөреслекне-хаклыкны әйтәсең дә бирәсең.

...Өйалдында аяк тавышлары ишетелгәч, Хәйдәр башлаган шешәне өстәл астына яшерде, стаканны, салынганын эчеп, самавар артына куйды. Йөзенә шундук кызыллык йөгерде.

Әнәс белән Әлфинур бергә кайттылар. Әлфинур карлы итекләрен селтәп кенә салды да:

— Нинди билгеләр алганымны әйтмим, әйтмим, үзегез белегез менә! — дип такмаклагач, түр якка кабаланып кереп китте, әтиәнисенең йөзендәге үзгәрешне сизмәде.

Әнәс исә күңелсезлекне ишектән керүгә үк сизде, дөресме икән бу хәбәр, дигәндәй, әле әтисенең, әле әнисенең күзләренә сынап карады һәм, каушап, пальто төймәләрен таба алмыйча кармаланды.

Хәйдәр, Әнәс янына килеп, аның пальтосын салдырышты, Гөлбану малаеның башыннан бүреген алып чөйгә элде. Әти кеше:

— Болай бит әле, Әнәс, эшләр... — диде дә тукталып калды. Бәхетенә каршы, сүзне Гөлбану эләктереп китте:

— Улым, без... ни бит әле... Әтиең белән уйлаштык-киңәштек тә, син каршы төшмәсәң, машина алырга булдык. «Жигули»ның иң яңа маркасын. — Ул иренә күз карашы белән ым какты. — Беренче булып, әтиеңә чаклы ук син йөртеп карарсың, яме, улым...

Гөлбануның бу хәбәреннән Әнәснең йөзенә шатлык йөгерде. Хәйдәр Гөлбануның да, Әнәснең дә күзләрендә яшь бөртекләре ялтырып җемелдәвен күреп сөенде.

1977

## Илдар Юзеев

# КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН...

ДРАМА, ИКЕ КИСӘКТӘН

КАТНАШАЛАР:

Малик Бикташев — кирпеч заводында каравылчы, 55 яшьтә.
Ясминә — хатыны, сельпода бухгалтер, 47 яшьтә.
Рим — уллары, 17 яшьтә.
Халик Бакыевич Бикташев — археология отряды җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты, 57 яшьтә.
Зөлхия — тол карчык, 70 яшьтә.
Дәринә — 17 яшьтә.
Әкбәр — 55 яшьтә.
Ядкарь — шофер, 23 яшьтә.
Борынгы кеше тавышы.

Вакыйга безнең көннәрдә бара. Август ае.

Пролог

Сәхнә алды. Халик Бикташев керә.

Халик. Туган ягым!.. Бала чагым йөгереп узган кыр-болыннарым, яшьлегем давылланган тау-урманнарым, басу капкасын ачып олы юлга озаткан кадерле авылым... Саумысыз?.. Күп еллар кайталмасам да, мин сезне һәр вакыт күңелемдә йөрттем...

Ядкарь *(керә).* Их, Халик абый, килеп җиткәндә генә ватылды бит!..

Халик. Төзәтерлек түгелмени, Ядкарь?

Ядкарь. Тиз генә рәтләрлек түгел шул... Ярый, борчылмагыз, берәр машинага тагып тарттырырмын мин аны.

Халик. Без инде килеп җиттек, Ядкарь! Әнә — алдыбызда — минем туган авылым Турай! Текә ярлы елга буенда, кырыйдагы йортта, энем Малик яши!..

Ядкарь. Энегезнең өе янына китереп җиткерәлмәдем...

---

Әсәр 1976 елда язылган. Драма буенча эшләнгән спектакль Республика күчмә театры, халык театрлары сәхнәләрендә уңыш белән бара.

Халик. «Узып китмә, балам» дип, әни туктаткандыр безне. Ядкарь... Менә монда гына анын изге туфрагы. Иң беренче булып мин шунда бардым... Исән-сау кеше туган җиренә кайчанда булса бер әйләнеп кайта. Әти генә кайта алмады.

Ядкарь. Юкка гына сагынмагансыз — сез туган яклар чыннан да матур икән, Халик абый!

Халик. Мин туган җир генә түгел, Ядкарь... Бабаларыбызның бабалары туган җир...

Ядкарь. «Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары»...

Халик. Әйе, түрләре, почмаклары! Кайчак мин, борынгы бабаларыбызның эзләреннән барганда, аларның васыять авазларын, җырларын ишетәм сыман...

Ядкарь. Сезгә археолог түгел, шагыйрь буласы калган, Халик абый!

Халик. Археология — үзе бер шигърият дөньясы.. Туган җиремә аяк баскач мин тагын да ныграк тоям: борынгы бабаларыбыз безгә нидер әйтергә телидер сыман...

Башта музыка, аннан борынгы кешеләрнең сүзсез хоры ишетелә. Халик шул фонда борынгы кешеләрнең чакыруын шигырь итеп әйтә.

Халик.

Кил, диләр,
Кил безгә...
Көрәштә егылган бабаңнар
Туфракка әйләнгән нигезгә —
Кил безгә...
Җан биреп яулаңган Хаклыкның
Дәвамы булып син кил безгә!
Киләчәк көнеңә барышлый
Узганнан ваемсыз атлама,
Кил, диләр,
Кил безгә...
Бабаңнар яшәгән нигездә
Хәзинәң, табышың саклана!..

Ядкарь. Аңлыйм, Халик абый!

Халик. Ярый, мин киттем!

Ядкарь. Мин сезне авылда көтәрмен, Халик абый...

Икесе ике якка китәләр.

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Вакыт кичкә таба. Ерак фонда — Кама. Якында гына Кама кушылдыгы, текә яр. Урман.

Уңда — балкып торган өр-яңа өй, ишегалды. Өйгә «Бу йортта Бөек Ватан сугышы ветераны Малик Бикташев яши» дигән язулы такта кадакланган. Алда — тирбәлә торган кресло, эскәмия.

Сулда — Зөлхиянең кечкенә генә искергән өе. Коймасы җимерелгән. Әкбәр, Маликның өе алдында капка ясый. Алдында—эш кораллары тартмасы.

Әкбәр *(җырлый.)*

Кара дуга, пар кыңгырау
Безнең атларда гына...

Үз тавышы үзенә ошады бугай, һаман шуны кабатлый. Дәринә керәп, Әкбәрнең җырлаганын тыңлап тора. Әкбәр, Дәринәне күреп, аңа карап җырын дәвам иттерә.

Рәхәтләнеп йоклап калдым
Сабый чакларда гына...

Дәринә. Әкбәр абый, һаман бер җырны кабатлыйсыз, башка җыр белмисезмени?

Әкбәр. Моннан әйбәт җыр юктыр, валлаһи!

Дәринә. Йокларга яратасызмыни?

Ә к б ә р. Үлеп! Сабый чакта дөньяны онытып йоклаган чаклар төшләргә керә... И йоклый идем, и йоклый идем...
Д ә р и н ә. Йокы мичкәсе...
Ә к б ә р. Әгәренки йокының мичкәсе булса, шунда кереп ятар идем дә, җиде төн, җиде көн йоклар идем... Минем хыялым шул... Ә син хыялыңа ирештеңме? Кәефең шәп күренә...
Д ә р и н ә. Ирештем бугай!
Ә к б ә р. Алдылармы?
Д ә р и н ә. Алдылар бугай. Инде җавап көтәм.
Ә к б ә р. И дөрес! Син алмаслыкмы? Яшьрәк булсам, үзем алыр идем, валлаһи... Өй салыргамы?
Д ә р и н ә. Архитектор булырга.
Ә к б ә р. Минем кебек?
Д ә р и н ә. Синең кебек үк түгел, киләчәк йортлары төзергә, Әкбәр абый...
Ә к б ә р. Уз, Дәринә, таптап уз... Киләчәк синеке! Синең кебек чибәр кызлар таптап узса да, рәнҗемәм. Их-ма! Әйдә өйгә кереп берне сыздыр әле!
Д ә р и н ә. Малик абый юкмы соң?
Ә к б ә р. Юк!
Д ә р и н ә. Рим?
Ә к б ә р. Ул да юк!
Д ә р и н ә. Кайда?
Ә к б ә р. Район үзәгендә! Сагындыңмы?
Д ә р и н ә. Юк ла...
Ә к б ә р. Яратасыңмы?
Д ә р и н ә *(кызарып, ачуланып).* Юк, искә дә төшмәде!
Ә к б ә р. Бер генә яшибез! Яшь чакта яратып кал, сеңелем... Их-ма... Кара дуга, пар кыңгырау... *(Ишекне ачып.)* Кер, берне җиффәр әле... *(Дәринә өй эченә керә. Пианинода заманча бер көй уйнаганы ишетелә. Әкбәр тәрәзәне ике якка ачып куя.)* Минем көйне уйна әле! Их-ма! Кара дуга, пар кыңгырау... Юк, минекен уйнамый...

Өеннән көянтә күтәреп Зөлхия чыга.

З ө л х и я. Әкбәр улым, буламы?
Ә к б ә р. Тссс! Кил әле монда...
З ө л х и я *(тәрәзә янына килә).* Ни бар?
Ә к б ә р. Өздерә бит!
З ө л х и я. Өздерүен өздерә...
Ә к б ә р. Әмма ләкин минем көй түгел...
З ө л х и я. Син дә сөйләнеп торган буласың... Көең бармыни синең. Карачкы! *(Ул булып.)* Кара дуга, пар кыңгырау...
Ә к б ә р. Зөлхый, яратам мин сине, дөньяда ике генә әйбәт кеше бар, берсе — үзем, икенчесе — син...
З ө л х и я *(кесәсенә тыгылып).* Гомер буе эшләп, туймадың инде акчага... Бер тәңкә җитәме?
Ә к б ә р. Саранланма, чибәр тути, өстә.
З ө л х и я. Оялмыйсың да, пенсия акчасын...
Ә к б ә р. Миңа бит пенсия бирмиләр, Зөлхый. Ояты юк. Тамак ачлыктан түгел...
З ө л х и я. Эчәргә инде... Кая куясыздыр шул акчаны, умырасыз гына үзегез. Малигыңнан сора!
Ә к б ә р. Илле дә шул гадәтеңне яратмыйм, Зөлхый, бурычка барыбер бирәсең бит инде, ник шул кадәр ялындырасың...
З ө л х и я. Акча бирәм, әмма бер шарт белән: «Кара дуга, пар кыңгырау» дип тәрәзә төбемдә теңкәгә тимә!
Ә к б ә р. Була ул, Зөлхый!

З ө л х и я. Мә, тот, Әкбәр! *(Акча бирә.)*
Ә к б ә р. Аллаһе әкбәр!
Д ә р и н ә *(тәрәзәдән).* Зөлхия әби!
З ө л х и я. Әбәү! Кем шулай өздереп уйный дисәм... Дәринә кызым, кайттыңмыни! Юлың уңдымы?
Д ә р и н ә. Уңды! *(Йөгереп чыгып Зөлхияне кочаклый.)*
З ө л х и я. Ходай тәгалә бишле билгеләрен генә биреп, усал укытучыларның күзен каплап, әчми-тартмый торган, машиналы кияүгә юлыгып, балда-майда йөзеп кенә яшәргә насыйп итсен, кызым!
Ә к б ә р. Аллаһе әкбәр!
З ө л х и я. Буй-сының, килеш-килбәтең күз явын алырлык, кызым, күз тия күрмәсен... Менә бу чалбар киюең генә...
Д ә р и н ә. Мода бит, Зөлхия әби!
З ө л х и я. Мода артыннан куам дип, чалбар балагына абынып егыла күрмә тагын...
Ә к б ә р. Сез картларга ярап булмас инде. Безгә, мәсәлән, яшьләргә, кызлар чалбар кисә дә, кимәсә дә ошый!
З ө л х и я. Монысы дөрес! Яшь чакта арыш капчыгы кисәң дә килешә! Капчык эче генә буш булмасын!
Д ә р и н ә. Бир, Зөлхия әби, суга үзем барып килим. Күршеләргәме?
З ө л х и я. Колонкага бар. Суы тәмлерәк... Мин, алай булса тиз генә кибеткә барып, чәй-шикәр алып килим! Рәхәтләнеп чәй эчәрбез!
Д ә р и н ә. Ярый, Зөлхия әби, киттек! *(Көянтәне иңенә салып, китә.)*
З ө л х и я *(карап калып).* Әбәү дә инсафлы, күз генә тимәсен. «Ычкындырма асыл кошны» дип, Римга күпме тукыдым. Яңа йортка менә диган килен!
Ә к б ә р. Йорт ничек?
З ө л х и я. Курчаклар яшәрлек инде.
Ә к б ә р *(карчыкны читкәрәк тартып).* Син аныерактанрак кара. Абзыең эшләсә эшли инде... *(Сокланып.)* Шәп, чукынган, ә?
З ө л х и я. Унҗиде яшьлек кыз сыман балкый. Тәрәзәдән күзне алмый карап торам. Рәхәтен күрсеннәр инде, ходаем!
Ә к б ә р. Әкбәр салган өй бәхетле була. Шәп бит, ә?
З ө л х и я. Өй шәп! Үзеңнең генә рәт юк: ни өең, ни хатының...
Ә к б ә р. Тамак тук, өс бөтен, аллаһе әкбәр, миңа тагы ни кирәк? Акча кесәгә керә дә сәлам биреп кенә уза. Зөлхый, дөньяда ике юньле кеше бар...
З ө л х и я. ...берсе — мин, берсе — син. Тагы ни кирәк? Акча бирдем.
Ә к б ә р. Акча бар! Мәле... *(Зөлхиягә акча бирә.)* Шунда берьюлы, үзеңә чәй алганда, миңа мәй алып кил инде!
З ө л х и я. Кит аннан, ялкау дисәм, Маликка менә диган өй салып бирдең...
Ә к б ә р. Ялындырма, барыбер алып кайтасың ич...
З ө л х и я. Сиңа аракы ташырга мине кем дип белдең?! Мә акчаңны! Үзең бар бик эчәсең килсә! *(Акчаны капка баганасына куеп, чыга.)*
Ә к б ә р *(акчаны алып).* Бозылды карчыклар, бозылды... Ата ялкауга әйләнделәр... *(Балтасын алып эшкә тотына.)* Кара дуга, пар кыңгырау...
Р и м *(йөгереп керә).* Ура! Сөенче! Әкбәр!
Ә к б ә р. Кибеттә ак бармы?
Р и м. Юк!
Ә к б ә р. Лоторей оттыңмы?

Р и м. Юк!

Ә к б ә р. Гашыйк булдыңмы?

Р и м. Юк!

Ә к б ә р. Үзең әйт!

Р и м *(кулындагы таныклыкны күрсәтеп).* Менә! Кара!

Ә к б ә р. Нәрсә?

Р и м. Права!

Ә к б ә р. Нинди права?

Р и м. Машина йөртергә!

Ә к б ә р. Колхозныкынмы?

Р и м. Үземнекен! Ура!

Ә к б ә р. Ура! Рим, Дәринә кайтты!

Р и м *(исе китмичә).* Шулаймыни... Әкбәр, мин бүгеннән үз машинама утырам!

Ә к б ә р. Сөенче синнән! Йөгер кибеткә! Юабыз!

Р и м. Аны юасы юк, ялт итеп тора! Әти кайда?

Ә к б ә р. Каравылда.

Р и м. Барыймммы? Кәтимме? Нишлим?

Ә к б ә р. Кибеткә барып кил!

Р и м. Үзем дә эчмим, кешене дә эчермим! *(Креслога җәелеп утыра да тирбәлә-тирбәлә.)* Тәки хыял тормышка ашты бит, малай! *(Ирония белән.)* Синең хыялың бармы соң, Әкбәр?

Ә к б ә р. Кибеткә барасы иде — зур сөенеч!

Р и м. Минем сөенеч сиңа кагылмый! *(Атасы тавышы белән.)* Эшлә! Әй, Акбар!

Ә к б ә р. Әү?

Р и м. Игәү бир әле!

Ә к б ә р *(тартмадан игәү алып бирә).* Мә! Нишләмәк буласың?

Р и м. Анысы — минем эш! *(Джинс чалбарын игәү белән ышкырга тотына.)*

Ә к б ә р. Нишлисең?

Р и м. Игим!

Ә к б ә р. Өр-яңа чалбарны... Туздырасың ич!

Р и м. Аның тузганын көтсәң, бер ел узар... Мин аны игәп момент туздырам!

Ә к б ә р. Төшенмим, энекәш!

Р и м. Мода! Хиппиләр иске-мосһы, тузган чалбар киюне затлы киемнән артыграк күрәләр!

Ә к б ә р *(сызгырып).* Сызгыра беләсеңме, абзыкай?.. Яңаны туздырганчы, мә, минекен ал да ки!

Р и м. Их, Акбар, Акбар!.. *(Үртәп).* «Кара дуга, пар кыңгырау...» Кара дуга кебек кәкрәйгәнсез... Ә без башкача җибәрәбез. *(Җырлап.)*

Нечкә билле чибәр кызлар
Безнең Зилләрдә генә...

*(Биеп китеп, Әкбәрне көчләп танцевать иттерә.)* Бие, Әкбәр, эшләмә! Бәйрәм! Тукта! Әтидән дә сөенче алыйм! *(Чыгарга барганда, каршыга килгән Зөлхиягә һәм Дәринәгә бәрелә. Дәринәнең сулары түгелә. Зөлхияне кочаклап.)* Зөлхый, сөенче.

З ө л х и я. Ялгыштың! Менә Дәринәне кочакла!

Д ә р и н ә *(атлыгып).* Рим, мин кайттым!

Р и м. Сөенче!

З ө л х и я. Сөенче булмый ни! Сагынып беткән үзеңне! Рәхәтләнеп чүкердәшегез! *(Әкбәргә.)* Карама, картлач, яшьләрне оялтасың... Үз вакытың белән керерсең, кызым... *(Өенә кереп китә.)*

Р и м. Машина — минеке!

Д ә р и н ә *(сөенеп)*. Шулаймыни?

Р и м. Права алып кайттым. Менә! *(Күрсәтә.)* Әтине генә утыртам.

Д ә р и н ә. Мине дә йөртерсеңме, Рим?

Р и м. Юк!

Д ә р и н ә. Нигә?

Р и м. Әллә нәрсә уйларлар.

Д ә р и н ә. Ни уйларлар? Дәринә сине ярата дипме?

Р и м. Юк, башкача уйларлар.

Д ә р и н ә. Ничек?

Р и м. Рим Дәринәне ярата дип...

Д ә р и н ә. Мине яратмаганыңны барысы да беләләр. Борчылма, Рим, мин тиздән авылдан китеп югалам.

Р и м. Кердеңмени?

Д ә р и н ә. Әйе!

Р и м. Шундамы?

Д ә р и н ә. Әйе! Ни эшләргә уйлыйсың, Рим?

Р и м. Энә түгелмен, югалмам!

Д ә р и н ә. Укырга исәп юкмыни?

Р и м. Мин хәзер чылбырдан ычкынган юлбарыс! Ун ел интектем! Җиткән! Гарык булдым! Әти бармы? Бар! Әни бармы? Бар! Баян, магнитофон, телевизор, транзистор, машина — барысы да минеке! Нигә миңа вуз! Әнә, әти биш класс белеме белән дә дөньяның артына тибеп яши! Менә яши әти! Нәселгә бер профессор җиткән! Казанда Халик абыйга кердеңме? Ул ярдәм иттеме?

Д ә р и н ә. Юк! Үзем... Тиздән синең күзеңә күренмәс өчен китәм!

Р и м. Ә мин сине барыбер сагынмам!

Д ә р и н ә. Ә мин сине барыбер сагынырмын... Классташ итеп булса да... Фотоңны алып китәм...

Р и м. Кайсы? Мин биргәннеме?

Д ә р и н ә *(кесәсеннән алып фоторәсем артындагы язуны укый)*. «Дәринә, онытма, барлык юллар да Римга илтәләр».

Р и м *(кул селкеп)*. Балаларча шаяру...

Д ә р и н ә. Ә мине барлык юллар Римнан алып китәләр... *(фоторәсемне сала.)* Син машинаң белән җилдәй узып китәрсең...

Р и м. Курыкма, без очрашмабыз. Бер юлдан бармыйбыз. Син вуз тәмамларсың, кияүгә чыгарсың. Аның машинасы, дачасы булыр... О, машина! Мин киттем! Иң беренче пассажир — әти!

Нечкә билле матур кызлар
Безнең Зилләрдә генә...

Д ә р и н ә *(кычкырып кала)*. Мин беркайчан да кияүгә чыкмыйм! *(Көянтәсен күтәреп китәргә кузгала.)*

Я д к а р ь *(җимерек койма артыннан)*. Дөрес! Кияүгә чыкмагыз!

Д ә р и н ә. Ой, сез кем?

Я д к а р ь. Соңга калган юлчы. Фатирга кертмәссезме?

Д ә р и н ә. Колхозның кунак йортына барыгыз!

Я д к а р ь *(Дәринә алдына чыга, япь-яшь гүзәл Дәринәне күреп, телсез кала. Дәринә, оялып, өйгә кереп китмәкче була)*. Туктагыз... Зинһар өчен... бер генә минутка!

Д ә р и н ә. Әй лә... Мин сезне белмим...

Я д к а р ь *(һаман Дәринәне карап)*. Сез... кем?

Д ә р и н ә. Мин — Дәринә...

Я д к а р ь. Дә-ри-нә...

Д ә р и н ә. Мин китим инде... Эшем күп...

Я д к а р ь. Чиләкләрегез авыр икән... Куеп торыгыз! *(Чиләкләрне алырга үрелә, Дәринәнең күзләренә карап тагын таң кала.)* Ах, Дәри-

нә... Исемеңне кемнәр куйган, сине күреп кем туйган?.. *(Чиләкләрне алып җиргә куя.)*

Дәринә. Сез кем?

Ядкарь. Таныш булыйк: археология экспедициясе шоферы Ядкарь Сирматов.

Дәринә. Әллә Сез Халик абыйданмы?

Ядкарь. Халик абый белән!

Дәринә. Ә үзе кайда?

Ядкарь. Тиздән килеп җитәр. *(Яңа йортка карап.)* Малик Бикташев биредә яшиме?

Дәринә. Дөрес килгәнсез, Малик абый сөенер инде?

Ядкарь *(тактадагы язуны укып).* «Биредә Ватан сугышы ветераны Малик Бикташев яши»... Турай авылының кызлары гына түгел, йортлары да матур икән... Әлбәттә, Сезнең бу өйгә бәйләнешегез бар?.. Сез аның кызы?

Дәринә. Юк! *(Зөлхия йортына күрсәтеп.)* Минем менә бу өйгә генә бәйләнешем бар, Зөлхия әбинең туганы мин...

Ядкарь. Димәк, килене түгел?

Дәринә *(ояла, көлә).* Мин нинди килен булыйм, ди...

Ядкарь. Ә нигә, менә диген килен!

Дәринәкәй суга барган,
Көянтәсе, чиләге,
Көянтәсе берни түгел,
Үзе кура җиләге!

Хуҗа үзе өйдәме?

Дәринә. Ул өйдә сирәк була. Төнлә — каравылда, көндез — кешеләргә өй сала.

Ядкарь. Бу өйне дә үзе салдымы?

Дәринә. Юк, үзе түгел.

Ядкарь. Кызык, кем?

Дәринә. Әнә... Әкбәр абый.

Ядкарь *(капка ясаучы Әкбәр янына килеп).* Сез салдыгызмы?

Әкбәр. Салдым дип... бераз бар инде...

Ядкарь. Йортны әйтәм.

Әкбәр. Әйе, тегесен дә, монысын да салабыз.

Ядкарь. Кулыгыз алтын икән Сезнең, абзый! Тәрәзә челтәрләре, кәрниз нәкышләре, һичшиксез, борынгыдан. Халик абый белән ачыкларга кирәк булыр.

Әкбәр. Нәрсәне?..

Зөлхия *(тәрәзәне ачып).* Дәринә кызым, кайда югалдың?!

Дәринә. Хәзер керәм!

Зөлхия *(Ядкарьны күреп).* Яныңда чит кеше дә бар икән...

Ядкарь. Исәнмесез, Зөлхия әби! Мин чит кеше түгел!

Дәринә. Халик абый белән килгән ул!

Зөлхия. И, Халик улым кайттымыни? Әйдәгез, алайса, барыгыз да чәйгә! Керегез, балакайлар, керегез!.. Табында бары белән кунак итәрмен.

Ядкарь *(Дәринәнең көянтәсен алып).* Талдин нечкә билләрегез авыртмасын, Дәринә, бирегез үзем күтәрим... *(Көянтәне күтәреп, Дәринә артыннан өйгә кереп китә.)*

Әкбәр. «Ачыкларга кирәк»... Йөриләр шунда эч пошырып... *(Эшли.)* Кара дуга, пар кыңгырау...

Малик, аның артыннан ияреп Рим керә. Малик эш киеменнән, кулында—балта

Малик. Кем анда безнең өй каршына машинасын ташлап киткән?

Р и м. Белмим! Әти, бир инде машинаны! Туйдым матайдан! Права алгач бирәм дигән идең!

М а л и к. Акылга утыргач дидем!

Р и м. Акылга утырдым, әти! Эчмим, тартмыйм! Кызлар белән йөрмим!

М а л и к *(Әкбәргә)*. Эшләр барамы?

Ә к б ә р. Бара. Синеке?

М а л и к *(креслога килеп утыра)*. Бармый карасын! *(Римга.)* Утырдым дисең инде?

Р и м. Утырдым, әти!

М а л и к. Акылга утыру өчен ничә шарт кирәк әле?

Р и м. Өч, әти!

М а л и к. Кабатла!

Р и м. Бәхетең узып барганда йоклап калма, — сикереп торып тот!

М а л и к. Бу булды — бер!

Р и м. Бәхетең капкаңа кермичә китсә, куып җитеп тот, ычкындырма!

М а л и к. Ике!

Р и м. Бәхет эзләп еракка чапма, аяк астыңнан чыгып сызмасын!

М а л и к. Маладис!

Р и м. Бир машинаңны, әти, бензин салынган!

М а л и к. Моның белән генә бетмәде. Син кем нәселе?

Р и м. Бикташевлар нәселе!

М а л и к. Машинаны кем алып бирде?

Р и м. Син, әти, син!

М а л и к. Нигә алып бирде?

Р и м. Бәхет ычкынса куып тотар өчен... беттеме, киттеме? Урам әйләндеримме, әти?

М а л и к. Бетмәде, тагын өстим!

Р и м. Өстә!

М а л и к. Кыр казына кызыкма!

Р и м. Ярар, әти!

М а л и к. Аягыннан бәйләсәң дә күккә карый. Йорт казын тап..

Р и м. Булды, әти!

М а л и к. Кемнәр турында әйтәм — төшендеңме?

Р и м. Төшендем, әти, кызлар турында әйтәсең... Кирәге юк!

М а л и к. Берсен тап... Ашыкмыйча тамга салып куй, кирәге чыгар!

Р и м. Мин кызлар эзләмим, кызлар мине эзли. Урамга чыгып бер сызгырсам — йөз кыз йөгереп килә!..

М а л и к. Син сызгыра белмисең ич, хәчтерүш!

Р и м. Тормыш өйрәтер әле...

М а л и к. Әкбәр, бу малайны синең белән икәүләп, балта тотарга, өй салырга, кирпеч заводын каравылларга өйрәттек. Эшкә кулы ятамы? Мине алыштыра аламы?

Ә к б ә р. Малай шәп, бер генә кимчелеге бар: ата ялкау! Каравылга килеп ятарга өйрәттем. Безне дә уздыра!

М а л и к. Сызгырырга өйрәт әле шул молокососны!

Ә к б ә р. Була ул! *(Сызгырып җибәрә).*

Тәрәзәдән Зөлхия карый.

Сиздеңме?

Р и м. Машинаны бирдеңме, әти?

М а л и к. Бикташевлар нәселендә ялкаулар юк, шул җөмләне мәңге онытмасаң — бирәм!

Р и м. Онытмам, әти!

М а л и к. Халик абыең әнә профессор! Әтиең дә, беләсең, төшеп калганнардан түгел...

Э к б ә р. Халик, дигәннән, монда бер кеше йөри...

М а л и к. Кем? Нинди кеше?

Э к б ә р. Халиктан килдем дигән була.

М а л и к. Халиктан?..

Э к б ә р. Халик та монда ди...

М а л и к. Халик?

Р и м. Ура! Халик абый кайткан! Әти, машина!..

М а л и к. Атаңның баш сөяге, нигә аны әйтми торасың? Халик?! Чынмы? Кайда ул?

Э к б ә р. Хәзер монда килә ди.

М а л и к. Менә бу сөенеч!..

Р и м. Машина белән барып алыйммы?

М а л и к. Бар, оч! Эзләп тап! *(Рим йөгереп чыга.)* Халик кайткан! Нәрсә карап торасыз? Чаң сук, бөтен авыл ишетсен! *(Сызгырырга тырыша, булдыра алмый.)* Яшьтәш, сызгыр! *(Экбәр сызгырып җибәрә.)*

Я с м и н ә *(ашыгып кереп)*. Атасы ни булды?

М а л и к. Халик кайткан, тиз генә — базга!

Я с м и н ә. Халик?! Атасы, үзем генә өлгерермен микән?

М а л и к. Экбәр! Сызгыр! *(Экбәр сызгыра, Зөлхия өеннән Дәринә, Ядкарь һәм Зөлхия йөгереп чыгалар.)*

З ө л х и я. Кибеткә индийский чәй кайтканмы әллә?

Я с м и н ә. Оятка калабыз инде, берни әзер түгел...

З ө л х и я. Ни булды, балалар?

М а л и к. Халик кайткан! Ясминә!

Я с м и н ә. Әү, атасы!..

М а л и к. Өстәлгә тез бөтенесен! Кара аны, оятка калырлык булмасын!

Я с м и н ә. Ярый, әтисе, син дигәнчә булыр!

М а л и к. Зөлхый!

З ө л х и я. Тыңлыйм, Малик улым!

М а л и к. Ясминәгә ярдәмгә! Өй ялт итеп торсын!

З ө л х и я. Ярый, улым! *(Чыга.)*

М а л и к. Дәринә!

Д ә р и н ә, аның артыннан Я д к а р ь керәләр.

Д ә р и н ә. Исәнмесез, Малик абый?

Я д к а р ь. Исәнмесез? *(Малик игътибарсыз калдыра.)*

М а л и к *(Дәринәгә)*. Исән! Кайттыңмы? Тавык тот! Бер әтәч, ун тавык! Йөгер! Тукта, башта өйгә кереп, пианиноның тузанын сөрт!

Д ә р и н ә. Очтым! *(Өйгә кереп китә.)*

М а л и к. Экбәр!

Э к б ә р. Тыңлыйм!

М а л и к. Пычагың кайралганмы?

Э к б ә р. Кайралган!

М а л и к. Ун тавыкны — кых!

Э к б ә р. Була ул! *(Чыга.)*

М а л и к *(Ядкарьга)*. Әй, син! Сез кем!

Я д к а р ь. Исәнмесез, Малик Бакыевич! Таныш булыйк — Халик Бакыевичның шоферы Ядкарь Сирматов! *(Кулын суза.)*

М а л и к *(күрешә)*. Теге әби патша арбасы синекемени? Исәнме, энекәш! Кайда соң үзе?

Я д к а р ь. Әниегез каберенә китте.

М а л и к. Шулаймы?.. Халик абыең белән миндә кунак булыр-

сың. Кайткач, минем ничек яшәгәнемне академикларга сөйлә, аңлашылдымы!

Я д к а р ь. Тырышырмын.

М а л и к. Бар, өйдән паласны алып чык!

Я д к а р ь. Ә сез аны үзегез алып чыгыгыз!

М а л и к. Ә? Егет, кунак булсаң тыйнак бул! *(Өйдән паласны алып чыга.)* Күрсен Халик энесенең дә дәрәҗәсен... *(Паласны җәя башлый.)* Беренче тапкыр җәелә! Иранский!

Я д к а р ь. Мондый келәмнәр җәеп элек патшаны гына каршылаганнар!

М а л и к. Халик патшадан киммени, ә?

Я д к а р ь. Ким.

М а л и к. Нәрсәсе!

Я д к а р ь. Халик абый җәяү дә йөри, ә патшалар җәяү йөри торган җиргә генә җәяү барганнар.

М а л и к. Минем малай анда да мотоциклда бара. Баласы шулай, ә атасы? Бикташевлар алдында патша ни, министр ни... Син өенең эчен кереп күр... Аннан соң болай кукыраеп тормассың!

Я д к а р ь. Май чүлмәге — тышыннан билгеле!

М а л и к. Әйдә, синең дә бер ярдәмең тисен. Өстәлне алып чыгыйк әле монда...

Я д к а р ь. Анысы — мөмкин... *(Өйгә кереп өстәл алып чыгалар.)*

М а л и к. Мондый өстәл күргәнең бармы?

Я д к а р ь. Юк.

М а л и к. Венский. Первый сорт! Авылда миндә генә!

Я д к а р ь *(өстәлнең астын карап).* Чыннан да заграничный икән... Монда «Шумерля» печате сугылган...

М а л и к. Ә? Шумерля? Утыртканнар, чукынганнар. Ярар, соңыннан мунчага куярсың. Энекәш, өй ничек?

Я д к а р ь. Һич тә моны өй димәссең, цивилизация! Бүгенге культура.

М а л и к *(өстәлне җыеп).* Культураның түбәсенә, түренә менеп, аяк салындырып утырам, төкерсәм — түбәндә калганның баш түбәсенә төшәр! Бер наданы булса — боларны алла бирде дияр иде! Әйтәм ич — Маликта юк нәрсә юк! Тырышалар, алышалмыйлар Малик белән! Хатын!

Я с м и н ә *(йөгереп чыга).* Әү, Малик!

М а л и к. Нишлисең анда?

Я с м и н ә. Токмач кисәбез!

М а л и к. Кунак алдында авызыңны турсайтып утырма! Миңа — синең хуҗаң — сельпо председателе түгел, академик килә!

Я д к а р ь *(тәрәзәдән Дәринәне күреп).* Гафу итегез, мин сезнең өйдә том-том китаплар күрдем. Карарга рөхсәттер?

Өйгә кереп китә.

М а л и к *(Ясминәгә).* Мин әйткәнне аңладыңмы?

Я с м и н ә. Нишлим соң, Малик?

М а л и к. Елмай.

Я с м и н ә. Елмаерга вакыт юк бит, Малик...

М а л и к. Кайчандыр авылда иң чибәр кыз булганыңны онытма...

Я с м и н ә. Искә төшерүең өчен рәхмәт.

М а л и к. Төшендеңме?!

Я с м и н ә. Тырышырмын, Малик.

М а л и к. Эшеңдә бул! *(Ясминә чыга.)* Зөлхый!

З ө л х и я *(кереп).* Нишлим, Малик улым?

М а л и к. Мин синең улың түгел... Кунак алдында ул сүзеңне әйтмә.

З ө л х и я. Улым кебек күргәнгә әйтәм инде, кем, Малигулла... Камилем белән бергә киттегез, бигрәк тә авыр ич ана кешегә, син кайттың балкып... ул калды ятып, әзмәвердәй яшь егет... *(Күз яшьләрен сөртә.)*

М а л и к. Каян чыга бу кадәр күз яше... утыз ел елыйсың инде... Узган эшкә салават. Син нәрсә, Зөлхый карчык, күпсенәсеңме әллә безнең тормышны?

З ө л х и я. Алла сакласын! Малик улым, сөенепләр бетә алмыйм тормышыгызга... Халик та кайткач, күңелем тулып китте, ачулана күрмә...

М а л и к. Кунак алдында узганнарны искә төшереп, балавыз сыгып утырма, ишеттеме колагың? Бүген безнең өйдә бәйрәм, сизденме, Зөлхый карчык?!

З ө л х и я. Бәйрәмдә кайгы качып тора, ди...

М а л и к. Кара кайгыңны оныт та ак мунча як!

З ө л х и я. Була ул, Малик, кайгымны мунчага ягармын... Сезнең мунча — оҗмах инде, суы үзендә, уты үзендә!

М а л и к. Төтене бөтен авылга күренерлек итеп як!

З ө л х и я. Күренер, алла боерса, мондый мунча — синдә генә...

М а л и к. Дошманнарның күзенә кереп, яшь чыксын! Көнләшүләреннән шартласыннар!

З ө л х и я. Фәрештәнең «амин» дигән чагына туры килсә, шартларлар...

М а л и к. Менә сиңа бер тәңкә акча... Дәринә сыра алып кайтсын... ташка сибәргә... Ясминәгә әйт — мунчаның тәрәзә төбенә быелгы юкә балы куйсын — сырага болгатып ташка тондырырлар чабынганда...

З ө л х и я. Маликкаем, шунда миңа да бер калак кына юкә балы бирмәссеңме, авыруым кузгалып тора, Гайникамал карчык...

М а л и к. Калса — алырсың... Бар!

З ө л х и я. Рәхмәт төшсен, балам... *(Чыгарга бара.)*

М а л и к. Тукта, бу атнага сөт өчен түләдеңме?

З ө л х и я. Чәй-шикәр алам дип, акчам бетеп китте, Малик, пенсиям килсен инде...

М а л и к. Бурычка алып түлә, мин төгәллек яратам! Төшендеңме? Кешедә аласым булса, йоклый алмый интегәм.

З ө л х и я. Төшендем.

М а л и к. Сыраның сдачасын үземә бирерсең. Бар. Дәрләт мунчаны! «Ах, Малик мунчасы, көн дә шулай булсачы!» диярлек булсын!

З ө л х и я. Диярләр, язган булса! *(Чыга.)*

М а л и к *(урамда машина тавышын ишетеп)*. Киләләр! Иллә дә маладис! Сигнал бир! Көндез дип торма! Фараларын кабыз! *(Сигнал.)* Әнә шулай! *(Үзе рульгә утырган кебек кылана.)* Кызлар бер чакырымнан юл бирсен, казларның йоннары очсын! Кермә! Тагын бер ура! *(Тәрәзәдән Ядкарьга.)* Шофер!

Я д к а р ь *(тәрәзәдән)*. Ни боерасыз?

М а л и к. Әнә магнитофонны ал... берәр мировой көй җибәр! Яңгырасын авыл! Бүген — Бикташевлар көне!

Ядкарь, магнитофонны тәрәзә төбенә куеп, музыка җибәрә. Х а л и к, аның артыннан Р и м керә, Ядкарь музыканы туктата, үзе Дәринә артыннан өйдән чыга. Дәринә китә. Ике туган беркадәр вакыт, бер-берсенә карап торалар.

Х а л и к. Малик!

М а л и к. Халик *(кочаклашалар)*.

Р и м. Әти, машина шәп! Бер дигән!

Х а л и к. Син үзгәрмәгәнсең!

М а л и к. Син дә — танырлык!

Х а л и к. Күпме җилләр исте, күпме сулар акты... *(Пауза.)* Ә кайчан гына әле без шушы өстәл буе гына малайлар идек... *(Малай чактагыча итеп.)* Малик — балык... Малик — балык...

М а л и к *(уенны кабул итеп).* Минме балык?

Х а л и к. Син — балык!

М а л и к. Тагын бер тапкыр әйтсәң, кирәгеңне бирәм... Абый дип тормам! Мин синнән көчле!

Х а л и к. Малик — балык! *(Кача, аны Малик куып йөри.)*

М а л и к. Минме — балык?

Х а л и к. Молекула!

М а л и к. Минме — молекула? *(Көрәшә башлый.)*

Х а л и к. Ә син шулаймы?! *(Алыша башлыйлар. Уенны аңламый калган Рим белән Ядкарь аларны аерырга тырышалар.)*

Р и м. Әти, нишлисең син, ник сугышасың?

Я д к а р ь. Халик Бакыевич... ни булды?

Х а л и к. Без малай чакларны искә төшердек!

Я д к а р ь. Ул чакта кем җиңә иде, Халик Бакыевич?

Р и м. Әти булмый кем булсын? Дөресме, әти?

М а л и к. Үзеннән сорагыз!

Х а л и к. Кечкенә булса да, ул абыйсын җиңә иде.

Р и м. Халик абый, машина ничек, шәпме?

Х а л и к. Машинаң да, үзең дә шәп! *(Маликка)* Римны башта танымадым. Сине куып җиткән!

М а л и к. Егет бер дигән!

Х а л и к. Әйе, замана алар кулына күчә...

М а л и к. Бирешергә исәп юк, замана безнең кулда әле!

Р и м. Әти! Урам әйләнеп килим!

М а л и к. Бар, улым, бар! Дөньяны әйлән!

Р и м. Очтым! *(Чыга.)*

М а л и к. Я, өй ничек?

Х а л и к. Сарай.

М а л и к. Син аның эчен күр!

Я д к а р ь. Ул андагы китап — ни генә юк!

М а л и к. Өй эчен бизәргә алдым. Дәринәдән башка укучы гына юк!

Х а л и к. Әйдә, алайса, эчен дә күрик!

М а л и к. Рәхим ит! Кара, күр!

**Малик белән Халик өйгә керәләр. Ядкарь ачык тәрәзәдән өй эченә карый: Дәринәне эзли. Кулына эскәтер тотып, өйдән Дәринә чыга. Аның ашъяулык җәйгәнен Ядкарь күзәтеп тора.**

Д ә р и н ә. Карамагыз шулай...

Я д к а р ь. Сине күрү белән, күңелгә җыр килә, Дәринә...

Өстәлгә эскәтер җәйдем
Чукларын салындырып,
Йөрәгемнең уртасында
Торасың ялындырып.

Д ә р и н ә. Сез борынгы җырлар яратасыз, ахры... Ә мин заман җырларына гашыйк! *(Көйли.)*

Я д к а р ь. Күпме җырласаң да искерми торган җырлар бар, Дәринә...

Д ә р и н ә. Ә мин мәңге искерми торган йортлар төзү турында хыялланам. Төзелеш институтына имтиханнар бирдем.

Я д к а р ь. Студент булуыгыз белән котлыйм, Дәринә! Димәк, без әле Казанда очрашырбыз! Минем дә хыялым бар...

Д ә р и н ә. Малик абыйлар кебек барысын да булдырасыгыз киләме? Кызыгасызмы, Ядкарь?

Я д к а р ь. Вакыты җиткәч барысы да булыр, Дәринә! Минем максат әлегә башкачарак — акылны баетасы иде!

Д ә р и н ә. Сез дә институтка керәсезме әллә?

Я д к а р ь. Киләсе елга! Сине куып җитәсе булмаса да, артта калмаска исәп.

Д ә р и н ә. Тырышып карагыз! Ой, чыгалар!.. *(Дәринә китә.)*

Малик белән Халик өйдән чыгалар.

М а л и к. Күрдеңме?

Х а л и к. Сезнең өчен бик шатмын, Малик! Котлыйм!

М а л и к. Синең ничә ел кайтканың юк әле?

Х а л и к. Ун елга якын...

М а л и к. Халик, озаккамы?

Х а л и к. Археология экспедициясе белән күрше районга килдек. Казу эшләре алып барабыз. Төп базабыз — Борнашта. Бер генә кечкә туган нигезгә кайтып килергә ниятләдем.

М а л и к. Керми китсәң — борылып та карамый идем!

Х а л и к. Я, тормышларың ничек, Малик?

М а л и к. Тормыш бит ул кая борсаң шунда борыла, Халик!

Х а л и к. Машина да алып җибәргәнсез...

М а л и к. Сатсалар, самолетын алырга була! Янсын председательнең йөрәге.

Х а л и к *(көлеп)*. Бик ачуыңны китердеме председатель?

М а л и к. Һәр эшкә аяк чалды... Аягы булмауга карамастан... Ярты бакчаны кисеп алды. Ветеран, имеш: минем өйгә дә энә балалар язу чәпеп киткәннәр — сугыш ветераны дип. Күрдеңме? Юкка якалашты Малик белән! Бикташевлар баш бирә торганнардан түгел! Председательнең өен кара да, минекен! Ничек, ә!?

Х а л и к. Өегез котлы булсын, Малик! Чыннан да — авылда иң матур өй синеке! Үзең салдыңмы?

М а л и к. Әкбәр эше! Оста булсаң да үз өеңне үзең салма, башка остадан салдыр, диләр бит.

Х а л и к. Әллә син ул һөнәрне ташладыңмы?

М а л и к. Башкаларга Әкбәр белән икәү салабыз. Мине беләсең, эшне кызу тотарга яратам, ә Әкбәр ташбака сыман бара, озак эшләп җан ачуларымны чыгара.

Х а л и к. Синең өйне дә озак эшләдеме?

М а л и к. Озак, но ләкин дә нерва бозылмады, җиренә җиткереп эшләде... Әмма ачуны китерә торган бер ягы бар Әкбәрнең...

Х а л и к. Бу — кызык...

М а л и к. Өй салган өчен акча алмый...

Х а л и к. Алмый?

М а л и к. Алмый и вәссәлам!

Х а л и к. Бәлки, азсынгандыр?

М а л и к. Мин бәядән тора торган зат түгел... Тотылмаган өр-яңа шытырдап торган йөзлекләрне менә шушы ялтырап торган өстәлгә ыргыттым — мә, Әкбәр, санамый гына ал!

Х а л и к. Алмады!?

Я д к а р ь. Чынлапмы?

М а л и к. Алмады... И алмый!.. Ялынып та карадым, сүктем дә, үз туксаны туксан.

Х а л и к. Хезмәте өчен акча алудан баш тартуны Әкбәр үзе ничек аңлата?

М а л и к. Мин дуслардан акча алмыйм, ди...

Я д к а р ь. Акчасы күптер аның...

М а л и к. Акчасы күп булса, мин моны әйтеп тә тормыйм! Хикмәт тә шунда — акчаны без күрәвен күрибез, Әкбәр акчасын күрми дә кала, алдан ук муеннан бурычка баткан була... Салып бетерә акчасын... Өендә казыгы да юк! Монда үзе... Миңа капка ясый...

Х а л и к. Тагын бушлай?

М а л и к. Синең килү әйбәт булды әле... Сине тыңлап акчаны алмасмы? Зөлхыйдән бер тәңкә алса алыр, миннән — бурычка алмас, миннән аракы эчмәс! Тукта, нишләп әле без кунакны сүз белән сыйлыйбыз...

Х а л и к. Ә Ясминә нигә күренми?

М а л и к. Әй, кызлар!

Самавар, чынаяклар, чәйнек күтәреп Я с м и н ә, З ө л х и я керәләр.

Менә Халик абзагызның сезне күрәсе килә. Исәнләшегез! *(Хатынкызлар оялчан гына исәнләшәләр.)*

Х а л и к *(Ясминә белән исәнләшеп).* О, Ясминә, бөтенләй яшь кызлар кебек!

М а л и к. Тамагы — тук, өсте — бөтен, кайгысы юк...

Х а л и к. Зөлхый апа, сезне дә таныдым!

З ө л х и я. Тануыңа мең рәхмәт. Халик бәгърем, атагыз Бакый мәрхүм дә бер чакрымнан танып хәл сораша иде...

М а л и к. Бик бетеренде карчык, хәлсезләнде... Ялгызы бит... Без ярдәм итәбез инде аз-маз... Сыеры да юк...

З ө л х и я. Әй, онытып та торам, Малигулла, сездән алган сөткә узган атна өчен түләмәгән бит... Бик зур рәхмәт, мә, санап ал, син бит төгәл кеше, Дәринә кызым коткарды, рәхмәт төшкере, менә өч сум... унике тиен... *(Барысы да уңайсызланалар.)*

М а л и к. Зөлхый карчык, вакыты түгел!

Я с м и н ә *(төзәтергә теләп).* Зөлхый, синнән кем акча сорый инде. *(Өстәл тирәсендә кайнаша, зиннәтле савыт-саба, эчемлек, шәраб алып чыга.)*

З ө л х ы й *(акчаны өстәлгә куеп).* Алай димәгез, күршеләр, акча сездән артмый ул... Аллага шөкер, ялгыз башка акча җитә...

М а л и к *(ачулы).* Зөлхый!

Х а л и к *(уңайсыз хәлне төзәтү нияте белән).* Зөлхый апа, коега һаман безгә... *(төзәтә)* монда йөрисезме?

З ө л х и я. Атагыз мәрхүмнең коесы урамда булыр ие, күршетирә, үткән-сүткән, талчыккан-сусаган эчеп китәр ие... Ширбәт ие, ширбәт... Ерак булса да, колонкага барам, әллә нишләп Малигулла коесының суы каты...

М а л и к *(чыгырыннан чыгып).* Туктыйсыңмы-юкмы син, Зөлхый карчык?

З ө л х и я. Зөлхый түгел, Зөлхия мин. Туктадым, бетте!

Х а л и к. Гафу итегез, Зөлхия апа...

М а л и к. Бар, мунча ягуыңны бел!

З ө л х и я. Мунча ягылган, Малигулла, төтене бөтен районга күренә!

М а л и к. Юлыңа ак җәймә!

Х а л и к. Уңайсыз килеп чыкты, Зөлхия апаны өстәл янына чакырырга кирәк иде...

М а л и к. Аларның заманы узган, Халик! Ташла әле шуны! Әйдәгез өстәлгә, монда утырабыз!!. Бөтен авыл күрсен! *(Өстәлгә эчемлек тезеп.)* Иң кадерле кунак өчен алынган... Син кайсын эчәсең, Халик? Әрмән коньягы? Француз коньягы? Куба ромы?

Х а л и к. Очрашу хөрмәтенә әнә... цинандали эчәрмен...

М а л и к. Юк, биш елга бер тапкыр очрашып... су эчеп утырмассың инде... *(Коньяк сала.)* Бу егетең эчәме?

Х а л и к. Ядкарь, утыр...

Я д к а р ь *(утырып)*. Бары тик цинандали! Башка берни дә кирәкми!

М а л и к. Эчкән кешене җенем сөйми, үзем дә эчмим! Әмма да ләкин бүген шушындый очрашуда академик туганым белән...

Х а л и к. Академик түгел, Фәннәр академиясенең сотрудникы белән...

М а л и к. Барыбер! Тот, Халик! *(Ядкарьга.)* Мә, энекәш... Ун тавык пешә торсын, без салыйк!

Х а л и к. Туганнар белән очрашу хөрмәтенә!

М а л и к. Яшик без! *(Тост күтәрәләр.)*

Х а л и к. Тукта әле, нигә әле без хөрмәтле хатын-кызларны табынга чакырмыйбыз?

М а л и к. Хатын-кызны алыштыра торган берәр машина уйлап таба алмыйсыз, галим дуслар, шулай булса, кызларыбыз өстәлебезнең бизәге булып кына утырырлар иде...

Я д к а р ь. Халик Бакыевич, патриархат?

М а л и к. Ярый, бүген сезнеңчә булсын!.. *(Табын тирәсендә йөгереп йөрүче Ясминәгә.)* Утыр, карчык! Бу венский өстәлгә...

Я д к а р ь *(төзәтеп)*. Шумерлинский...

М а л и к *(Ядкарьга)*. Тик тор! *(Ясминәгә)*... утырырга синең полный хакың бар! Сельпода бухгалтер, акчаны тиенenә кадәр өйгә алып кайта, хатын бер дигән!..

Я с м и н ә. Минем ирем, ичмасам, кунаклар алдында мактый белә...

Х а л и к. Ялгышмасам, Ясминә матур итеп җырлый торган иде гез...

Я с м и н ә. Юк, юк, Халик абый, биш былтыр инде җырлаганым юк... Оялмыйча...

М а л и к. Чыннан да, карчык, син элек җырлый идең түгелме? *(Халикка.)* Хәтерең шәп икән! *(Ясминәгә.)* Әйдә, Казан профессорлары алдында берне җиффәр әле булмаса... Шәһәрчә! Пианинога кушылып!

Х а л и к. Пианиногыз да бармыни?

М а л и к. Миндә юк нәрсә юк! Хромка, баян! Шуйский, Тульский! Аларның инде заманы узган! Пианино! Немецкий! *(Баш бармагын күрсәтеп.)* Менә!

Х а л и к. Аларда кем... Рим уйный торгандыр инде?

М а л и к. Кагылганы да юк!

Х а л и к. Кем уйный соң?

М а л и к. Без өйдә юкта Дәринә уйный. Шулай йөри-йөри остарып бара кыз... *(Кычкырып.)* Дәринә!

Д ә р и н ә керә.

Өйгә кереп немецкий пианиноның көмеш телләренә басып кына, Ясминә апаңны җырлат әле...

Д ә р и н ә. Исәнмесез, Халик абый. *(Халик исәнләшә.)* Ясминә апа, нинди көй җырлыйсың?

Я с м и н ә. Миңаияр...

Д ә р и н ә өйгә керә. Ясминә җырлаганда пианинода уйный. Ядкарь җырчыны түгел, өй эченнән ишетелгән музыканы бирелеп тыңлый.

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам,
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан.
Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам,
Хыялыма китәр идем

Кыр казлары артыннан.
Кыр казлары артыннан,
Китәр идем, тартынам;
Үз-үземне бәйләгәнмен
Хыялым канатыннан.

Тын булып кала. Дәринә чыга, Ядкарь аның янына килә.

Я д к а р ь. Искиткеч!

Х а л и к. Әйбәт җырладыгыз, Ясминә, рәхмәт... Дәринә, сезгә дә...

Д ә р и н ә. Үзегезгә рәхмәт... *(Чыга. Аның артыннан Ядкарь чыга.)*

М а л и к. Туктале, карчык, мин аңламадым, шундый да шатлыклы көндә нигә дип кайгылы җыр җырлыйсың?..

Я с м и н ә. Башка җыр белмим, Малик...

М а л и к. Белмәсәң дә, син андый хәсрәтле җыр җырлама! Әллә моның берәр көенече бар микән дип уйлаулары бар. Бар җирең дә җитешле, бөтен, шулаймы?

Я с м и н ә *(елмаеп, Маликның күңеле булсын өчен)*. Юк нәрсәм юк, Малик, шөкер...

М а л и к. Өйләнгәндә балда-майда йөздерәм дип вәгъдә бирдемме, хатын, әйт. Халик абыең алдында?

Я с м и н ә. Вәгъдә бирдең...

М а л и к. Үтәдемме?

Я с м и н ә. Үтәдең, Малик, рәхмәт инде...

М а л и к. Ефәккә төрәм дидем, төрдемме?

Я с м и н ә. Төрдең, әтисе, анысына да рәхмәт.

Халик, эче пошып, йөрергә тотына.

М а л и к. Бәхетле иттемме үзеңне?..

Я с м и н ә. Бәхетле иттең...

М а л и к. Сез әнә шифоньерны кереп карагыз! Кием кибете! Барысы да Ясминәнеке! Дөресме, хатын?!

Я с м и н ә *(ачуы килә барып)*. Барысы да минеке! Кигән юк!.. *(Чыга.)*

М а л и к. Киеп йөрергә вакыты-җае гына юк... Председатель: абыеңнан артта калгансың, дигән була! Я, Халик, төшеп калмадымы Малик? Ярый, син галим булдың! Минем ким җирем бармы синнән?

Х а л и к *(бер читкә китеп уйланып тора)*. Ким җирең юк, Малик...

М а л и к. Син үзеңә машинаны әллә кайчан алгансыңдыр инде?

Х а л и к. Минем машинам юк.

М а л и к. Аның каравы өең минеке кадәр генә түгелдер?

Х а л и к. Бер бүлмәле. Миңа шул да җиткән.

М а л и к. Карале, синең хәлләр ничек соң? Хатының һаман шулмы?

Х а л и к. Минем хатыным да юк!

М а л и к. Киттеме?

Х а л и к. Китте.

М а л и к. Яратмадымы?

Х а л и к. Эшемне яратмады — мин җәй буе экспедициядә...

М а л и к. Барып чыкмады диген, алайса?.. Хатын ташлаган... И дөрес эшләгән! Нинди хатын синең белән торсын! Их, Халик, Халик, әти карт мәрхүмнең хатасын кабатлыйсың!

Х а л и к. Ә? Нәрсә? Әти карт хатасын? Нинди хатасы бар әтинең?

М а л и к. Аның бөтен тормышы хата. Хәтерлә — халык председатель итеп сайлагач, ни кыланды... Бар иеме мөмкинлек мал җыярга?

Х а л и к. Бар иде.

Малик. Бар ие... «Кемнең кулында — шуның авызында» диләрме әле?

Халик. Шулай диләр!

Малик. Ә ул... Өйгә бер кадак та алып кайтмады. Имеш, «халык ничек яши — мин дә шулай яшим!» Әйттеме шулай!?

Халик. Әйтте!

Малик. Хәтерлә клуб мөдире булып эшләгән чагын. Барлы-юклы акчасын клубка тотты. Имеш, халыкка кирәк! Хәтерлә — трудармиягә барудан котылып була идеме?

Халик. Була иде!

Малик. Ә ул... Сыңар үпкә белән заводка китте. Халык язмышы хәл ителә, имеш! Әйттеме шулай?

Халик. Әйтте!

Малик. И нәтиҗә — үлде! И вәссәлам!

Халик. Ул үлмәде, хезмәт фронтында һәлак булды!

Малик. Шуннан аңа ни файда? Әни дә аның ише иде...

Халик. Әнигә тел тидермә — якты кеше иде мәрхүмә. Матур яшәде, матур китте. Әле генә аның изге туфрагыннан килдем.

Малик. Әле дә яшәр ие... Үзе гаепле. Сугыштан соңгы авыр елларда, тездән пычрак ерып, утыз чакрымнан чәчү орлыгы ташырга кем мәҗбүр итте? Шуннан кайтып егылды да! Яшь кеше түгел — калала иде.

Халик. Бу сүзләрне әйтергә ничек оялмыйсың, Малик? Мин куйган ташны үлән баскан... Әни туфрагына юлың өзелгән.

Малик. Таш куюың өчен рәхмәт анысы! Без бит эш кешесе — вакыт юк! Ә менә алар безне нужада калдырып киттеләр! Мин хәзер аларның ялгышын төзәтү өчен, көн-төн ял итми эшлим!

Халик. Ата-ана нигезендә аларга яман сүз әйтәсе булма!

Малик. Ата-ана нигезе? Юк аларның нигезе!

Халик. Без басып торган туфрак — ата нигезе!

Малик. Бу нигездә аның бер тамчы өлеше юк! Бу — минем нигез! Я, әйт, ул безгә нәрсә калдырды?

Халик. Ул дөньяга сине, мине калдырып китте.

Малик. Нинди файда? Миңа атадан сукыр бер тиен дә калмады! Өйне үзем салдым, малны үзем таптым! Мин аның хатасын төзәттем!

Халик. Тукта! Әтине тагын бер начар яктан искә алсаң... *(Тыела алмыйча баганага тотына.)*

Малик. Нишләтерсең? Их, әти мескен, әти мескен... Көч сынашырга исәпме? Карап карыйк!

Ядкарь *(йөгереп кереп)*. Халик абый, нишлисез?

Халик. Дөрес, Ядкарь... Без акыл белән җиңәсе кешеләр! Их, Малик, Малик... ата нигезендә бит...

Малик. Яшәүнең ни икәнен белмәгән нигездә менә мин яшим ичмасам!

Халик. Кайтмый калган Камил, әти һәм әни минем күңелдә синнән тереракләр!

Малик. Таптың бер сүз: ата нигезе! *(Баскыч астыннан баш сөяге һәм тимер кисәге ала.)* Менә шушы баш сөяге белән черек тимер кисәгеннән башка бернәрсә юк аның нигезендә! *(Халик алдына атып бәрә.)*

Халик *(сөякне кулына алып)*. Малик, нәрсә бу?!

Малик. Гап-гади баш сөяге.

Халик *(тимер кисәген тотып, гаҗәпләнеп)*. Ә монысы?! Моны каян алдың?!

Малик. Таптым.

Халик. Җир астыннанмы?!

М а л и к. Әйе.

Х а л и к. Баш сөяге белән бергә идеме?

М а л и к. Мин үзем күрмәдем! Бергә бугай!

Х а л и к. Малик, кем тапты?

М а л и к. Әкбәр.

Х а л и к. Каян?

Я д к а р ь. Каян?

М а л и к. Капка баганасы казыганда.

Х а л и к. Әкбәр кайда?

М а л и к. Әнә... шунда йөри...

Х а л и к. Чакыр аны тиз генә!

М а л и к. Әкбәр!

Ә к б ә р *(керә)*. Нәрсә бар? Исәнме, Халик, кайттыңмы?

Х а л и к. Исәнмесез, Әкбәр... Баш сөяген сез таптыгызмы?

Ә к б ә р. Ә? Нинди баш сөяге?

Х а л и к. Менә шуларны?

Ә к б ә р. Күргәнем дә юк!

Х а л и к. Менә монысын да сез таптыгызмы?

Ә к б ә р. Нәрсә соң ул? Беренче тапкыр күрәм.

Х а л и к. Әкбәр, сез капка баганасына чокыр казыдыгызмы?

Ә к б ә р. Казыдым.

Х а л и к. Шушыларны сез таптыгызмы?

Ә к б ә р. Юк! Юк!

Х а л и к. Әнә Малик әйтә: Әкбәр тапты, ди...

Ә к б ә р *(Маликка)*. Саттың?

М а л и к. Курыкма, болар милициядән түгел!

Х а л и к. Без — Фәннәр академиясеннән... археологлар...

Ә к б ә р. Шулаймыни? Нигә соң аны башта ук җүнләп аңлатмыйсыз? Әлләниләр уйлап бетердем...

Х а л и к. Боларны, димәк, сез таптыгыз?

Ә к б ә р. Мин таптым. Менә моның капка баганасын казыганда... шушында...

Х а л и к. Туганкай, беләсеңме бу нинди зур хәзинә, нинди кыйммәтле табыш! Бигрәк тә менә монысы...

М а л и к. Кыйммәтле... табыш?.. Нәрсә соң бу?..

Х а л и к. Бу — борынгы бабаларыбызның көмеш битлеге дип уйлыйм...

М а л и к *(көмеш битлекне Халик кулыннан йолкып ала)*. Көмеш?!

Х а л и к. Көмеш. Әмма без аны тикшереп карарга тиешбез. Синең өй янында фәнгә гаять кирәк булган табылдыклар чыкканлыктан, мин тиздән монда казу эшләре алып баруны кирәк табам.

М а л и к. Тукта әле, син туганыңа кунакка килдеңме, әллә минем өй астында казынып акча сугаргамы?

Х а л и к. Мин сиңа түгел, әтиемә генә дә түгел, борынгы бабаларыма кунакка килгән булып чыктым, Малик!

М а л и к. Булмаган ата малын даулашасыңмы?

Х а л и к. Син фән файдасына бу табылдыкларны бирергә тиеш буласың.

М а л и к. Сиңа?

Х а л и к. Әйе.

М а л и к. Төшендем. Ата малы! Бүләбез! Бетте-китте — вәссәләм! Менә сиңа монысы... борынгы бабаңның баш сөяге! *(Бирә.)* Миңа — монысы...

Х а л и к. Рәхмәт, Малик! *(Баш сөяген ала.)*

М а л и к *(аптырап)*. Алдың?! Шуны алдың? Их, Халик, шул көнгә төштеңме? Иске каберлектән скелетлар җыеп йөрергә калдыңмы? Әти мәрхүм дә шул хәлгә төшмәгәнне...

Халик. Мин әле кулыңдагы табылдыкны да бирерсең дип өмет итәм.

Малик. Кемгә ачык йөз күрсәтсәң ямаулык сорый, ди? Шушыны? Көмешне?

Халик. Әйе!

Малик. Сез, сүз боткасы пешереп, галим, бер дә тир түкмичә генә баемакчы буласыз? Малик үзе тапкан малын сезнең кебек акыллы башларга таратып бирә... Таптыгыз бер җүләр!

Халик. Бир, Малик, атамның изге рухы белән сорыйм...

Малик. Төшендем! Маликта да анлык кына баш бар. Мин сиңа бу нәмәрсәне бирәм...

Халик. Ышанам...

Малик. Ал...

Халик. Бир.

Малик. Түлә. Кыйммәтле табыш — сатып алыш!

Халик. Малик! Ул миңа түгел, фән өчен...

Малик. Кем өчен булса да, болар — минеке, телим — сатам, телим — атам!

Халик. Синең хакың юк!

Малик. Их, абый, шуларны сатып алырлык та акчаң юкмыни? Үз кесәңнән түләмисең ич...

Халик *(катгый).* Күпме сорыйсың?

Малик *(уйланып торып).* Өч йөз!

Ядкарь. Өч йөз?!

Халик. Малик, ничек оялмыйсың, ул — синең милкең түгел, халыкныкы!

Малик. Ах, шулаймы? Минем милкем түгелме? Алайса, баш сөягенә белән бергә — биш йөз!

Ядкарь. Биш йөз?! Халик Бакыевич...

Тынлык.

Малик. Телсез калдыгыз? Көчегездән килмимени? Шушы баш сөяген сатып алырга да хәлегез юкмыни? Мин акчасыз, ятим йөргәндә, миңа беркем дә бушлай мал китереп бирмәде... Мин малны хәләл көчем белән, сөялле кулларым белән таптым! Кайберәүләр миннән «атаңнан энә дә калмады» дип, бармак төртеп көлделәр! Менә хәзер миннән көлеп карагыз! Көлегез миннән! Ник көлмисез? *(Кесәсеннән төргәк акчалар алып.)* Менә алар, акчалар, җаныкайларым... Мин аларны җир астына төшеп, шахталарда эшләп таптым! Шушы җилкәм белән бүрәнәләр күтәреп йортлар салдым. Шушы кулларым белән, шушы күкрәгем белән! Беркемнең бернинди катнашы юк! Менә ул байлык... менә... *(Акчаларны өстәлгә сибә.)* Аларның ничек табылганын әнә Әкбәр дус белә... Әкбәр, җаным, синең монда хәләл көч белән тапкан акчаларың ята... Ал, Әкбәр, мә, төп-төгәл мең тәңкә!

Әкбәр. Юк, Малик, алмыйм!

Малик. Ал, яшьтәш, үз акчаң бит, син болар сыман кеше тапканны теләнеп йөри торганнардан түгел... Ал!

Әкбәр. Әйттем алмыйм дип, бетте!

Малик. Соңгы тапкыр әйтәм, Әкбәр, ал! Алмыйсыңмы?

Әкбәр. Алмыйм!

Малик. Алмыйсыңмы? Беләм: син үзсүзле, кире кеше! Ул акчалар миндә дә тора алмый! Мин кеше тапкан акчаны сакламыйм! *(Зажигалка чыгарып йөзлекләрне яндырмакчы була.)* Кирәкми миңа кеше тапкан! *(Әкбәр кузгалмый.)*

Ядкарь. Йөзлек! Яндыра! *(Акчага омтыла.)*

Халик *(Ядкарьга).* Ядкарь, кит!..

Малик. Хәзер мине туктатса, Әкбәр дус кына туктата ала...

Я д к а р ь. Әкбәр абый?..

Ә к б ә р. Малик, бир, алам...

М а л и к. Акылыңа килдең... Алырга булдың тәки? *(Әкбәргә килеп.)* Мә, Әкбәр, намуслы эшең өчен... Санап ал...

Ә к б ә р *(акчаларны алып, Халикка).* Мә, Халик абый, сатып ал кирәк нәрсәләреңне... *(Акчаларны бирергә килә.)*

М а л и к *(акчаларны тартып алып).* Юк! Бармый! Мин хәрәм акчалар алмыйм! Хәләл акчаларың юкмыни? *(Тынлык.)* Юк синең акчаларың?.. Ә мал бушка сатылмый...

П ә р д ә

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

Беренче кисәктәге күренеш. Төн. Халик ялгызы.

Х а л и к. Малик... Малик... Шушы нигездә уйнап үскән энем, нишләдең син? Ул вакытта игътибар итмәгәнмен: бала чакта ук син тиеннәр җыя торган идең... Малик... Малик... *(Портфеленнән баш сөяге ала.)* Әй, борынгы кеше, кайчандыр син дә киләчәк кешесе белән— минем белән, хыялыңда булса да, сөйләшкәнсеңдер. Син дә кайчандыр җир өстендә йөргәнсең, күкрәгеңдә кайнар йөрәгең типкән. Кайсы чор кешесе син? Ниләр уйладың, ниләр кичердең? Кылган эшләрең изгеме, явызмы? Әллә сугыш һөнәрен үзләштереп, халыкларны талап, кырып йөрдеңме? Әллә туган җиреңне яклап яуда һәлак булдыңмы? Әллә күршеләреңнең кем икәнен дә белмичә, әрләнгә шикелле, бар тапканыңны үз куышыңа ташып, үз байлыгың үзеңә ишелеп, эзсез югалдыңмы?! Борынгы кеше, син мине ишетәсеңме, син мине ишетәсеңме?!

Б о р ы н г ы к е ш е т а в ы ш ы. Мин сине ишетәм.

Х а л и к. Мине син чакырдыңмы?

Б о р ы н г ы к е ш е. Син минем чакыру авазын ничек ишеттең?

Х а л и к. Мин җир астын колак салып, күңел биреп тыңладым.

Б о р ы н г ы к е ш е. Тыңларга кем өйрәтте?

Х а л и к. Әти. Синең тавышың әтинеке кебек...

Б о р ы н г ы к е ш е. Синең тавышың да минекенә охшаган.

Х а л и к. Минем әтием Бакый бирегә яшиме?

Б о р ы н г ы к е ш е. Яши.

Х а л и к. Димәк, син минем борынгы бабам?

Б о р ы н г ы к е ш е. Әйе. Күпме еллар, гасырлар мин сине чакырдым, көттем... Балам, киләчәк, исәнме?

Х а л и к. Исәнме, бабам?

Б о р ы н г ы к е ш е. Кил, тагын да якынрак кил... Сине кочаклыйсым, чәчләреңнән сыйпыйсым килә...

Х а л и к. Мин үземнең синнән дә ераграк бабаларыма барырга телим. Хаклык өчен, Ирек өчен бабаларым ничек көрәшкәннәр — шуны белергә телим!

Б о р ы н г ы к е ш е. Ә ул сиңа нигә кирәк?

Х а л и к. Бүгенгене, Киләчәкне төзү өчен!

Б о р ы н г ы к е ш е. Онытмавың өчен рәхмәт, балам! Ләкин син аны белә алмассың...

Х а л и к. Нигә?

Б о р ы н г ы к е ш е. Чыганаклар җир астында югала баралар...

Х а л и к. Яхшылык, Матурлык җир астында калмый, югалмый!

Б о р ы н г ы к е ш е. Шуларның берсе — көмеш битлек югалды.

Х а л и к. Көмеш битлек?

Борынгы кеше. Әйе. Ерак бабаларыбызның рухын саклаган көмеш битлек. Аны кигән кешене бер дошман да җиңә алмаган, чөнки халык аңа әллә ничә гасырлар җыелган байлыгын, җан матурлыгын салган. Илбасарлар, патшалар көмеш битлекне кулга төшерү өчен сугышканнар, кан койганнар һәм аны юк итәргә тырышканнар... Ул көмеш битлекне күпме эзләсәк тә, без таба алмадык...

Халик. Көмеш битлек табылды!

Борынгы кеше. Табылды? Кайда ул?

Халик. Ул минем туганымда, Маликта. Әмма ул аны безгә бирергә теләми.

Борынгы кеше. Көмеш битлек мал түгел!

Халик. Әйе, мал түгел!

Борынгы кеше. Мин ышанам, балам, синең кебек оныклар яшәгәндә, көмеш битлек югалмас!

Халик. Ышан, бабам, мәңге югалмас!

Борынгы кеше. Югалмас! Югалмас! Югалмас! *(Тавыш җир астында югала.)*

Ядкарь *(кулына сөлге тотып керә)*. Халик абый, сез биредәмени? Сез төн буе йокламадыгыз, ахры. Машинада салкын булды шул...

Халик. Син дә соң гына йоклап киттең...

Ядкарь. Уянып китсәм — сез юк!.. Халик абый, мөмкин булса, әйтегез, сез ни уйладыгыз?

Халик. Мине Малик борчый... Аптырап калдым әле мин, Ядкарь...

Ядкарь. Аңлыйм... Мин энегезне нәкъ сезнең шикелле итеп күз алдына китергән идем...

Халик. Ни булган аңа, ни булган? Без бит бер ата, бер ана балалары...

Ядкарь. Аттан ала да, кола да туа диләр бит... Халик абый, әйтегез әле, энегез кулындагы көмеш битлекнең сере нәрсәдә соң?

Халик. Башта мин аның турында легенда барлыгын ишеттем. Әчтәлеге әлегә билгесез. Аннан соң мин көмеш битлекнең үзен күрдем.

Ядкарь. Кайда? Кайчан?

Халик. Ватан сугышы чорында... Разведчик юлдашым Владимирны күмәргә дип җир казыганда, көрәгем каты бер әйбергә бәрелде. Ул — көмеш битлек булып чыкты... Кара диңгез буендагы ул табылдыкны тылга озаттым... һәм менә... көтмәгәндә... шул битлекнең ише — ата нигезендә...

Ядкарь. Моңа таянып, Сез нәрсә әйтә аласыз соң?

Халик. Әнә... зәңгәр күк йөзендәге болытларны күрәсеңме?

Ядкарь. Күрәм.

Халик. Бабаларыбыз, әнә шул болытлар шикелле, күчеп йөргәннәр. Тарихта Бөек күчү дип аталган чор булган. Кайбер археологик табылдыкларга таянып, без бабаларыбызны Азов, Дон, Кара диңгез буйларыннан килеп урнашканнар дип фараз итә алабыз. Ләкин бу гипотезаны исбат итәрлек дәлилләр күп түгел. Шушы табылдыкны фәнни тикшереп, икесенең игезәк икәнен исбатлый алсак, бу — фән өчен бик әһәмиятле бер дәлил булачак!

Ядкарь. Димәк, без аны ничек кенә булса да, Малик абыйдан алырга тиеш. Ә ничек?

Халик. Мин ул сораган акчаны табам!

Ядкарь. Алай да бирмәсә, тартып алабыз!

Халик. Бирер. Ул кызып китте. Без аның төнге каравылдан кайтканын көтик. Ярый, ул кайтканчы, мин бер әйләнеп килим. *(Чыга).*

Я д к а р ь *(Зөлхия тәрәзәсенә килә. Тәрәзә чиертеп).* Дәринә. Минемчә, син нәкъ шушы тәрәзә янында йоклыйсың. Уян, Дәринә, таң ата... Мондый чакта йоклап яту — гөнаһ... *(Акрын гына сызгыра, тәрәзә пәрдәсе күтәрелә.)*

Алтын йөзек бирер идем
Көмеш йөзек биргәнгә,
Җаным суырып бирер идем,
Дәринәкәй, сылуым-иркәм,
«Сөям, җаным» дигәнгә.

Борынгы бабаларыбыз борынгы әбиләребез янына менә шулай килгәннәр.

Якут ташыннан куйдырдым
Йөзегем пыяласын,
Бер үрелеп карасана,
Кемнәрдән оялясың?

Тәрәзә ачыла: Дәринәнең нурлы йөзе күренә.

Дәринә... Җыр белән җавап бир!
Д ә р и н ә. Тс...с!

Ачмыйм тәрәзәмне ул килмичә,
Ятларны сөярмен белмичә...

Я д к а р ь. Дәринә, бабаларыбыз шушы Чулман буйларына җиде диңгез кичеп килеп, җиде ятка гашыйк булганнар. Андый хәлнең хәзерге заманда да булуы бик ихтимал. Элек егетләр кызларны тәрәзәдән генә тартып алганнар. Ризасыңмы?

Д ә р и н ә. Риза! *(Тәрәзәдән сикереп төшә.)* Һоп!

Я д к а р ь *(тотып алып).* Тирә-якта козгыннар күренмиме, җаным?

Д ә р и н ә *(кочагыннан ычкынып).* Үзегез козгын түгелме?

Я д к а р ь. Хәзерге козгыннар соң уяна. Аларга тыныч йокы!

Д ә р и н ә. Юлыма төшмәгез! Мин ашыгам!

Я д к а р ь. Дәринә, бәлки, юлларыбыз бер яккадыр?

Д ә р и н ә. Ә сез кай якка барасыз?

Я д к а р ь. Узган заманга.

Д ә р и н ә. Ә мин — киләчәккә!

Я д к а р ь. Киләчәк кызы, икебез ике төрле юнәлсәк тә, чынында без бер якка барабыз. Безнең юллар барыбер бер ноктада очрашалар. Минем белән очрашмыйча торып, син үзең төзиячәк киләчәккә барып җитәлмисең. Сизәм: борынгы кеше эзеннән бара-бара, мин сиңа — үземнең киләчәгемә килеп җиттем! Дәринә... Әйдә төшик су буена...

Д ә р и н ә. Әйдә!

Я д к а р ь.

Суларын эчик әле...
Канатлы кошлар артыннан
Канатсыз очыйк әле...

*(Китмәкче булалар).*

Р и м *(өйдән килеп чыга).* О! Хәлил! Галиябану! *(Ядкарь өстенә килеп.)* Беләсеңме, мин бүгенге заманның Исмәгыйле! Әмма мин сине атмыйм!

Я д к а р ь. Рәхмәт!

Р и м. Беләсеңме, мин сине нишләтәм!

Я д к а р ь. Әйтеп кара!

Р и м. Мин сине үземнең территориядән куам!

Я д к а р ь. Ә мин китмим! Бу территориядә безнең экспедиция фәнни эш белән шөгыльләнә!

Р и м. Безнең авыл кызының фәнни эшкә катнашы юк! Борынгы табылдыклар да, Дәринә дә — минем территориядә! Син нәрсә, Дәринәне дә бүләргә килдеңме?

Д ә р и н ә. Рим!

Я д к а р ь. Син бит Дәринәне яратмыйсың!

Р и м. Әйе. Мин аны яратмыйм! Сиңа да бирмим! Ул мине ярата. Димәк, синең хакың юк!

Я д к а р ь. Кызганыч, ләкин факт: мин монда кешеләр тудырган матурлыкны үзенеке генә дип уйлаучы кешеләрне күрәм!

Р и м. Калдыр да Дәринәне, ычкын!

Д ә р и н ә. Рим, тынычлан!

Я д к а р ь. Син аңа хуҗамыни?

Р и м. Мин өч вариант тәкъдим итәм!

Я д к а р ь. Әйтеп кара!

Р и м. Энҗе кебек тезелеп торган тешләреңне кесәңә тутырып китәсең! Монысы — иң шәп вариант!

Я д к а р ь. Китмим!

Р и м. Безнең зират матур... Агачлар шаулавын... кошлар сайравын тыңлап ятасың!

Я д к а р ь. Ятмыйм!

Р и м. Җаның тәнеңдә чакта тай моннан! Мин Дәринә кебек чибәр кызны хан заманы арбасында килгән кучерга биреп җибәрә алмыйм!

Д ә р и н ә. Туктагыз! Мин үз язмышымны үзем хәл итәм!

Р и м. Өченче вариант — мин сине дуэльгә чакырам!

Я д к а р ь. Шартың?

Р и м. Текә яр башына басабыз. Бокс!

Д ә р и н ә. Мин рөхсәт итмим!

Я д к а р ь. Мин дуэльне кабул итәм!

Р и м. Ярый... Хәзер мин район үзәгендәге дустымнан бокс перчаткалары алып киләм! Курыкмасаң — көтәсең!

Я д к а р ь. Мин үз сүземдә калам!

Р и м. Минем белән юкка узышасың, тәти егет! Карап карарбыз: киләчәккә кем алданрак барып җитәр?

Я д к а р ь. Мин узышмыйм! Киләчәккә — узганның, борынгының фатихасын алып барам.

Р и м. Ярый, син Зөлхый әбиеңнең фатихасын ала тор! Ватык арбаңны кемгә васыять итү турында да уйла! Мин хәзер киенеп чыгам да выжт! *(Өенә керә).*

Д ә р и н ә. Рим, тукта!

Я д к а р ь. Мелә ахмак! Борчылма, Дәринә! Мин аны имгәтмәм! Киттек юынырга!

*Чыгалар. Х а л и к керә. Зөлхиянең җимерелгән коймасы янына килеп уйга кала. Такталарны рәтләп куймакчы була. Өеннән Зөлхия чыга.*

З ө л х и я. Халик балам, синме бу?

Х а л и к *(борылып).* Хәерле иртә, Зөлхый апа!

З ө л х и я. Син генә булса да исемемне дөрес әйт инде, улым. Зөлхия диген... Сугыш чорында ирләр урынына җигелеп, үгезләргә, атларга акырып тупасланып беткәч, Зөлхый дигән кушамат тактканнар ие, ябышты да калды... Олысы да, кечесе дә Зөлхый дигән була... Ачу килми тагы... Зөлхия дисәләр, кыз чаклар искә төшеп, рәхәт булып китәр ие дә соң...

Х а л и к. Ничек йокладыгыз, Зөлхия апа?

З ө л х и я. Әй телләрең, май кебек эретә лә, Халик улым. Кая инде безгә йокы... Менә син кайткач, тагын Камил баламны искә тө-

шердем, төшкә дә килеп керде үзе... Шуның өстенә иртән синең шоферың, кем әле, Ядкарь дисеңме, тәрәзә янында җырлап җибәрмәсенме? Яшь чагым дип белеп, үзем тәрәзәдән сикереп төшә яздым, менә сиңа, ә?

Халик. Ни хәлләрдә яшисең, Зөлхия апа?

Зөлхия. Биргәненә шөкер, Халик улым· Авыр елларда чишелмәслек төеннәрне чиша-чиша, тешләр генә төшеп бетте. Әй, чәй эчәргә теш кирәкмени? Йөрәге кайчак айгыр кебек дулап куймаса, яшибез әле, улым, яшибез... Тик менә соңгы вакытта дулап куя шул...

Халик. Ялгыз башка авырга килмиме, өегез дә бик тузган...

Зөлхия. Энемнең кызы Дәринә бик акыллы..· бик тә ярдәмле... Өй нигә инде миңа, үз гомеремә җиткән... Күпме яшисе калгандыр инде... Авыл советыннан өй салып бирәбез дип килгәннәр ие дә, үзем риза булмадым... Безгә хәзер кеше бәхетенә сөенеп яшәргә генә калды... Карале, улым, нишләп сез машинада төн үткәрдегез, бу Кинәтбайларның өе болын кебек ич...

Халик. Машинада иркенрәк, Зөлхия апа...

Зөлхия. Әй, эттәгенәсе, үз абыйсына да урын тарайганмыни! Кил миңа, Халик улым, һәммә дусларыңны алып... Идәнгә утырып аяк бөкләп чәй эчәрбез...

Халик. Рәхмәт, Зөлхия апа, керербез...

Зөлхия· Карале, улым, бу Кинәтбай энең җир казыганда көмеш битлек тапкан ди, хакмы шул сүз?

Халик. Хак.

Зөлхия. Син шуны эзләп йөрисеңме?

Халик. Ул минем өчен көтелмәгән табылдык булды.

Зөлхия. Бик кирәкме ул сиңа?

Халик. Миңа түгел — ул фәнгә кирәк.

Зөлхия. Көмеш битлек диген... Менә сиңа әкият. Бәгырь кисәгем Камил дә шундый бәет, җыр, әкият кебек нәмәрсәләр белән җенләнер ие..· Хәтеремдә, ул да көмеш битлек әкиятен эзли торган ие...

Халик. Әйе, әйе... Зөлхия апа, тизрәк әйт, ул аны таптымы?

Зөлхия. Тапты.

Халик. Тапты?! Кайда ул?

Зөлхия. Укытучыларына илтеп биргән ие. Мәктәптә янгын вакытында бөтен җыйганнары янган, Камилем бик кайгырып йөргәне хәтеремдә.

Халик. Зөлхия апа, сез ул әкиятне үзегез хәтерләмисезме?

Зөлхия. Юк шул. Карт кешенең хәтере — тишек иләк, ди.

Халик. Камилнең ул әкиятне кемнән язып алганын белмисезме?

Зөлхия. Хәтерем ялгышмаса, Камил аны Ак бабайдан язып алды шикелле.

Халик. Ак бабайдан? Әйе, әйе, исемә төште, Урайданмы? Ул исәнме?

Зөлхия. Өлкән кеше, кичә бар, бүген юк...

Халик. Без аны ничек кенә булса да күрергә тиеш!

Зөлхия· Син аны сөйләштерә алмассың шул, балам... Ул чит кеше белән сөйләшми. Колакка да таман... Үзем генә бармасам.

Халик. Зөлхия апа... Зинһар, ярдәм ит!

Халик. Ядкарь! Рим!

Ядкарь, Рим, Дәринә өйдән чыгалар.

Ядкарь. Тыңлыйм!

Халик. Ядкарь! Зөлхия апа сине Ак бабай янына, Урай авылына алып барыр. Көмеш битлек турындагы легенда шунда... Ал магнитофонны, һәр сүзне язып бар! Машинаны төзәттерү ягын мин үзем

карармын. Аннары, иң мөһиме: киткәнче миңа Малик белән аңлашырга кирәк!

Я д к а р ь. Көмеш битлекнең серен ачарбыз, Халик абый!

З ө л х и я. Киттек, улым! *(Дәринәгә.)* Син, Дәринә кызым, кунакларга өстәл әзерли тор! Кадерле изге кешеләр болар!

Д ә р и н ә. Ярый, Зөлхия апа!

Х а л и к. Зөлхия апага биш чакрым җәяү йөрү авыр булыр, Рим, бир машинаңны Ядкарьга, яки үзең илтеп куй ялт итеп кенә!

Р и м *(Ядкарьга күрсәтеп).* Шушы Тутанхамонны? Яныннан җилдәй узып киткән «Зил»ләргә карый-карый, барсын әле тәпи-тәпи генә! Юк, Халик абый! Үзеңә булса — рәхим ит, моңа — шиш! Безнең — дуэль! Хәзер район үзәгенә — бокс перчаткалары алырга барам!

З ө л х и я. Ялынмагыз шуңа, улларым... Мин иркен сәхрәләрдә җәяү йөрергә яратам... Бигрәк тә менә шундый Камил улыма охшаган егет булганда... Әйдә, балам...

Я д к а р ь. Әгәр арысагыз, машинасын да табарбыз, Зөлхия әби... Хуш, Дәринә!

Д ә р и н ә. Хәерле юл сезгә, исән-сау әйләнеп кайтыгыз!

З ө л х и я. Сау бул, кызым Дәринә, улым Халик... *(Римга)* син дә сау бул...

Р и м (тупас). Бар, бар, юлыңда бул! Сез барып җиткәнче, борынгы бабагыз аягын сузмасын!

Зөлхия белән Ядкарь китәләр.

*(Дәринәгә.)* Дәринә! Әйдә минем белән!

Д ә р и н ә *(ачулы).* Бармыйм!

З ө л х и я өенә кереп китә.

Х а л и к *(Римга нәфрәт белән).* Син нигә аларны машинаң белән илтеп куймадың?

Р и м. Беренчедән, алар үзләре ялынмадылар, икенчедән, хәзер мин район үзәгенә барып киләм. Әйттем бит: дуэль!

Х а л и к *(үз-үзен тыныч тотарга тырышып).* Мин синнән сорыйм: син ник аларны машинаң белән илтеп куймадың?!

Р и м. Машина — минеке! Кемне телим — шуны утыртам!

Х а л и к *(чыгырыннан чыгып, Римның чигәсенә сугарга кизәнә дә туктальп кала).* Гафу итегез...

Р и м. Сукмыйсыңмы? Ә без, киләчәккә баручылар, сезгә, борынгы кешеләргә, шундый итеп сугарбыз, — археологлар да эзләрегезне эзләп таба алмаслар!..

Х а л и к. Югал күз алдымнан! *(Рим чыга).*

Ә к б ә р *(керә, капка эшләргә тотына. Җырлый).*

Рәхәтләнеп йоклап калдым
Сабый чакларда гына...

Х а л и к. Каравылда йоклап булмыймыни, Әкбәр?

Ә к б ә р. Мин саклаган ташлар гына йоклый...

Х а л и к. Әкбәр, мин сиңа карап-карап торам да, нишләдең син?

Ә к б ә р. Нәрсә? Кирпеч саклау гаепмени?

Х а л и к. Юк. Гаеп түгел. Кирпечне бит җитмеш яшьлек пенсионер да саклый ала.

Ә к б ә р. Каравыл ул болай гына...

Х а л и к. Эшләгән булып күренү өчен генәме?

Ә к б ә р. Безнең төп эшне белсәң... Энекәшең Малик белән өй салып йөрибез. Йорт салабыз да табышны икегә бүләбез... Салабыз да икегә бүләбез...

Х а л и к. Күрәм. Малик баеган. Синең малың бармы соң?

Ә к б ә р. Нигә миңа мал? Үзем белән алып китәргәме? Миңа Маликка кирәк... Ул озак яшәргә җыена... Мин бүтәнчә уйлыйм: гомер болай да кыска, яшәп калырга кирәк...

Х а л и к. Ягъни мәсәлән, ничек?

Ә к б ә р. Бүген тапкан — бүгенгә таман гына... Иртәгә — күз күрер... Менә шушы куллар барында — Әкбәр югалмас! Я, ничек, өй матурмы?

Х а л и к. Тышкы яктан караганда ул бик матур, Әкбәр! Чыннан да, кулларың алтын! Куллар алтын булу гына җитми әле. Дөньяда алтыннан да кадерле нәрсә бар...

Ә к б ә р. Син беләсең, бу өйне салган өчен мин сукыр бер тиен дә алмадым...

Х а л и к. Әгәр дә кешегә чыннан да яхшылык эшләргә теләсәң, ни өчен йортны Маликка салырга кирәк иде?.. Үзе балта остасы, көче җитә, сау-сәламәт...

Ә к б ә р. Туктале, син нәрсә, үз туганыңнан көнләшәсеңме әллә? Менә монысы инде килешми, агай-эне... Бигрәк тә сиңа... Малик әле бер хәл...

Х а л и к. Әгәр мин Малик урынында булсам...

Ә к б ә р. Нишләр идең?

Х а л и к. Иң башта өйне Зөлхия түтигә салып бирер идем...

Ә к б ә р. Ә? Кемгә дисең?

Х а л и к. Зөлхия түтигә!

Ә к б ә р. Зөлхиягә? Моңа?

Х а л и к. Әйе, аңа!

Ә к б ә р. Ни өчен аңа?

Х а л и к. Малик Зөлхия апа алдында мәңгегә бурычлы...

Ә к б ә р. Бурычы булса түләр иде... Көче җитә...

Х а л и к. Юк, акча белән үлчәнә торган бурыч түгел ул... Җан бурычы. Исеңә төшер: Зөлхия түтинең улы Камил белән Малик сугышка бергә киттеләр... Фронтка барганда ук дошман алар барган эшелонны бомбага тоткан. Камил аны туфрак-балчыктан актарып алып, саклап калган, үзе фронтка китеп, сугышның өченче елында һәлак булды, ә Малик госпитальдә ятып... туган авылга кайтты...

Ә к б ә р. Монда аның гаебе юк инде...

Х а л и к. Мин моны аны гаепләү өчен әйтмим... Зөлхия апа аның тормышын саклап калган кешене дөньяга тудырган кеше. Миңа Маликның аңа булган мөнәсәбәте аңлашылмый... Зөлхия апа аннан сөт ала... Ә минем туганым Малик шуннан оялмый, пенсиясен түләгән карчыкның тиеннәрен саный... Һәм сез, икәүләп, Зөлхия түтинең иске өе янында сарай салып ятасыз! Җаныгыз бармы сезнең, әллә кирпеч заводын саклый-саклый, җаныгыз да ташка әйләндеме?!

Ә к б ә р. Бер-ике көнгә кунакка кайтып тегене-моны күрү, гаеп итү җиңел ул... Ә менә син үзең нишли аласың?

Х а л и к. Риза булса, мин Зөлхия апаны Казанга үземнең квартирага алып китәм. Дәринә белән шунда торырлар. Мин аларга комачауламам, өйдә сирәк булам.

Ә к б ә р. Беләм, үзем дә беләм Маликның кайбер якларын. Ниндидер бер шайтани көч бар явызда ычкындырмый торган...

Х а л и к. Әкбәр, бир әле балтаны! Андый эшкә әвәслегем юкюгын, бераз булса да коймасын рәткә китерергә кирәк...

Ә к б ә р. Син Әкбәр эшенә кагылма, академик, үз эшеңне кара... мин әнә ялгыш синең эшкә тыгылып, бабаңның баш сөяген тартып чыгардым... *(Балтасын уйнатып.)* Каяле... Бигрәк искергән ич бу такталар... Шулай диген, Халик кордаш, ә? Безнең аяк астында зур-зур

калалар, авыллар яшәп яткан, диген, ә? Барысы да эзсез югалган, кара син, ә?

Халик. Юк, Әкбәр, югалмаган!

Әкбәр. Баш сөяге торып калган и вәссәлам! Бар — кеше, юк — кеше!

Халик. Юк, баш сөяге генә түгел. Кешеләр кулларына балта тотканнар, өй салганнар, мылтык тотып еркычлардан сакланганнар, чәчү чәчкәннәр, тормышларын матурайтырга омтылганнар, хыялланганнар, зәңгәр күккә, кыр казларына караганнар. Менә үзең ясаган өй кәрнизенең өлгесен син, үзең дә белмәстән, көмеш битлектән алгансың... Ә кемнәрдер кешеләр тудырган матурлыкны үзенеке генә иттереп баю турында гына уйлаганнар... Әмма андыйлар, мал артыннан куып, җан матурлыгын югалтканнар...

Әкбәр. Тагын нәрсә калган?..

Халик. Кешелек җәмгыятен үстерергә, дәвам итәргә без калганбыз. Мәхәббәт калган. Бездән дә мәхәббәтнең матур ядкаре булып, балалар калыр. Балалар ничек булса, киләчәк шундый булыр...

Әкбәр. Ягъни мәсәлән, балаларың булмаса? Бик нык теләп тә...

Халик. Андый кешенең матур эшләре, кешеләргә булган мәхәббәте кала... Бәхетсез мәхәббәт тә кала...

Әкбәр. Мәхәббәт каламыни?

Халик. Урта Азиядә экспедициядә йөргәндә мин Назлымхан сараен күрдем. Аның диварында «барысы да югала, мәхәббәт кала» дип язылган. Имештер, мәхәббәтнең ни икәнен белмәгән явыз хан Назлымхан исемле чибәргә гашыйк була, әмма теләктәшлек тапмый — кыз сарайлар төзүче алтын куллы егетне ярата. Ярсыган хан, Назлымханга атап, егеттән сарай салдырта һәм егетне үтерер алдыннан диварга: «Барысы да югала, мәхәббәт кала» дип яздырта. Хан да, егет тә сарайны Назлымханга багышлыйлар. Күпме гасырлар узган, ә чибәр Назлымхан белән алтын куллы егетнең мәхәббәте һәйкәл булып калган... Явыз хан исә онытылган!

Әкбәр. И калыр мәхәббәт, и югалмас мәхәббәт, и вәссәлам! *(Кулында балта уйнатып эшли.)*

Халик. Малик эштән кайтканчы, мин бер әйләнеп килим!

Китә. Өй эченнән Ясминә чыга. Ул затлы, матур күлмәкләрен кигән, зиннәтле алка-муенсаларын таккан, иңнәрендә — чиләкле көянтә. Ул бик яшь, чибәр күренә.

Әкбәр *(балтасын куеп, гаҗәпләнеп аңа карап тора да, кыюланып аңа каршы төшә).* Ясминә...

Ясминә. Әбәү лә... кем бу?

Әкбәр. Бу мин...

Ясминә. Әкбәр... шулай иртә килдеңме?.. Ә мин, кеше-фәлән уянганчы, чишмәгә барып килмәкче идем...

Әкбәр. Мин синең менә шулай элеккечә Ясминә булып чыгуыңны ничә еллар көттем, Ясминә... Син яшь, мөлаем, нәкъ мин яраткан Ясминә...

Ясминә. Әкбәр, син ни сөйлисең, әллә иртән үк эчтеңме?

Әкбәр. Юк, Ясминә, бер тамчы да эчмәдем... Әмма сине күргәч, ачуланма, бер җырлыйм әле... *(Җырлый.)*

Тамыр җәйдең, чәчкә атмадың
Йөрәгем уртасында...

Ясминә. Бу хакта сөйләшергә соң инде, Әкбәр... Мин инде чәчкә ата алмыйм... Әкбәр, нигә син өйләнмисең?

Ә к б ә р. Шушы яшькә җитеп аңладым: ярату бер генә була икән, синнән башка берәүне дә ярата алмадым... Өйләнеп берәүне дә бәхетсез итәсем килмәде...

Я с м и н ә. Син мине шушы хәлемдә дә яратасыңмы әллә, Әкбәр?

Ә к б ә р. Менә, Ясминә, кара... сиңа булган мәхәббәтем шушы булып калсын! Мин аны сиңа атап салдым!

Я с м и н ә. Менә ни өчен син өй салган өчен акча алмыйсың икән... Ә мин әллә ниләр уйлап бетердем...

Ә к б ә р. Хәзер инде ачыктан-ачык сөйләшсәк тә була, Ясминә, әйт яшермичә, синең күңелеңдә миңа карата әз генә булса җылылык бармы?

Я с м и н ә. Син — дөнья бәясе кеше, Әкбәр, эчү сиңа бер дә килешми...

Ә к б ә р. Эчәм икән — ул да йөрәк янудан, Ясминә... Әйт, Ясминә, ачык кына, һич шикләнмичә, мин сезнең тормышны бозарга ниятләмим. Дөресен әйт тә бир, басылсын бераз йөрәк януы. Нигә син минем сугыштан кайтканны көтмичә, Маликка кияүгә чыктың? Исән-сау кайтсам, кыр казлары киткәндә туй ясыйбыз дип вәгъдәләр бирешкән идек...

Я с м и н ә. Минем үземне дә гомерем буе шушы сорау телгәли, Әкбәр... Син сорама, мин җавап бирмим...

Ә к б ә р. Шулай да син бәхетлеме Малик белән? Бөтен нәрсәң җиткән, тулы... Бәхетең йөзеңә чыккан... Әгәр дә бәхетле булсаң, мин сөенәм генә...

Я с м и н ә. Мин бәхетле булып кыланам гына...

Ә к б ә р. Малик сине бәхетле иттем дип уйлый, ә чынында алай түгел икән...

Я с м и н ә. Син күңелең белән һич тә аңа пар түгел, Әкбәр... аның белән бергә каравылда торып, өй салып йөрүеңне аңламыйм...

Ә к б ә р. Бары сине күрү өчен генә, Ясминә! Ерактан гына булса да, нурлы гәүдәңне күрү өчен, ягымлы тавышыңны ишетү өчен...

Я с м и н ә. Мин хәзер тормышымны үзгәртә алмыйм, Әкбәр. Син бит үзеңнән көчлерәк, Әкбәр. Хуш, исән бул, без башка болай очрашырга тиеш түгел...

Кыр казлары кычкырган тавыш ишетелә.

Ә к б ә р *(югары карап).* Кыр казлары... Ясминә... кара...

Я с м и н ә *(күккә омтылып).* Кая очалар алар? Китәргә иртә ич әле...

Ә к б ә р. Ел саен китәләр, кайталар... Безнең булмаган туйны хәтерләтеп очалар.

Я с м и н ә. Алар китәләр дә мени?

Ә к б ә р. Җәй салкын килде, китәләр...

Я с м и н ә. Хушыгыз, кыр казлары...

Ерактан җыр тавышы ишетелә.

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан...

Ә к б ә р. Ясминәм...

Я с м и н ә *(һаман күккә карап).* Хуш, яшьлегем, хыялым! Хуш, Әкбәр җаным! Мәңге гафу ит!

Кыр казлары артыннан китә. Әкбәр аның артыннан карап кала.

Ә к б ә р *(әшкә тотына).*

Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан... Их!

Малик кайтып керә. Кәефе — әйбәт.

Малик. Нихәл, Әкбәр дус?

Әкбәр. Әйбәт.

Малик. Эшләр барамы?

Әкбәр. Бара.

Малик *(утыра)*. Кил әле, ял ит бераз! Сөйләшик күзне-күзгә терәп...

Әкбәр *(балтасын тотып аның янына килә)*. Килдем.

Малик. Утыр әле!

Әкбәр *(утыра)*. Утырдым.

Малик. Тыңла!

Әкбәр. Тыңлыйм.

Малик. Яшибез, малай, ә?

Әкбәр *(мәгънәле)*. Яшибез...

Малик. Кеше ишетерлек итеп әйт, яшибез! Яшибез бит, малай, ә!

Әкбәр. Кем? Безме?

Малик. Без яшибез!

Әкбәр. Синең белән мин?

Малик. Кем булсын синең белән мин булмыйча? Без яшәмичә, Зөлхый яшәсенмени? Әллә бабасының баш сөяген эзләп килгән Халик яшиме? Замана — безнеке! Без яшибез дөньяның артына тибеп... Әнә, узган-барган бөтен кеше күреп тора: *(тактадагы язуны укып)* Биредә Ватан сугышы ветераны Малик Бикташев *(басым ясап)* яши!



Әкбәр, барып, коймасын төзәтергә тотына.

Тукта, син нишләп ул якка чыктың әле?

Әкбәр. Койма төзәтәм...

Малик. Кемнекен?

Әкбәр. Зөлхия түти коймасын.

Малик. Ә капка?

Әкбәр. Нинди капка?

Малик. Минем капка!

Әкбәр. Ул минем капка түгел. Синеке!

Малик. Син нәрсә, шаяртасың?

Әкбәр. Шаяртмыйм.

Малик. Каптыңмы?

Әкбәр. Капмадым!

Малик. Тәк. Ә капканы кем эшләр?

Әкбәр. Мин өй салып бирдемме?

Малик. Салдың. Рәхмәт!

Әкбәр. Кулыңа балта тота аласыңмы? Көчең бармы?

Малик. Ә?

Әкбәр. Тот та эшлә!

Малик. Син нәрсә?

Әкбәр. Ә менә ялгыз карчык Зөлхый түтинең иске өен, җимерек коймасын кем төзәтергә тиеш? Аның улы Камил...

Малик. Камилнең сугыштан кайтмавына мин гаепләме?

Әкбәр. Әйт: Зөлхый түтинең өен кем ремонтларга тиеш?

Малик. Авыл советы!

Әкбәр. Авыл советы — ул син, мин, Мөхәммәтәмин... *(Тыныч булырга тырышып.)* Иң беренче чиратта Зөлхый түтигә өйне син салып бирергә тиеш!

Малик. Мин!?

Әкбәр. Әйе, син!

Малик. Мин — Малик Зөлхыйга өй салып бирергә тиеш. Ха-ха-

ха! Өй салган өчен бәлки мин аңардан акча да сорамам? Синең кебек...

Әкбәр. Әйе, бушлай!

Малик. Бушлай булгач, син салырсың инде!..

Әкбәр *(усал)*. Син аңа өй салып бирәсең! Син!

Малик. Ярый, ярый, алайса: өй салырга кем ул миңа?

Әкбәр. Зөлхый түти — синең күршең, тол карчык...

Малик. Тол карчыклар — буа буарлык...

Әкбәр. Аның улы Камил — сине үлемнән алып калган...

Малик. Каян казынып таптың?

Әкбәр. Археолог абыйларың мең ел җир астында яткан серне дә ачалар... Камил да сине җир астыннан казып чыгарган...

Малик. Дөрес! Шуның аркасында мин сугышка барып җитәлмәдем, исән калдым... И шуның белән үземне бәхетле саныйм. Үземне генә түгел, мин хатынны, улымны да бәхетле иттем... Сине дә юньле юлга кертергә йөрим. *(Дустанә.)* Әкбәр дус, хәзер генә эш сөйләшеп кайттым. Күрше Урай авылында. Бәясеннән тормыйлар. Каравылдан чыгабыз да, балтаны тотып машинага гына утырып — вышт! Киттек, малай, иртәгә үк... Мә бишне! *(Кул бирә.)*

Әкбәр *(кулын алмый)*. Димәк ки, Зөлхый түти өен ремонтламыйсың?

Малик. Мин — җүләр түгел... Димәк ки, син минем капканы эшләп бетермисең?

Әкбәр. Юк!

Малик. Эшлисең!

Әкбәр. Син — хан, мин борынгы зират каравылчысы түгел!

Малик. Эшләмисеңме?

Әкбәр. Юк!

Малик. Иртәгә минем белән Урайга бармыйсыңмы?

Әкбәр. Юк!

Малик. Иртәгә каравылга чыгасыңмы?

Әкбәр. Юк! Мин хәзер үк председательгә барам. Күптән төзүчеләр бригадасына барырга уйлап йөрим. Иң беренче эшем итеп — Зөлхый түтинең өен ремонтлауны сорыйм!

Малик. Башка сүзең юкмы?

Әкбәр. Безнең ара өзелгән! *(Балтасын куя).*

Малик. Сыз моннан, йолкыш, эзең дә калмасын!

Әкбәр. Юк, Малик, ялгышасың, төзүче егетнең йөрәк җылысы, мәхәббәте *(өйгә күрсәтеп)* ядкарь булып калыр, ә явыз ханның эзе дә калмас! *(Чыга.)*

Малик *(артыннан кычкырып)*. Синнән башка да яшәрмен! *(Кулына балта алып, эшләргә тотына. Көянтә күтәреп, судан Ясминә кайта. Малик, балтасын куеп, Ясминәгә аптырап карап тора.)* Ай-яй-яй-яй... Нинди бәйрәм хөрмәтенә киендең шулай?

Ясминә. Туганыңның кайтуы бәйрәм түгелмени?

Малик. Андый туган белән кабереӊ якын булмасын — казып чыгарып адәм рисвае итәр...

Ясминә. Килешмәгәнне кыланма инде... атасы, болай да халык әллә ниләр сөйли, баш сөяге өчен талашып, канга батып беткәннәр, имеш...

Малик. Һаман шул бер Малик башын чәйниләрме? Мин талашмыйм, Халик! Чистый әфтәритне төшереп бетерде. *(Сарказм белән.)* Абый! *(Ясминәнең киемнәренә карап.)* Үз коебызның суы сиңа ярамаганмы? Чишмәгә нигә дип бардың инде? Гомергә киенмәгән киемнәреңне киеп, бизәнеп-ясанып... Үзеңне күрсәтергәме?

Ясминә *(чиләкләрен куеп)*. Шулай дисәм, ни әйтерсең?

Малик. Үзеңне күрсәтергәме?

Я с м и н ә. Әйе!

М а л и к. Кемгә?

Я с м и н ә. Кешеләргә!

М а л и к. Кешеләргә... Төкер һәммәсенә! Кирәк чакта килеп миңа беркем дә ярдәм кулын сузмады! Һәркем үзе өчен яши! Әнә, фронтка барган һәркемнең күкрәгенә медаль чәпәп чыктылар. Миңа — юк! *(Язулы тактага күрсәтеп).* Шушы такта кисәге өчен сугышып йөрдем, димәк ки? Үзләренең дә потлары бер тиен!

Я с м и н ә. Нигә дип син миңа бу зиннәтле киемнәрне, алкаларны алдың? Мактану өченме?

М а л и к. Мактанырлык та! Кем үзенең хатынына шундый бүләкләр ала!

Я с м и н ә. Үземнең дөньяда барлыкны белдереп, иремнең бүләкләрен киеп, авыл буйлап уздым... Күрсеннәр, янәсе... Күрделәр, бармак төртеп күрсәтеп, көлеп калдылар... Карагыз, хан хатыны суга бара!..

М а л и к. Көнләшүдән шартласыннар!

Я с м и н ә. Малик, син, чынлап та, минем тормыштан көнләшәләр дип уйлыйсыңмы әллә?

М а л и к. Ә? Нәрсә? Син канәгать түгелме шушы тормыштан? Алган чакта сүз бирдем! Ефәккә төрәм, дидем. Төрдемме ефәккә?

Я с м и н ә. Төрдең.

М а л и к. «Миңа кияүгә чыксаң, алтын-көмешкә күмәм!» — дип ант иттем. Күмдемме алтын-көмешкә?

Я с м и н ә. Күмдең. Ефәк кәфенгә урап, алтын-көмешләрем белән тере килеш күмдең...

М а л и к *(көтмәгән иде, аптырап).* Ясминә, туктале, син ни сөйлисең?.. Ни җитми? Бөтен нәрсәң җиткән, тулы, бу өйне мин сиңа атап салдым...

Я с м и н ә. Салдырдың...

М а л и к. Валлаһи, Малик сарае дип әйтерлек! Син дә шуңа канәгать булмасаң...

Я с м и н ә. Малик, нигә дип син мине алдың?

М а л и к. Авылда беренче кыз булганың өчен, Ясминә!

Я с м и н ә. Соң булса да, аңладым, син мине машина алдым, төсле телевизор алдым, кер юу машинасы алдым, тузан суырткыч алдым, дип мактанган шикелле. Ясминәне алдым дип, күкрәк сугар өчен алдың... Янәсе, мондый әйбер авылда миндә генә!

М а л и к. Туеп сикеренәсең? Рәхәткә чыдамыйсың?

Я с м и н ә. Әйе, мин әйбер... Синеңчә, затлы әйбер... Халик абый әйтә: элек ханнарны затлы әйберләре белән бергә күмгәннәр, ди... Малик, син оныттың, кайчандыр минем тыпырчынып торган кайнар җаным бар иде!..

М а л и к. Мол-чать!

Я с м и н ә. Син мине суыткыч шикелле бер әйбергә әйләндердең...

М а л и к. Тузса — суыткычны алыштырып була...

Я с м и н ә. Ә менә сине алыштырып та булмый!

М а л и к. Башка сүзең юкмы?

Я с м и н ә. Юк!

М а л и к. Кер өеңә! Югал!

Тынлык. Ясминәнең авыр икеләнү кичергәне күренә. Еракта кыр казлары кычкырган тавыш һәм таныш җыр ишетелә.

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан...

Я с м и н ә. Китәләр... Китәләр! *(Тагын Маликка карый. Аннан, язмышына буйсынып, акрын гына өй эченә кереп китә).*

М а л и к *(капка янына утыра).* Кыр казлары артыннан... Болын кебек өй... Кабер салкынлыгы... Ах! *(Йөрәген тота. Торып, ярсу белән балтасын баганага кадый.)* Бетте! Иң якын дус дип йөргән Әкбәр ташлады... Таянычым дип йөргән хатынга ышаныч бетте! Әле дә ярый улым бар!.. Улым бар!.. *(Капка эшләргә тотына.)* Малик әле озак яшәргә җыена! Малик капкасыннан бәхет керүен керер, әмма чыкмас! Теләсә дә чыгармас Малик. *(Үзе дә сизмәстән.)*

Кара дуга, пар кыңгырау
Безнең атларда гына... Тьфу!

Х а л и к *(керә, Әкбәр дип белеп).* Әкбәр... *(Малик борылып Халикка карый, әмма эндәшми.)* Ә мин Әкбәр дип торам... Син икән, Малик! Кайттыңмыни? Хәлләрең ничек? *(Капка янына утыра.)* Сөйләшик әле бер туганнарча... утырып...

М а л и к *(утырмый, Халикка текәлеп).* Халик, нигә син кайттың?

Х а л и к. Сине, туганнарны сагынып...

М а л и к. Әйт, нигә син мине казып чыгардың?

Х а л и к. Син борынгы кеше түгел, Малик... Шулай да син үзеңнеүзең күмә барасың, туганкай...

М а л и к. Син зират казырга кайттыңмы?

Х а л и к. Мин сине коткарырга телим...

М а л и к. Син кайтканчы тып-тыныч яшәдем. Кайттың — бер көн, бер төн, тавыш-гауга, җәнҗал! Минем тормышны нигезеннән җимерергә кайткансың икән, туган абый!

Х а л и к. Бер көн эчендә нигезне җимерү мөмкин түгел. Димәк, тормышыңның нигезе дөрес салынмаган...

М а л и к. Минем нигезем менә монда — монда мин яшим!

Х а л и к. Бабаларыбыз, аталарыбыз безгә җир-туфрак кына калдырмый, шуның өстенә алар безгә кул белән тотып булмый торган ядкарь — бабаларының йөрәгенә күчеп кала торган иң изге орлык — мәхәббәт, матурлык рухы калдырганнар. Җаныңда әнә шул орлык корып бармыймы икән? Уйлаганың юкмы?

М а л и к. Мин тел белән тегермән тартып яшәмәдем, мин хәләл көчем белән, шушы саф кулларым белән мал табып яшәдем. Бүген мине дустым дип йөргән Әкбәр ташлап китте! Дүрт ягы кыйбла! Аны син котырткансың... Зөлхый улы Камилнең мине казып чыгаруын син генә беләсең! Ни пычагыма кирәк булды шуны казып чыгарырга!

Х а л и к. Дөньяда без оныткан, әмма онытырга тиеш булмаган нәрсәләр бар, Малик энем... Онытмыйк, без җирдә Камилләр өчен дә яшибез... Әгәр дә кешеләр үзләренең көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен генә яшәсәләр, кешелек һаман тау куышында яшәүче борынгы кеше дәрәҗәсендә калыр иде.

М а л и к. Миңа үз куышымда җылы, рәхәт иде... Хәзер анда кабер җиле исә... Синең аягың авыр булды... Яхшылык белән әйтәмҗүнле чакта сыз моннан!..

Х а л и к. Син моны... миңа, абыеңа әйтәсеңме?

М а л и к. Юк, абыема әйтмим...

Х а л и к. Мин сиңа кем? Туганмы? Әллә...

М а л и к. Туган булганчы, тумаган булсаңчы... Юк минем абыем, юк!..

Х а л и к. Ярый, хуш. Син абыеңны туган итеп санамыйсың... Шулай да булсын, ди... *(Авыр сулап).* Абый буларак, мин синнән китәм... Ә археология отряды җитәкчесе Халик Бикташев буларак, мин сездән китмим, Малик Бикташев! Рәхим итегез, менә минем рәсми кәгазьләрем... *(Документлар чыгара.)* Минем сезгә ике үтенечем... Юк...

Таләбем бар... иптәш Бикташев... Беренчесе — фәнни әһәмияте барлыкны искә алып, без тиздән баш сөяге һәм көмеш битлек табылган урынны казырга тиеш булабыз! Сез каршы килмисезме, иптәш Бикташев?

М а л и к *(балтасын күтәреп).* Болай да җитәрлек казындың! Шушы баскан урынымнан бер карыш та артка чигенмим, аңлашылдымы? Милиция алып килсәң дә кузгалмыйм! *(Исе китмәгән кыяфәттә багана эшләргә тотына.)*

Х а л и к. Отрядның икенче таләбе: фәнгә кирәк булуын искә алып, җир казыганда табылган көмеш битлекне Сез безгә бирергә тиешсез!

М а л и к. Көмеш битлек? Бик кирәкмени? Мин сораган сумманы алып килдегезме соң, академик иптәш?

Х а л и к *(акча чыгарып).* Рәхим итегез...

М а л и к *(әшеннән туктап).* Әһә... Болай булганда уйлап карыйбыз. Хәзер алып чыгам мин аны... *(Кереп китә дә көмеш битлекне алып чыга.)* Шулмы?

Х а л и к *(омтылып).* Әйе. Шул! Бирегез!

М а л и к. Тәки акча таптың әле?.. *(Елга ярына якынлаша.)* Ә миңа синең борынгы таныш-белешләреңнән сорап җыйган тәңкәләреңнең сукыр бер тиенгә кирәге юк! Бу — минем мөлкәт! Теләсә нишләтәм! Телим икән — биткә киям! *(Кия.)* Я, таптыңмы эзләгәнеңне? Таптыңмы? Битлек кигән шушы адәмне казып чыгардыңмы? Ә минем ул адәм белән очрашасым килми, беләсеңме шуны? Миңа борынгы бабаң да, үзең дә кирәк түгел! Минем алтын-көмеш, мал калдырырлык туганым юк! Менә, мә сиңа көмеш битлек!

Әйләндереп тора да, текә ярдан елгага ыргыта.

Х а л и к *(битлек артыннан ташланып).* Тукта! Акылыңа кил! Их!.. *(Маликның өстенә бара.)* Нишләдең син, ә?.. Нәрсәне югалтканыңны беләсеңме? *(Өстенә килә.)* Мин сине... моның өчен...

М а л и к *(балта тотып).* Якын киләсе булма...

Ядкарь йөгереп керә.

Я д к а р ь *(кычкырып).* Халик абый... Малик абый!..

Дәринә чыга.

Д ә р и н ә. Ни бар?

Халик та, Малик та җавап бирми.

Я д к а р ь. Халик абый... Дәринә... анда фаҗига...

Х а л и к. Ни булды?!

Малик капка янында утыра.

Я д к а р ь. Урайдан кайтканда Зөлхия әбинең йөрәгенә кинәт приступ...

Д ә р и н ә. Зөлхия әби?.. Ул... исәнме?!

Х а л и к. Кайда ул? Киттек!

Я д к а р ь. Юлда очраган машинага салып, больницага алып бардык. Ләкин врачлар коткара алмадылар...

Д ә р и н ә. Зөлхия әби!... *(Битен куллары белән каплый).*

Я д к а р ь. Аны үлемнән коткарырга мөмкин иде. Зөлхия әбинең хәле авырайгач, узып баручы машинаны туктаттык. Ул — Рим булып чыкты. Мин аннан Зөлхия әбине Урайдагы больницага илтүне үтендем. Әмма ул, «ашыгам, юл уңае түгел!» диде дә район үзәгенә китеп барды. Икенче машина килеп җиткәнче, ярты сәгатьләп вакыт узды, Зөлхия әбинең хәле тагын да начарланды...

Тышта машина тавышы ишетелә.

Рим *(йөгереп керә, кулында бокс перчаткалары).* Кайда теге Тутанхамон! *(Ядкарьны күреп, аның алдына перчаткалар ыргыта).* Мә! Киттек! *(Дәринәгә.)* Секундант! Шүрләдегез!?

Тынлык, беркем дәшми.

Дәринә *(Рим каршысына барып).* Син — үтерүче!

Рим. Ә? Нәрсә? Үтерүче?

Дәринә. Мин сине егет дип, кеше дип йөргәнмен...

Рим. Аңламыйм...

Дәринә. Син Зөлхия әбинең үлүенә гаепле, син!

Рим *(тыныч).* Зөлхый үлдемени? Шулай да булсын, ди... Монда минем ни катнашым?..

Ядкарь. Син аны йөрәгенә приступ булган хәлдә ташлап киттең. Аны коткару мөмкинлеге бар иде.

Рим. Карт кеше белән ни булмас... Минме? Минме гаепле? Мине нишләтерләр?

Дәринә. Таш бәгырьле генә түгел, куркак та икәнсең... Их, дөнья бәясе кеше иде Зөлхия әби!..

Рим *(Маликка).* Кара, болар мине гаепләп маташалар!

Малик. Карчык болай да бер аягы белән кабергә баскан ие... Бүген ычкынмаса, иртәгә дигәндәй... Курыкма! Мә, тот балтаңны!

Рим. Балта? Нигә ул миңа?

Малик. Капка ясарга!

Рим. Капкаңның миңа нигә кирәге бар?

Малик. Капканы ачып керүгә — атаң малы!

Рим. Нигә миңа мал? Миңа машина булса — җиткән!

Малик. Мин сиңа кем, башсыз малай?!

Рим. Үзең беләсеңдер!

Малик. Кем мин? Тот, мин сиңа әйтәм, балтаны!

Рим. Үзең тот!

Малик *(акрын гына).* Улым, тот балтаны... Әтиең әйтә бит... Бөтен өмет синдә! Әкбәр ташлады. Дүрт ягы — кыйбла! Минем уң кулым — син бар! Иртәгә үк Әкбәр урынына каравылга син барасың!

Рим. Бармыйм!

Малик. Берәүгә әйбәт бәягә йорт салырга сөйләштем. Әкбәр урынына — син!..

Рим. Бармыйм!

Малик. Син дә миңа каршы баш күтәрәсеңме, башсыз малай! Кем монда хуҗа? Атамы?

Рим. Хуҗа монда — мин! Син инде бер аягың белән кабергә баскансың...

Малик. Ә?.. Син әле шулаймы? Колагыңнан тартып аякка бастыргач, ата кирәк түгел?!

Рим. Күп телеңә салынма! Вакыт юк! Мин китәм!

Малик. Китәсең? Кая?

Рим. Машина — минеке! Акча сугарга!

Малик *(йомшап).* Улым... Тукта... сөйләшик... Инде син дә карт атаңны ташлыйсыңмы? Җаның бармы синең? Син уйнапмы, уйлапмы?

Рим. Прощай, кенәз!..

Малик. Кит! Югал! Машинаны калдыр!..

Рим. Мал булгәндә, машина барыбер миңа эләгәчәк... Сиңа нигә машина? Син анда җәяүләп тә барaласың!

Малик. Кит!..
Рим *(Дәринәгә).* Алып китәм! Барасыңмы? *(Дәринә дәшми, аңа нәфрәт белән карап тора. Ядкарьга, Халикка)* Ә сезнең белән, академиклар, тормыш юлларында очрашырбыз! *(Ядкарь алдыннан перчаткаларны ала.)* Дуэль — үз көчендә! Чао! *(Чыга).*
Малик. Атасыз яши алсаң да, малсыз яши алмассың... Кайтырсың! *(Халикка)* Син, ата нигезенә килеп, бөтенесен айкадың, ниятеңә ирештең...
Халик. Ни калдырдың син киләчәккә, кемне калдырдың?!.
Малик. Мин беркемгә дә, бернәрсә дә калдырмыйм! Миннән васыять көтмәгез! Бер кадак та!.. Ә хәзер... китегез... Барыгыз да китегез.. *(Картайган, хәлсезләнгән кыяфәттә акрын гына өй эченә кереп бара.)*
Ядкарь. Халик абый... без... китәбез?
Халик. Әйе, Ядкарь, базада безне төп эшебез көтә... Машинаны төзәткәч, син дә кайтырсың...
Ядкарь. Ә көмеш битлек?
Халик. Көмеш битлек тагын эзсез югалды.
Ядкарь. Ничек? Югалды?
Халик. Ул аны елгага ташлады!
Ядкарь. Елгага ташлады?!
Халик. Моннан да яманрак вариантның булуы мөмкин иде. Борчылма, Ядкарь, без көмеш битлекне табарбыз! Базага кайткач, мин мондагы табылдыклар турында җитәкчебез белән киңәшермен. Ышанам, без монда тагын килербез! Килербез!
Ядкарь. Килми мөмкин түгел!
Халик. Сез Ак бабайдан легенданы язып алдыгызмы?
Ядкарь. Өлгерә алмадык. Ул дөньядан китеп барган. Әмма мин өмет өзмим! Легенда шушы төбәктә яшәргә тиеш!
Халик. Әйе, инде очраштык дигәндә, борынгы кешенең эзләре тагын югалды...
Ядкарь. Аның каравы, бүгенге заман неандерталецын[1] казып таптык! Отчетка кертәбезме, Халик абый?
Халик. Бу табылдыкны бернинди отчетка да кертеп булмый, Ядкарь! Ул минем вөҗданымда кала. Үз гомеремдә мин җир астында калган йөзләгән авылларны, калаларны таптым, ташларга язылган, беркем укый алмаган хәрефләрнең серләрен ачтым, җиргә күмелгән тәңкәләрнең даталарын ачыкладым! Җир астында ниләр генә тапмадым! Борынгы заманда кемнәр яшәгән, ничек яшәгән? — мин гомерем буе шул сорауга җавап бирү белән мәшгуль булдым. Ә менә борын төбендәге туганым җир өстендә ничек яшәгән — шуны белмәгәнмен... Бу үз гомеремдә ачылган табылдыкларның иң көтелмәгәне, иң авыры... Хәзергә хуш, Ядкарь... Зөлхия апаны хөрмәтләп, соңгы юлга озат... Минем исемнән дә... *(Кыр казлары каңгылдашкан тавыш.)* Хуш, Ядкарь!

Кыр казлары артыннан китә.

Ядкарь. Хушыгыз, остаз!

Баскычта Малик күренә. Ядкарь Маликка аркасы белән тора.

Малик *(Ядкарьга карамыйча).* Кем бар анда? Син кем?
Ядкарь. Мин — узып баручы кеше!
Малик. Каян киләсең?

---

[1] Неандерталец — хәзерге кешенең беренче бабасы.

Я д к а р ь. Борынгы заманнан!

М а л и к. Кая юл тоттың?

Я д к а р ь. Киләчәккә!

М а л и к. Нигә монда тукталдың?

Я д к а р ь. Киләчәккә барганда бер уйланып алу өчен туктадым.

М а л и к. Сиңа кем кирәк?

Я д к а р ь *(язулы тактага карап).* Малик Бикташев дигән кеше бирелә *(басым ясап)* яшиме? Яшиме?

М а л и к. Юк, ул монда яшәми! Яшәми!

Я д к а р ь. Малик Бикташев дигән кеше монда яшәдеме?

М а л и к *(«Биредә Ватан сугышы ветераны Малик Бикташев яши» дигән язуны ала).* Чыннан да, яшәдеме?.. Яшәдеме?!

Караңгыланып калган өй эченә кереп югала. Еракта — Кама өстендә — салават күпере нурлана.

Д ә р и н ә *(Ядкарь каршына йөгереп килә. Туктап, кайгылы-сөенечле күз яшьләре белән).* Ядкарь!..

Я д к а р ь. Дәринә!..

Д ә р и н ә. Сез китмәдегезмени?!

Я д к а р ь *(Дәринә каршысына бара-бара).* Мин моннан ничек китим ди, Дәринә? Югалтуларым да, табышларым да монда! Мин монда тормышымдагы иң гүзәл табышны — сине таптым! Узганым да, киләчәгем дә шушында — борынгы бабаларыбыз нигезендә! Матурлык өчен, киләчәк өчен дуэль дә шушында булачак! Биредә кайчандыр яшәп җирдә матурлык калдырып киткән Бакыйлар, Камилләр һәм монда бүген яшәүче, көрәшүче Халик абыйлар рухы яшәр! Мин моннан ничек китим ди, Дәринә?!

П ә р д ә

Җәмит Рәхимов

# КҮПЕР

Кама буе — туган як,
Гөлләр үсә торган як!
Гүзәллеге күңелләрдән
Җырга күчә торган як.



Әйтәсе дә юк, нинди гүзәл, ниндиен мәһабәт елга ул безнең Кама! Аның ярында басып торганда күңелдә туган канатлануны, омтылуны, шатлыкны тел белән генә аңлатып бирү мөмкин түгел. Шуңа да халык аның матурлыгын, мәһабәтлелеген, бөеклеген җырларда җырлаган, дастан итеп сөйләгән.

Зурлыгынмы? Әйе, Кама Иделнең иң зур кушылдыгы, аның озынлыгы ике мең километрга якын, югары агымында ук елганың киңлеге урыны-урыны белән дүрт йөз метрга җитә. Ә инде Агыйдел килеп кушылгач, аның ярлары бер-береннән ике чакрымга кадәр ераклаша, тирәнлеге инде унбиш-егерме метр тәшкил итә. Каманың бассейны ярты миллион квадрат километрдан артыграк.

Алкынлыгынмы? Ихтимал. Удмуртиянең төньягында кечкенә генә Карпушата дигән авыл кырыенда мәгърур утырган карт каен төбеннән күз яшедәй саф сулы чишмә бәреп тора. Ул, юлында очраган чишмә-инешләрнең суын үзенә куша-куша, төньякка таба ага, исемен телгә алырлык елгага әверелә. Аннан: «Барлык зур елгалар Боз океанына коя ич», дигәндәй, кисәк кенә уңга борылып, зур гына кармак ясый да, кара урманнар эченнән, Урал тауларыннан агып чыккан бихисап вак елгаларның суын җыя-җыя, Пермь өлкәсе буйлап кабат Удмуртиягә ашкына, Татарстан җиренә килеп керүгә, икенче бер гүзәл — Агыйдел белән кавыша һәм республикабызны урталай ярып диярлек Иделгә омтыла. Татарстан буйлап ул өч йөз сиксән чакрым юл үтә. Кама төньяктан — кара урманнар, Урал чытырманлыклары ягыннан килә, бөтен буена диярлек шул яшел хәзинәдән аерылмый, шуңа суы мул, агымы саллы. Хисапсыз чишмә-инешләрне, вак елгаларны әйтеп тормастан, аңа Вишера, Ык, Иж,

Буй кебек эрерәкләре дә коя, ә Вятка белән Агыйдел үзләре генә дә елына 56 миллиард кубметр су китерәләр. Кама үзе исә Иделгә елына 130 миллиард кубметр, ягъни Иделнең үзеннән күбрәк су алып килә. Кайсы төп елга, кайсы кушылдык икәнен бар аерып кара син аларның.

Юмартлыгынмы? Бик мөмкин. Кама буе — илебезнең бик мөһим хуҗалык районнарыннан берсе. Мондагы хәзинәне кыскача гына санап чыгу да күп нәрсә турында сөйли: калий һәм аш тозы, ташкүмер, алмаз, төрле-төрле металл рудалары, нефть, электр энергиясе һәм менә инде куәтле йөк машиналары... Кама буеның дугалы атларны күмешле иген басуларын, Минзәлә, Актаныш күмәчен кемнәр белми! Урман һәм агач материаллары, кәгазь тагы! Кама бассейнында урманнар унбиш миллион гектарны биләп тора. Төньякта ул чыршы һәм ак чыршыдан торган тайга, комлырак урыннарда Себер агачлары — эрбет чикләвеге һәм карагай катыш наратлар. Елга көньякка авышкан саен, аның ярларында ылыслылар янында тар һәм киң яфраклы агачлардан торган урманнар башлана. Каманың түбәнге агымында исә инде юкә, имән, өрәңге, каен, усак, элмә, карама гына үсә. Шулай да Алабуга тирәсендә чыршы һәм ак чыршыдан торган урманнар очрый әле. Урман чытырманлыклары арасындагы дистәләрчә леспромхозлардан Кама ярына туктаусыз агач килеп тора. Алар бирeдә уннарча мең кубметрлардан торган салларга бәйләнә. Җәен инде сал кәрваннары берөзлексез түбәнгә — көньякның урмансыз районнарына ага, кайберләре — тазараклары — Каспий диңгезенең хәтәр дулкыннарын кичеп чыга, Кавказ тауларына барып җитә. Кама буеның яшел хәзинәсе Красновишерск һәм Соликамск комбинатларында эшкәртелеп, кәгазь рәвешендә бөтен илебезгә тарала. Матди байлыклардан тыш Кама хезмәт ияләренә сәламәтлек тә өләшә. Аның ярларында — күп кенә санаторийлар һәм ял йортлары. Ижевск минераль чишмәсе курорты исә ашказаны авыруларын дәвалау буенча тирә-якта дан тота.

Әллә соң тарихымы? Булыр да. Кама буеның искиткеч байлыклары, җәнлек тиреләре сәүдәгәрләрнең күзен бик борынгыдан яндырган. Новгород һәм Мәскәү купецлары төрле-төрле юллар белән елганың югарыгы агымына барып чыккан, Урал һәм төньяк халыклары белән сәүдә иткән. Унбишенче гасыр башында монда бертуган Калинниковлар тоз чыгару эшен башлап җибәргән. Казан ханлыгы җиңелгәч исә, Кама чын-чынлап Урал капкасына әверелгән. Эшкуар Строгановлар биредә күп күләмдә тоз чыгаруны җайга салганнар, күпләп балык тотуны оештырганнар. Бу яктагы борынгы шәһәрләрнең исемнәре дә тозга бәйле: Усолье, Сольвычегодск, Соликамск... Кама буйлап Уралга ачкүз Демидов тозагына төшкән тоткыннар узган. Таш билбауда бер-бер артлы заводлар барлыкка килгән, ә түбәнгә — Россия үзәгенә тимер-чуен әйберләр, туплар, башка кораллар аккан.

Халык күңелендә — болгар бабаларыбызның нигезләре, ил азатлыгын даулап йөргән азаматларның якты истәлеге саклана. Кама буенда Россиянең данлы кызлары: кавалерист-кыз, фельдмаршал Кутузов ординарецы Надежда Дурова, шагыйрә Марина Цветаева мәңгелек йокыда. Бу якларда Пугач полковнигы Бәхтияр баһадир, илебез фәненең даны һәм горурлыгы Дмитрий Менделеев, В. И. Ленинның дусты һәм көрәштәше Надежда Крупская, герой-шагыйрь Муса Җәлил, рәссамнар Шишкин һәм Максимов, башка бик күпләрнең эзләре, якты истәлекләре. Елга ярында егерменче гасырның иң зур төзелеше — Кама автомобиль заводы.

Матурлыгын, мәһабәтлегендер? Мөгаен, шулай. Кама буйлап теплоходта узганыгыз, «Тарловка» санаторие янындагы текә ярга ба-

сып, бу бөек елгага, иксез-чиксез су өстенә, зәңгәр рәшә булып ерак-еракларга сузылган урманнарга карап торганыгыз, елга буенның бормалы юлларыннан җәяүләп узганыгыз, Минзәлә ягындагы болыннарда печән чапканыгыз, тугай күлләре буенда ауда йөргәнегез, шул болыннардагы яшел ястыкка ятып аунаганыгыз бармы сезнең? Шул рәхәтлекләрнең берсен генә татысагыз да, Кама буе мәңге күңелегездән китмәс. Инде бәрәкәтле бу якларда булганыгыз юк икән, гафил калмагыз, киләсе җәйдә үк ял алыгыз да, куанычтай ак теплоходта, яисә йөгерек «Метеор»да узыгыз елга өстеннән. Гомер кармак тотканыгыз булмаса да, ау кирәк-яраклары алып, елга буена чыгыгыз, балык бер генә тапкыр чиертмәсә дә, көн буе ярда утырыгыз, йокысыз төн уздырыгыз, Кама таңын каршылагыз. Күптән онытылып беткән чыбык очы кардәшегезне хәтергә төшерегез дә Минзәлә ягына барып чыгыгыз. Ярдәмгә килдем дигән булып, болында билдән үскән печәнне тезмгә салып карагыз. Аннан ярның иң текә җиренә басып, Кама киңлекләрен күзәтегез. Менә шунда гына бу якның үзенә бер хуш исле һавасын татырсыз, башы болытларга тигән ак чыршы ябалдашлары астында назланырсыз. Мондагы урман чытырманлыклары арасына әллә нинди серләр, әкиятләр яшеренгән төсле. Менә хәзер Тукайның Шүрәлесе килеп чыгар, Шишкинның аюлары күренер сыман. Бу яктагы тугай-әрәмәлекләр тагы! Ул андагы карлыганнарның каралыгы, шомыртларның тәмлелеге, җиләкләрнең үлән арасында тәгәрәшеп ятуы, ул миләш-баланнарның әллә каян ымсындырып торуы, ул печән чүмәләләренең хуш исе! Юк, Кама буеның матурлыгын язып кына аңлату мөмкин түгел, аны үз күзләрең белән күрергә, үз күңелең белән тоярга кирәк.

Әлбәттә, әнә шуларның барын да үз итә, ярата халык. Миңа калса, мондагы һәр нәрсә, һәр истәлек Кама буеның комына кадәр каderле. Шулай да бу якларның тынгысызлыгы, бирелгәге хезмәт ыгы-зыгысы тарта төшә минем күңелне. Кама буенда — Чистайда дөньяда иң төгәл сәгатьләр эшләнә, Менделеевск заводында илледән артык төрдә химия продукциясе җитештерелә, Алабуга һәм Бондюг якларында «кара алтын» чыгарыла. Карт Чаллының боегып калган агач йортлары кырыенда ук тугыз-унике катлы өр-яңа ак кала күтәрелде, шәһәр янәшәсендә үк калкып торган гигант заводның җыю цехыннан «КамАЗ» маркалы машиналар чыгып чаба. Чаллы күршесендә генә яшьлек каласы Түбән Кама. Анда синтетик каучук, автомобиль шиннары эшләнә. Бераз арырак Европада иң зурлардан саналган Зәй ГРЭСы. Аның плотинасы кырыеннан ук нефть скважиналары башланып китә, асфальт өслекле олы юл республикабызның нефть районнарына илтә. Кама буеннан башланып, Оренбург өлкәсе чигенә барып тоташкан шушы гаять зур промышленность комплексы көнен дә, төнен дә шаулый, гөрли, чыңлый. Шулай, тынгысыз як бу, игелекле як, бәрәкәтле як!

Тукта, чамадан тыш хыялланып кителде бугай. Шулай инде, Кама ярында кеше елганың гүзәллеген-илаһилыгын гына, игелеклелеген-бөеклеген генә күрә. Ә бит уйлап баксаң, шушы ук Кама — олы бер су киртәсе — күпме кыенлык-мәшәкатьләр дә ясап килде.

Бүген менә, Кама буен зәгъфран, гәрәбә, әфлисун төсләренә бизәп, илебезгә муллык алып бай көз килгәндә, шушы кыенлык-мәшәкатьләр бары бергә кинәт кенә юкка чыкты — гасырлар буе бераүгә дә баш бирми җөгәнсезләнеп аккан мәгърур елга сабырланып калды: Прометейлар ихтыярына, Алыплар көченә, Сократлар зирәклегенә ия совет кешесе, Туган ил, партия, Ленин акылы, бүгенге заман фәне-техникасы белән коралланган совет кешесе тезгенләде аны.

Әнә ул «тезген» — Кама өстеннән утыз метрлар калкып торган бетон умырткалы дамба — бередән, минем аяк очыннан ук башланып, алкын елганың гомерлек юлына аркылы яткан. Дамба да, аның бер өлеше булып сузылган ГЭС бинасы да, гигант гидроузелның башка корылмалары да инде әзер диярлек. Тик урта бер җирдәге йөз илле метрлар чамасы киңлектәге «китек» кенә томаланмаган. Шуңа да Каманың ярсу суы иректә әле, ул йөзләрчә чакрымнарга сузылган су саклагычка җәелмәгән. Алай да елга кысрыклауларын, үзенә авызлык кидерергә маташуларын сизә, шуны өнәмичә, дәһшәтле улап, китектән түбәнгә ташлана. Гидротөзүчеләр исә аның ярсуын, үзен җөгәнләтмәскә тырышуын гүя сизмиләр, аны соңгы штурмга әзерлиләр.

Бер канаты аръяктагы зәңгәрләнеп торган урманга кереп югалгандай тоелган дамба буйлап алга атлаганда күзем баганадагы күркәм плакатка, эре хәрефләр белән язылган сүзләргә төшә: «Каманы буарга ике көн калды!» Күр инде, илкүләм олы эш хакында гап-гади дүрт-биш сүз белән язып куйганнар. Ә бит йөзләрчә инженерларның, техникларның, экономистларның, галимнәрнең җентекле хезмәтләрен, кыю фикерләрен, уй-исәпләрен, күп меңнәрчә эшчеләрнең күкрәк көчләрен, миллионнарча ат көчен туплаган машина-механизмнарның куәтләрен таләп иткән эш бу. Фәнни-тикшерену институтлары коллективларының, белгеч-галимнәрнең тырышлыгы белән барлыкка китерелгән дүрт-биш томлы проект турында фикер йөртмичә, менә бередә, елга өстендә башкарылган эшләрне генә күз алдына китерергә тырышып карыйк. Каманы буу ул — балчык бөяләр белән елганы бер тарафка кысрыклап, шул дамбалар белән уратып алынган мәйдандагы суны суыртып алу. ГЭС бинасы урнашачак шушы урынны казып, утырма балчыкны, комны башка җиргә күчерү; ныклы токымнарга — материк токымнарына тоташ бетоннан коелган нигез салу, аннан көнне төнгә ялгап, атналар-айлар буе корыч һәм бетон ташып, биеклеге—бораулау вышкасы, буе ярты чакрым чамасы станция бинасы салу; шул ук вакытта һәркайсы 78 мең киловатт егәрлекле уналты турбина, дистәләрчә арыкларны ачу-ябу җайланмалары, берьюлы берничәшәр йөз тонна йөк күтәрешле краннар һәм хәзерге заман гидроузелы өчен кирәкле бихисап башка механизм-приборлар монтажлау дигән сүз.

Елганың юлын томалау өчен тагын, Кама төбеннән исәпләгәндә, утыз-кырык метр биеклектәге, як-ягы бетон белән түшәлгән өч чакрымлы плотина, ике рәт суднолар үтеп йөрешле шлюз, аванпорт, РСФСР Елга флоты министрлыгының ремонт-эксплуатация базасы һәм портка килү юлларын саклый торган дүрт-биш километрлы дамба корырга кирәк. Әнә шул эшләрне башкарганда казып алынган балчык, ташып өелгән ком-таш, салынган бетон һәм тимер-бетон миллионнарча кубметрлар белән исәпләнә монда. Менә шушы инде ул Каманы буу дигәнең!

Әле болары да менә моннан — дамба өстеннән күренеп торганнары гына. Ә су саклагыч урынын хәзерләү кебек берничә елларга сузылган эшләр тагы. Анысы, ай-һай, мәшәкатьлесе, ай-һай, күп хезмәт сорый торганы. Алай гынамы, ыгы-зыгылысы, ызгыш-талашлысы. Шөкер, алары да инде артта калды: су басу зонасына кергән 2850 квадрат километрдагы мәйданда урман-әрәмәләр кисеп ташылды, чистартылды, 134 авыл һәм поселокны — барысы 13200 йортны, 139 колхозны, 21 совхозны һәм ике йөзгә якын башка объектларны, юл-күперләрне, электр-элемтә линияләрен, каберлекләрне күчерергә туры килде. Шушы эшләргә ГЭС төзүгә каралган чыгымнарның яртысы диярлек —368 миллион сум акча тотылды.

Тагы берничә көннән олы бер диңгез хасил булачак монда! Аның

киңлеге күз күреме җиргә җәелеп, озынлыгы Кама буйлап — 283, Агыйдел буйлап 205 километрга сузылачак. Яңа «диңгез»нең бөтен параметрлары да күптән зур төгәллек белән исәпләнгән инде: 13800 миллион кубметр су тупланып, өслеге генә дә 2651 квадрат километрга җитәчәк! Һәм бетон бođрага алынган шул көч-гайрәт халыкка хезмәт итәчәк.

Әле егерменче елларда ук — Совет республикасына Антанта тырнагы сузылганда, Идел буенда коточкыч ачлык хөкем сөргәндә, больницалар тиф чиреннән җәфаланучылар белән тулып, крестьян өйләрен чыра яктырткан чорда, бөек Ленин җитәкчелегендә ГОЭЛРО планы эшләнә һәм чынбарлыкка әверелә башлый. Утызынчы елларда исә «Зур Идел» планы туа. Бу план, Иделдә, Камада һәм башка елгаларда суднолар йөртү эшен яхшыртудан тыш, энергетика, басуларны сугару хаҗәтен, искиткеч зур районны су белән тәэмин итү һәм башка күп мәсьәләләрне күздә тота. «Зур Идел» — ул олы-олы су саклагычлар да, Идел буендагы коры далаларны сугару да, Мәскәү һәм Казан кебек зур калаларны биш диңгез порты итү дә, Мәскәү исемендәге, Идел-Балтика, Идел-Дон каналлары да, Европаның иң зур елгасы саналган Иделдән океанга чыгу мөмкинлеге дә, ВАЗ һәм КамАЗ кебек гигантлар, яңа калалар да, балык үрчетү бассейннары, Үзәк Россиядә флора һәм фауланы саклап калу заповедниклары да, ниһаять, дистәләрчә гидроэлектростанцияләр дә. Соңгыларын инде тиз генә санап чыгышлы да түгел. Идел-Кама каскадында гына күпме алар. Иваньково, Углич, Рыбинск, Горький, Куйбышев һәм Волгоград ГЭСлары. Менә инде Камада өченчесе сафка басты. Тагы Чабаксар ГЭСы, Астраханьнан астарак Иделдә иң көньяктагы гидроузел һәм Югары Кама ГЭСы төзелгәч, Идел һәм Кама тоташ күлләр тезмәсеннән торган искиткеч мул су хәзинәсенә әвереләчәк. Төньякка ага торган елгалардагы суның бер өлешен Каспий диңгезенә бору да шул ук «Зур Идел» планы бит ул. Әйтик, Печора елгасы суының бер өлешен Камага юллагач, Чаллы янындагы ГЭСның гына да куәте тагын кырык процентка артачак.

...Көзге салкынча иртә. Октябрь кояшы әле офыктан күтәрелергә өлгермәгән, ә Кама буе инде сабан туе мәйданына охшап калган. Бәйрәмчә киенгән халык, плотина турындагы ярга гына сыешмыйча, гидротөзүчеләр поселогының елгага якын урамнарын да тутырган. Бүген соңгы ыргым, ярсу Камага соңгы һөҗүм — плотинадагы йөз илле метрлы «китек» томаланып, алкын елганың гомерлек юлы ябыла! Моның өчен бар да әзер инде: яр буена меңнәрчә тонна таш, тимер-бетон ватыклары, махсус ясалган бетон пирамидалар ташып куелган. Вакытлыча ясалган бөя ерылып, котлован су белән тутырылган, ә әлеге «китек»нең ике яры йөзмә күпер белән тоташырылган.

Менә штурм сәгате килеп җитә — шартлы сигнал бирелә. Шуны гына көтеп торган йөзләрчә үзбушаткычлар Кама өстенә ташлана. Менә алар күпергә килеп керәләр һәм акрын гына алга баралар. Һәркайсы күрсәтелгән урында борылып, арты белән күпер кырыена килә һәм: «Бу-ух!» Ярсу агымга таш кантарлары, пирамидалар оча. Машиналар тагы һәм тагы килеп тора, елгага меңнәрчә тонна йөк чума. Ул исә әкияттәге Гуҗ сыман бөтен нәрсәне йотып кына тора. Менә су өстендә бетон пирамиданың очлы почмагы күренә. Икенчесе, өченчесе... Көчле су шавын күмеп, куәтле «Ура!» яңгырый, һавага баш киемнәре оча...

Мин, шатлыктан әсәрләнгән кешеләрне көч-хәл белән аралап, калкурак урынга күтәреләм һәм бинокльемне халык диңгезенә таба борам. Һай, кемнәр генә юк бүген Кама ярында! Шушы каланы, гигант автозаводны һәм искиткеч зур гидроузелны салган ир-егет-

лэр, хатын-кызлар гына түгел, могтэбэр аксакаллар да, муеннарындагы ал галстуклары җилфердэп торган укучылар да бар монда. Чү, бинокль пыяласына таныш йөзлэр килеп керде түгелме соң? Мин Түбэн Кама ГЭСы директоры Марат Габбасович Йосыповны җыйнак, төз гэүдэсеннэн танып алам. Энэ төзелешнең баш диспетчеры хаккас Роман Евграфович Коков, «Гидрострой» трестының участок начальнигы Абдулла Адельшин, бригадирлар Рэшит Фэтхетдинов, Анастасья Ильинична Давыдова, Мансур Шакирҗанов, Төймэ Сөлэймановлар, төзүчелэр Фэрит Вэлиев, Виктор Мардасов, Энвэр Батыршин, Фэнисэ Уразова, Зэлия Якупова, Нина Краснова... Шундый көндэ ни уйлыйлар икэн бу азаматлар?

Телэсэ кайчан, телэсэ нинди шартларда сабыр, басынкы булып кала торган Абдулла ага Адельшин Орелдан Берлинга кадэр тупчы булып авыр фронт юлы узуы хакында уйланамы, эллэ үз куллары белэн күтэрешкэн Новосибирск ГЭСын, Чита ГРЭСын, Обь һэм Енисей елгаларында салышкан башка гидроузелларны күз алдына китерэме? Эллэ соң биредэ, Түбэн Кама ГЭСы төзелешендэ үзе җитэклэгэн һэр өч бригаданың социалистик ярышта гел алда баруларын хэтергэ алып горурланамы? Барын да уйлый булыр сугыш һэм хезмэт ветераны, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Икенче Дэрэҗэ Ватан сугышы һэм «Октябрь революциясе» орденнарын юкка гына күкрэгенэ такмагандыр бүген.

Хезмэт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Мансур Шакирҗанов хатыны Фэния белэн төзелешкэ килгэн көннэрен, шушында бер гаилэ кешелэредэй дус булып киткэн Мария Соловьева, Анна Дмитриева, Раиса Кириллова, Гөлҗиһан Ногманова, Алексей Гаус, Шэйхеразый Мөхэммэдиев, Закир Афзаловлар белэн бергэлэп меңнэрчэ тонна бетон салган көннэрен башыннан кичерэ булыр.

Шундый зур төзелештэ гел хатын-кызлардан торган бердэнбер бригада җитэкчесе Анастасья Давыдова бүген дэ кызлары уртасында. Төзүчелэрнең йөзлэрендэ шатлык, елмаю. Һэр вакыттагыча чыркылдыйлар, җорланалар булыр. Шулай, куанырга, горурланырга хаклы алар бүген. Төрле миллэт вэкиллэреннэн төзелгэн бу интернациональ бригада төзелештэ үзенең дуслыгы, бердэмлеге белэн дан тота. Бригадир үзе Украинадан, Нина Краснова белэн Тамара Петрова — рус кызлары, Рима Миңнебаева, Сания Гайфетдинова һэм Зэлия Якуповалар шушы төбэктэн, Сэгыйдэ Илигбаева энэ мари кызы, Оля Юлтимирова — чуваш, Фэнисэ Уразова — башкорт... Бу чуарлык аларга җиң сызганып эшлэргэ дэ, бергэлэп туйлар, бэйрэм кичэлэре уздырырга да комачауламый. Бригадир күкрэген «Халыклар дуслыгы» ордены бизи.

Любомир Чкалов, Михаил Фролов, Владимир Ключник, Фэрит Вэлиев, Энвэр Батыршин, Виктор Мардасовлар биредэ беренче агрегатның статорын монтажлаган көннэрен һич онытмаслар. Алар Нарск, Братск, Красноярск, Павловск, Ингури ГЭСларының агрегатларын монтажлаган, Эрмэнстандагы атом электр станциясен төзешкэн егетлэр. Шулай да һэр төзелешнең үз үзенчэлеге. Монда да яңа, эксперименталь статорлар монтажларга туры килде аларга...

Икенче көнне гидроузел тирэсе чагыштырмача тынып калган иде. Тик плотинага су җыелуы һэм ГЭС бинасында белгечлэрнең, агрегатларны җибэрүгэ эзерлэнеп, мэш килеп йөрүлэре генэ биредэ, Кама өстендэ берничэ елларга сузылган киеренке хезмэт турында сөйлэп тора иде. Э бөтен мэһабэтлеге белэн калкып чыккан яңа ГЭС исэ халкыбызның тагы бер гүзэл җиңүе булып күңеллэрдэ горурлык хисе уята. Татарстан җирендэ тагы гигант — халык хуҗалыгына ел саен 1248 киловатт электр энергиясе биреп торачак гидроузел

сафка баса. Ул завод цехларына, нефть промыселларына, авылларга арзанлы энергия бирүдән тыш, Камада елга тамагыннан алып, Соликамск шәһәренә кадәр тирән су юлы хасил итә, Агыйделдә суднолар йөрү өчен уңай шартлар тудыра, Татарстан шәһәрләрен һәм Кама аръягы промышленность комплексын су белән тәэмин итә, балык үрчетү өчен зур мөмкинлекләр ача.

ГЭС һәм аның буасының болардан башка да игелекле яклары байтак. Шуларның берсе — су саклагычның хезмәт ияләренә ял итү урыны булуында. Куйбышев, Саратов һәм Волгоград «диңгезләре» янында җиде йөзләп ял итү урыннары булып, аларда берьюлы туксан мең хезмәт кешесенең сихәтләнүе мәгълүм. Нигә безгә дә форсаттан файдаланмаска? Түбән Кама «диңгезе» күп кенә шәһәравылларыбызның кырыена ук килеп җитәчәк бит. Елгадан йөз-йөз илле чакрымдагылар да килеп-китеп йөри алалар анда. Кил, су кер, балык каптыр, көймәдә йөз. Спортны, бигрәк тә су спортын киң җәелдерү өчен шартлар бер дигән булачак монда.

Кояшта ялтырап яткан корыч рельслар һәм булачак автомобиль юлы буйлап плотина өстеннән атлыйм. Менә син, әй, Кама аша күпер дә бит әле бу гидроузел! Плотина КамАЗны, Татарстанның нефть районнарын Мәскәү—Свердловск тимер юлы белән бәйли. Шуны тәэмин итү өчен Эгерҗе — Круглое Поле тимер юлын салу төгәлләнеп килә. Казан — Чаллы автомобиль юлы сафка басты. Әйе, яңа ГЭС Кама аръягында яшәүчеләрне республикабыз үзәге Казан белән, рус җире белән, Европа белән бәйләүче күпер дә әле ул. Ниһаять, киләчәккә күпер ул Түбән Кама ГЭСы!

## Шамил Рәкыйпов

# КАЙТУ



Ул үзенең Советлар Союзы Герое булуын белмичә үлеп китте...

Дөрес, бу хакта аңа госпитальнең баш табибы әйткән иде әйтүен. Хөкүмәт Указы басылган газетага төртеп-төртеп тә күрсәтте, анықына охшаш исем-фамилия астына шәмәхә каләме белән сызып та куйды. Хәсән башын гына чайкады. Каты яралы хәлдә кешеләр белән аралашу өчен аның ике генә мөмкинлеге бар иде: ул я «әйе» дигәндәй аяк кага, я «юк»ны аңлатып баш чайкый. Хәтере дә чуалган иде солдатның...

## Баш табип уйланулары

Хәсән Замановны бу госпитальгә 1943 елның ноябрь урталарында китерделәр. Кемлеген, кайсы часть сугышчысы булганлыгын раслаган бернинди документы юк иде аның. Янган киемнәренә карап, бермәл аптырап торгач, авыру тарихын тутыруны кичектереп, дәвалау эшенә керештеләр. Чир тарихы, ярыйсы гына калынаеп өлгерсә дә, кайбер мәгълүматлар теркәлергә тиешле урыннар буш килеш калган иде әле. Исем-фамилиясен кайчандыр Гөлҗәннәт Замановадан килгән хат кисәгенә һәм авыруның «әйе» дип баш кагып раславына нигезләнеп яздылар. Хатта Гөлҗәннәтнең өй адресы күрсәтелмәгән иде. Кыр почталарына җибәрелгән сорауларга көтелгән җавап алынмады. Гаскәрләр, кала арты кала алып, дәһшәтле ыргылу белән алга барганда, миллионнарча солдат арасыннан исем-фамилиясе дә төгәл билгеле булмаганын тиз генә ничек тапмак кирәк?

Шулай итеп, Хәсән Заманов, приюттагы теле ачылмаган табылдык нарасый сыман, үз почмагында тыныч кына ятты да ятты. Аңа кат-кат операция ясадылар, тәненә кереп кадалган ике дистәгә якын металл ярчыкларын чүпләделәр. Калай савыттагы суга алар чулт та чулт итеп чумды. Түзде солдат, ыңгырашмады да. Маңгаена тибеп чыккан эре салкын тир тамчыларын сөртүче шәфкать туташы Тамарага, тик аңа гына карап торды. Тамара, сабыйны юаткандай, аңа берөзлексез иркә сүзләр әйтте, дәрман бирде.

Баш табип шуны сизенде: авыру белән шәфкать туташы бу минутларда гүя бер тән, бер җан иделәр. Ярчыкны җәрәхәттән алыр өчен скальпельне батырганда, Хәсәннең күкрәге тетрәнә, Тамараның нечкә кашлары, җәя сыман түгәрәкләнеп, тартып-тартып куялар.

— Бу — яхшыга, — дип уйлады баш табип. — Авыруга көч бирер, ә яшь ханымга өстәмә юаныч булыр. Ак иңнәрендә каһәрле сугышның кара хәсрәтләрен күтәреп, адашкан киек каздай япа-ялгыз калган Тамараның кайгылары бераз басылмасмы. Ул арада бәлки Заманов сөйләшә дә башлар. Күзгә-күз карашып аңлашудан юаныч тапкан күңелләргә пар күгәрченнәрдәй гөрләшү насыйп булса, яшь тән иң авыр операцияләрне дә җиңелрәк кичерер иде. Эшләр шулайга таба борылыр шикелле. Авыруның чир тарихына теркәлгән анализ нәтиҗәләре хәтәр дошман — гангрена якынлашуын искәртәләр. Замановның аягына ампутация ясарга туры киләчәк. Бер гариплек өстенә икенчесе... Тамара бу хәбәрне ничек кабул итәр? Өркемәсме? Әлегә аның Замановка булган хисләре сыналмаган. Тамараның Замановны күңеленә якын итүе беренче мәхәббәтенең дәвамы гына ул. Әгәр ампутация яшь ханымны айнытып җибәрсә? Операция ясауны кичектерергә ярамый. Керешер генә идең, егетнең йөрәге бик зәгыйфь. Ул наркозны күтәрмәячәк... Димәк, аягын пычкы белән кискәнне Заманов тоеп ятарга мәҗбүр булачак. Шул чакта түзәрлек көч каян килер аңа? Тамара, бары тик Тамара гына булыша ала Хәсәнгә. Нишләр икән бу яшь ханым? Катлаулы синең язмыш, Заманов. Асылда кем соң син? Бәлки, чыннан да, зур батырлыклар күрсәткәнсеңдер. Ләкин Герой исеме бирелүчеләр арасыннан исем-фамилияңне күрсәткәч, ни өчен баш селектең? Ә шул ук исемлектә хәрби фельдшер Пушина фамилиясен күреп нигә шул чаклы сөенден һәм нигә, менә бу мин дигәндәй, гипслы кулларыңны кат-кат күкрәгеңә бәргәләдең? Әллә бөтенләй җиңеләя башлавың инде бу, Заманов? Пушина хезмәт иткән хәрби частька язып, синең хакта ни дә булса белергә теләвебез барып чыкмады. 520 нче полкның фельдшеры Ф. А. Пушинага, янгында калган яралыларны коткарганы өчен, үлгәннән соң Герой исеме бирелгән. Ул полкта Заманов фамилияле кеше бөтенләй юк. Полк госпиталенең кәгазьләре бомбага тоту вакытында янган... Тикшерүчеләр әйтмешли, бозра шунда йомылды, туганкай. Хәер, әгәр хөкүмәт Указындагы Герой, чыннан да, син икәнсең, иртәме-соңмы, барыбер Ватан үзенең батыр улына тиешле хөрмәтен күрсәтер. Ә хәзергә аңа Алтын Йолдыз түгел, медицина ярдәме кирәк...

Баш табип Замановның чир тарихына «Операциягә хәзерләргә» дип язды да, Тамараны үз янына чакырды.

## Шәфкать туташы хисләре

Тамара баш табип бүлмәсеннән чыкты да, стенага сөялеп, тынып калды. Почмактагы тумбочка өстендә яшел калфаклы ут яна, плитәдәге ак тимер тартмаларда, һәртөрле кертелмәгән хәлләргә әзер булып, пычак, кайчы, эскәк кебек кораллар кайный. Палаталардан саташып кычкырган тавышлар ишетелеп куя.

Өч ел буе ишетә инде Тамара андый тавышларны. Арада күңелгә иң якыны — Борис тавышы ишетелмәсме дип ничаклы көтте, тик булмады, булмас та инде, ахры.

Терелеп киткән яки гәүдәсе туганнар каберенә күчерелгән сугышчылар урынына тимер койкаларга бүтән яралылар китереп са-

лынгач, Тамара, яшерен бер өмет белән, беренче эше итеп, яралының күзләренә карый. Күзләр зәңгәр булса, йөрәге ашкынып тибә башлый, яңаклары кызышуын сизә, иреннәреннән бердәнберенең үкенечле ядкарь булып кына калган исеме атылып чыгар төсле тоела. Мондый чакта Тамара кайдадыр хәтер сандыгында сакланган таныш, кадерле тавыш ишетелмәсме дип көтә. Бөтен тәне-җаны белән көтә. Һәм, гадәттәгечә, һәр вакыт нәүмизләнеп, боегып кала. Чөнки тавыш ят була...

Борисның һәлак булуын үз күзләре белән күргән иптәшләре сөйләде Тамарага. Шулай да ире аңа һаман исәндер кебек тоела. Исән чагындагы кыяфәте белән күз алдына килә, көлә, елмая, шаярта... Төшләренә дә шулай керә.

Борис чик буе гаскәрләре лейтенанты иде. Алар заставада яшәделәр. Чик буе тыныч булмагангадыр, ахры, бала көткән яшь хатынын Борис Гродного китерде. Аның: «Нык бул, кадерлем!» дигән сүзләрен, уттай янган битеннән үбүен генә хәтерли Тамара...

Әйтерсең иренең сүзен үтәп, Тамара малай тапты.

Ул гомерендә беренче тапкыр бала имезергә әзерләнә иде. Йомшак мендәргә аркасын терәде. Изүен чиште. Йөрәгенең куанычлы зарыгу белән тибүе кулы аркылы бөтен тәненә таралды. Рәхәт, чиксез рәхәт иде имезергә бала китерүләрен көтүе. Кинәт сөттәй ак палата ишеге шартлап ачылды, тәрәзә пыялалары чәлпәрәмә килде. Түшәм ярылды, идән убылып төште...

Җимерекләр арасыннан нарасыен эзләп табарга тырышып, шашыныр дәрәҗәгә җиткән хәлсез яшь ананы санитар поездына китереп салдылар. Яралы аккоштай талпынды-талпынды да, укол кадагач, тынды. Тамара шулай хәрби госпитальгә эләкте. Терелгәч тә китмәде. Теләмәде. Турыдан-туры ут эченнән атна саен ничаклы кеше кайтарыла монда. Кем белә, бәлки әле... Сугышта нинди генә хәлләр булмый.

Көннәрнең берендә госпитальгә Киев тирәсендә яраланган сугышчыларны китерделәр. Тамара аларга дару өләште, гадәтенчә, һәммәсенең күзләренә карады, тавышларын тыңлады. Юк инде... Кинәт... Тамараның тез буыннары йомшарды. Ул түр почмакта тәрәзәгә каратып яткырылган сугышчы янына килде. Биләүдәге бала сыман, бөтен гәүдәсе марляга уралган иде аның. Башы да ап-ак. Күзләре... аныкыдай зәп-зәңгәр! Әллә нәрсә булды Тамарага. Ул тимер койка янына килеп чүмәште. Текәлеп карады. Эндәште. Һәм нәүмизләндерә торган чит тавышны көтте. Ә тавыш ишетелмәде. Кара көйгән иреннәр сизелер-сизелмәс калтырасалар да, өн чыкмый, тешләр генә тешкә бәрелә иде.

Борис түгел иде ул. Ләкин күзләре аныкы төсле ачык зәңгәр булганга һәм башкалар кебек чит тавыш биреп үзеннән шунда ук читкә этәрмәгәнгә, Тамара бу яралыны «үзенеке» итте. Дөрес, палатадагы ундүрт авыру һәммәсе аныкы. Ләкин бусы — башка. Исем-фамилиясенең нindидер могҗиза белән генә сакланып калган хат кисәгеннән табылуы, башкалар кебек чатнатып сөйләшә алмаганлыктан, моңаеп күзгә карап торуы, җәрәхәтләре күп булу сәбәпле, гел урын өстендә ятуы аны аерым хәлгә куя иде. Дежур торганда Тамара бу яралыны үзе ашатты. Авыру күзләрендә чагылган рәхмәт хисе Тамараны, дымга сусаган гөлне коендырып җибәргәндәй, сафландыра, балкыта иде. Алар бер-берсенә ияләшеп киләләр. Башкалардан аермалы буларак, үз йомышына йөри алмавы өчен дә читтән тыш ояла, читенсенә иде Заманов. Кая инде ул кайберәүләрдәге дорфалык, әдәпсезлек! Бу андый чакта оялып күзләрен йомар, колагына чаклы кызарыр... Мөгаен, Тамара үзе дә шундый халәттә

буладыр. Ләкин ул югалып калмый, икесе исеменнән дә без хәзер фәлән итәбез, төгән итәбез дип сөйләнә-сөйләнә, Замановка эш куша, булышырга ишарәли. Заманов шатлана-шатлана күнә. Ул аны һәр көн шулай тәртипкә китереп урынына яткыра.

Заманов Тамараны зарыгып көтеп ала. Шәфкать туташы үзе дә аңа ашыга. Әйтерсең бала имезергә ашыга. Нәрсә бу, кеше тормышы өчен җаваплылык хисе тоюмы, әллә бүтән тойгымы? Янында Тамара торса, ул операция ни дип уңышлырак чыга? Һәм... Замановның башын йөрәк өстенә куеп: «Түз, кадерлем, тагын беразга гына түз!» дип пышылдаганда ни дип күкрәккә сөт төшкәндәй була? Юк, тикмәгә түгел бу. Йөрәк сизенә: Заманов аның тормышында онытылмаслык эз калдыра торган чын кеше.

Шушы сизенүләрне раслагандай, газеталар Замановка Советлар Союзы Герое исеме бирелүен хәбәр иттеләр. Фамилиясендәге бер хәрефе туры килми килүен, Хәсән үзе дә шул хәрефкә ымлап башын чайкый чайкавын, ләкин бу — ул, ул! Геройлар шундый түземле һәм инсафлы булырга тиеш!

Баш табип ни өчен бу егетнең Заманов икәнлегенә ышанып җитми икән соң? Чит кешенең хатын кем йөртсен инде үз кесәсендә? Ул хатка ап-ачык итеп: «Гөлҗәннәт Замановадан Хәсән Замановка», дип язылган. Хатыны түгел, сеңелесе ул аның. Сеңелесе!.. Кызганыч, сорашып белешер өчен адресы сакланмаган ул Гөлҗәннәтнең. Ярый әле сакланмаган. Тәгаен белмәү яхшы хәзергә. Икесенә дә яхшы. Кеше кешесенә түгел, кеше киеменә дә иялəшә алмый Тамара. Аңа әйбер таушалмаган-керләнмәгән булсын. Ә чит ир — итәгеңә чаткы төшеп янгач салынган ямаулык ул. Моны теләми Тамара. Нигәдер алай булмас кебек. Нигәдер, нигәдер Хәсәнне һаман, һаман үзенеке итәсе, аны тизрәк терелтәсе килеп кенә тора.

Бер көнне Тамара: «Гөлҗәннәт исеме ни дигәнне аңлата?» дип язып Хәсәннән сорады. Авыру бирмәлгә аптырап калды. Телсез, кулсыз булгач, ничек җавап бирсен?! Ниһаять, куанып, күршесенең тумбочкасына ымлады. Тумбочка өстендә госпиталь егетләре бизәкле открыткалардан пөхтә итеп ясаган кәгазь тартма тора иде. Открыткада канатлы фәрештәләр очып йөрүе сурәтләнгән... «Ирләр, гадәттә, хатыннарын түгел, сеңелләрен фәрештәгә тиңлиләр», дип уйлады Тамара.

Заманов егет кеше булырга тиеш. Алай дисәң, нишләп әле ул, Герой исеме бирелү турындагы Указда хәрби фельдшер Фаина Пушина фамилиясен күргәч, әчкерсез елмайды, күзләрендә куаныч, сагыш чагылдырып, нәрсәдер аңлатырга тырышты? Икәү микәнни Замановның фәрештәсе? Хәер, фельдшер Пушина һәлак булган бит инде. Димәк...

Тамара тетрәнеп китте. Карасана,ниләр уйлый башлады ул! Көнләшә үк түгелме соң? Ә нәрсә?.. Замановны терелтер өчен кем шулай көч куя? — Тамара! Аны тәрбия кылудан кем шундый сәер тойгылар кичерә? — Ул!... Тамара кулын йөрәге өстенә куйды. Шуны гына көткән кебек, Замановның чир тарихы, халат итәгендә кыштырдап, идәнгә төште. Бу аны чынбарлыкка кайтарды. Иртәгәгә Замановны операциягә хәзерләргә... Аягына ампутация... Әйе, әйе, иң әүвәл терелтергә кирәк әле. Тамара — шәфкать туташы. Авыруның кайнар башын, теге чактагы кебек үк, йөрәгенә кысып: «Түз, кадерлем, түз!» — дияр.

Тамара ишек янагына битен куйды. Бераз тыңлап торгач, елмаеп: «Йоклый», — диде һәм, сак атлап, плитә ягына почмакка үтте.

Чираттагы операциядән соң Хәсәннең хәле яхшыра төшкән иде. Радио ул көнне берсеннән-берсе куанычлы хәбәрләр тапшырды. Ленинград фронтындагылар дошманның тугыз йөз көнгә сузылган үлем боҗрасын өзгәннәр. 2 нче Украина фронты гаскәрләре, Корсунь-Шевченко тирәсенә тупланган гитлерчыларны корал ташлатып, моңа риза булмаганнарын теге дөньяга озатканнар. Ә Мәскәүдә Партия Үзәк Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы трактор заводлары сала башларга кирәклеге турында карар чыгарган. Сугыш бетмәс борын бит бу! Танкларың җитәрлек булмаса, сугышта ватылганы урынына яңалары ажгырып килеп җитүгә тәгаен ышанмасаң, трактор кайгысы булыр идемени? Димәк, ярыйсы безнең эшләр, ярыйсы. Бәлки ярыйсыдан чак-чак кына алдарак та түгелме әле. Хәсән бер аягы белән чем-кара туфраклы Актаныш бразналарының дым рәхәтен яшьли үк татыган булса, икенче аягы белән Урал заводларының эссе тимер идәнендә басып тир түккән егет бит. Шулай дип әйтергә аның тулы хакы бар. Күҗәкә малайлары сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырга туры киләчәген белеп үсәләр. Хәсән ун яшеннән сабан сөрде. Аннары кырга трактор кирәклеккә инанып, юлбашчы әйткән йөз мең машинаны булдырырга дип, аркасына биштәр асып заводка китте. Башта «ЧТЗ» нигезләрен салуда катнашты. Кулыннан кәрәк, кәйлә төшмәде. Ял вакыты өчен һаман язны сайлады. Иртәнчәк кыр станындагы тракторлар янына ашыкканда баш очында канат җилпегән тургайлар җырында тел белән әйтеп бирә алмаслык рәхәтлек тапты. Җиргә хыянәт итмәве өчен, вазифасы кушканны гына түгел, күңеле йөкләгәнне барлык шартын китереп, төгәл һәм пөхтә үтәгәне өчен иртәнге кояш нурларында назланып яткан киң басу, басу өстендә алтын рәшәдәй тирбәлгән баллы һавада сайрашкан тургайлар—барысы-барысы аңа рәхмәт хисләре белдерәләр иде сыман. Эх, ул басулардагы рәхәтлек!.. Хет үзең күккә күтәрел, шунда гына ашкынуларың азрак басылыр шикелле иде...

...Хәсән трактор заводы салуның нәрсә икәнен яхшы белә. Сугышка чаклы Харьковтагы трактор заводында да булып, эретеп ябыштыру һөнәренә өйрәнеп кайткан иде ул. Фашистлар анда җимерекләр генә калдырып киткәннәр. Ләкин завод салыныр. Элеккесеннән дә куәтлерәк булыр ул! Эх, андагы осталар...

...Хәсәннең җәрәхәтле күкрәгеннән бер тиенлек акча хәтле металл ярчыклары табып алган җитез кулына газета тотып, палатага баш табип керде. Газетаны Хәсән укый алырлык урынга куйды. Указдагы бер фамилиянең астына сызылган иде...

Хәсән күз чите белән генә карап, тирәнтен кызыксыну галәмәте күрсәтмәгәч, баш табип аның янына утырды. Кәефен сорашты. Киңәшләр бирде. Дәвалануга кагылышлы сүз әйтелеп беткәч, ниһаять, газетага үрелеп:

— Бәлки... сезне, иптәш Заманов, тәбрик итәргә кирәктер, ә? — диде.

Хәсән башын чайкады. Указда хирург тарафыннан астына сызылган фамилиянең баш хәрефенә төртеп күрсәтте. Янәсе «С» бит, «З» түгел. Димәк, Герой исеме ниндидер Самановка бирелгән.

Хирург авыр сулап куйды:

— Бер хәреф бит, нибары бер хәреф туры килми! Кызганыч, госпитальгә китерелгәндә янында бернинди хәрби документың булмаган. Язып сорашыр идек, кайсы частьтан икәнлегеңне белмибез. Үзең хәтерләмисең — контузия нәтиҗәсе. Хәсән Заманов икәнле-

геңне дә кире кайтыр адресы булмаган хат кисәгеннән һәм итек кунычыннан чыккан кашыгыңнан укып кына белә алдык бит, хөрмәтлем! — дип урыныннан торды.

Хәсән, шулай шул дигәндәй, ияк какты. Арыды ул, күзләрен йомды. Башы кабат чатный башлады. Аның хәзергә һичнәрсәдә гаме юк иде. Упкынга төшеп киткәндәй булды... Күзен ачса, ул бөтенләй башка бүлмәдә, ә сөйкемле Тамара аның ябык беләгенә укол кадап тора иде. Тумбочка өстендә яшел калай түбәтәйле ут яна. Тоныкут яктысы андагы алмаларга төшкән. Тамара, бер алманы кискәләп, ашатырга теләде. Хәсән бер кисәге сиңа, икенчесе миңа дигәнне аңлатып, үзенә һәм кызга төртеп күрсәтте.

Алманы ашап бетергәч, Тамара:

— Тыныч йокы, тыйнагым! — дип пышылдап, Хәсәннең кайнар маңгаеннан үбеп, палатадан акрын гына чыгып китте.

Ул үзе генә калды. Теге көннән соң аны бәләкәй палатага күчергәннәр икән шул. Шәфкать туташы китергән алмалар шифасы тидеме, хәле яхшыра төште. Моны күреп Тамара да шатланды. Көне буе эшләгәннән соң, кайтып китәр алдыннан ул һаман палатага керә, Хәсәннең маңгаеннан үбә һәм гадәттәгечә: «Тыныч йокы, тыйнагым!» — дип ашыгып китеп бара. Шәп кеше син, Тамара. Бәхетле булсаң иде, сеңелкәем! Синнән күргән яхшылык, рәхимлелекне санап бетерерлек түгел. Рәхмәт, бик-бик зур рәхмәт үзеңә! — Хәсән шундый тойгы белән уйга чума. Элек Тамара палатадан акрын гына чыга иде, ә хәзер ашыга. Ник ашыга?

...Палатаның теге ягында баш табип бүлмәсе. Тамара аның янына керә. Алар анда нәрсә турындадыр пышылдашалар. Хәсән сизә: мең төрле мәшәкатьләре булуга карамастан, янәшә бүлмәдә аның хакында серләшергә дә вакыт табалар.

Яшь тәнгә тормыш кайта, фикерләү кайта, кисәк-кисәк булып, әллә кайлардагы томан эченнән хатирәләр калка...

Пышылдаулар, кайнар ирен, йомшак куллар, назлы караш... Аның Гөлҗәннәте — бердәнбере, сөеклесе ич бу. Кайда соң син, Гөлҗәннәт? Кайда?.. Тамарага мең-мең рәхмәт: ул, баш табип куш-канча дәвалап, мине генә түгел, миндә яшәгән сине дә терелтте. Хәсәнең сине табар, җир астыннан да табар! Соңгы хатың кайчан килгән иде әле? Сентябрьдә. Чөнки: «Урал итәгендә үскән соңгы чәчәкләрнең берсен сиңа ядкарь итеп салам», дип язган идең. Бәгырькәй, Уралда ич син! Җиңүебезне якынайту өчен шунда корал коясың! Кулларың җылысын онытмаган кебек, Уралда икәнлегеңне дә онытмас хәзер Хәсәнең! Онытмас. Зиһене яктыра башлады аның. Яктыра!..

Днепрны кичәр алдыннан хат язган идем. Алдыңмы син аны, Гөлҗәннәт? Алгансыңдыр... Син һаман бер җирдә — заводыңда бит. Танкоград күчми ул. Ә Хәсәнеңне менә ничә рәт күчерделәр инде. Үз частеның кайдалыгын белми, командирлары кем иде — хәтерләми... Дошман белән алышулары азрак истә. «Ирегез Хәсән Заманов немец-фашист илбасарларга каршы көрәштә батырларча сугышып һәлак булды», — дип язылган кара пичәтле хат җибәрделәрмени сиңа? Җибәрерләр шул. Чөнки мин үлгән булганмын, җаным... Хәзер менә өйдәгечә ак мендәргә баш куеп, ак җәймә өстендә ятуым могҗиза ул, могҗиза. Чит кешеләр түгел, үзем дә ышанып җитмәгән тагын бер могҗиза бар әле, Гөлҗәннәт. Имеш, синең аз сүзле ирең Хәсән — Герой! Советлар Союзы Герое! Ләкин шатланырга бик үк ашыкма әле, аппагым. Ник дигәндә, газеткә басылган хөкүмәт Указында исемем туры килсә дә, фамилиямдәге бер хәреф пашпырттагыча түгел бит. Без синең белән Замановлар, ә газеттә — Саманов. Заман белән Саманның арасы — җир белән күк арасы. Менә сиңа

бер хәреф, җаный... Әгәренки ул писер кисәге, чынлап та, эшипкә җибәреп, мин, чынлап та, Герой икәнмен һәм дә шул бер хәреф аркасында Алтын Йолдыздан мәхрүм калганмын икән, ул бәндәгә каргышым төшсен. Ләкин, җаный, бәлки юкка гына каргыймдыр мин аны. Герой кадәр Герой исеме бирерлек ни эш кылдым әле мин? Геройлар алар безнең ишеләр түгел. Алардагы баш, мин сиңа әйтим, зирәк акыл, батырлык безнең төшкә дә керми.. Менә сиңа үз күзләрем белән күргән бер пример...

Кырык бернең октябрь ахырларындамы, әллә ноябрь башындамы, Харьковны фашистка калдырыр алдыннан рота командиры мине бер төркем минерлар карамагына җибәрде. Безнең часть каладан иң соңгы булып чыгарга тиеш иде. Немецның кысуына һич түзәр әмәл юк. Менә шундый чакта окоптан чык та бөтенләй таныш түгел кешеләргә ияреп кит. Урамнарда ут котыра, төтен, шартлаулар. Менә-менә гитлерчылар бәреп керәчәк. Безнекеләр чигенеп бетте диярлек инде. Минерлар гына җитми. Йортларның шәбрәкләренә «күчтәнәчләр» куялар. Сугышка хәтле Харьковта азрак яшәгән кеше диптер, ахры, мине машина канатына бастырып, юл күрсәттереп йөртәләр. Аннары миналы әрҗәләр ташыталар, ишек төбендә сакта торалар. Шәп бер йортка ни өчендер ике «күчтәнәч» керттек. Берсе бәләкәйрәк, икенчесе өч йөз илле килолы. Бу бик зур булмаган йортны актарып ташларга беренче мина да җиткән югыйсә. Ә монда икене куялар. Әйткәнемчә, икенчесе чамасыз куәтле. Аны урнаштырырга кем килде дип беләсең? Инженер Ястребов. Трактор заводында безне укыткан иде ул. Мин аны шундук танып алдым. Моны үзенә әйтеп кенә тормадым — вакыты андыймыни?!

Тагын берничә йортның ишегалдына кереп казындык. Аннары аэродромда булдык... Ахырдан шуны әйттеләр: инженер Ястребов үзе уйлап чыгарган «акыллы миналар» куеп йөргән икән. Ягъни радио буенча идарә ителә торган нәмәрсәкәйләр булган алар. Шуларның берсен безнекеләр Воронеждан торып 14 нче ноябрьда төнлә шартлатканнар. Рәхимсез җәллад — Проскуров, Винница һәм Харьковта совет кешеләрен меңәрләп-меңәрләп җәзалатучы 68 нче дивизия командиры генерал Браун (кем белә, бәлки әле ул Гитлер сөяркәсе Ева Браунның агасы булгандыр?) иярченнәре-ние белән күккә очкан. Төн саен шартлау. Фашистлар Харьковта аны алгандагы сугышларда кырылганнан да күбрәк гаскәр югалтканнар. Һәм моны Ястребов эшләде. Менә ул — Герой...

Миналар куеп китү турында сүз чыккач, моңа фашистларның аеруча хирес булуларын әйтми ярамый. Икенче пример турында сөйләргә җыенуымны сизенәсеңдер, Гөлҗәннәт.

Запорожье каласы Днепр суының бу ягында икән ул. Аны безнекеләр дошманнан 14 нче октябрьда ук чистарттылар. Бик каты сугышлар булды анда. Каладагы һәр урамга, урамнардагы һәр йортка теш-тырнаклары белән ябыштылар бәдбәхетләр. Биш көн, биш төн буена гөрелте тынмады. Алтынчы көнне фашист түзмәде. Киткәндә бөек Ленин исеме белән аталган Днепрогэсны шартлата башладылар. Моңа алдан ук хәзерлек күрелгән. Март аенда ГЭСка унике вагон шартлаткыч матдә китергәннәр... Мылтык пулясының, тугыз грамм гына булса да, биш чакрымга җитеп үтерә алуын искә төшерсәк, фашистлар Днепрогэска куеп калдырган ике йөз мең кило шартлаткычның нинди җимергеч көчкә ия булганлыгын күз алдыңа китерә алырсың дип уйлыйм.

Бер заман дөнья тетрәп куйды, күккә бишәр катлы йорт зурлыгындагы ташлар очты. Башланды... Бөтен Советлар Союзы халкының көче кергән Днепрогэс корылмалары, шулай бер-бер артлы шартлап, күккә оча дип торабыз. Бәхеткә, алай булмады. Плоти-

наның бер чите һәм станция бинасы гына ваттырылган иде. Шартлаулар бүтән кабатланмады. Озакламыйча ГЭСка безнең частьлар бәреп керде. Алар «тәмуг машиналарына» тоташтырылган бикфорд җепләрен, электр үткәргеч чыбыкларны кисәргә керештеләр. Уннарча чыбыклар, җепләр буенча барып, алар төенләнгән урынга төшсәләр, анда дистәгә якын гитлерчыны кырып салып, коточкыч шартлауларны булдырмый үлеп калган совет сугышчысы ята. Йөзе танырлык түгел, кесәләрендә бернинди документ-фәлән юк. Кем ул — тәки белмәгәннәр. Ул билгесез Геройның гәүдәсен зур хөрмәт-пачут белән Днепрогэс бинасы алдына күмгәннәр[1]...



Менә шундый азаматларны гына мин Герой дип саныйм, җаный. Ә минем алай тарихка язарлык батырлыгым юк. Шуңа күрә Герой исеме миңа түгелдер, бүтән сугышчыга бирелгәндер дип исәпләп тынычланам.

Син тагы батырлык кылырга ирләр генә һәвәс дип әйтә бу дигән фикергә килмә, Гөлҗәннәт! Һич алай уйламыйм.

Сугышта мин, айбикәм, «Татарстан колхозчысы» дигән танклар колоннасын күрдем. Мамедов дигән командир (ул да Советлар Союзы Герое, җаный!) әлеге корыч машиналарның фашист кулындагы калаларыбызны азат итүдә бәрәгәйле эш башкаруларын сөйләде. Запорожье өчен барган сугышларда да аларны без тимер ташкынга охшаттык. Прәме ут уйнаттылар дошман окоплары өстендә. Аннары сытып-изеп, таптап уздылар.

Фронтка җитәрлек кадәр ризык биргән алтын куллы, сиңдәй уңган һәм дә түземле Татарстан хатын-кызларының сокландыгыч батырлыгы түгелмени бу, ә?

Танкысын коючы да — сез, аларны, колонналап сатып алып, сугыш кырына китерүче дә — сез. Җаный, сезнең халык фронтта да батыр. Шундый батырларның берсе — украин кызы Фаина Пушина — ирләрдән дә тегеләйрәк гайрәт күрсәтмәгән булса, хәләлең турында кара пичәтле кәгазьне икенче кат җибәрерләр иде сиңа. Бу юлы газраил якадан тотып кына калмас иде, җаный.

Хәл болай булды.

Мине күрше полк санитарлары табып, үз санчастьларына китергәннәр, җәрәхәтне бәйләп, миңа кан җибәргәннәр. Күзләремне ачтым. Хәл юк, баш чатный. Без бер бүлмәдә утызлап яралы. Ачык ишекнең теге ягында да халык шуннан ким түгелдер. Тылга озатылыр өчен Святошино дигән җирдә машиналар көтеп ятабыз икән. Алгы сызык, ягъни мәсәлән, ике якның сугыша торган җире янәшәдә генә. Шартлаулардан өебез дерелдәп-калтырап тора. Ә Фаина-бәгырь, әле беребез, әле икенчебез янына килеп, күгәрчендәй гөрләп юата, су эчертә, баш астындагы биштәреңне рәтли яки өстеңдәге шинелеңне төзәтеп яба. Минем янга почмакка ешрак уза, ник дигәндә, борылып ятарга да хәлем юк, көчкә-көчкә тын алам. Вакыт-вакыт йокымсырап китәм сыман, ул — һуштан язуым икән...

Көтмәгәндә дошман самолетлары безнең тирәне бомбага тотарга керешә. Җир селкенә, бөтен өй эче хәрәкәтләнә. Бер вакыт түбәне каерып ыргытты. Янабыз!.. Аякка баса алганнар, аксап-туксап, урамга ашыкты. Фаина аларга булыша. Төтен. Өстә моторлар гүли, пулемет такылдый. Әрнеп кычкыралар, ярдәм сорыйлар. Мин ыңгырашам гына. Өй дөрләп яна. Шинелем пыскый, баш астындагы биштәрем төтенли. Теге юлы үлемнең килүен сизмичә дә калган идем.

---

[1] В. И. Ленин исемендәге Днепрогэсны тулысынча шартлатудан коткарып калган бу каһарман ирнең кем булуы һаман әле ачыкланып җитмәгән. Аның гәүдәсе күмелгән кабер өстенә монумент куелган, шунда ук мәңгелек ут яна. Каберне Днепрогэс эшчеләре зур кайгыртучанлык һәм мәхәббәт белән карап торалар.— Автор.

Әллә нинди икән ул: тынны кыса, пешерә, яндыра, чәчләр, кашлар көя... Айбикәм-бәгърем, синең белән бәхилләштем, әнкәй, әткәй белән...

Шунда яныма, дөрләп янган ут эченә, син кергәндәй тоелды. Ул — Фаина-фәрештәм икән. «Де ты, хлопчик?» — ди. Үзенең ябынган плащ-палаткасына ут ява, аркасы көйри.

Мин ыңгыраша гына алдым. Фәрештәм мине, кочаклап, ут эченнән алып чыкты.

Тагын самолетлар килеп җитте. Тагын бомбалар сызгырды, пулеметлар такылдады. Фәрештәмнең мине күкрәге белән каплаганын гына хәтерлим...

Хөкүмәт Указында хәрби фельдшер Фаина Пушинага да Герой исеме бирелүе әйтелгән иде... Шатлыгымның иге-чиге булмады, тик кайгылы сөенеч иде бу, чөнки Указда фельдшерның һәлак булганлыгы әйтелгән иде.

Минемниләр майтаруым турында тәгаенрәк беләсең киләмени, Гөлҗәннәт? Сөйлим, җаный, сөйлим... Исемә төшсен өчен, күңелемнән генә булса да, һәммәсен сөйлим.

Өченче ноябрь иртәсе иде. Һөҗүмгә күтәрелергә әмер көтеп, окопта ятабыз. Кичә һәммәбезгә фронт Хәрби советының мөрәҗәгатен укыдылар. Анда: «Алдыбызда — рус калаларының әнкәсе, Ватаныбыз бишеге — Киев. Монда күп гасырлар элек куәтле Русь дөньяга килде... Менә егерме биш ай инде фашист-җанварлар тыныч совет гражданнарын мәсхәрә итәләр, талыйлар, үтерәләр. Киевтагы фабрика һәм заводларны, берсеннән-берсе зиннәтле биналарны һәм ямь-яшел урамнарны яндыралар, изге җиребез көрәшчеләренең каберләрен һәм һәйкәлләрне мыскыллыйлар, пычраталар...» диелгән иде анда.

Без полк байрагы алдына тезләнеп ант иттек: «Үлсәк үләрбез, әмма Киевны дошманнан йолып алырбыз!» —дидек. Монда килгәнче без Великий Букрин дигән җирдән кузгалып караган идек. Шул Киевны алу өчен инде. Ике тапкыр талпынсак та рәт чыкмады. Немец, каһәр, безнең юлга хисапсыз күп гаскәр куйган икән. Техникасы да күп дәҗҗалның. Күрә торып чебен урынына кырылырга ярамый бит инде. Һөҗүмне түбәннәнрәк, немец көтмәгән җирдән башламый чара юк. Гаскәрләрнең беришләре алгы сызыкта һаман атыша, ә без төнлә сиздерми генә Днепрның теге ягына чыктык та яр буйлап аскарак тәпиләдек. Ике йөз чакрымлап ара үтеп, Десна суын һәм дә янәдән Днепрны кичеп, Лютеж дигән урынга окоплар казып урнаштык. Юл газабы — гүр газабы, диләр. Без пычрак изеп, фашист сизмәсен өчен тәмәке дә кабызмыйча, патрон әрҗәләрен җилкәдә ташый-ташый, марш уздык. Мин—разведчик бит, гел алда булдым. Кушканны тиешенчә үтәдем. Яңгыр чиләкләп койды. Ә без, җаный, моңа сөендек кенә. Ник дигәндә, фашист самолетлары оча алмый иде. Ничаклы гаскәрнең күченүен тәки белми калдылар.

Днепрны кичү сират күперен кичүдән ким булмады. Монда безне фашист күрде, хәйләбезне аңлады. Ярсып, иренен чәйнәп, барлык коралларыннан атты. Барыбер теге якка чыктык. Беренчеләр сафында мин дә бар идем.

Менә инде без Лютежда. Әйткәнемчә, Киевка кузгалырга әмер көтәбез. Һәммәсе әзер. Шулчак, җылы җил исеп куйгандай, хәбәр таралды: фронт командующиебыз генерал Ватутинга Верховный Башкомандующийдан телеграмма килгән. Ул без башлаячак һөҗүмне сузмаска, Киевны алтынчы ноябрьдан да калмыйча алырга кушкан.

Ничек инде куанмыйсың моңа?! Дөньяны җимерердәй булып, безнең туплар ата башлады. Төтен таралырга өлгермәде, яңгыр басылды, күк аяза төште һәм атна буе тик яткан очкычлар эшкә керешге. Танклар кузгалып китте. Алар артыннан, «ур-ра!» кычкырып, без йөгердек. Мин — разведчик бит, гадәттәгечә, гел алда.

Безнекеләрнең күпчелеге әле һаман кичүдә. Шуңа күрә уңъяк ярда көчләр санаулы иде. Фашист сукыр түгел, моны күреп тора һәм, лөгыйнь, безне киредән Днепрга мәтәлдерергә ниятли. Саранча өере кебек киләләр. Беренче ыргылуларын авызлыкладык, икенчесен, өченчесен... Автоматтан аттым, хәнҗәрем белән чәнчедем, кулларым белән будым, типтем, тешләдем... Чигенмәдек. Артка борылып карамадык. Ник дигәндә, ышандык: тагын аз гына түзсәк, төп көчләр килеп җитәчәк. Аннары... әнә сугыш кыры тынып калды. Хәзер коралларны тәртипкә китерергә, старшинадан яңа дискылар, гранаталар алырга, бәлки тамак ялгарга да мөмкин булмасмы әле. Ашамаган, чәй эчмәгән солдат солдатмыни ул?! Безнең дивизия тулысынча диярлек Урал, Себер ягы егетләреннән тора. Ә алар чәйнең кадерен белә! Иң әүвәл сугыш кирәк-яраклары хәстәрләп куйдык. Ник дигәндә, ашамый-эчми торып була, ә патрон, гранатасыз — юк. Сугышта шуннан да яманы юк. Эчкә җылы кермәсме дип, кәтилүктән тәмләп чәй эчәргә керешкән генә идем, безгә таба фашист танклары килүе күренде. Карыйм күзне ачыбрак: танклар түгел, үзйөрешле орудиеләр икән. Руслар әйтмешли, керән эче тормадан татлы түгел дигәндәй, барыбер корыч аждаһа инде, башнясы гына юк. Ян-якка ату өчен бөтен гәүдәсе белән борылырга тиеш бу корт хәшәрәт. Безнең окопларга таба үрмәлиләр. Ярар, чәйне ахырдан эчәрбез инде, алайса, дим. Эссе булмагае әле монда, дим. Ата-ата киләләр тегеләр. Әле алга, әле артка туп төшеп ярыла. Окоп төбенә чүмәшсәң, өскә туфрак ишелүе бар, чүмәшмәсәң — кыйпылчыклар кигәвен өередәй оча. Терелэй күмелеп калу хәтәррәк дип, окоптан чыктым. Ике кулда ике граната. Танкка каршы ташлый торганнар. Алгарак шуыштым. Аждаһалар якынлаша. Берсе алдагы окопларыбыз өстендә борылгалап, аларны иша башлады. Үтеп китүчә, арттан моторны яндырмасыннар дип, шулай эшли моны немец. Каршы киттем. Ике ара унбишегерме колач калгач, бисмилла әйтеп, гранатаны томырдым. Колакларымны тондырып, бик каты шартлады. Башны калкытып карыйм: төтенләп ята бәдбәхет. Читкәрәк шуыштым. Кыйгачлап үз окобыма чыгарга исәп. Булмады: икенче машина юлымны бүлде. Соңгы гранатам белән өченче аждаһаны шартлатканда, әллә ничә җирдән яраланган идем инде. Алдымда кинәт ут чүмәләсе калыкты. Текә таудан аска тәгәрәгән арбадан егылгандай булдым. Өстемә бүрәнәләр ишелде сыман. Бер нәрсә уйларга өлгермәдем. Ишетмәдем дә, тоймадым да... Туганнар каберенә җирләр өчен казып алганда селкенеп куйганмын. Йөрәкне тыңлап карасалар — акрын гына тибә икән. Госпитальдә күзләремне ачтым. Берсеннән икенчесенә күчерделәр. Кистеләр, тунадылар. Иртәгә менә аяк белән бәхилләшергә туры килә... Ичмаса тел ачылсын иде тизрәк. Юкса Җиңү көнендә «ур-ра!» кычкырмыйча утыру бер дә килешмәс! Синең белән дә чүкердәшәсем бик-бик килә, Гөлҗәннәт! Син мине көтәсеңдер, айбикәм? Көтәсең. Зарыгып, сагынып көтәсең. Мин инде озакламам, җаным. Сугышулар бетте инде миңа. Ә сүзебездә тордык без: Киев алтынчы ноябрьда азат ителде. Фашистны шактый дөмбәслисе бар әле барлыгын. Моны инде бүтәннәр башкарыр. Аяксызларны сугышка җибәрмиләр. Пехотада тәписез берни майтара алмыйсың. Култык таягы белән заводта да эш таба алмавың мөмкин әле...

Рядовой Хәсән Заманов терелә, озакламый теле дә ачыла. Һәм ул, җаен туры китереп, Тамарага үзенең Гөлҗәннәте барлыгын әйтә. Керфекләре яшькә манчыла моңсу ханымның, ләкин ул ни актан, ни карадан бер сүз әйтми.

Госпитальдән киткәндә ул Хәсәнне поездга озата төшә, тыйнак кына саубуллаша да перронга чыгып баса, вагоннар күздән югалганчы карап кала. Аннары кич утырып хатлар да яза ул үзенең зәңгәр күзле дустына. Госпитальгә Уралдан җавап хатлары килә: Тамараны кунакка чакыралар.

Шәфкать туташы вәгъдә дә итә, әмма һаман вакыт таба алмый...

Җиңү көнендә Хәсән Замановның урам яңгыратып «ур-ра!» кычкыруын күпләр хәтерли. Кич ул клубка килә. Холкына турылыклы калып, күзгә кереп торган җиргә түгел, ә кырыйгарак утыргангамы, исемен телгә алучы да, түрдәге өстәл янына чакыручы да булмый аны. «Җиңү хакына аякны калдырып кайттым, кайтуга мин инвалид башым белән муеннан эшкә чумдым. Онытмаска тиешләр иде мине дә», — дип уйлый Хәсән, үпкәсен Гөлҗәннәткә дә сиздерми генә. Ләм-мим эндәшми. Карап утыра. Уйлана. Бераздан үзен үпкәләткән башлыкларны хаклыга саный башлый. Эшкә кергәнсең икән, утыз икең даулаганга кергәнсең. Пенсияң тамагыңны туйдырырлык булмаганга кем гаепле? Дәрәҗәңә күрә әҗере. Әнә анда өстәл янында күбесе капитан да майор. Дан орденнары, Александр Невский, Суворов, Кутузов, тагын әллә нинди бүләкләрнең тулы кавалерлары... Ә син ике-өч медаль кисәгең белән түргә титакламакчы буласың. Гөлҗәннәт әйтә әйтүен: «Әгәр,— ди,— синең урыңда җебемәгәнрәк бүтән кеше булса, Мәскәвенә кадәр барып җитәр иде, дереслекне таптырыр иде,— ди.— Йолдызың да булыр иде, пенсияң дә җитәр иде, квартирның да рәтлерәген бирерләр иде»,—ди. Әлбәттә, бирерләр иде. Ләкин ул йолдызны эзләп табасы бар шул әле. Ничек итеп эзлисе — менә мәсьәлә кайда. Пенсия рәтләтеп йөргәндә шунда язып утыручыга сүз каткан иде дә, ахырдан ник авыз ачуына үкенеп бетә алмады. Көлде генә ул адәм. Хәсәннең янган, тишекле иске шинелен күздән үткәргәч, башының чатнавы-чатнамавы белән кызыксынды. Теле әйтеп бетермәгәнне күзләреннән укыды аның Хәсән. Авыр контузиядән соң Герой гына түгел, мин маршал диючеләр дә бар бездә, туганкай, диярләр иде ул күзләр. Кызгану күрде Хәсән ул күзләрдә. Терелеренә бер төрле дә ышаныч калмаганнарга госпитальдә табиплар шулай карый... Хәсән мескен түгел, җәлләүгә мохтаҗ түгел.

Хәсән шулай фикер йөртә. Гөлҗәннәтнең ара-тирә әйтеп куйган шырпылы сүзләрен гүя ишетми дә. Өйгә кайткач, үзенең солдат кружкасына тотырып хәмер сала. Юаная башлаган хатынының биленнән кочып:

— Кайгырма, айбикәм. Бәхет җир өстендә булмаса, җир астында табылыр, — ди. Сүзен җилгә очырмый: шахтага төшә. Алты ел буе аста эшли: рельсларны ябыштырып юл сала, кысылган һава яки су килсен өчен торбалар суза, газ кудыргыч җиһазларны түшәмгә беркетә, шахта машиналарын төзәтә. Кайда эш туктала — Заманов шунда. Ашыгыч ярдәм кебек килеп тә җитә, эретеп ябыштыру аппаратын көйләп, түшәм терәүләрен энҗе нурлар белән коендыра-коендыра, тимер кисә, тимер ябыштыра. «Первомайская» шахтасы җитәкчеләре бу тырыш эшчене тиз күреп алалар. Замановның рәсе-

ме Почет тактасына куела, аңа Мактау грамоталары, бүләкләр тапшырыла. Квартираның да яңасын бирәләр.

Курчак өе төсле матур аш бүлмәсендә җиңнәрен сызганган көләч Гөлҗәннәт пилмән бөгә, аның янында, ай тирәсендәге якты йолдызлар сыман, ике кызчык — Гөлҗиһан белән Гөлмәрьям бөтерелә.

— Кызларым-йолдызларым, — ди бәхетле ата Гөлҗиһан белән Гөлмәрьямнең чәченнән сыйпап, — исән чакта әйтеп калдыра торган васыятем шул сезгә: үскәч, минем һөнәремне үзләштерегез...

Хәсән Заманов 1951 елда вафат була.

Кызлар, әтиләре васыятенә турылыклы калып, Североуральскидагы профессиональ-техник училищеда укыйлар, икесе дә электросварщик һөнәрен үзләштерәләр.

Еллар үткәч, Гөлҗәннәт, ике кызын ияртеп, Баяновка поселогындагы зиратка килде... Бер төркем эшчеләр койма буендагы кабернең тутыккан рәшәткәләрен алмаштыралар иде. Кабер янсенең Советлар Союзы Герое булганлыгы турында Мәскәүдән хәбәр кайткан... Шәһәр үзәгендәге Тынычлык мәйданына алсу мәрмәрне чүкеп ясалган истәлек таш куйганнар. Аның Алтын Йолдызы да, Алтын Йолдыз астындагы «Советлар Союзы Герое Хәсән Замановка» дигән сүзләр дә тутыгуга мәңге бирешми торган затлы сары металлның кайнар эретмәсе белән йөгертелгән.

Гөлҗиһан искергән рәшәткәне кискәндә эреп аккан һәм җиргә төшеп югала барган ахактай тамчыларга карап уйга чумды. Энисе дә, сеңелесе Гөлмәрьям дә шундый авыр халәттә. Ничә кат килделәр алар шулай өчәүләп, күпме яшь түктеләр әнә шул тимер рәшәткәләргә тотынып. Бу минутта да эрегән металл түгел, өчесенең ачы күз яше җиргә тама шикелле тоелды аңа.

Өчесе дә тавышсыз-тынсыз гына елыйлар иде. Яшьле күзләрендә әрнүле сагыш, сагыш, сагыш...

Кабер өстенә «Советлар Союзы Герое Хәсән Заманов. 1912—1951» дип язылган яссы, шома ташны бастырып куйдылар. Һәммәсен дөрес язганнар. Эх, мең тугыз йөз кырык өчнең ноябренда ук шулай дөрес язган булсалар...

Кабер янындагы өч җанның дөньясын моң, моң, моң сарды...

Аларны шунда рәсемгә төшерделәр. Бу рәсем хәзер миндә. Кабер. Рәшәткә янында өчәү. Сагышлы күзләр.

Мин һаман уйланам. Әгәр ялгыш бер хәрефне төзәтү дистә елларга сузылмаган булса...

# ПУБЛИЦИСТИКА

*Совет халкының матди һәм рухи байлыкларын саклап тоту һәм ишәйтә бару безнең социалистик җәмгыятьтә дәүләт күләмендәге эш, бөтен халык эше итеп карала. Тарих һәм культура һәйкәлләренә сакчыл караш тәрбияләү — шул зур эшнең зур бер өлеше.*

*Бездә тарих һәм культура һәйкәлләрен саклаучыларның Бөтенроссия җәмгыяте менә ун елдан артык эшләп килә. 1976 елның октябренда ил күләмендә тарих һәм культура һәйкәлләрен саклау буенча махсус Закон кабул ителде. Совет халкы үзенең төп Законында: «Тарихи истәлекләрне һәм башка культура байлыкларын саклау турында кайгырту — СССР гражданнарының бурычы һәм вазифасы», дип язды.*

*Илебезнең матди һәм рухи байлыкларына сакчыл мөнәсәбәттә булу, аларны ишәйтә баруга хезмәт кую барыбызның да бурычы һәм вазифасы... Журнал редакциясе шул турыдагы фикерләре белән уртаклашуны сорап, Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, тарих һәм культура һәйкәлләрен саклау буенча Бөтенроссия җәмгыятенең Татарстан бүлеге Советы президиумы председателе, профессор Мансур Хәсән улы Хәсәновка, СССР Фәннәр академиясенең археография комиссиясе әгъзасы, доцент Миркасыйм Габделхәй улы Госмановка, СССР дәүләт премиясе лауреаты язучы Гомәр Бәшир улы Бәшировка мөрәҗәгать итте. Түбәндә аларның җаваплары урнаштырыла.*

**Мансур Хәсәнов**

## БӨТЕН ХАЛЫК ЭШЕ

Безнең социалистик җәмгыятьтә тарих һәм культура һәйкәлләре социалистик милек, җәмәгать милке, халык байлыгы дип игълан ителгән. Халык милкенә сакчыл мөнәсәбәттә булу — СССР гражданнарының төп конституцион бурычларыннан берсе. «...байлыкларны саклау, арттыра бару һәм алардан киң файдалану», Конституциядә күрсәтелгәнчә, «совет кешеләрен әхлакый һәм эстетик тәрбияләү, аларның культура дәрәҗәсен күтәрү өчен» кирәк.

Менә нилектән эшче һәм крестьяннар дәүләте беренче көннәреннән үк, Владимир Ильич Ленин инициативасы белән, тарих һәм культура һәйкәлләрен исәпкә алу һәм саклау, аларны хезмәт ияләрен тәрбияләүдә файдалану юнәлешендә хәлиткеч чаралар күрде. Менә нилектән партиябез һәм Совет хөкүмәте тарих һәм культура байлыкларына карата ленинчыл мөнәсәбәттә булып килде һәм шундый мөнәсәбәтне илебезнең яңа Конституциясендә законлаштырды.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Леонид Ильич Брежнев партиянең XXV съездына отчет докладында, совет кешеләрен «идея ягыннан тәрбияләү мәсьәләләре, коммунизм төзүче яңа кешене тәрбияләү проблемалары безнең бөтен эшебездә зур урын алып торуын» ассызыклап әйтеп», «... бөтен тәрбия эшенең куелышына комплекслы якын ки-

лү, ягъни, хезмәт иямәренең төрле группаларының үзенчәлекләрен исәпкә алып, идея-политик, хезмәт һәм әхлак тәрбиясенең тыгыз бердәмлеген тәэмин итү» бурычын куйды. (КПССның XXV съезды материаллары. Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 74 бит.)

Хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүнең шушы колачлы программасы Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан тагын да нәтиҗәлерәк төстә тормышка ашырыла башлады. Барлык тәрбия эшләре совет халкының революцион һәм хезмәт традицияләрен үстерә баруга, социалистик патриотизм һәм интернационализм рухын тирәнәйтүгә, хезмәт ияләрендә югары әхлак сыйфатлары, коммунизм идеалларына бирелгәнлек хисләре тәрбияләүгә багышланды.

Шушы зур эштә халыкның культура һәм тарих һәйкәлләрен саклау җәмгыятенең дә өлеше күзгә күренерлек. Мондый оешма Россия Федерациясендә инде дистәдән артык ел дәвамында эшләп килә. Җәмәгать тәртибендә эшләүче бу оешма бүгенге көндә унике миллионнан күбрәк кешене берләштерә. Җәмгыятьнең мөмкинлекләре елдан-ел зурая бара. Мәсәлән, узган ел дәвамында һәйкәлләрне саклау һәм реставрацияләү эшләренә кырык миллион сум акча тотылды.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең алтмыш еллыгы хөрмәтенә уздырылган Бөтенроссия смотрына кушылып, безнең Татарстан җирендә тарих һәм культура һәйкәлләрен барлау, төзекләндерү җәһәтеннән дә күзгә күренерлек эшләр башкарылды. Мәгълүм ки, безнең республика революцион көрәшкә, Совет власте үсеше тарихына бәйләнешле, бишьеллыклар дәвамында эшче һәм крестьяннарның хезмәт батырлыгына караган истәлекләргә гаҗәеп бай. Башкалабыз Казан шәһәрен генә алып карыйк. Ул — В. И. Ленинның революцион яшьлеге чыныккан шәһәр. Юлбашчыга бәйле изге урыннары белән ул дөньяның төрле почмакларыннан миллионнарча кешеләрнең күңелен үзенә тартып тора. Казандагы В. И. Ленин музей-йортында кырык ел эчендә йөз дә дүрт илдән дүрт миллионнан артык кеше булды. Безнең җәмгыять Ленин урыннарын өйрәнү һәм пропагандалауны үзенең иң мөһим эшләреннән берсе итеп саный.

М. И. Калинин, Я. М. Свердлов, Н. Э. Бауман эшчәнлеге белән бәйле тарихи урыннар ачыкланды һәм төзекләндерелде. Җәмгыять шулай ук Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовның 90 еллыгын, М. Җәлилнең 70 еллыгын лаеклы рәвештә үткәрүдә зур өлеш кертте: аларның тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган фәнни конференцияләрне оештыруга катнашты, аларга бәйләнешле истәлекләрне барлады, М. Җәлилнең архивын сатып алды, Г. Тукайның туган якы Тукай-Кырлайда мемориаль үзәкне коруга акчалата ярдәм күрсәтте.

Күренекле химиклар А. М. Бутлеров һәм А. Е. Арбузовның тормыш һәм эшчәнлеге Татарстан җире белән бәйле. А. Е. Арбузовның йөз еллыгы республикада зурлап уздырылды. Быел А. М. Бутлеровның йөз илле еллыгы билгеләп үтелә. Моңа әзерлек эшләре 1976 елның ноябрендә Татарстан АССР Министрлар Советының шул юбилейга хәзерләнү турында махсус карары чыгарылгач та башланды. Бөек галимнең истәлеген мәңгеләштерү буенча хәзер гаять зур эшләр төгәлләнеп килә.

Мәгълүм ки, Лев Николаевич Толстойның балалык һәм яшьлек еллары Казанда үткән. Быел бөек әдипнең тууына 150 ел тула. Безнең җәмгыять шушы истәлекле юбилейны үткәрүгә дә үзеннән зур өлеш кертә.

Тарих һәм культура һәйкәлләрен саклау җәмгыятенең халык арасында тәрбия эше шул һәйкәлләр саклап тотылганда гына нәтиҗәле була ала. Ә аларны саклау эше исә матди чыгымнар тотуны сорый. Шуңа күрә дә булган мөмкинлекләрне кирәгенчә файдалануның һәм идеологик, һәм экономик җәһәттән мөһим әһәмияте бар.

Җәмгыятьнең Татарстан бүлеге республикадагы тарих һәм культура һәйкәлләрен төзекләндерү, саклануга кую һәм реставрацияләү буенча 1976—1980 нче елларга махсус план эшләде. Анда Казан Кремлен реставрацияләү эшләре зур урын алды. Казанлылар һәм башкалабыз кунаклары күреп торалар: биредә стеналар һәм башнялар яңартыла, галереялар яңартыла, агач түбәләр ныгытыла. Кремльдәге эшләр белән беррәттән, Казанда тагын Әҗем, Апанай мәчетләрен, Петропавел соборын,

XVII йөз һәйкәле — София чиркәвен, Казан университетының Астрономия обсерваториясен реставрацияләү буенча да эшләр алып барыла. Борынгы Болгар дәүләтенә кергән Биләр, Сувар һәм башка шәһәрләрнең архитектура һәйкәлләрен, Свияга һәм Раифа архитектура һәйкәлләрен ремонтлау һәм реставрацияләүгә, саклап тотуга зур чыгымнар билгеләнде. Бу бишьеллыкның ахырына борынгы Болгар һәйкәлләрен торгызу, яңарту буенча төп эшләрне төгәлләп, аларны халыкка күрсәтерлек музей хәленә китерү күздә тотыла. Соңгы елларда биредә бик күп нәрсә эшләнде дә инде. Шул уңайдан, мәсәлән, Болгар һәйкәлләре өчен бүлеп алынган җирләрне сөрдермәү, заповедник мәйданында аэродром һәм төрле корылмалар төзетмәү өчен республиканың һәйкәлләрне саклау органнарына күп көч куярга туры килде. Тарих һәм культура истәлекләренә карата саксыз мөнәсәбәт күренешләре Куйбышев районында гына түгел, башка урыннарда да, кызганычка каршы, әле очрап куйгалый.

Һәйкәлләрне барлау, төзек тотуның тәрбияви әһәмиятен пропагандалауның иң ышанычлы мөмкинлеге — аларга шефлык итү. Бөек Ватан сугышында Җиңүнең утыз еллыгына әзерлек вакытында йөзләрчә обелисклар, монументаль сәнгать һәйкәлләре безнең җәмгыятьнең башлангыч оешмалары һәм коллектив әгъзалары тарафыннан үрнәк төстә тәртипкә китерелде. Бу юнәлештә Казан шәһәренең Ленин район советы эше аеруча мактау һәм хуплауга лаек. Биредә барлык төр һәйкәлләр промышленность предприятиеләре карамагына тапшырылган: һәйкәлләрнең төзеклеге өчен алар җаваплы.

Соңгы елларда гына бездә ике йөздән артык тарих һәм культура һәйкәле исәпкә алынды. Шулардан алтмыш сигезе дәүләт саклыгына тәкъдим ителде. Бу эштә Казан төзүче-инженерлар институты, Казан университеты студентлары, Киров районы халык музее җитәкчелегендәге ветераннар актив катнашалар. Тарих һәм культура һәйкәлләренә шундый игътибарлы мөнәсәбәт үрнәкләрен күпләп санарга мөмкин булыр иде.

Һәйкәлләрне барлау һәм өйрәнү нәтиҗәсендә Казандагы дүрт йөз истәлекле урын һәм һәйкәл хакында белешмә материал тупланган бер том хезмәт әзерләнде. Хәзер Татарстандагы һәйкәлләргә багышланган икенче том өлгертелә.

Безнең җәмгыять — ирекләләр, патриотик аңы һәм йөрәге кушуы буенча җәмәгать тәртибендә эш алып баручы гражданнар оешмасы ул. Без җәмгыятьнең сан ягыннан да үсә баруына, аның башка җәмәгать оешмалары белән дә эшлекле бәйләнешен ныгытырга тырышабыз.

Җәмгыятьнең республика Советында тарихи-революцион һәйкәлләр, архитектура истәлекләре, әдәби һәйкәлләр, пропаганда һәм музыка культурасы, һәм халык хореографиясе һәйкәлләре секцияләре эш алып бара. Һәйкәлләрне халык арасында пропагандалау секциясенең тырыш эшчәнлеген күрсәтеп үтү кирәк. Алар матбугат, радио һәм телевидение аша республикабызның тарихи һәм культура мирасына багышланган әңгәмәләр оештыралар: Татарстанда революция хәрәкәте эшлеклеләре, гражданнар сугышы һәм хезмәт ветераннары турында сөйлиләр. 1976 елда Казан шәһәренең тарихи һәм культура һәйкәлләрен пропагандалауга игътибар аерата зур булды. Әйтик, телевидениенең «Кичке Казан», «Идел» кебек тапшыруларында бу тема даими урын алды.

Татарстанның истәлекле урыннарын рәсемнәр һәм илһамлы сүз белән сурәтләгән альбомнар чыгарылды, Казандагы архитектура истәлекләрен күрсәтүгә багышланган фотокүргәзмә оештырылды, татар әдәбияты эшлеклеләренең тавышлары язып алынды.

Музыка культурасы һәм халык хореографиясе һәйкәлләре секциясе дә үз эшен җәелдерә башлады. Татар халык җырларын язып алу буенча экспедицияләр оештырыла.

Инде әйтелгәнчә, Казан галимнәренең күпчелеге безнең җәмгыятьнең күпкырлы эшчәнлегендә бик теләп катнашалар. Ләкин без алардан тагын да күбрәк ярдәм көтәргә хаклы. Җәмгыятьнең файдалы эшчәнлегенә үз өлешләрен кертүне Казан тарихчылары үзләренең патриотик бурычын һәм конституцион вазифаларын үтәү итеп карау дәрәҗәсенә күтәрелә алырлар дип ышанырга кирәк.

Моңарчы без туган якның истәлекле һәйкәлләрен чагылдырган значоклар, су-

венир әйберләр, открыткалар җитешмәвенә зарлана идек. Хәзер бу кимчелек тә төзәтелеп килә. «Казан» альбомы, «Татарстан шәһәрләре буйлап», «Ульяновскидан Казанга кадәр» дигән китаплар һ. б. чыкты. Казанның шәһәр төзелеше үзенчәлекләре турында хезмәт әзерләнде. Җәмгыять әгъзаларыннан кино һәм фотосөючеләр эшчәнлеге җайга салынып килә. «Аталарыбызның данлы юлыннан», «Сөембикә манарасы» дигән фильмнар, мәсәлән, Бөтенроссия фестивалендә яхшы бәя алды. Казан турында һәм «Волгарь-доброволец» фильмнары да фестивальгә тәкъдим ителде.

Җәмгыятьнең Татарстан бүлеге дүрт йөз меңләп кешене берләштерә. Зур сан бу! Әмма бурыч шундый: мәктәп яшеннән алып бар халык безнең сафларда булырга тиеш. Чөнки тарих һәм культура байлыкларына хуҗаларча мөнәсәбәт тәрбияләү — коммунизм җәмгыятенең яңа кешесен тәрбияләүнең аерылмас бер өлеше ул.

Җәмгыятьнең кайбер башлангыч оешмаларында үз якларындагы кыйммәтле истәлекләрне күреп-белеп җиткермәү кебегрәк кимчелек яшәп килә, үткәндәге яки бүгенге, тарихтан сакланып калган һәм сакланырга тиешле нинди дә булса истәлекле урын, һәйкәл булмаган төбәк юк. Өйрәнергә, ачыкларга, сак астына алырга һәм халыкта шуларга карата хуҗаларча кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләргә кирәк. «1976—1980 нче елларда СССР халык хуҗалыгын үстерүнең төп юнәлешләре»ндә шул хакта бик ачык итеп: «Музейлар эшен, тарих һәм культура һәйкәлләрен саклау һәм пропагандалауны яхшыртырга», диелгән. Коммунизм җәмгыятенең матди нигезен күтәрә баруга юнәлтелгән хуҗалык планнары гомум коммунистик тәрбия эшендәге бүгенге һәм перспективага караган бурычларыбыз белән әнә шулай тыгыз бәйләнә.

## Миркасыйм Госманов

# САКЛАП КАЛАСЫ ИДЕ

Тарихи истәлекләрнең мөһим өлешен тәшкил итүче кульъязма китапларны, төрле характердагы документларны җыю һәм саклау мәсьәләсе хакында сөйли башлаганчы, бер сәеррәк сорауга җавап эзлисе килә. Безнең татар халкы мөстәкыйль бер халык булып формалашканнан бирле күпме язма әсәр иҗат итеп, нихәтле кульъязма китап күчерде икән?

Бу сорауга беркайчан төгәл җавап булмастыр, ахры... Шулай да, моңарчы сакланып калган өлештән чыгып та, безгә кадәр килеп җитә алмаган «бербөтеннең» күләме хакында азмы-күпме якынча фикер йөртеп булыр сыман. Конкрет саннарга мөрәҗәгать итик. Казан дәүләт университеты каршындагы гыйльми китапханәдә чама белән алты-җиде мең кадәре татар кульъязмасы саклана (татарча әсәрләр генә түгел, бәлки татар җирлегендә төзелгән, күчерелгән төрле телләрдәге кульъязмалар гына!). Ленинград, Мәскәү һәм Уфа китапханәләрендә өч-дүрт мең нөсхә китап бар. Йөзләгән татар кульъязмасы Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан дәүләт музеенда саклана. Чит ил китапханәләрендә дә берничә йөз татар кульъязмасы булырга тиеш. Төмән, Тубыл, Томск, Алма-Ата, Ташкент, Бохара, Сәмәрканд һәм Бакуларда да безнең Идел буенда күчерелгән китапларны дистәләп-дистәләп очратырга мөмкин. Шулай итеп, безнең көннәрдә гыйльми учреждениеләрдә саклanучы татар кульъязмаларының тулаем санын якынча 10—11 мең дип чамаларга мөмкин (ләкин бу әле бик якынча сан гына...).

Күпме, әллә азмы? Минемчә, элек тудырылган, гамәлдә булган язма репертуарның бик бәләкәй генә өлешен тәшкил итә ул. Моның шулай икәнлеген күрер өчен башка характердагы саннарга мөрәҗәгать итик. Соңгы елларда Казан дәүләт универ-

ситеты каршында кульязмалар җыю буенча махсус экспедиция эшләп килә. 1963 елдан бирле, биш йөзләп эреле-ваклы авылларны тикшерү нәтиҗәсендә, өч меңнән артык кульязма җыелды. Шуның 80—85 процентын татар кульязмасы тәшкил итә. Меңгә якын кульязманы соңгы 5—6 ел эчендә Казан һәм Уфа гыйльми институтлары хезмәткәрләре туплады. Мәгәр экспедицияләр оештыручы әлеге оешмалар татарлар яши торган төбәкләрнең нибары 7—8 процентын гына тикшереп чыга алдылар. Димәк, шундый район һәм авылларның барысын да йөреп, җентекләп эзләнеп чыксак, чама белән исәпләгәндә, без иң кимендә тагын 30—35 мең кульязма җыя алыр идек.

Хәзер инде гарәп хәрефләре белән татар җирлегендә язылган кульязмаларның гомум язмышына игътибар итик. Татарлар бу язу белән болгар чорыннан, ягъни тугызынчы-унынчы гасырдан алып, безнең чорга, төгәлрәк әйткәндә, XX гасырның 20—30 нчы елларына кадәр актив файдаланган. Шул мең еллык тарих дәвамында иҗат ителгән әсәрләрнең, күчерелгән китапларның иң зур өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җитә алмаган. Чөнки төрле яулап алу сугышлары, восстание-чуалышлар вакытында, ягъни таш диварлар җимерелеп, агач биналар көлгә әверелгән чакларда, кәгазь китаплар меңәрләп-меңәрләп һәлак булган. Идеологик бәрелешләр чорында да, әйтик, христиан миссионерлыгы һөҗүме нәтиҗәсендә туздырылган мәчет-мәдрәсәләрдәге бик күп китаплар юкка чыгарылган. Шулай ук өлкәбезнең агач архитектура патшалыгы булуын да онытмыйк. Бездә, мәсәлән, кайчандыр ут афәтенә очрамаган авыллар бик сирәк. Кайбер авыллар урамы-урамы, хәтта тулаемы белән янып беткән. Билгеле, мондый иҗтимагый һәм табигый хәвеф-хәтәрләр вакытында ничәмә-ничә буыннар дәвамында иҗат ителгән, тудырылган кульязмалар көлгә әйләнгән... Менә шул объектив бәла-казалар өстенә кәгазь дигән материалның чагыштырмача кыска гомерле булуын да өстәсәк, кайчандыр реаль репертуарда булган әсәрләрнең бик бәләкәй өлеше генә саклана алуына ышанырбыз. Шуңа күрә безнең көннәргә хәтле сакланып килгән — җыелган һәм әле җыелмаган — кульязма байлыгыбыз элекке реаль, ягъни тудырылган репертуарның якынча өч-дүрт процентын гына тәшкил итәдер. Артык булмастыр кебек.

Димәк, без авыллардан ел саен җыеп кайта торган һәм исәп-хисап документларында «ике йөз кульязма», «өч йөз илле китап» дип күрсәтә торган «эре саннар» чынбарлыкта зур казалардан котыла алган кечкенә өлешләр, бәләкәй процентлар гына икән. Икенчерәк итеп әйткәндә, без элгәрге «бөтеннәрнең» кыйпылчык һәм ярчыкларын гына җыя алабыз икән...

Менә шушы хәлләрнең барысын да игътибар үзәгендә тотсак, тарихи истәлекләрне саклау, алардан файдалану хакындагы яңа Законның әһәмияте тагы да аңлашыла төшә. Кульязма китаплар, төрле акт документлары да, закон билгеләгәнчә, тарихи истәлекләрнең бер өлешен тәшкил итә.

Яңа Закон шулай ук, моңарчы туплаган бай тәҗрибәдән чыгып, борынгы чор истәлекләр генә түгел, бәлки яңа заман әсәрләренә дә игътибар итүне таләп кыла. Бу табигый: борынгыны белмичә, яңаны аңлап булмый, яңаны, хәзергене сакларга өйрәнмичә торып, борынгыны хөрмәт итә алуы бик читен. Ниһаять, бу Закон тарихи истәлекләр хакында берьяклы политик, яисә тар милли принциптан гына чыгып кайгыртмый, ә гомум кешелек культурасы югарылыгыннан, гомум совет культурасы интересыннан торып кайгырта. Менә шуңа күрә тарихи истәлекләрне саклау, табигатьне саклау кебек үк, яңа Конституциядә дә чагылыш тапты. Димәк, татар тарихи истәлекләре, шул җөмләдән татар кульязмалары да, совет халкының гомум культура мирасының бер өлеше буларак, яңа Закон химаясенә алына.

Халкыбызның язма культура мирасын җыю, саклау һәм өйрәнү юлында без шушы зур принциптан чыгып гамәл итәргә тиешбез.

Тарихи истәлекләрне саклау һәм файдалану өлкәсендә дәүләтебез алга куйган яңа бурычларны истә тотсак, без җыя торган һәр яңа кульязманың фән өчен нинди әһәмияткә ия булуы бик ачык аңлашылыр. Элгәрге «бөтен» турында чын-чынлап дөрес фикер йөртер өчен, аның «өлешләрен» күбрәк табарга кирәк безгә.

Ләкин бурычыбыз эзләү һәм җыю белән генә чикләнми. Төп бурыч — саклау һәм файдалану. Кульязмаларны чын-чынлап саклауны бары гыйльми китапханәләр, архив һәм музейлар гына тәэмин итә ала. Болай кистереп әйтүнең сере шунда ки, шәхси

китапханәләр, кагыйдә буларак, кыска гомерле була. Чөнки һәр буынның үз уку репертуары бар. Әйтик, узган гасырда язылган, күчерелгән китапларны бүгенге ил агалары да укый алмыйлар инде. Димәк, иске китапларның реаль кыйммәте, тормышчан конкрет хаҗәте юкка чыга, шуңа күрә алар чормага менәләр, утын келәтләренә күчәләр, яисә, кызганычка каршы, юк ителәләр. Шул рәвешчә моннан 80, 90, 100, хәтта 200 еллар элек күчерелгән, шуннан бирле ата-баба истәлеге, гаилә милке булып сакланып килгән китаплар киләчәк буыннарга калмый. Алар белән бергә борынгы бабайларның уй-фикерләре, шатлык һәм моңнары, зирәк тәҗрибәсе һәм кайгыхәсрәтләре дә мәңгегә югалалар. Бабайларның җанлы авазларын, «тере сүзләрен» болай югалту гаять аянычлы, әлбәттә.

Борынгы репертуарның калган хәтлесен туплау өчен, әлбәттә, галимнәрнең тырышлыгына киң җәмәгатьчелегебезнең дә булышлыгы кирәк. Укучылар шуны дөрес аңласын иде: ата-баба истәлеге булган кульъязмалар аерым кулларда, хосусый милекләрдә түгел, бәлки гыйльми китапханәләрдә генә чын мәгънәсендә гомерле булалар, хәтта яңа гомер белән яши башлыйлар. Тарихи һәм рухи культура истәлекләрен, кульъязма мирасыбызны без бер үзебез өчен генә түгел, киләчәк буыннар өчен дә сакларга тиешбез.

**Гомәр Бәширов**

# ӘЛЕ СОҢ ТҮГЕЛ

**Үткәндәгеләргә илтифат — мәдәниләкне вәхшәттән аерып торучы бер сыйфат ул.**

**А. С. Пушкин.**

Күптән түгел Казан урамыннан колхоз базарына таба баручы, аркасына берничә кием чабата аскан бер авыл бабаена күзем төште. Өч-дүрт шәһәр кешесе бабайны туктаттылар да чабаталарын шундук алып та бетерделәр. Бу хәл мине кызыксындырды. Нигә кирәк булыр икән хәзерге шәһәр кешеләренә чабата? Чабата сатып алучы бер ханымнан сорамыйча булдыра алмадым. «Кызык бит. Мондый аяк киеме турында күп ишетсәм дә, юньләп күргәнем юк иде. Минем ата-бабам чабата киеп үскән кешеләр бит!..» — диде ханым.

Бу ханымның сүзләрендә мин халыкның башыннан узганнарга игътибарлылык, ата-бабасына ихтирам ишеттем.

Революциягә кадәр шәһәр мещаннары сала кешесен әнә шул чабата белән битәрлиләр: «Әй, гыйбеди! Кая тыгыласың монда чабатаң белән?!» — дип мыскыллыйлар иде... Заманалар үзгәрде. Революция елларында калага килгән чабаталы авыл егетләре һәм авыл кызлары, тиз арада шәһәр культурасын үзләштереп, яңа тормыш коручылар сафына бастылар.

Кечкенә чакта безгә «утка төкермә, иренең кутырлар, җилгә каршы төкермә, үз битеңә төшәр» ди торганнар иде. Тарихны «төзәтергә» ярамаган кебек, аннан көләргә дә ярамый, бәлки аны ничек булса, шулай өйрәнергә, белергә, хәзерге һәм киләчәк тормыш өчен аннан гыйбрәт алырга кирәк. Хәзерге яшьләр арасында илебез ирешкән җиткелекле тормышның кадерен белмичә, дәүләт һәм җәмәгать милкен исраф итүчеләр, ваемсызлык һәм җавапсызлык күренешләре аз түгел. Болар, ми-

немчә, күбесенчә, тарихны белмәүдән, аннан сабак алырга теләмәүдән килә. Кайбер яшь кешеләр тарихта безнең заман кешесе игътибар итәрлек бер ни дә юк, чөнки безнең бабайлар элек тоташ надан булганнар, бик йомыкый һәм томана яшәгәннәр дигән фикердә тора. Дөрес, ул заманнардагыны хәзерге белән чагыштырып булмый. Аерма бик зур. Шулай да халыкның культура дәрәҗәсе аттестатлар, дипломнар саны белән генә үлчәнми бит. Халыкның мең еллардан бирле тупланып килгән бай тормыш тәҗрибәсе, гасырлар буена халыкны халык итеп саклап килгән үз теле, изге гореф-гадәтләре, үз культурасы бар. Бу бай культура аның күңелендә сакланган, фольклорында, җиде-сигез гасыр буена язылып килгән әдәбиятында, ниһаять, матди җиһазларында, архитектурасында, кулланыш һәм бизәнү әйберләрендә гәүдәләнеп калган.

Минемчә, халыкның матди культурасына да игътибар итәргә, аны да өйрәнергә вакыт җитте. Чөнки саклау чарасын хәзер күрмәсәң, бераздан бик күп нәрсәнең бөтенләй юкка чыгуы ихтимал.

Бу хакта хөкүмәтнең махсус карары чыгу уңае белән, әлеге иксез-чиксез бай мирасның иң элек кайсы төрләренә игътибар итәргә соң?

Хәзер авылларның байтагында этнографик музейлар ачу гадәткә кереп бара. Мин моны ифрат кирәкле культура чараларының берсе дип әйтер идем. Мин үзем, бу изге эшне иң элек халык тормышында зур әһәмияткә ия булган төрле зур вакыйгаларга бәйләнешле материалларны туплау һәм саклап калудан башларга кирәк дияр идем. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның төрле истәлекле әйберләре, солдат хатлары, өс-баш киемнәре, кораллар, медальләр һ. б. Кайбер авылларда бик күп еллардан бирле язылып килә торган шәҗәрәләр табарга мөмкин. Инде борынгырак заманнарга кереп киткәч, иң кирәкле материаллар итеп, мин башта халыкның зирәклеген, тапкырлыгын күрсәтә торган оригиналь әйберләр туплауны максат итеп куяр идем, мәсәлән, бөтен авылны бетереп, көтүче таягын эзләр идем. Көтүче бабайның үзе озынлыгы шул сырлы-сырлы сөян таягы кечкенә чагында безгә әкиятләрдәге суксаң телисә нәрсәне барлыкка китерә торган тылсымлы таяк кебек күренә иде.Ниләр генә булмый иде ул серле таякта! Һәр йортта ничә сыер, күпме тана, сарык, кәҗә йөри бабайның көтүендә? Шуларны көткәнгә Гыйльмениса, Хәерниса, яисә Бибиҗамал, Гайникамал түти күпме түләгән, тагын күпме түлисе калган? Авылның барлык терлек-туарын теркәргә бухгалтер дәфтәрендә, ихтимал, берничә бит кирәк буладыр. Ә менә көтүче бабай шуны куш бармак калынлыгы бер таякка язу-сыз-нисез сыйдыра иде. Бабайның чалгы пәкесе бер кирт ясадымы — бер сыер, тагын бер кирт — ике тана, алты сарык та бер кирт... Әле бит һәр йортныкы аерым-аерым исәпләнә. Анысы тамгалар ярдәмендә. Тамга дигәннән, авыллардагы һәр йортның җир тамгасын җыеп музейда күрсәткәндә ифрат кызык чыгар иде. Нинди билгеләр генә очратмыйсың тамгалар арасында! Каз аягы, дуга, балта, божра, сәнәк тамга. Аларны чынлап торып өйрәнгәндә, тамгаларның мәгънәсез сызыклар гына түгел, бәлки борын заманнардан бирле буыннан-буынга күчеп килә торган нәсел символлары булуы ачыкланыр иде. Элекке морзалар, князьләр, графларның үз гербләры булган икән, нигә игенче агайга алардан калышырга?

Яисә менә элекке һөнәрчеләрне алыйк. Аларның, хәзергечә әйткәндә, клиентлар белән ике арада квитанция урынына йөртелә торган биркәләре дә бик кызык иде. Буяучы яки тире иләүче буе өч-дүрт, калынлыгы бер сантиметр булган сөяк кисәгенә пәке белән ниндидер билгеләр ясый да, шуны урталай ярып, яртысын киндергә яки тирегә тага, яртысын сиңа бирә. Менә сиңа квитанция! Аны бер мошенник та боза да, төзәтә дә алмый!

Тарихчылар раславынча, борынгы заманнарда хезмәт иясенең күпчелеге мохтаҗлыкта, шактый ук кысынкы шартларда яшәргә дучар ителгән. Әмма халык, әнә шул авыр тормышны аз гына булса да җиңеләйтү өчен, әйләнә-тирәсен, эш коралларын кулыннан килгән кадәр матурларга, аларга күркәмрәк төс бирергә омтылган. Әгәр дә игътибарлырак булсагыз, сез хатын-кыз эшендә кулланылган киерге, каба, бәләк, орчык кебек эш коралларыннан башлап, көянтә, чиләк кебекләргә кадәр һәммәсендә төрле матур орнаментлар, күңелгә хуш килердәй бизәкләр очратырсыз. Болар һәркайсы билгеле бер эстетик зәвык белән эшләнгән булыр. Мәсәлән, көянтә-чиләк ак-сыл-зәңгәргә яисә яшелгә буялып, чиләккә көмеш чәчәкләр яисә йолдызлар төшере-

лә. Әгәр урган җир өстеннән челтер-челтер килгән тавыш ишетсәң, белеп торасың, Мәкәрҗә урагы челтери һәм ул урак кызлар кулында булырга тиеш! Нигә челтери? Чөнкиуракның сап очына металл боҗра тагылган.

Авыл музейларына куярга элекке сырлы-сырлы, буяулы дугаларны, шул дугаларга тагыла торган төрле зурлыктагы кыңгырауларны табып булмасмы икән? Шулай ук урак урганда киеп чыгыла торган җиңсәләр дә музейларны тулыландырып җибәрер иде.

Халыкның, бигрәк тә хатын-кызның бик борынгыдан килә торган бизәнү әйберләре үрнәкләрен саклап калганда ифрат та мактаулы бер эш башкарылган булыр иде. Мәгълүм ки, алка, йөзек, балдак, беләзек, чулпы кебек бизәнү әйберләрен чүкеп, коеп һәм башка ысуллар белән эшләп чыгаруда бу һөнәр белгечләре заманында гаҗәп зур осталыкка ирешкәннәр иде. Галимнәрнең раславына караганда, татар һөнәрчеләренең алтын-көмештән эшләп чыгарган бизәнү әйберләре оригинальлек, нәфислек, затлылык ягыннан мәшһүр Көнчыгыш осталарының эшләре белән тиңләрлек дәрәҗәгә менгән булган. Менә шуларның үрнәкләрен киләчәк буынга да саклыйсы иде бит. Кайберләрен, бик тырышканда, бәлки сувенир итеп хәзер дә эшләп чыгарырга мөмкинлек туар иде.

Су һәм җил тегермәннәренең халык тормышында зур урын тотулары өлкән яшьтәге кешеләрнең һәрберсенә билгеле. Бу корылмалар үзләре һәм алар тирәсендә булып узган күп төрле тарихи вакыйгалар матур әдәбиятка да, халыкның авыз иҗатына да кереп калган. Гомумән, элекке заманда тегермәнсез авыл булмаган диярлек. Болардан җил тегермәннәре хакында сүз алып бару, ихтимал, бөтенләй урынсыздыр инде. Чөнки безнең республикада җил тегермәнен никадәр эзләсәң дә таба алмыйсың. Әмма җил тегермәне элекке татар авыллары пейзажының аерылгысыз бер элементы булганлыктан, балаларны таныштыру өчен, музейларда аларның макетларын күрсәткәндә дә яхшы булыр иде.

Ә менә су тегермәннәренең кайберләрен саклап калырга мөмкин әле. Балтач районының Янгул һ. б. кайбер авылларында, Азнакай районында берничә су тегермәне әле дә бар.

Су тегермәнен, аның буасын, гомумән, бөтен тирә-юнен бозмыйча саклауның тарихи яктан гына түгел, бәлки хәзерге хуҗалык өчен дә әһәмияте зур. Хәзерге яшьләрнең кайберләре «надан, чабаталы» дип кимсетеп телгә ала торган борынгы авыл кешеләре алай мәнесез надан булмаганнар, буаларны урынын белеп, барлык инженерлык законнарын дөрес һәм акыллы кулланып, мәңгелек итеп буганнар. Шуның нәтиҗәсендә, алар буаны комплекслы файдалануга ирешеп, бер атуда дүрт-биш куян алганнар. Менә уйлап карагыз! Тегермән ашлык тарткан, ярма ярган, буаның шул суы еракларга кадәр дым таратып, болыннарда мул үлән уңышы үстергән; буада һәм инешләрдә күп булып төрле балык үрчегән; авыл тирәсендә суга муллык булганлыктан, каз-үрдәк асрарга киң мөмкинлек туган. Моннан тыш, буа тирәсендә яшеллек зонасы хасил булып, анда игенчегә файдалы вак кошлар һәм җәнлекләр үрчүен, андагы микроклиматның якын-тирәгә дымлы һава һәм кислород таратып торуын, табигать матурлыгын һ. б. искә алмыйча мөмкин түгел. Кызганычка каршы, су тегермәннәре бетерелгәндә буалар да ерылып акты, авыл болыннары өстә санап үтелгән әнә шул уңайлыклардан бөтенләй мәхрүм калды. Шуның өстенә, электән килгән экологик баланс бозылу нәтиҗәсендә, су буйларында, болыннарда эрозиягә киң юл ачылды, элек булмаган чокырлар, коры елгалар хасил булды, якын-тирәдәге чишмәләр корыды, тегермән тирәсендәге яшеллек юкка чыгып, ул тирә ташландык җиргә әверелде.

Буалар мәсьәләсен хәзер кайберәүләр мелиораторлар өстенә аударырга әзер торалар. Дөрес, соңгы елларда мелиорация эшләре киң колач алды. Ләкин мелиораторларның хәзергә әле зур массивлар белән эш итүен истән чыгарырга ярамый. Авыл җирендә агып ята торган кечкенә елгаларда, инешләрдә су режимын тәртипкә салуны мелиораторлардан көтеп ятуның һич кирәге юк. Элекке буаларны тәртипкә китерергә, инженерлык кагыйдәләренә туры китереп яңасын салырга һәр колхозның көче җитәчәк. Ростов һ. б. өлкәләрдә авыл буаларының кирәклеген күптән шулай аңладылар инде.

Халыкның архитектура һәйкәлләрен саклау җәһәтеннән, минемчә, кайбер мәчет биналарына, шулай ук татар авылларында гына очрый торган, бик тә оригиналь стильдә салынган аерым өйләргә игътибар итәсе иде. Дингә өндәү урыны буларак, хәзер мәчетләрнең һичбер кирәге һәм әһәмияте калмады. Ә халыкның архитектура һәйкәле итеп саклардай мәчет биналары очраштыргалый әле. Латвия ССРдагы Юрмала шәһәреннән үрнәк алып, бәлки кайбер мәчет биналарын этнография музее итеп файдалану мәслихәттер?

Инде торак йортларга килгәндә, андый оригиналь йортлар Арча районының Әтнә, Яңа Кенәр, Олы Мәңгәр авылларында сакланган булырга мөмкин. Бу йортларның төрле бизәкләре, орнаментлары да халыкның эстетик зәвыгын өйрәнергә файдалы материал булыр иде дип ышанасы килә

Моңа кадәр тарихи әһәмияте яки культура ягыннан кыйммәте булган матди байлык хакында сүз барды. Болардан тыш тарихи вакыйгаларга яисә бөек шәхесләргә бәйләнешле урыннар һәм йортлар да күп бит әле. Мәсәлән, Казанда Л. Толстой, М. Горький һ. б. яшәгән, А. С. Пушкин булган йортлар бар. Шулай ук әдәбиятыбызның классиклары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ф. Әмирхан исеме белән, революционерлардан Мулланур Вахитов, Хөсәен Ямашев, Камил Якуб исемнәре белән бәйләнешле йортлар да аз түгел. Безнең уебызча, Татарстан урамындагы Г. Тукай яшәгән «Болгар» номерлары һичшиксез сакланырга, анда Г. Тукайның мемориаль бүлмәсе ачылырга тиеш.

Үз вакытында патша реакциясенә һәм дини караңгылыкка каршы көрәшнең иң «кайнар ноктасы» булган «көфер почмагы», шул тирәдәге чиксез кыен шартларда кыю фикерле, прогрессив һәм революцион эчтәлекле газета-журналлар чыгарылган биналар бөтен килеш сакланса, киләсе буыннар һәм тарих каршында зур әһәмиятле эшләр башкарылган булыр иде.

Уйлашыйкчы, әле соң түгел!

**Шакир Абилов,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ПОЭЗИЯБЕЗ ТАРИХЫНА ЯҢА ИСЕМ

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының археография экспедициясе алып кайткан борынгы кульъязмаларны күздән кичергәндә, бер җыентыкның шигъри юлларында Габди сүзенең берничә тапкыр телгә алынуы, өстәвенә, язган вакыты һәм урыны да күрсәтелгән булуы игътибарны үзенә тартты.

Иске кульъязма җыентык 13×16 см, текст өлеше 9×12 см зурлыгында. Һәр биттә 13 юл, карасы куе көрән төстә. Европа кәгазе. Вакытында куелган бит санына карaганда, баштан 10 кәгазь төшкән, соңгы бит 139 саны белән өзелә. Баштан ахырга кадәр бер кул белән язылган.

Шушы кульъязманың 44—54 нче битләрендә Габди исемле авторның шигырьләре урын алган, барлыгы 520 шигъри юл.

Һәр вакытта тынмаюбән
Сәна[1] әйтер сандугач;
Мескен Габди, нә ятырсән
Кичә-көндез, күзең ач.

Яисә:

Үлгәндин соң бу дөньяга
Канда[2] булыр килмәкең!
Мескен Габди, ярагъ әйлә,
Белмәзмүсән үлмәкең!

— дигән юлларда язучы үзенә Габди дип эндәшә. Моның поэтик исем икәнлеген аның:

Хәлаеклар арасында
«Мескен Габди» ирде нам,

— дигән сүзләре дә аңлата. Халык арасында шагыйрь «Мескен Габди» исеме белән танылган була. Борынгы әдипләрнең күбесе шикелле, Габдинең тормышы турында да әсәренә таянып кына сүз йөртергә мөмкин.

Аның яшәгән һәм иҗат иткән еллары турында да без әсәрләреннән чыгып фикер йөртәбез:

Сәнәдә һәм тарих ирде
Мең дә йөз дә йикрем бердә,

[1] Сәна — мактау.
[2] Канда — кайда, ничек.

яки:

**Тарих ирде мең дә йөз дә**
**Йикерме бередә төз,**

— ди.

һижри 1121 ел — хәзерге хисап буенча 1709 нчы елга туры килә.

**Мескен Габди, ярагъ әйлә,**
**Яшең улды һәм утыз,**

— ди ул шигырьләренең берсендә.

1709 елда утыз яшь тулгач, ул 1679 елда туган була. Бу — бунтарь йөрәкле, атаклы суфи шагыйрь Мәүла Колый иҗат иткән еллар. Мәүла Колый хикмәтләре Габдигә яшь вакытында ук тәэсир иткән булуы мөмкин. Чөнки Габди дә суфичылык карашларында торып язган. Ул үзен мелла-укымышлы кешеләрдән саный, ә Габди иҗат итү урынының исә Казан шәһәре икәнлеген сөйли:

**Мескен Габди, тәгърифнамә**[1]
**Шәһрең булгай һәм Казан.**

Гуаһлык иткән, язган урыны, мактаган җире Казан шәһәре булгач, Габдинең урта гасыр татар шагыйрьләренең берсе икәнлегенә шик калмый. Шулай итеп, татарның борынгы әдипләре рәтенә яңа бер исем өстәлә, ул — шагыйрь Габди.

Габди XVII йөз ахырында һәм XVIII йөз башында яшәп иҗат иткән. Бу — татар халкы тормышында бик авыр чор. Степан Разин җитәкчелегендәге крестьян хәрәкәтләре канга батырыла, татар һәм башкортларның золымга каршы чыгышлары бер-бер артлы бастырыла тора. Социаль изүдән интеккән хезмәт халкын ислам дине тагын да тирәнрәк рухи басынкылыкка этәрә, түземлелеккә өнди. Мондый социаль атмосфера шагыйрь Габдине дә борчый, андый авыр хәлне ул җирдәге көчләрдән түгел, ә алладан дип уйлый.

**Мөселманнар, сабыр кылыңыз:**
**Агыр булды бу дәвер,**

— дип, авырлыкның асыл сәбәпләрен аңламаса да, үзенең киңәшләрен бирә.

**Бер-берегез арасында**
**Кылмагыл золым, җәбер;**
**Шөйлә**[2] **булган кемсәнәгә**
**Бакмагыл, йөзең чәвер**[3]**.**

Бирсдә исә ул үзара җәбер һәм золым эшләмәскә, әгәр андый кешеләр булса, алардан йөз чөерергә, алар белән эш итмәскә куша. Авыр шартларда яшәүче кешеләрнең хәлен җиңеләйтү өчен ул юмарт булырга чакыра:

**һәр ни капсаң, дус-иш берлә**
**Ултырубән бергә йиеңез**[4]**.**
**«Кемнәр барыр оҗмахка!» дип**
**Сурсалар, «Сәхи!»**[5] **диеңез.**

һәм:

**Сәхилекне кылган кеше**
**Ахирәттә нур тик ярур**[6]**...**
**Бирмәгәннәре оҗмахка**
**Йитмәенчә юлда калур,**

— ди. Бу дөньяда юмартлык (сәхилек) күрсәткән кеше үлгәч оҗмахлы булса, саран зат исә тәмуг газапларына дучар булачак дип, мал-мөлкәтлеләрне юмартлыкка өнди.

---

[1] Тәгърифнамә — мактау, тасвирлау, белдерү хаты. Ул «намә» (китап, әсәр) сүзе белән бергә язылганлыктан, «Тәгърифнамә»не әсәрнең исеме итеп тә карарга була: «Мактау китабы».
[2] Шөйлә — шулай.
[3] Чәвер — чөер.
[4] Йиеңез — ашагыз.
[5] Сәхи — юмарт.
[6] Ярур — балкыр, яктырыр.

**Хәер кылгыл алла өчен**
**Йимешең булса тулуг бакча;**
**Аямагыл алтыныңны,**
**Капчык берлә биргел акча.**

Урта гасырда иҗат иткән күп кенә алдынгы фикер ияләре феодализм җәмгыяте тудырган эгоистлыкка, масаюга, хезмәт кешесен түбәнсетеп карауга каршы чыкканнар. Габди дә кешене кимсетеп карауга, аннан көлүгә каршы:

**Үз гаебең үкеш күргел,**
**Кеше гаебен һәргиз[1] күрмә.**

Яисә:

**Хәлаектин мәсхәр[2] итеп,**
**Күзең кыеп, кашың кирмә,**

**— дип яза ул.**

Бу юллардан кешегә карата ягымлылык, аерым бер җылылык беркелеп тора. Шагыйрь кешене кимсетүгә корылган тәкәбберлекне бетерергә тели.

Әхлак, әдәп кагыйдәләре бер урында катып калган яисә үзгәрми торган нәрсә түгел. Һәр заманның үз тәртипләре нигезендә оештырылган мораль кагыйдәләре булган кебек, әхлак тәртипләре дә бар. Габдидә дә менә шушы ике төрле мораль бергә үрелеп бара.

**Тикмә[3] йирдин мал алмагыл,**
**Тырнакыңны каптырып...**

**Сургучылар сөаль сурар,**
**Тапмаганны таптырып;**
**Мескен Габди йимә ашны,**
**Хәлаекны бактырып.**

Биредә әдәплелек мәсьәләсен дин һәм шәригать таләпләре рәвешендә генә аңлау дөрес булмас иде. Шигырьдә мәсьәлә киңрәк куела. Монда башкаларның малына кулны сузмаска кирәк диелә. Габди, гомумән, әдәп, әхлакка зур әһәмият бирә. Ул баланы тәрбия итү һәм аның ата-анага хезмәт күрсәтергә, аларны хөрмәт итәргә тиешлеге хакында да яза.

Кешеләрнең үз-үзләрен тотулары, әдәпле, әхлаклы булулары шагыйрь язганнарда дин морале күзлегеннән бәяләнә, әлбәттә. Урта гасыр шагыйре өчен бу караш табигый. Энгельс сүзләре белән әйткәндә, ул вакытларда «...әгәр аерым сыйныфларның мәнфәгатьләре, таләп һәм ихтыяҗлары дини пәрдә артына яшеренгән булган икән, бу әле һич кенә дә эшнең асылын үзгәртми һәм заманның үзенчәлекле шартлары белән аңлатыла»[4].

Габди — ортодоксаль ислам өйрәтүләрен яклаучы булу белән бергә, рәсми суфичылык карашларын да алга сөрүче. Ул үз чоры җәмгыятенең җәбер-золымын, заманының авырлыгын күреп борчыла. Шул шартларда мескен хәлендә яшәүчеләрне күреп кызгана, җәбер-золымны булдырмаска тырыша. Ләкин ничек?.. Беренчедән, ул күндәмлеккә, сабырлыкка өндәсә, икенче яктан, тәмуг газаплары белән куркытып, милек ияләрен, байларны игелекле кешеләр итеп тәрбияләргә тели.

Кешелеклелек сыйфатларын югары бәяләп, авыр хәлдә калган халыкка ярдәм кулын сузарга чакыру — Габди иҗатының төп идея юнәлеше.

Габди шигырьләре үз заманындагы хаким сыйныфларның хезмәт халкына карата рәхимсезлекләрен күрсәтүе белән дә зур әһәмияткә ия.

**Ир колакын тиштермәңез,**
**Кол кылмакта иң салып;**
**Хатын борынын тиштермәңез,**
**Йөзләренә иң салып.**

[1] Һәргиз — һичкайчан.
[2] Хәлаектин мәсхәр итеп — кешеләрдән көлеп.
[3] Тикмә — һәрбер.
[4] К. Маркс, Ф. Энгельс. Соч., т. VIII, 360 бит.

Биредә сүз бизәнү әйберләре тагар өчен колак яисә борынны тишterүгә каршы тору турында түгел, бәлки социаль мәгънәгә ия булган фаҗигале күренеш хакында бара. XVII йөзнең ахыры һәм XVIII йөзнең башларында колониаль изүгә, алпавытлар золымына түзә алмый крестьяннар өледән-әле баш күтәреп тора. Кузгалышларда катнашучылар соңыннан авыр җәзаларга тартылганнар, күпләрне колакларын, борыннарын, хәтта телләрен кисеп мирза-феодалларга, алпавыт-түрәләргә коллык хезмәтенә җибәргәннәр. Мәсәлән, Оренбург комиссиясе начальнигы В. А. Урусовның 1740 елда Сенатка җибәргән кәгазендә баш күтәрүләргә катнашучыларның төрлечә җәза ителүләре санала. Шулар арасында 301 кешенең, камчы белән суктырылганнан соң, борыннары кистерелеп, «турылыклы старшина» Бардагул карамагына җибәрелүләре әйтелә.[1] Е. Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышларында катнашучыларның да бер өлеше шундый ук җәзага тартылган[2]. А. Пушкинның «Капитан кызы» повестенда 1741 еллардагы баш күтәрүләргә катнашкан өчен колагы да, борыны да, теле дә киселгән бер тоткын башкорт сурәтләнә.[3] Мондый җәберләүләр хезмәт ияләре массаларын куркыту, аларны азатлык, ирек өчен көрәштән ваз кичтерү өчен эшләнгәннәр. Габди исә әнә шундый кимсетүләргә каршы чыга.

**Ир колакын, хатын борнын**
**Берен-берен кисәрләр;**
**Монда явыз кылганнары**
**Анда исенә төшәрләр.**
**Ир колагын тиштерсәңез —**
**Тәмуг төбен тишәрләр.**
**Хатын борнын тиштерсәңез,—**
**Зөбанилар тишәрләр.**
**Бу эшләрдин [гыйбрәт] алып,**
**Явыз эшне ташлаңыз...**

Шулай итеп, шагыйрь дин аша куркыту юлы белән изүче сыйныф кешеләрен явыз эшләрдән тыярга тели. Ул заманда изүчеләрнең башбаштаклыкларына турыдан-туры каршы бару аңа мөмкин булмый.

Һәр заманның алдынгы фикер ияләре иң катлаулы һәм авыр шартларда да хезмәт ияләренең күңеленә юл таба алганнар — аны җәбер-золымнардан араларга омтылып, кешелеклелек сыйфатларын яклап чыгыш ясаганнар. Шагыйрь Габди дә үз халкының кызганыч, авыр язмышын җиңеләйтергә хыялланган, шул турыда борчылган. Ул үзеннән соң калачак ватандашларына иң ягымлы, җылы сүзләр белән мөрәҗәгать итә:

**Мән үләрмен, сез калгайсыз,**
**Яраннарым, яруларым [4].**
**Мәндин сәлам барчаңызга,**
**Яриләрем, барилярым.**

Каршыбызда Габдинең алтмыштан артык шигыре. Шагыйрь аларда тормышка мөнәсәбәтен белдергән, чынбарлыкны чагылдырган. Юллардагы ритмик үлчәүләрнең билгеле саннарда, сүзләрнең аерым тәртиптә аваздаш ярашып килүләре, аларның мәгънә тезмәсе белән үзара тыгыз бәйләнгән булып, бер бөтен музыкаль сөреш, гармония барлыкка китерүләре шигырьләрнең сәнгатьчә эшләнгәнлеген күрсәтәләр. Габди үзенчәлекле әсәрләр иҗат иткән. Аның һәрбер шигыре диярлек аерым үлчәүгә, көйләнешкә һәм формага ия. Менә «Ата-анага хезмәт ит»[5] дигәне:

**Атаң берлә анаңа**
**Хезмәт иткел күп-күп;**

---

[1] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I. Изд-во АН СССР, М.— Л., 1936, 370 бит.
[2] С. Х. Алишев. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании. Казань, 1973, 186—192 битләр.
[3] А. С. Пушкин. Сайланма әсәрләр. Казан, 1929, 680—681 бит. («Капитан кызы».)
[4] Яру, яр — якын, иптәш.
[5] Исемнәр, шигырьләрнең эчтәлегеннән чыгып, шартлы биреләләр.

**Иртә торып, һәр көн дә**
**Аякларын үп-үп.**
**Һәр ни әйтсә, анларның**
**Сүзләрене йуп-йуп;[1]**
**Сабыр кылгыл, һәр нәчә**
**Кыйнасалар «дөп-дөп!»**

Бу шигырьнең язылуына өч гасырга якын, ә теле нинди гади, аңлаешлы! Сабыйларга мәрәҗәгать иткәндә, шагыйрь шундый садә, ягымлы тел белән яза алган. Тигез ритмик үлчәү, шигырьнең көйгә тартып торуы, рифмадаш сүзләрнең кабатланып әйтелүләре мәгънәне тагын да көчәйтә, фикер тыгызлыгы бер бөтен бөҗра эченә алынган кебек. Шигырьнең эчтәлеге үзенә бер елмаю, җылы юмор белән дә өртелгән.

Габди җирле халыкның җанлы тел байлыгына таяна. Тырнак белән каптыру, күз кыю, каш киру, күз алартып, күңел каралту, сакал чаларту, кул алышу, атказану кебек сүзләр халык теленнән алынганнар. Аның чагыштырулары да тормыш күренешләре белән бәйле.

Габди шигырьләренең вәзен-ритмы төрле үлчәүдә килгән кебек, рифмалары да бик төрле. Ул шигъри юлларның аһәңлелегенә, музыкаль яңгырашына игътибар иткән. Шигырьләренең күбесе көйләп укуга корылган, алар халык җырларына тартым.

Болар һәркайсы аның үзенчәлекле шагыйрь булуы хакында сөйлиләр. Габди күп гасырлы татар поэзиясе казанышлары җирлегендә күтәрелгән һәм аның үсешенә үзе дә нык тәэсир иткән, өлеш керткән. Габдидәге шигъри формалар алга таба Кандалый һәм күп кенә башка шагыйрьләр иҗатында тагын да үстерелә, сәнгатьчә яңа сыйфатлар ала.

Габди шигырьләренең укымышлы кешеләргә элек таныш булганлыгы ачыла бара. Мәсәлән, 1927 елда әдәбият сөюче З. Максудова, Бәшир бине Габдулла тарафыннан 1770 елда Тирсә мәдрәсәсендә төзелгән җыентыктан алып, шигъри үрнәкләр бастыра[2]. Алар арасында авторлары күрсәтелмәгән аерым куплетлар һәм ата-анага хезмәт күрсәтү турындагы шигырь Габдинеке булып чыктылар. 1784 елда мелла Хәбибулла бине Хәсән күчергән икенче бер җыентыкта да Габдинең шигъри юллары бар.

Габди әсәрләренең язылу вакыты һәм урыны төгәл билгеле булганлыктан, алар тел белеме өчен дә кыйммәтле ядкарьлар булып саналалар.

Урта гасырдагы төрки тел фәндә күп вакытта ниндидер абстракт, гомуми, ягъни төрки халыкларга уртак бер тел итеп карала. Телнең конкрет сөйләм җирлеге һәм хәтта ул телне тудырган халык үзе дә югалып кала. Ә чынлыкта исә шагыйрь шул урында яшәгән халыкның җанлы сөйләме нигезендәге әдәби телне файдалана. Габдинең «язган җирем — Казан, телем — төрки» дигән моңа бик ачык мисал. Габди язган төрки тел — шул вакыттагы Казан татарларының җанлы сөйләм теленә нигезләнгән әдәби тел ул. Бу, үз чиратында, тел белеме фәне өчен дә зур әһәмияткә ия.

Татар әдәбияты тарихының кайбер этаплары әлегәчә җитәрлек өйрәнелмәгән. Мәсәлән, XVIII йөзнең җитмешенче елларында иҗат иткән шагыйрь Мәүла Колыйдан XVIII йөзнең соңгы чирегендә яза башлаган Габдрәхим Болгарига (Утыз Имәнигә) кадәр бер гасырлык дәвер хәзергәчә әдәбиятыбыз тарихында ак тап булырак кала килде. Әлбәттә, ул чорда да әдипләр, шагыйрьләр булган һәм иҗат иткән. Ләкин бүгенгә кадәр әдәбиятның үсү юлында аерым урын тоткан, әлеге чорда яшәп, үзеннән соң эз калдырган, чын әдип яисә шагыйрь дип аталырдай берәр зуррак шәхесне күрсәтү кыен иде. Шагыйрь Габдинең поэтик авазы яңадан әдәбиятка кайту белән, XVII һәм XVIII йөз араларындагы әнә шул бушлык күпмедер дәрәҗәдә тулыландырылыр һәм моңа кадәр билгесез кала килгән бу шагыйрь әдәбиятыбыз тарихында үзенә лаек урынны алар дип ышанырга кирәк.

[1] Й у п — йеп, җеп.
[2] «Безнең юл», 1927, № 11, 35—37 битләр.

Түбәндә укучылар игътибарына Габди шигырьләреннән кайбер үрнәкләр китерелә

1709 ел

## ЗОЛЫМ-ҖӘБЕР КЫЛМАГЫЗ

Мөселманнар, сабыр кылыңыз,
Агыр булды бу дәвер.
Һәр ни булса — алладиндер,
Бел, димә «кяфер-гәүр».
Бер-берегез арасында
Кылмагыл золым-җәбер.

Шөйлә булган кемсәнәгә
Бакмагыл, йөзең чәвер.
Үз кавемең арасында
Мең гаебең бер күренер.
Мескин Габдинең күзенгә
Җөмлә галәм тиң күренер.

## АШ-СУ АШАТ ХАЛЫККА

Аш-су ашат хәлаекка,
Нигъмәтең булса, йиеңез.
Сәвенмәгел угыл-кызың
Туганга — тугса игез.
Һәр ни капсаң дуст-иш берлә,
Ултырубән бергә йиеңез.
Кемнәр барыр оҗмахка дип,
Сурсалар, «сәхи!» диеңез.

Сәхилекне кылган кеше
Ахирәттә нур тик ярур.
Сәхилекне кылмаенча
Күп адәмнәр гафил калур.

## АЛТЫНЫҢНЫ КЫЗГАНМА

Хәер кылгыл алла өчен,
Йимешең булса тулуг бакча.
Аямагыл алтыныңны,
Капчык берлә биргел акча.

Бу дөньяның бары кырау —
Малың тормас ушбу көнчә.
Эстәгәнен табар кеше
Бу дөньяда үлмәенчә.

## ГАЛИМНӘРНЕ ЯКЫН КҮР

Кичә-көндез собых-шам,[1]
Галимнәрне төн белеш.
Галим катындан сөрсәләр,
Катына отры йылыш.
Йыракдин күрсәң анларны,
Катына килеп кул алыш.
Күңелен алып, көн дә кил —
Бер вакыт булма чалыш.

[1] Собых-шам — иртә-кич.

## КУНАККА ХӨРМӘТ КҮРСӘТ

Миһманны [1] күрсәң, алыстан
Йөкреп барып каршы ал.
Ивгә [2] килтер, хөрмәт идеп
Астына мендәр аның сал.

Тагамың [3] килтер алдына,
Гәр булса,— аяма бал.
Хезмәтеңез заигъ булмас,
Алла бирер сәңа ял [4].

---

[1] Миһман — кунак. [2] Ив, ү — өй. [3] Тагам — ашамлык.
[4] Ял — түләү.

## ШӘҺРЕ КАЗАН

Мескин Габди ярагъ әйлә,
Яшең булды һәм утыз...
Тарих ирде мең дә йөз дә
Йиккерме бередә төз.

Яхшы атың чыгарубән
Үзең өчен ат казан.
Бу йигетлек чеплә бикин [1],
Карыйлык [2] мисле [3] хазан [4].

Алла әмерен тотмаганнар,
Шиксез, ул — юлдин азан [5].
Мескин Габди, тәгърифнамә
Шәһрең булгай һәм Казан.

---

[1] Бикин — кебек, шикелле.
[2] Карыйлык — картлык (текстта — карыйклык). [3] Мисле — кебек. [4] Хазан — көз.
[5] Азан — азган.

## ТЕЛЕ — ТӨРКИ

Араешкә [1] кием кимә,
Башка кимә яхшы бүрки.
Мескин Габди барчадин кәм,
Шәһре — Казан, теле — төрки.

Мән үләрмен, сез калга[й] сыз.
Яраннарым, яруларым.
Мәндин сәлам барчаңызга,
Ярләрем, барларым.

---

[1] Араеш — бизәну, купшылану.

## ЯЗЛАР КИЛСӘ, ИГЕН ИК

Мескин Габди нәзар кылып [1],
Үз тәгатен [2] кылды аз.
Нә ятырсән зикер [3] әйтмәй,
Тәсбих әйтер торна-каз.

Тәүбә кылып, кайта күргел:
Имди вакыт булды яз.
Кыш киләдер, иген иккел,
Монда торыр сәңа яз.

---

[1] Нәзар кылып — күзәтеп, фикер итеп. [2] Тәгать — күндәм булу. [3] Зикер — алла исемен искә алу.

# БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Ринат Мөхәммәдиев**

## ӘГӘР СИН ЯНМАСАҢ, ӘГӘР БЕЗ ЯНМАСАК...

*Шигъриятебезгә гражданлылык күзлегеннән бер караш*

**Весь мир разорван по самой середине. А так как сердце поэта — центр мира, то в наше время оно тоже должно самым жалостным образом разорваться.**

**Генрих Гейне.**

**Тукай тирәнгә кергән, уртага, диңгезнең актарылган төшенә кергән, диңгез белән бергә кайнаган, диңгез үзен яр читендәге ташларга китереп бәрер дип куркып калмаган.**

**Сибгат Хәким.**

Әдәбиятыбызның нигез ташы булган, соңгы 60—70 ел эчендә генә дә халкыбызга Г. Тукай һәм Һ. Такташны, М. Җәлил һәм Ф. Кәримне, Х. Туфан һәм С. Хәкимне алып килгән, бүген дә татар әдәбияты дигәндә аның йөзек кашы буларак күз алдына килгән поэзиябез турында сөйләшәсе сүзләр, уртага салып аңлашасы мәсьәләләр байтак. Бүгенге поэзиябезнең гражданлык йөзе мәсьәләсе — шуларның берсе.

Гражданлылык (әлбәттә, аны олы мәгънәсендә — үз мәгънәсендә аңлаганда) поэзиянең генә түгел, гомумән, әдәбият һәм сәнгатьнең мәртәбәсен, сугышчанлыгын һәм иҗтимагый тормыштагы урынын, йөзен билгеләүче сыйфат. Чын сәнгать әсәре аңардан башка мөмкин дә түгел. Шигърияттә исә, хис һәм акыл көче бергә кристаллашкан үтә нәфис жанрда, гражданлылык әсәрнең һәм иҗтимагый, һәм эстетик кыйммәтен билгеләүче төп критерийга әйләнә. Әйе, эстетик кыйммәтне дә билгеләүче критерийга. Шигырьне — шигырь, шагыйрьне — шагыйрь иткән дә, чамасызлык, гамьсезлек яисә битарафлык күрсәтелсә, шигырьне һәм шагыйрьне харап иткән дә ул —

гражданлылык. Дөрес, чын сәнгать әсәрендә авторның гражданлык позициясе су өстендә йөзеп йөргән майны хәтерләтергә тиеш түгел һәм ул, мин монда дигәндәй, ерактан кычкырып та тормас. Әсәрнең эчтәлегеннән саркып, рухыннан бөркелеп, аңардан алынган эстетик ләззәткә какшамас һәм көчле бер пафос биреп торырга тиеш ул. Ә бу пафос үзенең табигате белән иҗади шәхеснең тормышка мөнәсәбәте, иҗтимагый-политик карашлары һәм фәлсәфи-эстетик позицияләренең сәнгатьле формадагы чагылышы булып тора.

Бездә гражданлык поэзиясе төшенчәсен шактый тарайтып аңлау һәм аңлату да яшәп килә әле. Аны нинди дә булса бер актуаль иҗтимагый-политик вакыйга яисә проблема уңаена язылган публицистик рухлы шигъри юллар белән, күзгә төртелеп торган риторика белән генә чикләп карау бар. Бу нигезсез һәм тар караш, әлбәттә. һәм ул үзенең нәтиҗәләрен дә күрсәтә килә. Соңгы еллар өчен характерлы булган бер мисал: Чили вакыйгалары бөтен прогрессив кешелекне тетрәндерде. Көньяк Американың иң ерак читендә урнашкан бу ил патриотларының батырлыгы һәм фашистик хунтаның кансызлыгына татар шагыйрьләре дә битараф калмады. Дистәләгән авторлар тарафыннан дистәләгән шигырьләр язылды. Башта алар вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрде, аннан шагыйрьләрнең җыентыкларында урын алдылар. Бу кадәресе өчен көндә бары шатлык хисләре генә туа. Ә менә ул шигырьләрнең эчтәлегенә, тематик диапазонына, шагыйрьләребезнең алардагы мөстәкыйльлеге һәм табышлары ни дәрәҗәдә булуга игътибар итүче булса, яхшы хәтерлидер: ихтыяры, туган җиренә мәхәббәте үлемнән дә көчлерәк булган азатлык сөюче шагыйрь һәм җырчы Виктор Хара истәлегенә багышланган иде ул шигырьләрнең күпчелеге һәм, нигездә, игезәкләр иде алар. «Хара» исемен «гитара» белән рифмалаштыру һәм гитараның өзелгән кылларын өзелгән җыр, өзелгән гомергә тиңләүдән узучы булмады да диярлек. Бу кадәресе дә олы һәм чын поэтик табыш, әлбәттә. Әмма шунысы кызганыч, ул табышларны безнең шагыйрьләр бары тик кабатлады гына. Нәтиҗәдә, әлеге шигырьләр үзәк матбугатта басылган, үзәк телевидениедән яңгыраган җыр һәм шигъри әсәрләрнең кайтавазы сыман гына кабул ителде. Бу уңайдан М. Әгъләмовның «Тагын бер көн...» дип исемләнгән шигырен генә аерым искә алмый мөмкин түгел. Әлеге оригиналь әсәрдә яшь шагыйрьнең зур гражданлык пафосы белән сугарылган тирән кичерешләре үзенчәлекле һәм кабатланмас шигъри яңгыраш тапкан. Ерак тарихка караган Болгар темасы белән дә шундый ук хәл кабатланды һәм дәвам итеп килә. Шәһре Болгарга мөнәсәбәт, нигездә, шагыйрьләребезнең ерак бабалары белән горурлануы яисә хәрабәләргә карап моңлануыннан ерак китмәде. Төрле авторлар — яшь, урта буын һәм хәтта өлкән шагыйрьләребез дә — поэтик материал белән эш итүдә бер тирәдә таптандылар, җитди теманың яңа катламнарын үз иҗат мөмкинлекләренә генә таянып, мөстәкыйль рәвештә әлегә күтәрә алмадылар. Ә уйлап баксаң, шул характердагы мисаллар байтак икән.

Бу күренешне ничек аңлатырга соң? Аны тудырган сәбәп поэтик шәхеснең гражданлылыгына барып тоташа кебек. Шагыйрьләребездә гражданлылыкка омтылыш чиксез зур һәм алар аеруча актуаль, киң җәмәгатьчелекне тирәнтен кызыксындырган, борчыган мәсьәләләргә, я булмаса билгеле бер чорда популярлашып киткән темаларга игътибарлы булуны үзләренең беренчел бурычы санайлар. Ә менә шушы бурычны, әһәмиятле һәм олы бурычны, мөстәкыйль рәвештә һәм сәнгатьчә югарылыкта хәл итү өчен һәр очракта да әзер булмыйлар, ашыгалар. Тул җыйганны көтми, күңелдән, йөрәктән кат-кат кичерми, тема белән рухланып йокысыз төннәр үткәрми генә җәмәгатьчелек фикере аша эләктереп алынган факт һәм мәгълүматлардан шигырь ясарга тотыналар. Аерым очракларда моның нәтиҗәсе кызыклы гына һәм хәтта җылы гына да булып тоелырга, кабул ителергә мөмкин. Бу кадәресе инде шагыйрьләребезнең профессиональ осталыгыннан килә, ә ул түбән түгел. Әмма шигырь — туңган йөрәкләрне дә җылытырлык, күңелләрне тетрәндерерлек, яисә назлап иркәләрлек шигырь — алай гына тумас. Югары гражданлык поэзиясен һич кенә дә авторның, изге ният белән (!), әмма ашыгыч рәвештә, үзенең җәмәгатьчелек каршындагы гражданлык бурычларын үтәүгә омтылышы нәтиҗәсендә язылган шигъри юллары белән бутарга ярамый. Омтылыш — яхшы нәрсә. Шулай да әле ул күктәге ак болытлар, кысыр болытларны гына хәтерләтә. Күпме генә көтмә, алардан шифалы яңгыр тамчылары барыбер таммас, кырлар һәм болыннарның сусавы басылмас.

Гражданлык поэзиясе, әлбәттә, тематик яктан чикләнмәгән. Ул тема белән түгел, ә шагыйрьнең шәхес һәм гражданин буларак үсеш дәрәҗәсе, югарылыгы, идея-политик хәзерлеге һәм рухи байлыгы белән билгеләнә. Шунда ук табигый талантның хәлиткеч ролен хәтердән чыгарырга ярамас. Әйтик, һәммә йөрәкләр өчен дә исеме изге һәм якын булган даһи Ленинга багышлап безнең татар шагыйрьләре генә дә күпме шигъри әсәрләр иҗат иткән. Араларында чын мәгънәсендә оста язылганнары да байтак. Ә минә әдәбиятыбызда Ленин образының чагылышы турында сүз чыкты-мы, ни өчендер икеләнеп янсә аралап тормый гына, иң элек Һади Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын искә алабыз — чөнки ул шагыйрьне мәшһүр В. Маяковский югарылыгына күтәргән әсәр. Аннан тел очына, нәфис шигъри миниатюра буларак, С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә»се килә.

**Казан әле, Казан уянмаган.**
**Яфрак белән яфрак серләшә.**
**Йөрим таңда Ленин урамында,**
**Күңлем Ленин белән сөйләшә.**

Бу юлларны вакыт-вакыт, эчке бер күтәренкелек белән каядыр ашкынып атлаганда, уйламастан үзалдыңа көйли башлыйсың. Һәм шундый мизгелләрдә үз-үземне бүлеп сорау биргәнем, уйга калганым бар. Нигә әле бөтенләй искә дә алмаганда нәкъ менә шушы әсәр тел очына килгән, хикмәт нәрсәдә — темадамы, әллә ул юлларның шигъри камиллегендәме? Сүз дә юк, тема һәм әсәрнең камиллеге дә үзенекен итә, әмма төп сәбәп — шигырьнең югары гражданлык пафосы белән ихлас (!) сугарылган булуында.

Өлкән шагыйребез иҗатыннан тагы бер шигырьгә мөрәҗәгать итәсе килә:

**Авыруыма врач кирәк түгел,**
**Йөрәгемнең белəм дәвасын:**
**Һәр ел саен кайтып иснәп киләм**
**Авылыбызның чиста һавасын.**

**Язар өчен илһам эзлә, диләр,**
**Урын эзлә, диләр, ямьлерәк.**
**Никтер минем шигъри хисләремә**
**Арышларның исе тәмлерәк!**

**Яннарына барам агайларның,**
**Фикерләрен ишетеп карарга;**
**Җырларымда телим гомрем буе**
**Алар рухы белән янарга.**

С. Хәкимнең «Шигырьләр» томына эпиграф буларак китерелгән ул. Һәм очраклы рәвештә генә түгел, бик урынлы китерелгән. Чөнки ул шигырь — шагыйрьнең, без белгән шагыйрьнең, нәкъ үзе! Туган җиргә һәм Ватанга булган иксез-чиксез кайнар мәхәббәтен шулай сабыр гына, салмак кына, әмма үткәзеп, күңелләргә сеңдереп әйтә белә Сибгат ага. Аның бөтен яшәү мәгънәсе, уй-фикерләре, шатлык һәм борчылулары әлеге мәхәббәт, олы мәхәббәт белән бергә береккән. Шагыйрьнең «Немец дәфтәреннән» һәм «Карловы Вары шигырьләре» цикллары да, ерак җирләргә бәйле булуга карамастан, туган җиргә мәхәббәт хисләре белән өртелгән, кая гына барып чыкмасын, ул үзенә тормыш бүләк иткән төбәге Арча якларына, Татарстанга тугры кала.

Поэзия секциясе утырышларының берсендә яшьләр С. Хәкимгә: «Сез шагыйрь булмасагыз, нинди һөнәрне сайлаган булыр идегез?» кебегрәк сорау бирде. «Врач янсә агроном...» — җавап кыска булды. Күрәмсең, шагыйрь өчен көтелмәгән сорау булмаган, аның сөйләвеннән үк бу хакта инде моңа кадәр дә уйланган булуы сизелеп тора иде. Шагыйрьнең кешегә һәм табигатькә булган эчкерсез мәхәббәте аның бөтен иҗаты буена лейтмотив сыман кабатланып килә, дәвам итә. Бер карашка алай артык күзгә бәрелеп, ташланып тормаган лирик шигырьләрнең халык тарафыннан җылы кабул ителүе һәм күңелләрнең түреннән урын алуы серен дә сабыр холыклы өлкән шагыйребезнең чын мәгънәсендә үз Ватаны гражданины булуыннан, җиргә һәм кешеләргә мәхәббәтенә ахыргача тугрылыгыннан эзләргә кирәктер.

... Сүз бүгенге поэзия турында бара. Ә күңелдә Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Кандалыйлар... Көр күңелле, азатлык сөючән, көчле рухлы һәм сугышчан поэзиябезнең чишмә башы шулардан булгангамы. Шигъриятебездә яңа дәвер ачкан Тукай рухы исә бөтен поэзиябезгә — аның үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә нур сибеп тора. Шул нур яктылыгында Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим һәм Х. Туфаннар йолдызлыгы балкый. Кайсын гына алма, иҗаты һәм бөтен тормыш юлы белән чын гражданлык үрнәге булып торалар.

Шигъриятебез олы, традицияләрне искә алганда күңелдә горурлык хисләре уяна. Чын шагыйрьләр һәрчак Ватан һәм халык белән булган, алар белән бергә утка кергән, үзе янса янган, әмма рухын, намусын, җиргә һәм кешеләргә булган мәхәббәтен, Ватанга һәм халыкка тугрылыгын яндырмаган, исән килеш алып чыккан. Бүгенге татар поэзиясе әнә шундый традицияләре булган поэзия ул. Шагыйрьләрен халык элеккечә үзенең рухын чагылдырган җырчы, күңеле көзгесе, намусы һәм ышанычы буларак таный, хөрмәт итә. Тукай, Такташ, Җәлилләр яулаган шушы ышаныч һәм олы исемне бүген актив иҗат итүче шагыйрьләребез ни дәрәҗәдә аклыйлар соң? Күңел шул сорауга җавап эзли.

Бүгенге шигърият турында сөйләшүне иҗат индивидуальлекләре белән беренче карашка ук үзләренә җәлеп итеп торган аерым исемнәр тирәсендә генә фикер алышуга кайтарып калдырасы килми. Чөнки укучыга Татарстан китап нәшрияты гына да ел саен дистәләгән авторларның шигырь җыентыкларын тәкъдим итә.

Соңгы еллар иҗаты белән Нури ага Арсланов гаҗәпләндерүдән туктамый. Әллә инде без олыгаябыз, әллә шагыйрь үзе яшәргәннән-яшәрә генә бара, вакыт үзган саен аның хикмәтле поэзиясе укучылар арасында киңрәк мәйдан яулый килә.

Өлкән буын вәкилләреннән Гамил Афзалның уйчан һәм сабыр лирикасы, үтә чәнечкеле сатирик шигырьләре бүгенге татар поэзиясенең үзенчәлекле һәм бай сәхифәсен тәшкил итми диеп кем әйтә алыр?!.

Язмышның авыр баскычларын узып, туган җиргә, азатлыкка һәм кешеләргә булган мәхәббәте кат-кат сыналган Нәби Дәүлинең уй-кичерешләре дә шигырь сөючеләрне битараф калдыра алмый.

**«Сезнең белән очам, очам!» — диеп,**
**Торналарга әйттем сүземне.**
**Йөгердем дә, кинәт җирне үптем,**
**Җир дә үпте минем йөземне.**

Шагыйрьнең шундый гадәти юллары да үзенә бер җитдилек белән кабул ителә, ассоциатив фикерләүгә җирлек бирә. Дөрес, заман укучысының таләпләрен искә алып бетермәүдәнме, бераз сузыбрак яза шагыйрь, салмак, басынкы агышлы шигырьләрне ярата төшә.

Зәки Нури да Бөек Ватан сугышы елларында яшьли чыныгу алган, шәхес буларак сыналган шагыйрь. Әмма, Н. Дәүлидән аермалы буларак, ул кыска яза. Аның җор телле, нечкә юмор белән сугарылган лирик шигырьләре һәм дүртьюллык сатирик миниатюралары да җиңел кабул ителә, җылы кабул ителә. Сүз дә юк, З. Нури поэзиябездә гасырлар буе яшәп килгән сугышчанлык традицияләрен дәвам итүче шагыйрьләребезнең берсе булып тора.

**... Ялкынын ерып атладык,**
**Ә карын «җылы» дидек.**
**Чөнки без Ватан сакчысы,**
**Без Ватан улы идек.**

**Сукмакларны кушып, юллар**
**Сузыла төрле якка.**
**Маягым иткән җырым бар**
**Юлларда йөргән чакта:**

**«Яшәсен җирдә уртак юл,**
**Юл ача күңел күзен!» —**

**Бу — минем кыйблам яктысы,**
**Илемне сөю сүзем.**

Әлеге юллардагы ватанпәрвәрлек пафосы шагыйрьнең бөтен иҗатына хас күренеш. Һәм гаҗәп тә түгел, ул — аның тормыш сукмагы — үткәне, бүгенгесе, гомумән, яшәү мәгънәсе белән бергә береккән, кат-кат сыналган, кичерелгән сыйфат. Ул шагыйрь иҗатында жанр яисә тематика кысалары белән генә дә чикләнми — лирикада, сатирада булсын, бер үк дәрәҗәдә чагылыш таба, ачыла килә. З. Нуриның соңгы еллар иҗаты белән танышудан туган нәтиҗәләр бу.

Урта буын шагыйрьләребез дигәч тә, күз алдыма Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеев килә.

Ш. Галиев балалар өчен шигърияттә сокландыргыч зур уңышларга, табышларга иреште. Ул тудырган образлар — Шәвәлидәй тапкыр һәм шук замана балалары — яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдә, балаларда әдәбиятыбызга мәхәббәт уятуда әйтеп бетергесез әһәмиятле роль уйныйлар. Өлкәннәр өчен әсәрләрендә исә ул, я үтә нечкә сиземле лирик, я җиңелчә юмор белән өртелгән шаян шигырьләр авторы, я кешедәге кимчелекләрне, бер карашка уйнап-көлеп кенә, ә чынлыкта үткен каләме белән күздән яшьләрне чыгардай итеп тәнкыйтьли дә белгән сатирик буларак күз алдына баса. Шагыйрьнең рухи дөньясы бай һәм күпкырлы... (Гомумән, безнең тәнкыйтьтә әлегә поэзиядәге юмор һәм сатирага игътибар җитенкерәми, гражданлык мәсьәләсе уңае белән дә шигъриятнең бу сугышчан төренә махсус тукталырга мөмкин булыр иде. Г. Афзал, З. Нури, Ш. Галиев, һәм Г. Рәхим кебек шагыйрьләрнең сатира һәм юмор өлкәсендәге уңышлары моңа нигез бирә. Мәсьәлә көн тәртибендә тора, аны тикшерү якын киләчәк эше.)

И. Юзеевнең да иҗат диапазоны шактый киң. Әмма ул, барыннан да бигрәк, поэзиябездә халык иҗатыннан ук килгән традицияләрне дәвам иткән тирән кичерешле лирик, халкыбызның үзе кебек үк оптимист шагыйрь, музыкаль һәм моңлы шагыйрь.

Бу ике шагыйрьне үзара якынайткан сыйфат шулай да нидән гыйбарәт соң?.. Икеләнми әйтергә була — иҗатларының шигъри камиллеккә ирешкән гражданлылыгында, хәрәкәтчән һәм актив булуында ул охшашлык. Һәр икесенең уй-кичерешләре заман һәм халыкның иҗтимагый-политик, рухи-эстетик омтылышлары белән бергә үрелеп килүендә. Алар бәхетле шагыйрьләр — илебезнең ышанычлы адымнар белән алга үтүенә ихлас шатлана беләләр. Алар борчулы шагыйрьләр — җәмгыятебез өчен чит булган һәр кимчелекне, үзара мөнәсәбәт һәм әхлактагы теләсә нинди житешсезлекне күреп уйга калалар, тирән кичерәләр. Дөнья, кешеләр һәм тормышның гүзәллеге аларны эчке бер күтәренкелек белән иҗатка рухландыра. Мәхәббәте олы, рухы нык, кичерешләре тирән һәм борчулары күп булган шагыйрьләргә ышанмый мөмкин түгел.

Урта буын шагыйрьләр арасында Х. Камалов, М. Шабаев, Ә. Баянов, С. Сөләйманова һәм Р. Гәрәй кебек иҗатлары белән махсус игътибарга лаеклы кызыклы һәм үзенчәлекле лириклар да бар. Әйтик, Хисам Камалов белән Рәшит Гәрәй исемен безнең тәнкыйть соңгы елларда ни сәбәптәндер оныта төште. Бит Х. Камаловның үзендә генә дә күпме яңу, күпме кайнарлык бар. Аның һәр шигъри әсәрендә ачыргаланып типкән ярсу йөрәкнең сулышын тоймау мөмкин түгел. Тормыш һәм авыр сугыш сынауларын узган шагыйрь рухы белән бирешмәгән, аның идеаллары якты.

Ә Р. Гәрәй лирикасы миңа тымызык кына, үткәзеп, сеңдереп кенә яуган җәйге җылы яңгырны хәтерләтә. Үзенең сабырлыгы һәм әйтелү формасы белән генә түгел, күңелләргә алып килгән шифасы белән дә җәйге челләдә яуган яңгырга охшаган аның шигырьләре.

Кешелек алдында заман үзенең проблемаларын куя тора. Җирдә тынычлык өчен көрәш, коралсызлану, әйләнә-тирәлекне, табигатьне саклау мәсьәләләре бүген шуларның иң әһәмиятлеләре. Туган илебез һәм ленинчыл партиябез аларны тормышка ашыру, хәл итү өчен көрәшнең инициаторы һәм әйдәп баручысы. Бөтен прогрессив кешелекне тирән дулкынландырган, борчыган һәм хәтта тетрәндергән әлеге глобаль проблемалардан читтә торган шагыйрь булырга мөмкин түгел. Шәхес һәм гражданин буларак шагыйрь бу көрәшнең алгы сызыгында торырга, М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй һәм Н. Баяннар кебек батырлыкка әзер булырга тиеш. Һәм мин

шагыйрьләребез әлеге олы көрәштән читтә торалар дип әйтергә һич кыймас идем. Х. Туфан һәм С. Хәким, Н. Арсланов һәм Н. Дәүли, З. Нури һәм Г. Афзал кебек өлкән буын шагыйрьләребезнең бөтен иҗаты Ватанга һәм туган җиргә, кешеләргә чиксез мәхәббәт хисләреннән тора.

Ә урта буын вәкилләре һәм яшьләр заман тудырган җитди мәсьәләләрне бөтенләй яңа шартларда яңача күтәреп чыгуга омтылыш белән иҗат итәләр. Ш. Галиев һәм И. Юзеев, Х. Камалов һәм Ә. Баяновның шигырь һәм поэмалары бер-бер артлы күз алдыннан уза.

**Каберләре бөтен Европада...**
**Исемнәрен бергә җыйганнар —**
**Авылдашлар мәйдан уртасына**
**Уртак бер таш — һәйкәл куйганнар.**

**Взвод-взвод баскан солдатлар күк**
**Исемлекләр саф-саф торалар...**
**Үткәннәрдә алар калсалар да,**
**Киләчәкне саклап торалар.**

**(Ш. Галиев).**

Үсмер чагы, хыял канатларында гына йөзәр чагы авыр сугыш елларына туры килгән шагыйрьнең күңелендә озак йөргән, кат-кат кичерелгән уйларның кайтавазы ишетелә бу шигырьдән. Ул сугыш кырларына әтиләрен, туганнарын озатып калган, әле малай гына булсалар да әчке бер батырлык белән шунда атлыгып торган буын вәкиле. Фронттамы, тылда — хезмәт фронтының алгы сызыгындамы, һәрхәлдә, ул буын өлешенә дә җитәрлек эләккән, язмыш иркәләмәгән аларны. Шуңа күрә дә сугыш афәтенең байтак кыенлыкларын бик яшьли татырга өлгергән, яшьли олыгаерга мәҗбүр булган шагыйрьләрнең тавышына колак салганда икеләтә игътибарлырак булырга омтыласың. Аларның өзелеп калган үсмер чак хатирәләре, югалткан иптәш һәм кардәшләре «үткәннәрдә калсалар да, киләчәкне саклап торалар». Ә киләчәк турында оныттырга хакыбыз юк!..

Инде шигъриятькә алардан соң килүче буын вәкилләре:

**Җиребезне исән килеш**
**Кояш тирәли тагын бер**
**Зырылдатып әйләндердек —**
**Бәхетлерәк кем бар бездән!!**

— дип, чын күңелдән куана икән (Ренат Харис шигыре) — бу поэзиябездә озак еллар буена сыналып, күтәрелә килгән гражданлык рухы сүнми-сүрелми, ә көчәя бара дигән сүз.

Гомумән, әлеге буын шагыйрьләр шигъриятебездә яңа һәм кызыклы күренеш. Бу бәхәссез! Сүз Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов һәм К. Сибгатуллиннар турында бара. Буыннар арасында үзе бер атау буларак күз алдына килгән Роберт Әхмәтҗановны да, шигъри фикер йөртү үзенчәлегеннән чыгып, шартлы рәвештә, алар белән янәшә куярга мөмкиндер. Ә алар артыннан М. Әгъләмов һәм Зөлфәтләр килә. Әдәбиятка зур эрудиция, белем һәм бай фантазия белән килүче буын бу. Аларның тормыш тәҗрибәсе дип аталган багажы да җиңелләрдән күренми. Бәлки ул багаж артык бер төрлерәктер — анысы бик мөмкин. Чөнки соңгы ун-унбиш елда әдәбиятка килүче яшь авторларның биографиясе, гомумән, бер-берсенә, ике тамчы су кебек үк булмаса да, шактый охшаш күренәләр. Шуны искә төшергәндә көрсенеп куярга да мөмкин, әмма артык борчылыр урын шулай да юк. Поэтик шәхесләр буларак төрле-төрле алар, һәркайсының үзенә генә хас стиль үзенчәлекләре бар. Ике Әхмәтҗановны үзара бутау мөмкин булмаган кебек (туганнар янсә игезәкләр түгел!), Р. Фәйзуллин белән Р. Харисны, Г. Рәхим белән Р. Мингалимовларны янәшә куюыбыз да шулай ук бик күп шартлылыкларны истә тотып кына. Бүгенге татар поэзиясен алардан башка күз алдына китерүе кыен. Һәм шунысы аеруча куанычлы, алар иҗаты дөнья һәм туган илебез халыклары шигъриятенең бүгенге югарылыгыннан калышмый.

... **Телсез экрандагы сыман, оеп**
**Тора кырлар! Ап-ак, чырайсыз...**
**Җ и л и с ә р г ә к ы й м ы й т о р г а н ю л д а н**
**Җ ы р л а п у т у к а я!! У ң а й с ы з...**
**Сагындырдың, узган яшьлек сыман,**
**коргаксыттың, яңгыр, син безне!**
**Дымнарыңны алып безнең яктан**
**син сыйлыйсың, әнә, диңгезне!..**
**Күк диңгезгә тамчың төшеп сүнә,**
**күбекләнеп коя суга су...**
**Т ө н е б у е й ө р ә г е м ә я в а...**
**А һ, й ө р ә г е м т ү г е л ш у л б а с у!..**

Роберт Әхмәтҗановның бу шигырендә («Коры елда») генә дә күпме яну, тынгысыз йөрәкнең күпме өзгәләнүе бар. Яңгыр тамчысына сусаган басуларның хәләтен— хәер, бер басулар гына сусый микән әле — ике күзен офыклардан алмый көн-төн яңгыр болытларын көткән игенченең хәләтен, өмет һәм борчуларын шулай гади, шагыйрәнә әйтеп бирү өчен шагыйрьдән күп кирәкме?.. Аз да түгел, күп тә түгел — олы гражданлык һәм талант кирәк. Талант — табигать бүләге, ә гражданлык хисләре — ата-ана һәм мәктәп, коллектив һәм җәмгыятьтән, поэтик шәхес формалашкан шартлардан. Уңдырышлы туфракта туып, рухы көр, хезмәте белән гүзәл кешеләр арасында үскән буын вәкиле Роберт Әхмәтҗанов. Шуны аңлап, табигать һәм үзен тудырган халкы алдында зуррак җаваплылык хис итсен иде, үсүдән, эзләнүдән туктамасын, бер тирәдә тупырдаган тышаулы атка охшап калмасын иде ул. Шагыйрь, иң беренче чиратта — шәхес, ә аннан җәмгыятьнең актив әгъзасы — гражданины да булырга тиеш! Чын хакыйкать шундый, аны исбатлап тору таләп ителми.

... **Күзләремне йомдым... Ил хакына**
**Кичеп шомлы, биек үткелне.**
**Өнсез, тынсыз биек тау сыртында**
**Туганнарым бара шикелле.**
**Арада — мин.**
**Ялгыш ташка бастым!..**
**— Әни! Кичер, китәм мин җырдан...**
**Тик**
**И л ө ч е н т ы н л ы к к и р ә к ч а к т а**
**Х ә т т а с и ң а «Х у ш!» д и п к ы ч к ы р м а м.**

Бу юлларның авторы яшь шагыйрь Зөлфәтнең заманча актив һәм көрәшчеләр рухы белән сугарылган поэзиясе елдан-ел җитдиләнә бара, көтелмәгән яңа яклары белән ачыла килә. Кайберәүләр аның аз язуына, сирәк басылуына борчылалар кебек. Ә мин исә иҗатында ярсу, романтикларга хас ашкынулы шагыйрьнең матбугат битләрендә басылуга килгәндә үтә сабыр һәм аек акыллы булуына сокланам гына. Уйлавымча, бу — шагыйрьнең пассивлыгыннан түгел, әдәбият һәм укучы алдында олы җаваплылык тоеп иҗат итүеннән, иҗади шәхес буларак үз-үзенә үтә таләпчән булуыннан килә. Яшерен-батырын түгел ич, Зөлфәт һәм М. Әгъләмовның болай актив кына күренгән яшьтәшләре дә байтак, әмма аларның бер ишесе иҗади активлык белән әрсезлек арасында буталып күп кенә көчләрен сарыф итәләр, вакыт-вакыт шигърият дигән олы дөньяны примитивлаштырып аңлауга кадәр җитәләр. Һәр язганыңны шигырьгә санап укучыга тәкъдим итүдә түгел, ә үз халкыңның рухын, гамен, йөрәк тибешен тоеп, шуны шигъри камиллек дәрәҗәсенә күтәреп берәгәйле тасвирлау, берәгәйле әйтеп бирә белүдә шагыйрьнең активлыгы. Әдәбиятның, шигъриятнең һәм сәнгатьле сүзнең абруен төшерергә ярамый безгә!..

Есенинның «Минем бөтен иҗатым бер олы мәхәббәткә, Ватаныма мәхәббәткә багышланган» кебек сүзләре бүген аеруча актуаль яңгырыйлар кебек. Заманыбыз үзе максатларның олылыгын, төпле булуын, вакланмавын таләп итә. Шагыйрьләр, шигъри шәхесләрнең дә тоткан юлы туры, киң һәм якты булсын иде шулай.

Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Рәдиф Гатауллинның соңгы җыентыклары һәм

бигрәк тә Рәдифнең «Европада татар шагыйрьләре» циклы белән танышканда күңелдә әледән-әле поэзиябезнең киләчәге өчен ышаныч һәм матур өметләр уяна. Яуланган биеклекләр белән генә канәгатьләнергә җыенмый шагыйрьләр. Юкса, соңгы елларда профессиональләшү куркынычы, яшьлек януларының сүрәнләнә баруы, борчуларының кими төшүе яңый башлаган иде аларга. Лирик поэзиябезнең матур традицияләрен дәвам иткән бу өч авторның үсеш юлы — максатларының эреләнә баруы, гражданлык позицияләренең активлаша төшүендә.

Шул күзлектән караганда, яшьтәшләре Р. Фәйзуллин һәм Р. Харис иҗаты күп кызыклырак.

**Йөрәк кыса кайчак,**
**Тын кысыла...**
**Һавадандыр, диләр, һавадандыр...**

**Һавадандыр —**
**Урасы ашлыкны черетә яңгыр.**
**Һавадандыр —**
**Һава Җирдәге бар нәрсәгә кагылып тора.**

**Ил-җирләрне тоташтыра —**
**Кипрны да, Кытайны да, Ливанны да,**
**Чилидагы канга баткан диварны да...**

Истән, күңелдән чыкмый йөрәкне һәм тынны кысып торган әнә шундый борчулар, олы борчуларда яши Ренат Харис. Басудагы игеннәр өчен булсын, илләр, халыклар һәм Җир язмышы өчен булсын, аның борчуларында мин шагыйрьлек, олы гражданлык күрәм. Шул ук вакытта үзенчәлекле шигъри табышлар, оригиналь образларга да бай бу шагыйрь әсәрләре, вакыт-вакыт үзен рәссамга да охшатып куясың. Дөрес, Р. Харис шигырьләре алай ук йөгерек укылмыйлар, стиль авырлыгы һәм сурәтләү чараларының без гадәтләнгәннән ешрак килүе, бер-берсенә янәшә торуы да аларны кабул итүдә өстәмә мәшәкатьләр тудыра. Әмма нәтиҗәләр ясарга ашыкмыйк, ул поэзиядә өзлексез эзләнә, өстә яткан катламнарда гына түгел, ә тирәннән эзләнә. һәм таба да!.. Поэзиябезгә мең «ошый-ошамый» критерийларыннан чыгып кына бәя бирүдән, шигъри индивидуальлекләргә мөнәсәбәттә үзебезнең чикләнгәнлектә чикләнеп, традицион формалар тарафдары гына булып калулардан котылырга, качарга иде бит.

Мәсәлән, Р. Фәйзуллинның «Кыска шигырьләр»ен — бер, ике, өч дүрт (...) юллыкларын үзем дә шигъри бөтенлеккә ия әдәби продукция буларак кабул итә алмыйм. Аларның формасы ук ясалма булуларына ишарәли сыман. Шигырь төшенчәсенә тар караштандыр ул бәлки. Кат-кат укыйм, нидер бар да кебек үзләрендә — тәэсир итә, хис һәм тойгыларны да уята түгелме?

*
* *

**Зәңгәр күктә ап-ак болытлар!**
**Ватаным, дип баккан күзләрем...**

*
* *

**Җителдеме гомеремнең яртысына!**
**Билләр сына. Гөлләр сына. Илләр сына...**
**Дөнья болай тыныч кына...**

**ҖИНАЯТЬ**

**Болында мин ялгыш өздем**
**тамыры белән бер ал чәчәкне!..**

**Салават күперендә ал төс**
**тоныкланып калгандай булды.**

Чын-чынлап шигъри һәм тирән ассоциацияләргә нигезләнгән юллар ич. Аларның гадәти булмаган формасына артык игътибар биреп, эчтәлегенә, сулышына колак салырга онытмыйбыз микән? Ул кыска шигырьләр арасында әле, чынлап торып уйлаганда, мөстәкыйль әсәр булып өлгермәгәннәре дә булырга мөмкин (кемдә генә юк алар?..). Нибарысы матур бер шигъри деталь, шигъри заготовка хәлендәге юллар да очрый. Ләкин нюансларны, диалоглар яисә монологларны, кыска шигырьләрме — һәркайсы өзлексез иҗади эзләнүләрдә булган шагыйрьнең үсеш юлында яңа бер этап. Һәм бу тәҗрибәләрне дә Р. Фәйзуллинның һәркемгә якын, үз булган шигырь, поэмаларыннан аерып карарга ярамый. «Мин сиңа йомшак таң җиле...», «Менә без дә үсеп җиттек, әни!..», «Аккошлар», «Башны салларга салып...» кебек чын мәгънәсендә халыкчан җыр һәм шигырьләр авторы, фәлсәфи лирик шагыйрь (әлеге кыска шигырьләр дә фәлсәфи уйланулардан гыйбарәт) Ватанга һәм кешеләргә бетмәс-төкәнмәс олы мәхәббәт белән эзләнә, иҗат итә. «Гадиләргә гимн» һәм бигрәк тә «Көрәшчеләр» поэмасының пафосына, рухына колак салыгыз:

**Әгәр без дә эндәшмәсәк!**
**Күрә торып, күрмәс булсак,**
**ишетә торып, ишетмәсәк!**
**Уяу бул, Рух!**
**Һәр мизгелдә мәгънә.**
**Бер мизгелдә**
**гөл ава ала,**
**ил ава ала...**

Колак төбендә Сибгат Хәким кабатларга яраткан: «Шагыйрь борчылырга тиеш! Шагыйрь янарга тиеш!..» кебек сүзләр яңгырап тора. Шагыйрь — борчуларда. Шагыйрь — яна... Соң, әгәр ул янмаса, әгәр син янмасаң һәм әгәр без янмасак, кем җылытыр икән дөньяны?..

**Шәрәф Әхмәдуллин**

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ ЭСТЕТИК ТӘРБИЯ

Алсу күбәләге июнь иртәсенең,
Тәрәзәмә килеп чиртәсең.
Яшьлек, сиздермичә киләсең дә,
Сәлам, дисең һәм тиз китәсең.

Такташ мәрхүм үзенең яшь гомерен
Зәңгәр урман итеп сурәтли.
Шулай инде, табигый бер закон:
Китә яшьлек, нке сөйләшми.

...Ләкин үкенмәслек безнең яшьлек,
Кире кайтмас булып китсә дә,
Яуладык без иркен, мул тормышны,
Без бәхетле, картлык килсә дә.

Бу юлларның авторы Габделхак Сафиуллин Буа районы «Коминтерн» колхозында шофер булып эшли. Аның авылдашы Ибраһим Садриев пьесалар һәм шигырьләр яза. Арада басылганнары да бар, сәхнәдә уйналганнары да. Әлбәттә, мондый мисалларны теләсә кайсы авылдан табып буладыр.

Шул ук районның Иске Суксу авылыннан Д. Камалетдинова авыл советында секретарь булып эшли. Буш вакытларында ул да илһамланып шигырь яза.

Сагнуларым, ярсу диңгез кебек,
Ярларыннан ташый ыргылып.
Тыңларсыңмы, таңнар аткан чакта
Яңгырасам матур җыр булып!..

Фәния Әхмәтова исә Яңа Чынлы авылында яши. «Мин, — ди ул, — бала чактан бирле беренче группа инвалиды. 32 ел урын өстендә. Йөри алмыйм...». Әмма Фәниянең язмыш сынауларына бирешергә исәбе юк, әдәбиятны ярата һәм үзе дә шигырьләр яза.

Яшел чыршы — өй түрендә,
Тирәсендә — балалар.
Кыш бабай бүләк өләшә —
Кыш көнендә алмалар.

Шук, шаян шул кыш бабай да
Нәниләрне көлдерә;
Гел бишлегә укыгыз, дип
Үз теләген белдерә.

Китерелгән мисалларның мәгънәсе шул: эшче булсын, колхозчы булсын, интеллигент булсын, ул танылган язучыларның әсәрләрен уку белән берррәттән, үзе дә кулына каләм ала. Бу — иҗат эшенең массалашу күренеше, коммунизм төзүче җәмгыятьтә яшәүче кешенең эчке дөньясы үсүен, баюын раслаучы дәлил.

Шундый шартларда әдәби-эстетик тәрбия мәсьәләләренең әһәмияте бермә-бер арта. Чөнки моны һәрьяктан камил кеше — коммунизм җәмгыяте кешесен тәрбияләү бурычы таләп итә. Партиябез дә хезмәт ияләренең иҗади сәләтләрен, ихтыяҗларын, зәвыкларын даими камилләштерә баруны идеология эшенең бер бурычы итеп саный. Бу бурычны тормышка ашыруда әдәби тәнкыйтьнең роле аеруча зур. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мәгълүм карарында мәсьәләнең бу ягына махсус игътибар юнәлтелгән иде.

Хезмәт ияләрен эстетик тәрбияләүгә татар совет тәнкыйте нинди өлеш кертә соң? Куанычыбызга каршы, аз өлеш кертми. Мәсәлән, талантлы әдәбият галиме Хатип Госманның күп кенә хезмәтләрен һәм мәкаләләрен искә алырга мөмкин. Тормышка һәм шагыйрь иҗатына тирән караш, конкретлык, дәлилләргә бәйлык, фикер ачыклыгы аның хезмәтләрен укучыга аеруча якын итә. Тәнкыйтьче белән бергә фикер йөртүдә укучы бит үзе дә катнаша, сәнгать телен өйрәнә, аның сурәтләү чараларын сиземли, күрә, тоя, танып белә. Әйтик, Һ. Такташның «Алсу» поэмасындагы:

**Салкын карга басып Алсу килә,**
**Үзе көлә,**
**Үзе сөйкемле,**
**Үзе усал,**
**Үзе болай бер дә**
**Усал түгел кебек шикелле, —**

дигән строфада «үзе» сүзенең кабатланып килүе бар кешегә дә аңлашылып бетмәве мөмкин. Ә Х. Госман аны нечкә сиземләү белән укучыга аңлатып бирә: «Бу сүзнең функциясен шагыйрь ике яклы итеп алган булса кирәк: бер яктан, «үзе» сүзе Алсудагы характер сыйфатларын берәмлекләп, аерым-аерым атап бирү өчен һәм сыйфатны калкытып күрсәтү өчен кирәк, икенче яктан, Алсуның гаять җитез, алмашынып, уйнаклап торган, хәтта бер-берсенә капма-каршы төсле күренгән бу характер сыйфатларын шагыйрь «үзе» сүзе аркылы бер үзәккә җыйнап ала... бер-берсе белән һич тә килешмәстәй нәрсәләрнең (үзе усал, үзе усал түгел шикелле) Алсу характерында сокландыргыч рәвештә килешә алуларын күрсәтә, шушының белән аның тирәндә яткан сыйфатын — рухи бөеклеген ачып сала». Күрәсез, Хатип Госман сүзнең, сурәтләү чарасы һәм образ тудыра торган куәтле корал буларак, эчке халәтен тирән тоемлау белән аңлатып биргән. Болай конкрет фикер йөртү укучы өчен исә бик әһәмиятле. Ул әдәбиятны аңларга, матурлыкны тоярга өйрәтә, укучының эстетик зәвыгын камилләштерә.

Әйе, сәнгать матурлыгын тою, хис итү өчен сәнгатьне аңлый белергә кирәк. Ә эстетик зәвык кешегә әзер килеш тумыштан ук бирелми. Ул төпле белемгә таянган хәлдә генә уяна, үсә, камилләшә ала. Аны башта уятырга кирәк, аннары үстерергә, тәрбияләргә, камилләштерергә... Әдәби тәнкыйть менә шушы юлда укучының ышанычлы ярдәмчесе булып тора. Нәкъ менә әдәби тәнкыйть сәнгать телен үзләштерүдә укучыга ярдәм итә, аны сәнгать матурлыгын бәяли белергә өйрәтә, аңа матурлык критерийларын бирә.

Дөрес, тәнкыйтьнең үзенә генә хас тикшерү объекты бар. Китап һәм тормыш, китап һәм автор, китап һәм әдәби процесс — ул объект шуннан гыйбарәт. Әмма тәнкыйтьче үзенең һәр адымын, мөмкин кадәр, укучы белән бергә атларга тиеш. Икенче төрле әйткәндә, әдәби тәнкыйть мәкаләсе укучыга яхшы аңлаешлы булсын. «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарда да бу таләп махсус искәртелә. «...Редакцияләр,— диелә анда,— тәнкыйть материалларының... аңлаешлылыгына җитәрлек игътибар бирмиләр».

Укучы белән ачыктан-ачык сөйләшүнең, аңлаешлы тәнкыйть мәкаләләренең ни дәрәҗәдә зарури булуын күрсәтү өчен Фәнис Яруллинның «Кешене кешеләр күтәрә»[1] исемле мәкаләсеннән бер өзек китерик: «Минем алдымда,— дип яза

[1] «Казан утлары», № 10, 1972, 175 бит.

Ф. Яруллин,— бик күп хатлар ята... Адреслары төрле булган кебек, хатларның авторлары да төрле кешеләр. Кайсы укытучы, кайсы пенсионер, кайсы мәктәптә укучы, кайсы сатучы. Төрле-төрле һөнәр ияләре язуга карамастан, хатларның күбесендә бер үк сораулар кабатлана. «Җилкәнне җилләр еккач» дигән повестьның герое Фәнияр чынлап та бар кешеме? Аның адресы ничек?

...Мари республикасы, Бәрәңге районыннан Рушания Газизова: «Повестьның геройлары Фәнияр белән Илсөянең адресын сала алмассызмы? Олы йөрәкле, саф мәхәббәтле Илсөягә хат язып, аның белән якыннан танышасым килә».

Норлат районыннан Рәмзия Мәүлетова: «Фәүрия, Илсөя, Гаделшин, Гөлсәйдә, Нәсимә һәм Ризваннарның чын исемнәрен язып җибәрегез әле».

Свердловск шәһәреннән Янчурина Әлүдә: «...Оятыма каршы, Фәнияр Гатауллинның бер нинди шигырен дә укыганым юк, бәлки, игътибар итмәгәнмендер. Повестьны укыган көннән башлап, Фәнияр бер дә уемнан китми. Әгәр мөмкин булса, Фәнияр турында язып җибәрегез әле. Ул университетны тәмамлый алдымы? Шигырьләр язуын дәвам итәме? Кайда яши? Илсөя белән бергәме?».

Күренә ки, хат авторлары образлар телен аңлауда бер үк хатаны кабатлыйлар: сәнгать факты белән тормыш факты арасына тигезлек билгесе куялар. Шул характердагы хатлар тәнкыйтьчене искәртеп торалар: әдәби әсәргә анализ ясаганда укучыны онытырга ярамый. Киресенчә, укучы тәнкыйтьче белән бергә фикер йөртүдә катнашсын, аның ярдәмендә сәнгать телен, образлар телен аңларга өйрәнсен, үзенең хисләрен яңартсын, эстетик зәвыгын үстерсен, камилләштерсен, әдәби фикерләү сәләтен көчәйтсен. Сүз уңаена немец шагыйре, коммунист И. Р. Бехер сүзләрен искә алып үтәсе килә: «Укучы — тәнкыйть иң элек менә кем игътибарына юнәлтелергә тиеш. Укучы — менә кемнең эстетик зәвыгын, әдәбият буенча фикер йөртү сәләтен үстерү өчен тырышырга тиеш тәнкыйтьче. Чөнки укучы үсмәсә, язучының да иҗат үсеше тоткарланырга мөмкин» [1].

Әйтергә кирәк, татар әдәби тәнкыйте вәкилләре үз хезмәтләрендә күпчелек очракларда шулай эшлиләр дә. Югарыда Хатип Госман хезмәтләрен телгә алып үткән идек инде, андый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Проза тәнкыйтебездән И. Нуруллин мәкаләләрен дә искә алырга була. Гадәттә ул авторларны да, укучыны да бер дәрәҗәдә күздә тота: беренчеләре өчен аның фикерләре — күрсәтмә, икенчеләре өчен — сабак булып тора.

Алыйк Рафаэль Мостафинның «Тема, идея, әдәби осталык» исемле мәкаләсен. Биредә барлык мәсьәләләр — әдәби процесска, язучы эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр укучы катнашы белән хәл ителәләр. Укучы биредә тәнкыйтьчене тыңлый, аның белән бергә әсәрләрне дөрес бәяләргә өйрәнә, матурлык критерийларын танып белә.

«Әдәби әсәрләргә бәя биргәндә, — дип күрсәтә Р. Мостафин, — без төрле критерийлардан чыгып эш итәбез. Шуларның иң нык таралганы, мөгаен, тематик критерийдыр»... Тәнкыйтьче шунда ук укучыга аңлатма бирә: «Бу бик табигый һәм аңлашыла торган нәрсә. Чөнки әсәрдә дистәләрчә, йөзләрчә еллар элек булып узган тарихи вакыйгалар турында сүз барамы, әллә бүгенге көннең иң мөһим күренешләре тасвирланамы, язучы тормыштагы интим нәрсәләр тирәсендә әйләнәме, әллә заманның зур проблемаларын күтәрәме — безнең өчен барыбер түгел» [2].

Укучыларга сәнгать телен өйрәтү буенча күргәзмәле сабак бирү җәһәтеннән караганда, филология фәннәре докторы Гали Халитның «Шагыйрь, чор, герой» [3] исемле теоретик хезмәте, шулай ук Нил Юзиевнең «Шигырь гармониясе» [4] зур әһәмияткә ия булып тора. Гәрчә әлеге хезмәтләр катлаулы теоретик мәсьәләләрне чишүгә багышлансалар да, дәлилле фикер йөртүләре белән укучыга сәнгатьнең асылын, аның табигатен, үзенчәлеген, телен аңларга ярдәм итәләр.

Әлбәттә, укучыларның әдәбиятны аңлау дәрәҗәсен күтәрүгә, аларның эстетик зәвыкларын тәрбияләүгә хезмәт итүче әдәби тәнкыйть югарыда китерелгән мисаллар белән генә чикләнми. Биредә тагын Азат Әхмәдуллин, Флорид Әгъзәмов, Флүн Му-

---

[1] И. Р. Бехер. Шигърият принципы. Т. 14, 419—420 бит, 1972, Берлин (немец телендә).
[2] Рафаэль Мостафин. «Казан утлары», 1972, № 9, 151—152 битләр.
[3] Гали Халит. Казан, 1971.
[4] Нил Юзиев. Казан, 1972.

син хезмәтләрен, Фарваз Миңнуллин, Нурмөхәммәт Хисамов, Хуҗи Мәхмүтов... мәкаләләрен, Фатих Урманчиев, И. Ахунҗанов... рецензияләрен күрсәтергә кирәк.

Бу уңайдан язучыларыбыз өлешен дә истән чыгарырга ярамый, әлбәттә. Укучыларга сәнгать телен өйрәтүдә сабак булырлык мәкаләләр алар тарафыннан да әледән-әле язылa тора. Элегрәк еллардан шагыйрь Әхмәт Исхакның бер мәкаләсе хәтергә кереп калган. Анда автор: «Чагыштыруны Тукай үзенең иҗатында аеруча күп һәм уңышлы куллана»,— дип язуга ук, әлеге мәсьәләне гомуми халык иҗаты процессына нисбәтән алып карый һәм анда нинди урын тотуын ачыклый. «Татар халык җырлары да бит,— дип күрсәтә Әхмәт Исхак,— нигездә шундый чагыштыру чараларына корылып төзеләләр. Дүрт юллык җырларның беренче ике юлы күп вакытта нинди дә булса бер күренешне ала да, җырчының кичерешләрен шундый күренешләр белән янәшә куеп, аларны бер-берсе белән чагыштыра — охшата, тиңли яки каршы куя». Әйтелгәннәрне раслау өчен автор дәлил китерә:

**Иделләр агып бетсә дә,**
**Комнары кала икән,**
**Хәсрәтләре үтсә дә,**
**Моңнары кала икән.**

Шуннан соң гына Әхмәт Исхак укучыны яңадан Тукай иҗатына алып килә, фикерен һәркемгә аңлаешлы формада дәвам итә. Шул рәвешчә, укучы авторга иярeп фикер йөртә, өйрәнә.

Кызганычка каршы, әле еш кына әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә укучы турында онытыла. Тәнкыйтьченең игътибары бары ике адресатка — әдәби процесс һәм авторга гына юнәлтелә. Тәнкыйтьче үз фикерләрен конкрет мисаллар белән дәлилләп торуны зарури санамый.

Бу җәһәттән Т. Галиуллинның «Тормыш — шигърият чишмәсе» исемле мәкаләсе гыйбрәтле. «Татар халкының батыр улларын калкурак, масштаблырак итеп сурәтләүгә омтылу,— дип яза Т. Галиуллин,— яшьләр иҗатында да ачык төсмерләнә». Бу — тезис. Ә менә аны исбатлау: «Р. Харисовның «Мулланур» шигырендә динамика, киеренке драматизм, «лирик накал» хас. Шагыйрь Мулланур батырлыгының бөеклеген, эчке рухи матурлыгын, үлемсезлегенең нигезен ачып бирергә ниятли. Ул иске теманы яңача чишә, героена яңа сызыклар өсти» [1].

Ләкин бу «исбатлау» дигәнебез үзе исбатлауны сорый торган булып чыккан. «...Калкурак, масштаблырак итеп сурәтләүгә омтылу»ны ачып саласы, күрсәтәсе урынга тәнкыйтьче яңадан тезис артыннан тезис тезеп китә. «Мулланур» шигырендә динамика, киеренке драматизм, «лирик накал» хас», «Мулланур батырлыгының бөеклеген, эчке рухи матурлыгын, үлемсезлегенең нигезен ачып бирергә ниятли»; «...Иске теманы яңача чишә, героена яңа сызыклар өсти».

Болар үзләре ачыклауны, исбатлауны таләп итәләр. Әйтик, «иске теманы яңача чишә» дибез икән, моны һичшиксез дәлилләргә кирәк. Укучы өчен коры тезис санама, «теманы яңача чишү»не күрсәтеп бир. Бары тик шундый конкрет сөйләшү генә укучыга сәнгать телен үзләштерергә ярдәм итәргә мөмкин. Тәнкыйтьче исә бу хакыйкатьне истән чыгарган. Хәлбуки, Т. Галиуллин — әдәбиятны, сәнгать телен тирәнтен сиземләүче оста белгеч. Аның мәкаләләрендә укучы ихтыяҗларын, эстетик зәвыкларын камилләштерү зарурлыгын да онытмавы аерата әһәмиятле. Бу теләкне «Тормыш моңын тоеп» исемле мәкалә авторлары Рифат Сверигин һәм Фәрит Хатипов игътибарына да ирештерәсе килә. Чөнки алар да үзләренең югарыда исемләнгән хезмәтләрендә укучыны онытып җибәрәләр, сүзне, башлыча, язучы белән ике арада гына алып баралар. Алыйк мәкаләдәге мондый тезисны: «Әмирхан Еники кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең һәм кеше язмышының эчке, психологик тирәнлекләренә үтеп кереп, шул тирәнлектә яткан драматизмны да үзенчә бер осталык һәм тәгәллек белән ачып бирә белә» [2].

Әлбәттә, болай раслау язучы өчен җитәрлек ачык, конкрет. Ә менә укучы әлегә канәгать түгел. Чөнки ул «...кеше язмышының эчке, психологик тирәнлекләренә үтеп керү»не тәнкыйтьченең ачып бирүен көтә. Әйе, син, тәнкыйтьче, әнә «...шул тирәнлектә

[1] Т. Галиуллин. Яңа үрләр яулаганда. 1972, 17 бит.
[2] Рифат Сверигин. Фәрит Хатипов. Тормыш моңын тоеп.— «Казан утлары», № 1, 1978, 131 бит.

яткан драматизмны... үзенә бер осталык һәм төгәллек белән бирә» белүне укучыга исбат ит. Әйтик, язучы ничек «үтеп керә», ничек «ачып бирә?» Моның өчен ул сүз сәнгатенең нинди сурәтләү чараларыннан файдалана? Укучы менә шундый сорауларга җавап көтә. Мәкаләдә исә андый җавап юк. Һәм шул характердагы мисалларны әлеге мәкаләдән күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев мәкаләләре белән танышканда да шундый кимчелекләр белән әледән-әле очрашырга туры килә...

Әдәбият турында сүз йөрткәндә укучыны истән чыгару, я булмаса аның белән дәлилсез сөйләшү газета-журнал редакцияләренең әдәби бүлек эшчәнлегендә дә үзен нык сиздерә. Матурлыкны, әдәби осталыкны танып белергә омтылучы һәм шул ук вакытта үзләре дә иҗат дәрте белән янучы кешеләргә әдәби бүлек гадәттә шундый җавап бирә: «Шигырегезне баса алмыйбыз. Әдәби эшләнеше йомшак». Бу йомшаклык нидән гыйбарәт? Моңа җавап булмый. Әйе, редакция бүлегендә авторларның һәркайсына озын хатлар язып өлгерә алмыйлар. Ләкин моннан чыгу юлы бар: ул — тәҗрибәле язучыларны, яшь тәнкыйтьчеләрне файдалану. Аннары редакциягә килгән кульязмалар турында матбугат битләрендә әледән-әле әңгәмәләр оештыру кирәк. Дөрес, андый әңгәмәләр моннан берничә еллар элек аз булса да газета битләрендә күренгәләп килә иде. Соңгы елларда гына бу әһәмиятле эш ни өчендер гамәлдән төшеп калды. Әйтәсе дә юк, бик кызганыч.

Әдәби тәнкыйтьнең эстетик тәрбия өлкәсендәге ролен киметүче сәбәпләрнең тагын берсе бар: тәнкыйть күп вакыт әдәби хәрәкәтнең алгы сафында атлаучылар иҗаты белән генә шөгыльләнә, бер исемнәр тирәсендә генә бөтерелә. Сафның урталыгында, як-ягынданиләр бар! Бу мәсьәлә аның игътибарыннан төшеп кала. Әйтик, Рәшит Гәрәй — күптәннән бирле язып килүче шагыйрь. Хәлбуки, аның иҗаты, һәм бер аның гына түгел, күпме шагыйрьләр иҗаты турында хәзергә кадәр матбугатта төпле фикер әйтелгәне юк әле.— Бу фактларның эстетик тәрбиягә ни бәйләнеше бар? — диюләре мөмкин. Бәйләнеш шул: матурлыкны раслауда кулланылган буяулар, үзенчәлекле төсләр хезмәт ияләренең әдәби-эстетик зәвыкларын тәрбияләүдә тулы килеш файдаланылмый кала.

Хәзерге чорда әдәби тәнкыйтьнең бурычлары зур һәм катлаулы: шундыйларның берсе — киң катлау хезмәт ияләрендә югары эстетик зәвык тәрбияләү, халык иҗат көчләренә ярдәм итү. Бу бурычны үтәү буенча тупланган уңай тәҗрибә — киләчәктә тагын да баетылырга тиеш.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Рим Шириязданов**

## АНЫҢ ДӘРТЕ, ДӘРМАНЫ БЕЛӘН...

*Язучы Нурихан Фәттахның иҗат портретына эскизлар*

Һәр әдипнең төптән, ерактан килә торган иҗат тамырлары була, булырга тиеш. Ул тамырлар әдәбиятыбызның бик күп буын вәкилләре калдырган әдәби-культура мирасына, әдәби традицияләргә дә, халыкның үткән һәм бүгенге тормыш-яшәеш катламнарына, аның иксез-чиксез күңел дөньясына да барып тоташа. Менә шундый җирлектә язучының кешелек идеаллары, гражданлык асылы, иҗади шәхесе үзенең конкрет тәүдәләнешен, табигый яшәешен таба. Шул тамырлар әдипнең иҗатын үз халкының рухы, күңел яктысы, туган җир һавасы, аның моң-аһәңнәре белән сугаралар; идеаллар, әхлакый кыйммәтләр, диварга беркетелгән лозунглар булып калмыйча, әдип әсәрләренең һәр күзәнәгенә сеңәләр, сурәт-образларны, аларның һәр хәрәкәтен, омтылышларын эчтән яктыртып торалар. Куптарып кара син аларны әсәрдән, кымшатып кара әдип, шагыйрь күңеленнән!

Дөрес, бу югары материяләр, еш кына очракларда тегеләр яки бу әсәрдә өскә калкып, күзгә бәрелеп тормый, аларны кулга тотып күрсәтүе кыен, чөнки алар төптә, күзәнәкләр эчендә, дөресрәге, алар — әдәби тукыманың эчке рухы, җаны. Аны күңел белән генә тоярга була.

Алда әйткәннәребезне бүгенге буын каләм осталарыбызның бик күп әсәрләре мисалында расларга булыр иде. Прозаик Нурихан Фәттах иҗаты да шундый.

Нурихан Фәттах әдәбият мәйданына бик яшьли аяк басты. һәм бик табигый рәвештә шул юлдан атлап та китте. Н. Фәттахның илленче елларда язган беренче хикәяләре үк нииндидер бер садә табигыйлекләре белән аерылып тора. Алар талгын һәм тигез агышлы, сүзләр-сурәтләр дә үзләреннән-үзләре туып, калкып, сиздермичә генә күз алдыннан үтә торалар, ага торалар. Әсәрләренең теле дә шундый — агым су кебек табигый һәм гадәти. Бу очракта автор әдәби телне, халыкның сөйләм телен нык өйрәнгән, әйбәт үзләштергән дип әйтү ничектер коры һәм килешсез ишетелер кебек. Дөресрәге — тел аның үзенеке, ул аның канында һәм җанында, әдип һәм тел икесе дә — бер бөтен.

Язучының заман темасына язылган хикәяләре, повесть, романнарының геройлары хакында да шуны ук әйтергә туры килә. Геройлар дигәч тә, кем әйтмешли, аларның да күбесе «әллә кем түгел»: безнең һәрберебез дә көн саен очраша, таныша, аралаша, дуслаша яисә ачуланыша торган «үз» кешеләр. Авылдан ФЗОга укырга китеп шахтер булган Әхтәм («Буранда» хикәясе), шәһәрдә яшәүче кызының баласын асрарга алып кайтып килүче әби («Әттә!»), сугыш кырында башын салган егетенә менә



ничәмә еллар инде тугрылык саклап яши торган Газима апа («Бер тамчы күз яше»), техникум бетереп, авыл медпунктында мөдир булып эшләүче Саҗидә, авыл агайлары, студентлар, яшүсмерләр — барысы да язучының замандашлары, күз күргән яисә без бик яхшы белгән кешеләр. Эш шунда ки, бу гадәти кешеләр турында Н. Фәттах бик гадәти яза, геройларны гадәттән тыш хәлләргә куймый, алар әсәрдә нинди дә булса шаккатырлык эшләр дә башкармыйлар, күз алдында ук әллә кем булып, үзгәреп тә китмиләр. Күп очракта алар хикәя яисә повестька килеп кергәнче, хикәяләү барышында һәм әсәргә нокта куелганнан соң да әле шактый вакытлар шул ук хәлдә, элекке эш-гамәлләрен кылып яши бирәләр. Автор гүя ки алар гомеренең бер өлешен, үзләренә сиздермичә генә, тылсымлы нурлар белән яктыртып ала. Ут сүнә, ә әлеге танышларыбыз, бик якын кешеләргә әверелеп, безнең күңелләрдә яшәвен дәвам иттерә. Күңел байлыгы, хисләр киеренкелеге, фидакарьлек, олы җанлылык рухи гарип булмаган һәр кешедә бар икән, үз уйларыбыз белән мавыгып, үз тормышыбызны кайгыртып һәм тормыш мәшәкатьләренә бирелеп, без аларны күреп, тоеп кына җиткермибез икән...

Язучының әсәрләренә салынган бердәнбер фикер түгел бу, әлбәттә. Н. Фәттах геройлары, бик гадәти һәм гади кешеләр булсалар да, һич тә сүлпән, инерт кешеләр түгел. Башка бер шартларда, көтелмәгән хәлләрдә алар кыю адымга да, тәвәккәллеккә, хәтта кайчак дуамал эш эшләп ташларга да сәләтле. Шулай да язучы әсәрләрендәге уңай типларның, әйтик, Һарун, Мансур, Фәридәләрнең («Бала күңеле далада»), Зәйтүнә, Сәгыйтьләрнең («Сезнеңчә ничек?»), Мәдинә, Ләйләләрнең (шул исемдәге хикәяләр), яисә Газимәнең характерларындагы төп сыйфатлар — тыйнаклык, чыдамлык, хискә бирелүчәнлек. Әмма җиңел холыклылык түгел ул. Хисләре тирәндә ята, уй-тойгылар каяндыр төптән кузгала; тормышка бик җитди карый торган беркатлы, вөҗданы саф кешеләргә хас булган сабыр, басынкы хисчәнлек ул. Автор, күрәсең, шундый кешеләрне ярата, аларга битараф кала алмый.

Хәер, Н. Фәттах әсәрләрендә башкарак типтагы уңай геройлар да аз түгел. Аларны нәрсә берләштерә соң? Ни өчен алар беренче карашка (ник беренче карашка гына?) шундый гади, садә кешеләр булып күренәләр дә, әллә ни зур үзгәреш кичермичә, әсәрдән китеп тә баралар? Мондый әсәрләрнең сәнгать ягыннан кыйммәте зурмы, укучыга алар нәрсә алып килә? Сорауларны шулай кабыргасы белән тезеп куюыбыз бары фикерне калкурак, ачыграк итеп әйтү өчен кирәк. Монда бөтен эш язучы сайлап алган тасвирлау ракурсында, күрем яссылыгында, сурәтләү алымында.

Үз геройларының күп төрле потенциаль сыйфатлары арасыннан берсен, икесен күз уңына алып, шуларны калку итеп күрсәткән, үстергән, үрнәк булырлык итеп сурәтләгән каләм осталары бар. Андый әсәрләрдә шәхеснең героик сыйфатлары ничек тәрбияләнүе, формалашуы, әйдәп баручы төп характер билгесенә әверелүе, ниһаять, аның кылган батырлыгы яисә кире типның акрынлап никадәрле тирән әхлакый упкынга тәгәрәве сурәтләү объекты итеп алына. Әдәбиятыбызда лаеклы урын алган мондый әсәрләр бездә байтак. Н. Фәттахның стиле, алымы башкарак. Аның геройлары күбесенчә гадәти көнкүреш шартларында, көндәлек мәшәкатьләр эчендә яшиләр, гади эш-фигыльләре белән мәшгуль булалар. Автор аларның яшәү шартларын, шөгыльләрен, кешеләр белән нинди мөгамәләдә булуларын җентекләп һәм тәфсилле итеп сурәтли. Әмма иң әһәмиятлесе шунда ки, һәр тормыш детале, дөньяның «вактояге», нәни ситуацияләр, кешеләрнең кылган гамәлләре һәм алар арасындагы төрле каршылыклар, бәрелешләр геройларның психологиясе аша үткәрелә, автор тор-

мыш-яшәеш вакыйгаларын образларның эчке дөньясы аша чагылдыра, аларның психологиясен шул ситуацияләр аша яктырта һәм сыный бара. Конкрет тормыш детальләре һәм вакыйгалары аңа шул максат өчен хезмәт итә. Н. Фәттах образның эчке халәтен һәр мизгел тоеп, тәфсилләп аңлатып бара. Геройлар асылда әсәрнең буеннан-буена рухи һәм әхлакый сынау үтәләр, кешелек сыйфатларын эзлекле һәм котылгысыз рәвештә ача баралар. Укучы исә әсәрнең башыннан ук геройларының күңел дөньясына керә, герой белән бергә шул ук сынауларны үтә.

Н. Фәттах, шул рәвешчә, үз геройларын рухи чыныгу процессында күрсәтергә ярата. Бу, әгәр шулай әйтергә ярәса, кешенең гомер агышында очравы ихтимал булган кискен, хәтәр сынауларга хәзерлек чоры. Һәркемдә дә яшь чагыннан ук нинди сыйфатлар үзлексез тупланып килә, акрынлап характер калыплана, ныгый. Язучы үз геройлары гомеренең бик аз өлешен генә тасвирласа да, укучы аларның киләчәктә ничек яшәячәкләрен,ниләр майтарырга сәләтле булуларын яхшы ук ачык күзаллый.

Әлбәттә, Н. Фәттах геройлары да кайчак кискен хәлләргә, гадәттән тыш ситуациягә эләккәлиләр. Мәсәлән, «Буранда» исемле хикәядә шахтер Әхтәмнең авыру әнисен күрергә кайтканда бәлага очравы тасвир ителә. Поезддан төшеп, авылга менә кайтып җиттем дигәндә коточкыч буран чыга. Мондый хәлдә юлны югалтуың, адашып һәлак булуың да ерак йөрми. Кыскасы, ситуацияне теләсәң ничек куертырга, көтелмәгән борылышлар ясарга мөмкинлек туа. Ләкин автор андый юлга басмый. Аның бөтен игътибары үз героеның эчке кичерешләренә, рухи дөньясына туплана. Ә егетнең кемлеген, бөтен эч серләрен белү өчен буран үзе генә дә бик җиткән. Безнең Әхтәм үлем газаплары яисә нинди дә булса маҗаралар кичермичә, өенә исән-имин кайтып җитә. Монда шунысы мөһим: Әхтәм бу төндә кар-буранны гына түгел, үз-үзен, үзенең ваемсызлыгын җиңгән. Ул инде тормышка, әнисенә, тирә-ягындагы кешеләргә карата башкарак мәнәсәбәттә булачак. Һәрхәлдә, тормыш агымында гамьсез генә тирбәлеп баручы йомычкага әверелмәячәк.

Я булмаса, «Ләйлә» хикәясендәге киеренке коллизияне алып карыйк. Авыру Ләйләнең, үлем куркынычы янавына карамастан, бала табарга, ана булырга җыенган вакыты. Шундый хәвефле, шундый изге ниятләр белән яшәгән Ләйләне, үлем белән якалашыр көннәре җиткәндә, һич уйламаган җирдән газиз ире ташлап китә. Хәл, чыннан да, гадәттән тыш киеренке. Әмма авторның максаты фаҗиганы куертуда, шул фонда героиняны мөмкин кадәр калкурак итеп күрсәтүдә түгел. Ләйләне алда тагын да җаваплырак сынаулар көтә, аның әле газиз баласын тәрбияләп үстерәсе бар. Һәм язучыны үз героинясының рухи дөньясындагы үзгәрешләр, аның күңелендәге яңа, якты башлангычның җиңеп чыгуы кызыксындыра. Драматик вакыйга кояшлы, оптимистик аңгыраш ала.

Персонаж язмышына шушы рәвешчә якын килү язучыга сурәт колачын киңәйтергә, замандашларыбызның тулы канлы психологик портретларын тудырырга ярдәм итә. Әйләнә-тирәбездә төрле эш-фигыль, көндәлек гадәти тормыш мәшәкатьләре белән мәш килеп йөргән кешеләр, үзләре гади булган хәлдә, бай рухи дөньялары, мәгънәле яшәешләре, күңел түрләрендә яшеренеп яткан күркәм сыйфатлары белән ачылып китәләр.

Язучының башлангыч чор иҗатында, аерым алганда, 1957 елда ук дөнья күргән «Сезнеңчә ничек?» романында һәм кайбер хикәяләрендә, шулай ук 1966 елда басылган «Бала күңеле далада» романында да кимчелекләр юк дип булмый. Мәсәлән, «Куян йөрәк» (1956), «Ялгыз нарат» (1958) хикәяләрендәге Нургали, Гата карт образларына нәкъ менә психологик яктан нигезләү җитенкерәми, аларның кылган гамәлләре вак бер әшәкелек күренеше булып кына кала. «Бала күңеле далада» романындагы кибетче кыз Мәрьям, механизаторлар бригадасы комсоргы Мансур образлары исә бер очракта эзлеклелек җитмәүдән, икенче очракта психологик характеристиканы артык ваклап җибәрү нәтиҗәсендә тәгәлләнми калалар. Н. Фәттахның кайбер әсәрләрен сюжет-композиция ягыннан да җыйнаграк итеп булыр иде. Кыскасы, тәнкыйть сүзе әйтерлек, бәхәсләшерлек урыннар да бар. Ә биредә исә без, беренче чиратта, каләм остасының художниклык үзенчәлеген абайларга, психологик сурәт остасы буларак, күзәтүләре үткенләгән чамаларга тырыштык. Чыннан да, бу сыйфат-хасиятләр— Н. Фәттах иҗатының көчле һәм отышлы ягы, аның «үз ияре».

Нурихан Фәттах үз замандашларының тормыш-яшәешен, авыл һәм шәһәр көн-күрешен, гадәти хезмәт башкарып, заман йөген җилкәләрендә күтәреп баручы бүгенге буын кешеләренең күңел дөньясын сизгер тоя, психологик нечкәлек белән сурәтли.

Н. Фәттах әдәбиятка бик яшьли килеп, бик табигый рәвештә үзләшеп китте дигән идек.

«Безнең хикәяләр» җыентыгында «Утлар» исемле хикәясе беренче тапкыр матбугатта күренгәндә Нуриханга егерме генә яшь була. Әмма, төбәлебрәк караганнан соң, мондый фикер язучының яшьлек чорында язган иң уңышлы хикәяләре тәэсирендә туганлыгына ышанасың. Баксаң, алай ансат кына булмаган икән. Әле Ватан сугышы елларында урта мәктәптә укыганда ук әдәби иҗат тәҗрибәләре ясый, шигырьләр яза, күңел дәфтәрләре алып бара ул. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәч, фольклор экспедицияләренә дә йөреп, кечкенәдән үк зиһененә сеңдереп килгән халык иҗаты әсәрләрен, җырлар, мәкальләр, бәетләр җыюда катнаша, халыкның җанлы телен, ырым-йолаларын, тарихи легендаларны өйрәнә.

Университетны тәмамлап, нәшриятта, газетада эшли башлауга, ул зур дәрт белән татар теле фразеологик сүзлеген төзү эшенә керешә. (Әдипнең архивында фразеологик берәмлекләрнең зур гына картотекасы һаман саклана.) Илленче еллар башыннан ул рус авторларының балалар өчен язылган әсәрләрен тәрҗемә итә башлый. Соңрак Н. Фәттах тәрҗемәсендә В. Гюгоның «Хокуксызлар» романы, А. С. Серафимович хикәяләре, Бальзакның берничә хикәясе татар телендә басыла. Ул яңа чыккан әсәрләргә рецензияләр, аерым мәкаләләр дә язып килә.

Шул ук илленче елларда Н. Фәттах балалар әдәбиятында да каләмен сыный — нәниләр һәм кече яшьтәге мәктәп балаларына хикәяләр җыентыгы бүләк итә. Ул хикәяләр дә озын гомерле булдылар: Татарстан китап нәшрияты аларны 1976 елда «Безнең бабай» исеме белән аерым җыентык итеп кабат бастырды.

Нурихан Фәттах зур әдәбиятка үз буыныдашлары, илленче еллар яшьләре образлары белән килеп керде. Ул бала һәм үсмер чагы авыр сугыш елларына туры килгән, белемгә, яшәүгә сусаган, якын һәм ерак киләчәккә зур ышану, өмет белән карый, шуны якынайту өчен теләсә нинди эшкә әзер торган бай романтик хыяллы буын иде. Күбесе яшьтән төпле белем туплап өлгермәгән бу яшьләргә үзләре яшәгән чорның күп кенә катлаулы проблемаларын аңлау, әлбәттә, җиңел түгел иде. Уку һәм эшләү, җәмгыять өчен файдалы һөнәр сайлау, шәхес һәм заман, шәхес һәм коллектив мөнәсәбәте, шәхси тормыш һәм коллектив тормышы кебек мәсьәләләр яшьләрнең үзара әңгәмәләрендә булсын, комсомол җыелышларында булсын — һәрвакыт диярлек телдән төшми, төрле фикерләр, бәхәсләр кузгата. Гаҗәп тә түгел, чөнки бу буын — миллионнарча яшь гражданнарның гомерләрен алып киткән сугыш афәтеннән соңгы беренче ишле, дәртле буын.

Әдәбиятыбызда илленче еллар яшьләренең киеренке, кайсыдыр яклары белән каршылыклы хис-тойгыларын чагылдырган әсәрләр шактый тудырылды. Н. Фәттахның проза әсәрләре шулар арасында күренекле урын тота. Аның студентлар тормышыннан алып язылган «Сезнеңчә ничек?» романы, «Берничә хикәя» җыентыгы нәкъ әнә шул елларның яшьләре тормышына багышланган да. Романда язучы студент яшьләрнең тормыш тәҗрибәсе туплавы, уку-укыту һәм хезмәт, яшьлек-мәхәббәт, әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Әмма ул, бик хаклы рәвештә, өлеге буын яшьләрен үзбаш яши торган төркем итеп, халык тормышыннан аерып куймый, алар өлкән буын кешеләре белән тыгыз элемтәдә, элгәрге һәм яңа совет чынбарлыгында туган традицияләрне дәвам иттерүчеләр буларак гәүдәләндерелә.

Илленче елларда Н. Фәттахның тормышны өйрәнү колачы киңәя һәм тирәнәя бара. Ул халык иҗаты һәм гореф-гадәтләре, тарихы белән кызыксына. 1957 елда профессор А. П. Смирнов җитәкчелегендәге археологик экспедициягә килеп кушыла, борынгы Болгар хәрабәләрен казуда катнаша. Шул ук вакытта яшьләрнең бүгенге тормышы да аны һаман үзенә тартып тора. Ә илленче еллар урталарында республикабызның меңнәрчә егет һәм кызлары чирәм җирләрне үзләштерү өчен Казакъстан далаларына китә башлагач, бу патриотик хәрәкәт Н. Фәттахны да үз эченә бөтереп ала. Ул ике ел рәттән берничә ай буе Павлодар өлкәсендәге «Казан»

совхозында яши, чирәм күтәрүчеләрнең тормыш һәм хезмәтен җентекләп өйрәнә, бик күп кешеләр белән таныша, дуслаша. Шул ук вакытта язучы иркен далаларда терлек-туар асрап көн күрүче казакъ картларыннан борынгы легендалар, сөйләкләр тыңлый, аларның тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен игътибар белән күзәтә... Шушы ерак сәфәрләрнең нәтиҗәсе буларак, 1962 елда «Бала күңеле далада» исемле роман язылып бетә. Чирәм җирләр күтәрергә килгән якташларыбыз тормышын һәм эшләрен сурәтләгәндә дә автор (гәрчә тема һәм тормыш материалы мөмкинлек бирсә дә) героик пафоска күчми, артык куе буяулар кулланмый. Әсәр башыннан ахырынача реалистик сурәтләү чаралары белән хәл ителә. Бары тик аеруча истәлекле вакыйгаларны тасвирлаганда (мәсәлән, дала буйлатып беренче буразнаны салганда) гына әдип романтик хикәяләү алымына мөрәҗәгать итә. Авыл егете Һаруннар, армия хезмәтеннән кайткан Барыйлар, шәһәр кызы Фәридәләр — гап-гади яшь егетләр һәм кызлар, шапырынмый-нитми генә фидакарь хезмәтләрен башкара бирәләр. Бу җирнең төп тоткалары — әнә шундый кешеләр. Әсәрдә чирәм җирләр күтәрүче якташларыбызга лаек булырлык күркәм образлар тудырылган. Бригадир Барый, аш пешерүче Фәридә һәм башка геройлар саф намуслы, ихлас күңелле кешеләр булып хәтердә калалар. Ә тракторчы Һарун, бөтен совет әдәбияты күләмендә алып карaганда да, чирәм җирләрне үзләштерүчеләрнең әдәби образлары арасында иң уңышлыларыннан саналырга хаклы.

Моннан ун ел элек аерым китап булып чыккан «Мөдир Саҗидә» повесте белән язучы яшь замандашларыбызның әдәби портретлары галереясен уңышлы дәвам иттерде. Ул әсәр Н. Фәттахның заман темасына багышланган иң отышлы әсәре дисәк тә хата булмас. Повесть әдипнең арсеналында моңарчы файдаланылмый килгән әдәби мөмкинлекләр, яңа сурәтләү чаралары барлыгын күрсәтте. Әсәр җиңел һәм җыйнак ритмы, теленең нәфис гадилеге белән аерылып тора, ул гүя үтәдән-үтә кояш нурында коендырылган. Ә Саҗидә образы безнең әдәбиятка ниндидер яңа нәфис аһәң, яңа көй алып килде шикелле. Болай караганда әллә нәрсә юк та кебек үзе. Булдыра алган кадәр тырышып кына эшли кыз, авыл халкына медицина хезмәте күрсәтүне җайга салырга омтыла. Авылның культура-агарту эшләрендә дә катнаша. Тик бер кимчелеге бар: җиңелчәрәк холыклы, җитмәсә, бераз гына үпкәчел дә. Әмма никадәрле күңел сафлыгы, ихласлык, бәхетле киләчәгенә нинди нык ышаныч аңарда! Шулар аны рухи нәфис итә.

Без ирексездән Саҗидә характерындагы кечкенә кимчелекләрне гафу итәбез, киләчәктә аның алардан арынаЧагына ышанабыз. Повестьтан яшәү дәрте, оптимизм рухы бөркелеп тора. Шик юк ки, әсәр яшь буынны рухи тәрбияләү эшендә киләчәктә дә әле безнең җәмгыятькә озак хезмәт итәр.

Мөдир Саҗидә, Ләйлә, Мәдинә, «Кол Гали» трагедиясендәге Чәчкә... Н. Фәттах әсәрләрен укыганда хатын-кыз образларына игътибар итми кала алмыйсың. Сокландыргыч әчке гүзәллеккә ия алар. Олы җанлылыклары, сизгер нечкә күңелләре, тугрылык сыйфатлары белән әдәбият күген яктыртып торалар.

Хезмәт сөючән, ихлас күңелле, тыйнак фидакарьлек сыйфатларына ия булган замандаш образларын иҗат иткәндә язучы халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи мирасы, мәңгелек рухи кыйммәтләре хакында да уйланмый калмый. Бөек Октябрь революциясе хезмәт иясе массаларының гасырлар буена яшеренеп, басылып яткан әчке энергиясен, яңа гадел җәмгыять төзү өчен көрәш дәртен уятты, ил бәхетен һәм азатлыгын саклап дан алган меңнәрчә батырларны үстерде. Әдип шушы каһарманлык, фидакарьлекнең генетик һәм әхлакый тамырларын эзли, халыкның азатлык, хөрлек рухы чыганакларын табарга омтыла. Әнә шулар язучыны тирәнгә, тарих катламнарына чакыралар да инде.

Әдәбиятыбызда җитди тарихи әсәрләргә ихтыяҗ күптәннән сизелеп килә иде. Шул зарури ихтыяҗны сизгән хәлдә, Н. Фәттах бүгенге буын әдипләребез арасыннан беренче булып әдәби-тарихи жанрда эзләнүләрен башлап җибәрде. Әмма аңа тарихи әсәрләрне иҗат итү принциплары, сюжет-композиция, сурәтләү алымнары һәм тел, тарихи вакыйгаларны тасвирлаудагы документальлек һәм язучының хыял ирege кебек мәсьәләләрне хәл итүдән элек бөтенләй башка эш белән шөгыльләнергә туры килә. Халкыбыз тарихы, шул исәптән болгар чоры хакында җентекле попу-

лар хезмәтләрнең һич тә җитәрлек булмавы әдипне җиң сызганып беренчел тарихи чыганакларны өйрәнүгә керешергә мәҗбүр итә. Н. Фәттах шәһре Болгар хәрабәләренә һәм болгар тарихы белән бәйләнешле башка урыннарга сәяхәтләр ясый, әйтканебезчә, археологик экспедицияләрдә катнаша, борынгы һәм хәзерге заман тарихчыларының хезмәтләрен, сәяхәтнамәләрне өйрәнә. Язучы эзләнүләре барышында фольклор әсәрләренә генә түгел, телнең үзенә дә мөрәҗәгать итә, борынгы төрки телне өйрәнү белән бергә, хәзерге татар һәм башка төрки телләр лексикасындагы тарихи катламнарны күтәрә. Үз сүзләре белән әйткәндә, «кешенең борынгы аң-карашларын, борынгы тормышын чагылдырган һәм җанлы сөйләм телендә әлегәчә сакланып килгән кайбер сүзләрнең һәм сүз тезмәләренең «археологик» катламнарын ачып, төрки халыклар тарихына һәм этнографиясенә кагылышлы» материаллар туплый[1]. Әдипнең фәнни юнәлештәге эзләнү һәм тикшеренүләре инде ике дистә еллар дәвам итә.

Әнә шул рәвешчә, язучының иҗат лабораториясе белән янәшә фәнни эзләнү һәм тикшеренү лабораториясе дә барлыкка килә. Һәм, әйтергә кирәк, Н. Фәттахның боларның соңгысында башкара торган хезмәте мөстәкыйль әһәмияткә ия.

Менә шушындый киң колачлы эзләнүләр, тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, соңгы сигез ел эчендә Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романы (1970), «Кол Гали» трагедиясе (1974), «Ерак гасырлар авазы» (1976) исемле тарихи язмалары мәйданга чыкты[2].

Тарихи әсәр иҗат итәргә алынган әдип, һичшиксез, тарихи гыйлемле булырга, тарих фәне туплаган белемнәр югарылыгында торырга тиеш. Монысы һәркемгә аңлашыла торган шарт. Әмма тарихчы әдип болар белән дә канәгатьләнеп кала алмый. Ул үзе сурәтли торган чор-дәверләрнең рухи тормышына, халыкның тарихи психологиясенә, шул чор кешеләре кичергән уй-хисләр дөньясына үтеп керергә омтыла. Һәр халыкның дөньяны кузаллавында, эчке табигатендә, уй-фикерләү рәвешендә дәвердән-дәвергә бик акрын үзгәреш кичереп һәм, халык теле кебек үк, нигездә сакланып килә торган үзенчәлекләр дә бар. Тарихчы әдип боларны бик нечкә тоярга, хәтта махсус өйрәнергә тиеш. Ул үзенчәлекләр шул заманның рухына керү өчен язучыга үзенә бертөрле күпер хезмәтен дә үтиләр.

Н. Фәттахның тарихи әсәрләрендә бу сыйфатлар сизелеп тора. Ул болгар чоры дөньясын, анда яшәгән халыкның холык-фигылен, уйларын һәм гамәлләрен шактый калку төсмерле, җанлы итеп күз алдына бастыра.

«Әтил суы ака торур» романында сурәтләнгән X гасыр һәм «Кол Гали» трагедиясендә гәүдәләндерелгән XIII гасыр — болар һәр икесе Урта Идел буе халыклары тарихында хәлиткеч дәверләр. Төрки халыклары тарихындагы героик чор — Беренче һәм Икенче каганлык заманнары инде үткән, Хазар каганлыгы да X йөздә үк инде сүнүгә, таркалуга таба бара. Ул чорлардан нигездә тарихи риваятьләр, легендалар, сөйләкләр генә торып калган. Ләкин тормыш тукталмый. Игенчелек һәм һөнәрчелек, сәүдә үсә. Идел буенда мәктәп-мәдрәсәләр салынып, китап гыйлеме, укымышлылык тарала башлый. Утрак тормышта яшәүче ыруглар саны арткан-арта, яңа шәһәрләр калка, аларда төрле кавем, кабилә, ыруг кешеләре туплана бара. Шул нигездә яңа этник берәмлек — болгар халкы оеша. Ләкин боларның барысы эзлекле рәвештә тормышка аша барсын өчен бер шарт — үзәккә туплаучы тотрыклы дәүләт булуы кирәк. Һәм Урта Идел буендагы беренче феодаль дәүләт — бөек Болгар патшалыгы барлыкка килә. Идел-Чулман болгарлары, бигрәк тә аның хәрби-феодаль катлавы өчен бу дәвер — үзенә күрә шулай ук героик дәвер. Алар Идел, Чулман, Агыйдел, Җаек буйларында яшәүче күп санлы кабиләләрне берәм-берәм үзләренә буйсындырып, бер үзәккә туплап, шактый көчле дәүләт төзүгә ирешәләр. «Әтил суы ака торур» романында язучы Болгар иле тормышындагы әнә шул киеренке, катлаулы чорны тасвирлый. Сәреләчәк җирнең ызаны сызылгач, хикәяләү юнәлеше билгелән-

---

[1] «Казан утлары», 1976 ел, 9 сан, 152 бит.
[2] Әле күптән түгел Н. Фәттах тагын «Сызгыра торган уклар» исемле зур күләмле тарихи әсәренең беренче китабын тәмамлады.

гәч, әдипнең хыялы эшкә тотына. Романның алдагы бүлекләрен укуга ук бер-берсенә капма-каршы теләк-омтылышлар, персонажларны котылгысыз бәрелеш-орышларга китерәчәк ситуацияләр, алышынып торган кискен вакыйгалар эченә кереп чумасың. Шунысын да әйтеп куярга кирәк: сюжет хәрәкәте, киеренке көрәш күренешләре һәрберсе диярлек төгәл тасвирланган көнкүреш шартлары фонында бара; ныгытылган кальга, аның эчендәге өйләр, чатырлар, сырганнар, табигать күренешләре — болар кинога төшерерлек дәрәҗәдә җанлы, төгәл, ачык. Автор хәтта кешеләрнең фикерләү рәвешен, сүз сөрешләрен, сөйләшү-көлү, елау-сыктау, сөенеч-шатлыкларын күрә, ишетә кебек. Монда да язучы иң элек тарихи мәгълүматларга, үзенең белем һәм эрудициясенә таяна. Романның төп каршылыклары тарихи чынбарлыкка нигезләнгән. Хазар хаканы белән Алмыш хан, Алмыш белән Ямгырчы би, Күрән би, болгар тарханнары белән тирә-яктагы ыруг-кабиләләр арасындагы бәрелешләргә тукталмыйча, Ак бүре ыругы башлыгы Күрән би белән Утташ кам арасындагы эчке көрәшне генә алып карыйк. Утташ кам — ыругның дин башлыгы, Тәңре белән «алыш-биреше» булган, йола сагында торучы кеше. Ә ыругның көнкүрешендәге яңа шартлар: утрак тормышта яшәү, җитештерү һәм сәүдә үсеше, чит халыклар белән аралашу, Идел буенда гарәп алласы белән төрки Тәңресе арасында башланып киткән ярыш, гыйлем-укымышлылыкның таралуы күп кенә борынгы йолаларның да, Тәңренең дә көчен киметкән. Утташ кам сихерләре генә Ак бүре ыругына иминлек тәэмин итә алмый башлаган. Шушы нигездә Күрән би белән дин башлыгы арасында каршылык кискенләшә. Әмма ул әлегә ачыктан-ачык бәрелешкә барып җитми. Утташ кам яшертен рәвештә үч алырга мәҗбүр. Мәсьәләнең әнә шулай куелышы тарихи барышка туры килә.

Әсәрнең отышлы якларын күпләп санарга булыр иде. Автор еракта калган чорның киң картинасын, бер дәүләт булып оешып килүче кабиләләр тормыш-көнкүрешенең шактый тулы панорамасын тудыра алган.

Әсәр матбугатта күренү белән укучыларда зур кызыксыну тудырды, кызу-кызу бәхәсләр уятты, төрле очрашулар, роман буенча фикер алышулар вакытында авторга бик күп теләкләр әйтелде. Ул теләкләрнең күбесе шул чор тормышының әсәрдә гәүдәләнеш тапмый калган якларына кайтып кала иде. Әмма язучыдан анысын сурәтлә, монысын яз, дип таләп итү бигүк дөрес түгел. Хәер, вакытлар үтү белән әсәргә җәмәгатьчелекнең карашы да тотрыклана төште, романның иң төп хасиятләрен билгели торган сыйфатлары тиешенчә бәяләнде дип әйтергә мөмкин.

Әлбәттә, әдәбиятыбызның тарихи роман жанрындагы беренче тәҗрибәсе буларак, әсәр кайбер җитешсез яклардан да азат түгел. Принципиаль булмаган детальләргә тукталып тормыйча, әсәрнең төп уңай герое Тотыш образының ничек хәл ителүе мәсьәләсен алып карыйк. Менә без ярсу хисле һәм шул ук вакытта дуамал холыклы шул Тотыш белән очрашабыз. Аңарда угыз белән Чулман төркие биенең каны бергә кушылган. Ярым кыргый табигать эчендә иркенлектә үскән, йола һәм түрә кагыйдәләренә буйсынып яшәргә өйрәнмәгән, күңеле белән беркатлы, хис-тойгыларга тиз бирелүчән һәм шактый тотнаксыз бу егет укучыны көтелмәгән вакыйгалар, хәтәр борылышлар эченә алып кереп китә. Романның сюжеты төрле маҗараларга да, драматик вакыйгаларга да бай. Язучының фантазиясе яңадан-яңа коллизияләрне өстәп кенә тора. Сюжет җепләре нык төйнәлә, хәтта бераз гына чуалып та китә. Язучы бердәм дәүләт оешу процессын, бик хаклы рәвештә, канлы бәрелешләр, мәкерле интригалар аркылы тасвирлый да. Хазар хаканына бәйлелектән котылу, илне имин яшәтү өчен бердәмлек кирәк. һәм нәкъ менә шушы чорда Урта Иделдә яшәгән кабиләләр арасында, тарихи зарурият рәвешендә, бер үзәккә тартылу тенденциясе өстенлек ала. Һичкемгә баш бирергә теләмәгән, Алмыш ханны дошманы санап йөргән Тотыш алыпка да, объектив мәҗбүрияткә буйсынып, болгар патшасына хезмәт итәргә туры килә. Язучы тарихи үсешнең объектив закончалыкларын биредә әнә шулай сәнгать чаралары белән оста гәүдәләндерә. Ләкин алга таба әсәрдә Тотышның шәхси сыйфатлары, дуамал хис-тойгылары өстенлек ала башлый. Ул тарихи барышның эзлекле хәрәкәтенә бер ялгызы каршы чыга, баш күтәрә һәм ахырда үзен-үзе һәлакәткә китерә. Әмма аңарчы ул әле, өермәле хисләрендә бөтерелеп, әсәрнең эзлекле сюжет җебен шактый чуалтып өлгерә. Монда урта гасыр шәрык әдәбияты, мәхәббәт дастаннары үрнәкләренең тәэсире сизелә

кебек. Батыр һәм тәвәккәл болгар хатын-кызлары, Тотышның дөньясын ташлап, сөйгән яры артыннан читкә китүе һ. б. кайбер детальләр шуңа ишарәли. Биредә мин нәрсәгә басым ясап әйтәсе килә. Идел-Чулман буйларында беренче дәүләт — болгар бабаларыбыз иленең иминлеге өчен көрәшеп, бәйсезлеген саклап, аның нигезендә таш булып ятып калган меңнәрчә каһарманнар да булган. Аларның хәрби куәте Болгар дәүләтенең ничә гасырлар яшәвен тәэмин иткән, культура үсеше, этник бердәмлек — болгар халкы оешу өчен тышкы шартларны булдырган. Идел болгарлары чорына багышланган күләмле әсәрнең төп геройлары рәтендә әнә шуларны күрәсе килү шуңа бик табигый дә.

«Әтил суы ака торур» романы, тулаем алганда, үз туган җиреңә, халкыңны яратырга, аның белән горурланырга, көчеңне кызганмый аңа хезмәт итәргә өйрәтә. Әсәрнең зур иҗтимагый әһәмияте дә шунда.

Халыкның борынгы рухи тормышы, эчке дөньясы, туган җиренә мәхәббәте турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләгә тукталып китмичә булмый. Сүз М. Кашгариның мәгълүм сүзлегендә теркәп калдырылган, Идел-Чулман төркиләре, болгарлар җырлаган борынгы мәшһүр җыр хакында бара. Романның исеме дә «Әтил суы ака торур» дип, шул җыр юлыннан алынган. Бу, чыннан да, бик борынгы һәм бик мәшһүр җыр булса кирәк. Җырның халык иҗаты тегермәнендә бик нык эшкәртелеп, халык телендә шомарып, шигъри яңгырашы җиренә җиткерелгән булуы да шул турыда сөйли. Җырда Идел-йортта яшәүче бабаларыбызның үз туган җирләренә мәхәббәте, аның бай һәм гүзәл табигате белән горурлануы чагыла, Идел буйларында яшәгән төрки кабиләләр, борынгы болгарлар бу җирләрне үзләренең туган туфрагы дип санаган булулары күренә. Әмма, шул ук вакытта, җырның бүгенге телебездәге аңлатмасы гаҗәпсенү хисе уята. Әсәргә сүз башында җырның соңгы ике юлына «Күлләрендә бака һәм балык күп булыр» дигән аңлатма бирелгән. Хәер, бер монда гына түгел. Кемдер аны беренче булып шулай «тәрҗемә иткән» һәм җыр инде ничәмә ел әнә шул аңлатмада бер фәнни хезмәттән икенчесенә күчеп тик йөри бирә. Ләкин тәрҗемә ышандырмый. Чыннан да, ник әле балык белән бака янәшә куелып, «бака муллыгы» зур горурлык хисе тудырсын икән? Бу халыкның эстетик зәвыгына туры килми. Бака халык иҗатында беркайчан да матурлык идеалы булып тормаган. Бака белән балыкны бер-берсенә торырлык җан ияләре кебек санап янәшә куярга берниндә нигез юк. Һәм дөрес тә: бу җырда бака турында сүз бармый. Игътибар белән карап бакканда, бака сүзенең җир-су хайваны булмыйча, багу, күрү тамырыннан икәнлеге күренә. Җырның беренче юлында «ага» фигыленең «ака», икенче юлда «кага»ның «кака» формасында килүе дә шуны раслый. Димәк, «Балык тәлим бака торур» дигән юлны «балыкны күп багар, үстерер» дип укырга тиеш булабыз. Җырдагы образлылык, чынлап та, эстетик яктан төгәл һәм эзлекле: Иделебез тау, урманнар, далалар кичеп, талгын дулкыннарын текә ярларга, биек кыяларга кага-кага, киң күкрәгендә бихисап күп балыкларны тирбәтә-тирбәтә багып үстерүче шәфкатьле ана булып күз алдына баса.

Инде килеп, җырның соңгы юлы да дөрес аңлатылмаган. Дөресрәге, аңа аңлатма бөтенләй бирелми, алдагы юл белән кушып: «Күлләрендә бакасы да, балыгы да күп булыр» гына диелә. Хәлбуки, «Күлең тәкый күшәрүр»нең үз мөстәкыйль мәгънәсе бар. Беренчедән, Идел турындагы җырда тагын нинди дә күлләр турында сүз бармый. «Күлең» сүзе кульязмадан күчергәндә үк дөрес укылмаган булырга тиеш. «Күлең» урынында «кулың», ә серле һәм аңлаешсыз булып тоелган «күшәрүр» сүзе урынында гап-гади төрки сүзе «кушыру» булуына шикләнмәскә мөмкин. Әле дә татар агае «кулың кушырып утырма» дип сөйли. Шул рәвешчә, монда сүз Иделдәге балыкның кул кушырып, кушучлап сөзәрлек дәрәҗәдә күп булуы хакында бара. Һәм моңысы тарихи чыганакларга да бик туры килә. Гарәп сәяхәтчеләре, мәсәлән, Идел буена XIV гасырда килгән гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати, чыннан да, Иделдәге балыкның күплегенә хәйран калып, кушучлап алырлык дигәнрәк мәгънәдә яза. Шулай итеп, җырны: «Идел суы ага торыр, кыя төбен кага торыр; балыгын да бик күп багар, кул кушырып алырлык», дип уку дөрес булачак.

Бу хакта тәфсилләп сөйләвебезнең сәбәбе шунда ки, «Әтил суы ака торур» романындагы вакыйгалар нәкъ менә шул Идел-Чулман буйларында бара, әсәрнең геройлары, башка җырлар белән беррәттән, шушы җырны да көйләп үсәләр. Автор

әледән-әле үз геройларының эчке дөньялары, тойгы-омтылышлары, туган җиргә, ил-көнгә, нәсел-ыруга бирелгәнлек хисләре хакында сөйли. Идел һәм бихисап болак-инешләрнең, шул елга-күлләр, чишмәләр буенда җәйрәп яткан болын-тугайларның табигый матурлыгын бик нечкә тоя белүче кешеләрне сурәтли. Һәм шул ук вакытта алар җырлаган гүзәл җырларның берсе — безгә килеп җиткән бердәнбер җыр — әсәрнең беренче битендә үк хата аңлатыла. Дөрес, алда әйткәнчә, авторның ул үз аңлатмасы түгел, автор монда инерция буенча, электән килгән әзер «фәнни аңлатманы» файдаланган.

Н. Фәттахның «Кол Гали» трагедиясе язучының конкрет образ аша тарихилык принцибын чагылдыруында яңа зур адым булды. Әсәрнең үзәк герое — тарихи шәхес, шагыйрь Кол Гали — биредә яңа сыйфатта гәүдәләндерелә. Ул бөтен көчен һәм гомерен Болгар-йортның бердәмлеген ныгытуга багышлый, илгә кара яу булып ябырылып килгән дошман һөҗүменә каршы бөтен кавемнәр белән бергә күтәрелгәндә генә халыкны, дәүләтне саклап калып булачагына тирәнтен ышана. Элекке әсәрендә хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләргә язучы биредә җавап бирә, төп геройны гәүдәләндерүдә, образ чишелешендә алга зур адым ясый. Шагыйрь күктәге алладан бигрәк, җирдәге гүзәллеккә, мәхәббәткә, кешеләрнең эчке һәм тышкы матурлыгына табына, шул җир кешеләренең күңелендә бөреләнеп, илаһи бер көч-кодрәт белән бәреп чыккан шигъри сүзгә тугрылык саклый. Аның коллыгы да, галилеге дә шушында. «Кол Гали» трагедиясендә Н. Фәттах шагыйрьне нәкъ әнә шундый итеп күз алдына бастыра.

Нурихан Фәттах тарихи әсәрләре белән халкыбызның бик еракта калган тарихын сәнгатьчә гәүдәләндерүнең моңарчы күрелмәгән үрнәкләрен бирде, матур әдәбият чаралары белән ил һәм халкыбыз кичергән җаваплы дәверләрне, аның ерак гасырлар тузаны астында күмелеп яткан тормыш һәм көрәш сәхифәләрен ачты. Якын киләчәктә яшь каләм ияләребез арасыннан шушы эзгә басучылар табылыр, өлкән язучы үрнәге аларда әле үзенең сурәтчесен көтә торган тарихи чорларыбыз капкасын кагарга дәрт, дәрман уятыр дип ышанасы килә.

Язучы Нурихан Фәттах үз гомеренең бишенче дистәсен түгәрәкләде. Илле яшь иҗат гомеренең әле бары тик яртысы дип санаган хәлдә, аның киләчәк гомере яңа иҗади ачышлар, казанышлар белән яктыра барачагын шикләнми әйтергә мөмкин.

# НИЯТЛӘРЕ ЯХШЫДАН ТҮГЕЛ

Бу китапка килү юлым шактый әйләнгеч булды. Библиографик күрсәткечләрне актарганда, 1975 елда Берлинда Клаус Ремер тарафыннан аңарга рецензия язылган булуын белдем башта. Һәм беренче чиратта шул рецензия белән танышып чыктым. Эзләнүләр СССР Фәннәр академиясенең Иҗтимагый фәннәр буенча фәнни информация институтына китерде. Шунда гына Патрик фон цур Мюленның «Свастика һәм совет йолдызы арасында. Совет көнчыгышы халыкларының икенче бөтендөнья сугышындагы милләтчелеге» (1971 ел, Дюссельдорф)[1] хезмәте белән танышырга насыйп булды.

Тышлыкта ук автор турында кыскача мәгълүмат бирелгән. Шушы китап нигезендә ул Рейн университетының философия факультетында (Бонн шәһәре) диссертация дә яклаган икән. Димәк, бу фәннилеккә дәгъва иткән хезмәт булып чыга. Хәер, шактый күләмдәге библиография дә шул хакта сөйли булса кирәк. Автор ФРГның күп кенә дәүләт архивларында казынган. Берлин документлар үзәгендә шактый гына папкалар актарган һәм Нюрнберг процессы материаллары белән танышкан. Кулланылган әдәбият исемлегендә берничә совет галиме һәм хәрби җитәкчеләренең дә хезмәте искә алына.

Әмма китапны укый башлау белән авторның фән кешесе һәм объектив булырга азапланулары күз алдында эреп юкка чыга. Мюлен «абвер-профессор» түгел-түгелен (сугыш чорында фашистларга хезмәт итеп, гитлеризм тар-мар ителгәчтен политик фәннәр өлкәсенә ташланган әрсезләрне шулай дип атыйлар). Димәк, аңа аклануып яисә үз-үзен агартырга маташып торасы да юк. Ул сугыштан соң гына мәйданга чыккан буын вәкиле, эре буржуазия карашларын яклап чыгыш ясаучы тарихчы. Һәм, тулаем алганда, тарихи фактларга да ул буржуаз объективизм күзлегеннән чыгып якын килә. ФРГның кайбер ачыктанация реакцион позициядә торган тарихчылары кебек Мюлен фашизмны акларга омтылмый. Алай гына да түгел, автор фашистларның кансызлыкларына күпмедер нәфрәтләнеп тә карый кебек әле (21 һәм 46 битләрдә). Әмма кешеләр белән мөнәсәбәттәге ерткычларча явызлыкны ул, немец илбасарларына гомумән хас нәрсә дип түгел, ә гестапо һәм СДның аерым «тайпылыш»лары буларак кына аңлатырга тели.

Мюленның игътибар үзәгендә милләтчелекне идеологик һәм политик аспектларда өйрәнү мәсьәләсе тора. ГДР галимнәренең фикеренчә, авторның төп методологик бәласе дә нәкъ менә мәсьәләнең куелышыннан ук башлана. Милләтчелек төшенчәсе астында ул туган җирен ташлап качкан ак эмигрантлар милләтчелеге белән совет хезмәт халкының патриотизмын бер казанга салып бутамакчы була. Мәсьәләнең социаль-политик эчтәлегенә авторның аңлы рәвештә күз йомарга азаплануыннан башка нәрсә түгел бу. Ә бит Мюлен фәлсәфәсенә карап фикер йөртсәң, имеш, буржуаз милләтчелек белән совет патриотизмы арасында артык зур аерма да юк икән... Чынлыкта исә боларның беренчесе социализмга каршы юнәлтелгән реакцион хәрәкәт, ә икенчесенең шул яңа системаны яклап көрәшкә күтәрелгән зур бер көч булуы һичкемнән яшерен-батырын түгел.

[1] Patrik von zur Mühlen. Zwischen Hakenkreuz und Sowjetstern. Der Nationalismus der sowjetischen Orientvölker im Zweiten Weltkrieg. 1971. Droste Verlag. Düsseldorf. 256 s.

Автор Көнбатыш Европа советологлары арасында шактый киң таралган мифтан, СССРда рус һәм рус булмаган халыклар арасында конфликт яшәп килә дигән сафсатадан чыгып, һәр урында шушы «антагонизм»ны эзләп иза чигә. Бигрәк тә шунысы аянычлы, ул фәнни кызыксынудан чыгып кына түгел, бу мәсьәләне фашистлар Германиясенең икенче бөтендөнья сугышында ничек файдалануы һәм, янәсе, файдаланылмаган мөмкинлекләр турында да фикер йөртә. Нәтиҗәдә, Мюленның эзләнүләре ачыктан-ачык советка каршы юнәлеш ала. Һичкемнән дә сер түгел, әле бүген дә Көнбатышта СССР халыклары арасындагы милли мөнәсәбәтләрне киеренкеләтергә азапланучылар байтак. Һәм бу пропаганданың турыдан-туры социалистик җәмгыять һәм дәүләт строебызны какшатуга юнәлтелгән булуы да аңлашыла... Шундый перспективадан чыгып Мюлен, беренче чиратта, Кавказ, Урта Азия һәм Идел буе районнарыннан киткән буржуаз милләтчел эмигрантларга мөрәҗәгать итә. Дөрес, ул аларның эшчәнлеген бәяләүгә, чагыштырмача объектив килергә тырыша, хәтта аларның шпионлык эшләренә һәм турыдан-туры фашизмга хезмәт итүләренә дә күз йомып уза алмый.

Китапның икенче бүлегендә (ул барлыгы 7 бүлектән тора) фашистларның совет хәрби әсирләренә мөнәсәбәттә алып барган политикасы «анализлана». Фашист илбасарларының әсирлеккә дучар ителгән совет гражданнары белән ерткычларча мөнәсәбәтен танырга мәҗбүр булса да, бу күренешне ул сугышның беренче периодына гына хас нәрсә иде дип аңлатырга тели. Ә тарихи фактлар исә моның киресен сөйли. Фашистларның «кешелеклелеген» (бу сүзләрне янәшә куюым өчен гафу үтенәм— М. А.) күрсәткәндә автор бигрәк тә Розенбергның Көнчыгыш министрлыгына һәм көнчыгыш халыкларын «өйрәнүче» фашист профессоры Г. Мендега үзенең ачыктан-ачык симпатиясен яшерә алмый. Аларны аз санлы милләт вәкилләренең тормышын саклаучы фәрештәләр итеп күрсәтергә омтыла (48 бит). Фашистларның хәрби әсирләрнең бер төркемен үз якларына аударырга азаплануы да бит кеше ресурслары табар башка чара калмаганнан уйланылган буш бер омтылыш кына була. Моңардан кешелеклелек идеяләрен эзләүне һич кенә дә башка сыйдырып булмый. Илбасарларның төрле милләт вәкилләреннән аерым легионнар төзеп маташуы, барыннан да элек, СССР халыкларының бердәмлеге, дуслыгын какшатуга юнәлтелгән булуы да сер түгел. Чөнки бу бердәмлек һәм какшамас дуслык Бөек Ватан сугышы елларында гаять зур һәм хәлиткеч мораль-политик фактор булып торды.

Әмма Мюлен үзе дә «милли легионнар» һәм «милли комитетлар» төзергә азапланулардан фашистлар зур булмаган милләт вәкилләренә нинди дә булса хокуклар бирергә омтылдылар дигән нәтиҗә ясарга җөрьәт итми кебек (59, 65 битләр). Чөнки шул ук фашизмның СССР халыклары вәкилләрен «унтерменш»лар (кеше булып формалашып җитмәүчеләр) итеп санавын кая куясың... Шулай да ул үзенең хезмәтендә фашизм идеологиясенең кайбер каршылыкларын сиземләсә дә, аның авантюристлыгын һәм совет гражданнарының социалистик Ватанга булган олы мәхәббәтен, бирелгәнлеген аңларга теләми. Гомумән, Көнбатыш Германия тикшеренүчесе, шактый бай фактик материаллардан файдалануына да карамастан, ясаган нәтиҗәләрендә, кагыйдә буларак, нигезсез кала.

Күзәтелә торган китапта «милли комитетлар» функциясен яктыртуга да урын киң бирелә. Аерым алганда, «Идел-Урал» комитеты һәм 1944 елда Грайфсвальдта уздырылган «милли» татар конгрессы эшчәнлекләренә игътибар юнәлтелә. Мюлен фашистлар тарафыннан оештырылган һәм аларның контроле астында узган әлеге җыелышны татарлар үз теләкләре белән чакырдылар дип ышандырырга тели. Ә Идел-Урал буржуаз дәүләтен төзүнең әле 1918 елда ук хезмәт халкы тарафыннан кире кагылуы һәм аның көн тәртибендә гади халык вәкилләренең һичнинди омтылышлары да чагылыш тапмавы турында ләм-мим.

Бу оешма җитәкчесе Шәфи Алмасның принципсыз һәм буш кеше булуын таныса да, автор герой-шагыйрь Муса Җәлил батырлыгын бәяләүдә бөтенләй урынсыз һәм сәер яңгырашлы нәтиҗәләр ясый. Янәсе, М. Җәлил эшчәнлеге аның бары тик милли хисләре, үз халкы культурасы өчен янып яшәве белән генә аңлатыла. Ул күзгә бәрелеп торган хакыйкатьне күрмәгән булып кылана — татар совет шагыйренең ялкынлы патриот булуын, социалистик Ватанга һәм коммунистик идеалларга бирелгәнлеген «абайламый» уза. Кайбер примитив, наив сәбәпләр табып һәм шуларга нигезләнеп, патриот-шагыйрьнең фашизмга кар-

шы көрәшкә күтәрелүен очраклы хәл дип аңлатмакчы була. Бу очракта да Мюлен совет патриотизмының тугандаш халыкларны уртак Ватан өчен көрәштә берләштергән һәм рухландырган тиңдәшсез зур көч булуын аңлый алмый.

Сүз уңаенда мәсьәләнең тагын шул ягына игътибар итми узу ярамас. Китапның авторы еш кына артык ашыгычлык белән олы нәтиҗәләр чыгарырга ярата. Мәсәлән, Муса Җәлил һәм фашистларга каршы аның җитәкчелегендәге оешма турында сноскалардан күренгәнчә, Мюлен үз Ватаныннан йөз чөергән сатлык җаннардан алынган мәгълүматлар буенча гына фикер йөртә. Юкса, М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең Г. Солтанов ише шундый сатлык җаннар доносы нәтиҗәсендә кулга алынулары һәм җәзалап үтерелүләре күптәннән мәгълүм бит. Куллары канга буялган андый адәм актыкларының ни сөйлисе алдан ук билгеле булса кирәк...

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында политик-масса һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы карары уңаена да сүз куертып, шундый ук принципсызлык күрсәтә автор. Һичнинди җитди дәлилләре булмауга да карамастан, ул татар коммунистларын милләтчелектә гаепләргә омтыла (209 бит).

Иен университеты доценты Клаус Ремер (ГДР) бик урынлы билгеләп үткәнчә, Мюленның эзләнүләре, нигездә, совет халкының Коммунистлар партиясе җитәкчелегендәге казанышларын һәм Бөек Ватан сугышы кырларында күрсәткән тиңдәшсез батырлыкларын буяп, киметеп күрсәтүгә юнәлтелгән. Һәм шул ягы белән ул К. Гелен, С. Штеенберг, В. Штрик-Штрикфельдт, И. Хофманн кебек «советологлар»ның хезмәтләрен хәтерләтә.

Тулаем алганда, Мюленның бу хезмәте безгә социалистик тугандашлыкның дошманнары әле дә яши һәм атмосфераны элеккечә буржуаз-милләтчелек идеяләре белән агуларга әзер торалар дигән хакыйкатьне тагын бер кат искәртә булса кирәк.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
тарих фәннәре кандидаты.

# МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАНГАН КИТАП

Татарстан китап нәшрияты язучы Мәхмүд Максудның Муса Җәлил турындагы **«Сагынган минутларда»** дигән китабын яңадан бастырып чыгарды (беренче басмасы 1963 елда дөнья күргән иде). Бу — авторның соңгы хезмәте.

Муса Җәлилнең вакытсыз «югалуы» Мәхмүд Максудка нык тәэсир итте. Әмма ул якын иптәше, дусты һәм туганы Мусаның шулай билгесез генә югалуына ышанмады. М. Җәлилнең 1976 елда Мәскәүнең «Матур әдәбият» нәшриятында чыккан сайланма әсәрләренә кереш сүздә шул уңайдан Мостай Кәрим:

«...Мәхмүд Максуд миңа Җәлилнең болай тик кенә, «билгесез...» югала торганнардан түгеллеген кат-кат әйтте»,— дип язган иде.

Әйе, шулай нык ышана иде Мәхмүд. Аның ышанычын бернинди шомлы хәбәрләр дә какшатмады. Хакыйкать ачыклангач, Мусаның һәлакәте өчен чиксез кайгырды. Бу кайгы тирән шатлык һәм горурлык хисләре белән бергә үрелгән иде. Мусаның үзе юк, асылда исә ул мәңге үлемсез!

Мәхмүд Максуд, каты авыруына да карамастан, Муса турында яза башлады. Озак язылды бу китап. Әмма бер дә өзелмичә диярлек язылды. Баштарак автор китап өстендә көн саен берничә сәгать эшләп, сәламәтлеге начарланган саен эш вакытын кыскарта барды һәм, ниһаять, эш «сәгате» көнгә 50 минуткача кимеде.

Мәхмүд Максуд китабының кереш сүзен болай башлый: «Муса Җәлил турындагы язмаларымны элек мин истәлекләр белән генә чикләргә уйлаган идем. Ләкин моның мөмкин түгеллеген бик тиз аңладым. Муса Җәлилнең тормышы аерылгысыз рәвештә иҗаты белән бергә бәйләнгән. Төгәлрәк әйтсәк, болар икесе бер бөтенне тәшкил итәләр». Кечерәк форматтагы 200 гә якын биттән торган китапта без Муса Җәлилнең иҗатын һәм тормышын күрәбез.

«Шагыйрь трибунада» дип исемләнгән бүлектә «Муса кешенең күңелен үзенә тарта белә иде. Ул ничектер, сиздермичә генә, күңел түрендә үзенә гомерлек урын ала белә иде. Муса турында сакланган иң кадерле тойгы дип менә шуны әйтәсе килә... Аның ашыкмый гына әйткән гади генә сүзләре ары-бире чәчелеп югалмый, бәлки, җылы тойгы янсә нәфрәт хисе булып, күңелгә берегә»,— дип искә ала автор. һәм аның сәхнәдә торып:

Җыелыш иде...
Комбат
йөрәгеннән
Чыккан тавыш белән эндәште:
— Я, егетләр...
фронт.
Кем языла?
Кем иле өчен курыкмас көрәшче?

кебек юлларны укуын күз алдына китерә. Шул уңайдан уйлануларга бирелә: «Туктагыз, сәхнәдә кем соң? Йөрәгеннән чыккан тавыш белән комбат сүзләрен шагыйрь сөйлиме, әллә комбат үзе шагыйрьме? Шулайдыр, ахрысы. Шагыйрьдер ул комбат».

«Тар гына бүлмәнең киң күңелле хуҗасы» дигән бүлектә исә Муса Җәлилнең Мәскәүдәге бүлмәсе, кечкенә генә шул бүлмәдә барган зур әңгәмәләр турында, шагыйрьнең киң күңеллелеге һәм кунакчыллыгы турында сөйләнелә. Чыннан да, сокланырлык сыйфат бит ул киң күңеллелек һәм кунакчыллык. Ул безнең бөтен халкыбызга хас! Бу хакта сүз чыккач, Җәлилнең кунакчыллыкка һәм киң күңеллелеккә мөнәсәбәтен белеп китү дә кызыклы булыр. Мәсәлән, китапта шагыйрьнең Ялтада авырып ятучы Галимҗан Ибраһимов янында булуы һәм аннан алган тәэсирләре турында языла. 1928 нче елда Муса Җәлил Севастопольдән Ялтага хәтле җәяүләп барып, иң башта Галимҗан Ибраһимовның хәлен белешергә юнәлә. Авыру язучы аны бик яхшы һәм ачык чырай белән каршы ала, «үзенең иң яраткан энесе килгән шикелле шатлана». Бу йортта Муса Җәлил өчен хәтта ванна да хәзерләнә. Шагыйрь бу очрашу турында китапның авторына түбәндәгечә сөйли:

— Я, үзең уйлап кара инде, мин кем аның каршында? Бер малай бит! Ә шундый зур хөрмәт! Шундый кайгыртучанлык! Бик уңайсыз булды булуын, ә шулай да җаным рәхәтләнде. Көч җыйдым мин анда.

Китаптагы бүлекләрнең берсе «Генрих Гейне — Муса Җәлилнең кунагы» дип атала. «Кечкенә генә, тар гына бүлмәнең хуҗасы киң күңелле иде, дидек... киң күңелле генә түгел, киң карашлы, киң колачлы иде ул»,— дип яза автор. Бу бүлектә әңгәмәләр вакытында ике дусның төрле мәсьәләләргә тукталулары хакында сөйләнелә. Алар шигырь турында да, фәнни коммунизмның нигез ташын салган Карл Маркс эшчәнлеге турында да һәм, ниһаять, Гейне шигырьләре турында да зур кызыксыну белән сөйләшәләр. Утырдашлар Гейне шигырьләрендәге нәфислеккә сокланалар, аның русча, немецча һәм татарча вариантларын укып үзара фикер алышалар.

Германиянең олы шагыйре Гейне әсәрләре илебез халыклары телләренә тәрҗемә ителеп, йөз меңнәрчә тираж белән чыгарылган бер вакытта, фашист ерткычлары ул әсәрләрне утка яктылар. Шул ук фашистлар хәр ирекле Гейнега гашыйк Муса Җәлилне тоткын иттеләр, фашистлар тарафыннан үлемгә хөкем ителгәч тә Җәлил Гейне турында изге хисләр саклый. «Алман илендә» дигән шигырьне тирән дулкынланмый уку мөмкин түгел. Ул шигырьдәге Гейне исеме Маркс, Энгельс, Тельман, Клара Цеткин һәм немец халкының башка онытылмас уллары һәм кызлары исеме белән рәттән телгә алына.

Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман җиренә.
Күтәрелсен Тельман трибунага,
Маркс, Гейне кайтсын иленә,—

ди Муса Җәлил.

Муса Җәлилнең газета-журнал редакцияләрендә эшләве турындагы истәлекләр дә зур кызыксыну уята. Автор егерменче елларда Мәскәүдә татар телендә чыккан газета-журналларны искә алып, аларны хәзерләүдә М. Җәлил башкарган эшнең колачына сокланып сөйли. Мәсәлән, **«Октябрь баласы»** редакциясендә җаваплы редактор Мусаның үзеннән башка күпмедер вакыт тагын бер сотрудник эшләгәне хәтеремдә. Ул секретарь булгандырмы, анысын ачык хәтерләмим. һәрхәлдә, Муса журналның бөтен эшен үзе алып бара иде»,— дип языла китапта.

Авторның хәтере чынбарлыкны дөрес саклаган. «Октябрь баласы» редакциясендә утызынчы еллар башында секретарь булып Рабига Зарипова эшли. Шулай да журналга урнаштырылган кечкенә генә хәбәрне дә Муса үзе укымый янсә редакцияләми уза алмаган. Журналистлар үрнәк алырлык яхшы сыйфатлар гомумән бик күп була Мусада.

Герой-шагыйрь истәлегенә багышланган хезмәтләр һәм китаплар аз түгел-түгелен. Мәхмүд Максудның «Сагынган минутларда» исемле китабы исә Җәлилнең тормышын һәм иҗатын гәүдәләндерүдә үзенчәлекле урын алып, әлеге хезмәтләрне тулыландырып тора. Китап җиңел укыла һәм күңелгә тирән үтеп керә.

«Сагынган минутларда»ны икенче кат чыгару герой-шагыйрь Муса Җәлилгә дә, китапның авторы Мәхмүд Максудка да ихтирам билгесе дип аңлыйм. Китапта, беренче басмасы белән чагыштырганда, байтак кына үзгәрешләр дә бар. Ә үзгәреш, ягъни төзәтүләр әсәрне яхшыртуга хезмәт итәргә тиеш. Кагыйдә буларак, төзәтмәләрне автор үзе кертә. Инде автор юк икән, бу җаваплы эш редактор җилкәсенә төшә.

Редактор Гөлшат Зайнашева иптәш тә үз бурычын үтәргә тырышкан һәм беренче басмадагы кайбер төгәлсезлекләрне уңышлы итеп үзгәрткән. Әмма яңа басмага кертелгән аерым үзгәртүләрне уңышлы дип әйтмәс идем, аларның кайберләре Мәхмүд Максудка хас ук түгел...

Мәсәлән, титул битнең икенче ягында кыска гына аннотация урнаштырылган. Анда, «китап 1960—1963 елларда язылды», диелгән. Мәхмүд Максуд исә 1962 елның 10 ноябрендә безнең арадан киткән иде инде. 19 нчы биттәге икенче абзац «...шигырьнең нәфасәте турында фикер йөртү безгә алай бик кыен булмады» дип тәмамланасы урынга, «...бик рәхәт, күңелле булды» дип тәмамланган. Бу бөтенләй икенче нәрсә, «рәхәт» каян килеп чыккан соң? Сүз Гейненың немец телендәге шигыре уңаена ике татар әдибенең фикер алышуы турында бара иде бит.

«Барган саен Мәскәү якынлаша» дигән бүлектә Ватаныбыз башкаласы Мәскәүнең төрле халык вәкилләреннән сәнгать осталары тәрбияләп үстерүе турында сөйләнелә. Бу татар композиторларыннан Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов, архитектор Гайнетдинов иптәшләр мисалында гәүдәләндерелә. Ни сәбәптәндер, «...ә беләсезме, хәзер ул үзе (сүз Гайнетдинов турында бара) Мәскәүдә архитектура институтында укыта», дигән җөмлә кыскартылган. Революциягә кадәр университетларда, институтларда татарлардан укытучы түгел, студентлар да юк дәрәҗәсендә иде бит. Авторның шуңа басым ясап әйтәсе килүе табигый. 141 нче биттә: «Бер хикәядә, мәсәлән, бер урта хәлле крестьян Теләче базарыннан исереп кайта да, канга батырып хатынын кыйный»,— кебек җөмлә урнаштырылган. Бу Мәхмүд Максудныкы түгел. «Михнәттән башы чыкмаган ярлы крестьян»... дип тасвирлый ул. Бу хәлдә картина бөтенләй икенче төс ала.

«Сагынган минутларда» китабының 101 нче битендә Мәхмүд Максудның: «...Муса Җәлил әсәрләрен туплаучы һәм анализлаучы иптәшләр төрле басмалардагы текстларны чагыштырып, авторча бирергә тиешләр», дигән сүзләре бар. Бу киңәшне башка язучылар мирасы белән эш иткәндә дә хәтердән чыгармаска иде бит.

**ХАК МАКСУДОВ.**

# СОН СУЛАРЫН ЭЧКӘН УЛ...

*Заһидулла Яруллинның 90 еллыгына*

Заһидулла Яруллин музыка сәнгатенең революциягә кадәрге тарихында тирән эз калдырган музыкантларның берсе булды. Башта атаклы гармунчы булып танылган Заһидулла Яруллин тиздән пианист булып үсеп җитә. Әмма барыннан да элек без аны музыкант-импровизатор, көйләр чыгаручы композитор буларак беләбез.

Ул 1888 елның 10 октябрендә Мамадыш өязе Сон елгасы буена салынган Кече Сон авылында ярлы крестьян Ярулла Баязитов гаиләсендә дөньяга килә. Кечкенә Заһидулла шул чор татар тормышының бөтен ачысын, моңын-зарын татып үсә.

Әтисен ул бөтенләй хәтерләми, бары тик аның зифа буйлы, шәп биюче булганын, ашлык суккан вакытта кибән башыннан егылып төшеп үлгәнен генә ишетеп белә. Берничә ел үтүгә алар әнисез дә калалар. Ләкин әнисенең гаҗәеп моңлы тавыш белән мөнәҗәт укуы, озын көйләргә басынкы гына җырлавы биш яшьлек Заһидулланың күңелендә гомергә онытылмаслык илаһи бер моң булып кала.

Ун-унике яшьләргә чаклы Заһидулла төрле гаиләләрдә тәрбияләнә. Чистай шәһәрендә музыка кораллары төзәтү остасында асрау малай булып хезмәт иткәндә, ул гармунда уйнарга өйрәнә, хуҗалары белән ярминкәләргә йөри. Бу чорда яшь малайга русларның шәһәр музыка культурасы көчле тәэсир ясый. 1902 елда Мәкәрҗә ярминкәсенә килгәч, беренче мәртәбә ул татар халык музыкантлары белән очраша, аларның татар, башкорт, рус көйләрен гаять оста башкаруларына хәйран кала, йотлыгып тыңлый.

Заһидулла ага Яруллинның музыкант булып формалашуында башта рус музыкантларының йогынтысы зур булса, ярминкәләрдә татар халкының атаклы скрипка осталары Мөхәммәтша Мостафин, Мәкәрҗә Гайсалар белән очрашулары аның бөтен тормышын үзгәртеп җибәрә. Ярминкә бетүгә Заһидулла хуҗасы белән эшне өзеп, Нижний Новгородтагы күңел ачу ханәләренең берсенә музыкант-гармунчы булып эшкә керә. Бу елларда яшь татар музыкантларына махсус белем алу өчен мөмкинлекләр дә, милли музыка клублары да булмый.

Билгеле булганча, 1905 ел революциясе Россиядә яшәгән халыкларның культура тормышына да зур үзгәрешләр кертә. Татар музыкасында да яңарыш чоры башлана. Казан, Әстерхан, Оренбург, Троицк, Уфа, Пермь, Чиләбе, Петропавловск, Омск, Эстәрлетамак, кыскасы, татарлар яши торган һәр шәһәрдә диярлек әдәби-музыкаль түгәрәкләр һәм кичәләр оештырыла. Мондый кичәләрдә алдынгы татар яшьләре белән бергә халык музыкантлары да катнаша. Танылган гармунчы Заһидулла Яруллин алдында яңа мөмкинлекләр ачыла. Уфа музыканты Г. Ижбулдин чакыруы буенча Заһидулла Уфага күчеп килә. Аның осталыгы бу вакытта көннән-көн камилләшә, техникасы да шомара, үсә бара. Аның исеме атаклы гармунчылар белән бертәттән йөри башлый. Ләкин Заһидулла Яруллинны гармун гына канәгатьләндерми. Ул оста пианист булу турында хыяллана. Нәкъ шул вакытта аның эзләгән укытучысы да табыла. Уфа кино-



*Рәсемдә (алда): Заһидулла Яруллин (сулда) һәм А. С. Ключарев. Артта (сулдан уңга): Фасил Әхмәтов, Аллаһияр Вәлиуллин, Мирсәет Яруллин.*

театрларының берсендә пианист булып эшләүче И. Я. Шнейдер Яруллинда зур талант барлыгын күреп, аның белән җитди күнегүләр алып бара. З. Яруллинның сәләте бик тиз ачыла, ул күзгә күренердәй уңышларга ирешә.

1912 елны З. Яруллин Казанда каршылый. Тиздән атаклы җырчы Фәттах Латыйпов концертында беренче мәртәбә пианист-аккомпаниатор булып катнаша. Казан Заһидулла Яруллинны яратып каршылый. Казанның атаклы җырчылары Ф. Латыйпов, С. Айдаров, Ф. Гумерова, Ә Бәхтизина, виртуоз гармунчы Ф. Туишев, скрипка осталары И. Козлов, Г. Зайпин һәм башкалар белән Заһидулла Яруллин бик күп концертлар бирә. Шәһәр кинотеатрларында пианист булып эшли. Заһидулла Яруллин халыкның яраткан музыканты булып китә.

Кинотеатрда сеанс барган вакытта картинага карап музыка уйнап утыру Заһидулла Яруллин күңеленә бик хуш килә. Аның импровизация осталыгы үсә бара. Ул үзе дә сеанслар арасында уйный торган ансамбль өчен бер-бер артлы яңа көйләр иҗат итә башлый. Өлкән музыкант Мөхәммәт Яушев әйтүенә караганда, яшь музыкант чыгарган көйләр халык арасында популярлык яулаган. Шәһәрдәге скрипкачылар, гармунчылар концертларда Яруллин көйләрен еш башкарганнар. Кызганычка каршы, Заһидулла Яруллинның ул көйләре сакланмаган диярлек. Нота битләренә бары ике көй язылып калган.

Заһидулла аганың халык арасында нык таралып, бүген дә уйналып килгән көйләреннән берсе — «Тукай маршы», икенчесе — «Җәмилә»[1]. «Тукай маршы»ның сәхнәдә уйнала башлавына алтмыш елдан артык вакыт үтте. Ләкин без аны бүген дә яратып тыңлыйбыз. Гәрчә «Тукай маршы» иң элек ансамбль өчен язылган булса да, 1917 елгы революция көннәрендә татар пролетариаты, революцион җырлар белән беррәттән, Тукайның үз сүзләре белән бергә шушы маршны да җырлаган. Гражданнар сугышы елларында татар полклары «Тукай маршы»н җырлап эшелоннарга төялгәннәр, «Тукай маршы»н җырлап фронтның алгы сызыгына кергәннәр.

Заһидулла Яруллин Казанда Г. Камал, Г. Коләхметов, Г. Кариевлар белән аралаша, И. Козлов, Шишков кебек рус музыкантлары белән иҗади дуслык урнаштыра. Шул ук елларда ул булачак мәшһүр композитор Салих Сәйдәшевкә музыка дәресләре бирә. Заһидулла Яруллин «Сәйяр» труппасы каршындагы музыка ансамбле белән дә җитәкчелек итә.

---

[1] Татар халык җырлары. 1941 ел, 47 бит. А. С. Ключарев редакциясендә.

Октябрь революциясен зур шатлык, тирән дулкынлану хисләре белән каршы алган Зәһидулла Яруллин Совет хөкүмәте чакыруы буенча бөтен энергиясен һәм талантын культура фронтында хезмәткә, халыкны агарту эшенә багышлый. Ул Казан гарнизонының хәрби коллегиясе каршындагы татар драма труппасы оркестрында эшли, гадәте буенча гармунчы да, пианист та, композиторлык эшен дә алып бара. 1922 елда Татнаркомпрос каршында Академик үзәк Зәһидулла Яруллинны татар совет эстрадасының иң күренекле артистлары белән бергә, Коминтернның III конгрессы делегатларына әзерләнгән концертта катнашу өчен Мәскәүгә җибәрә.

Егерменче еллар — Зәһидулла Яруллин иҗатының чәчәк аткан чоры. Ул «Колхозчылар», «Ялда», «Колхозчылар җыры», «Элегия», «Авыл көе» кебек актуаль темаларга күп кенә яңа көйләр иҗат итә.

Әмма кечкенәдән ятим үсеп, авыр тормышта яшәү талантлы музыкантның сәламәтлеген какшата. Шул сәбәпле аңа үзенең туган авылы Кече Сонга кайтып яшәргә туры килә. Авылда ул музыка кораллары ясау эшенә керешә, иҗади эшен — яңа көйләр язуын да дәвам иттерә. 1945 елда элекке Кызыл Йолдыз районы газетасында: «1945 елның шатлыклы көннәрендә, явыз дошманны җиңү тантанасына багышлап, З. Яруллин яңа өч көй чыгарды», дип хәбәр ителә.

1958 елда Зәһидулла ага Яруллинны, җитмеш еллык юбилее белән тәбрикләү өчен, Татарстан Композиторлар союзыннан аның якын дусты Александр Ключарев, Аллаһияр Вәлиуллин, Зәһидулла аганың кече улы Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтовлар килә.

Зәһидулла Яруллинның татар совет культурасы һәм сәнгате каршындагы роле аның үз иҗаты белән генә чикләнми. Ул атаклы «Шүрәле» балетының авторы—Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган талантлы композитор Фәрит Яруллинны тәрбияләп үстергән, аны музыка дөньясына алып кергән, укыткан, олы иҗат юлына чыгарган. Бүгенге көнне гаилә традициясен Зәһидулла Яруллинның кече улы Мирсәет Яруллин дәвам иттерә.

**ФАТЫЙМА ВӘЛИЕВА,**
**музыка белгече.**

# ҖИҢ СЫЗГАНЫП ЭШЛӘР ЧАК

*Рафак Тимергалинга 50 яшь*

Казан шәһәренең Ленин районында урнашкан мәһабәт Пресса йортының җиденче катындагы эш бүлмәсенә барып керсәм дә, тормыш һәм семья хәл-әхвәлләре уңае белән аның иркен һәм матур фатирына кагылсам да, исәнлек-саулык белешүнең татарча гадәти ритуалларыннан соң, китап шкафларына күз салам. Киштәләрнең тулылана баруына игътибар итәм, кайберләрен актарып та карыйм. Аның квартирасында да, эш бүлмәсендә дә төрле темага караган фәнни әдәбият һәм китаплар һаман күбәя бара. Аларның һәркайсында диярлек автографлар — чын күңелдән язылган рәхмәт сүзләре. «Сезгә зур ихтирам белән...»— дип, өлкән буын язучы һәм шагыйрьләр үз хезмәтләрен бүләк иткәннәр. Алтмышынчы-җитмешенче елларда әдәбиятка килгән яшьләр исә ачыктан-ачык: «Укытучыма...» «Өйрәтүчемә...» «Кулыма каләм бирүчеләрнең беренчесе Сез идегез...» яисә «Минем күпме генә әсәр Сезнең кулдан үтмәде икән инде? Шулар өчен рәхмәтемнең бер очкыны булсын иде бу истәлек» кебек ихлас сүзләр язып имзаларын куйганнар. Һәм бер дә урынсызга түгел, чөнки ул китапларның дөньяга чыгуына, яки матбугатта беренче бәя алып, укучыларга тәкъдим ителүенә дә аның көче кергән, катнашы булган! Шуның белән бергә ул тәрҗемә иткән китап һәм брошюралар, аның тәрҗе-

мәләре кергән политик-экономик, әдәби-теоретик, фәлсәфи һәм тарихи хезмәтләр, төрле җыентыклар бит әле никадәр!



Инде бераз олыгая төшеп, чигәләрендә көмеш бөртекләр күренә башлауга да карамастан ул һаман элекке — студент еллардагы кебек, рәхәтләнеп көлеп җибәрә, җор телле, үткен сүзгә аптырап калмый һәм, кирәк икән, нинди генә шартларда булмасын, үз фикерен принципиаль рәвештә яклый торган ир-егет... Әйе, нәкъ үзе — 1928 елның октябренда Актаныш районының Иске Байсар авылында туган, Пучы урта мәктәбен һәм аннан соң В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган югары белемле филолог; илленче елларда «Татарстан яшьләре» (ул вакытта «Яшь сталинчы» дип атала иде) газетасының бүлек мөдире һәм күп еллар буена шул ук газетаның редакторы да булып эшләгән Р. Тимергалин. Поэзия сөючеләр исә аны яшьлекнең ярсу хисләре белән өртелгән «Безнең таңнар» дигән шигырьләр җыентыгы авторы буларак та хәтерли торгандыр.

Гомумән, Рафак Тимергалинның бөтен тормышы һәм иҗат эшчәнлеге вакытлы матбугат һәм әдәбият белән бәйләнгән. Мәскәүдә КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлагач та ул журналистика һәм әдәбияттан аерылмады — КПССның Татарстан өлкә комитетында матбугат, радио һәм телевидение секторы мөдире булып эшләгән елларында Татарстандагы һәм бигрәк тә Казанда чыга торган газета-журналлар эше белән ныклап таныша, тыгыз элемтәдә була һәм аларга юнәлеш бирүдә катнаша. Моннан уналты ел элек, «Социалистик Татарстан» газетасы баш редакторының беренче урынбасары булып эшли башлагач, аңа әнә шул «танышлык» зур ярдәм күрсәтә.

Республика газетасының эше бик катлаулы. Аның көн саен чыгачак һәр санын алдан ук кирәкле материаллар, әһәмиятле һәм актуаль материаллар белән тәэмин итәргә кирәк — чөнки газета көнгә генә түгел, сәгатькә соңга калуга да түзә алмый. Һәр көн санының эчтәлеген һәм шул санда яктыртылырга тиешле үзәк темаларны алдан планлаштыру, редакциянең районнардагы махсус корреспондентлары белән даими бәйләнеш, булачак мәкаләләр авторларына киңәшләр бирү, материалларның фактик дөреслеген һәм сыйфат дәрәҗәсен билгеләү, аларга төзәтмәләр кертү, көн саен укучылардан килеп торган дистәләрчә хат-хәбәрләр белән танышу һ. б. — боларны кем генә исәпкә алып бетерергә мөмкин икән?! Шулар белән бергә үк, үзәктән телетайп аша килә торган официаль документларның, чит ил хәбәрләренең һ. б. дөрес тәрҗемә ителүен дә игътибар белән тикшереп барырга кирәк. Тагын да өстик: Р. Тимергалинга газетаның промышленность һәм авыл хуҗалыгы, совет төзелеше бүлекләре хәзерләгән материаллар өчен дә, шулай ук әдәбият-сәнгать һәм гомумән культура мәсьәләләренең газетада ничек чагылуы өчен дә җавап бирергә кирәк. Менә ничә еллар инде газетада һәр атна саен чыгып килә торган махсус «Әдәбият-сәнгать сәхифәсе»н даими оештырып баруда да аның хезмәте зур.

Газета укучылары тарафыннан көтеп алына һәм яратып укыла торган ул сәхифәләрдә өлкән буын язучыларыбызның да, хәзер инде үзләре әдәби хәрәкәтнең төбенә җигелеп тарта торган «урта буын» дип аталучыларның да, шулар белән бергә яшьләрнең дә күпме проза һәм поэзия әсәрләре, тәнкыйть материаллары

басылып чыкты. Культурабызның актуаль мәсьәләләрен күтәрүдә, тәнкыйтьчеләрне һәм әдәбият галимнәрен, театр, музыка, сынлы сәнгать белгечләрен газета тирәсенә туплауда гомумән «Социалистик Татарстан» редакциясе һәм аның бүлекләренең актив эшләвен күрсәтергә кирәк. Әдәбият һәм сәнгатебезнең үсеше, чәчәк атуы өчен боларның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын әйтеп тә торасы юк. Һәм менә шул эшләрне оештыруга, аларга юнәлеш бирүгә газетаның баш редактор урынбасары Рафак Тимергалин үзеннән гаять зур өлеш кертә.

Төрле елларда Казан шәһәр советы депутаты булып сайланган һәм күп еллар инде КПССның Казан шәһәр комитеты члены, республика Халык контроле комитеты члены Р. Тимергалинны җәмәгать эшлеклесе буларак та яхшы беләләр. Күпләр аның хезмәте авырлыгын һәм җаваплылыгын аңлый. Үтенеч белән килгәннәр дә байтак. Үпкәләүчеләр дә очрарга мөмкин. Нишлисең, төрле хәлләр булуы табигый. Журналист янына — принципиаль һәм таләпчән оештыручы янына киләләр бит ул кешеләр.

Р. Тимергалинга 1968 елда ТАССРның, ә 1978 елда РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Димәк, татар совет журналистикасы өлкәсендә озак еллар һәм нәтиҗәле эшләнгән. Инде зур тәҗрибә тупланган, эшләү стиле ныгыган, коллектив белән мөнәсәбәтләр юлга салынган. Шулай да алдагы эшләрнең дә очы-кырые күренми. Һаман күбрәк көч куеп, җиңне ныграк сызганып хезмәт итәсе көннәре алда әле.

Һич авырмыйча, хәзерге сәламәтлегеңне саклап, бөтен талантыңны җигеп, тагын да активрак хезмәт итүеңне телибез, Рафак дус Тимергалин!

**НУР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.**

# ТҮРЕБЕЗДӘ: АЙСОРЛАР

*Борынгы заманның иң зур дәүләтләреннән берсендә яшәгән ассирия халкының (барлыгы миллион ярым чамасы) хәзерге буыны Гыйракта (850 мең), Иранда (250 мең), Америка Кушма Штатларында (130 мең), Латин Америкасында (50 мең чамасы), Якын Көнчыгышның башка илләрендә (460 мең) һәм Советлар Союзында (24 мең) яши. Хәзерге Ираннан башлап Урта диңгезгә һәм Мисырга хәтле мәйданны биләгән Ассирияне башта Вавилон яулый, аннары монгол баскыннары талый, соңыннан бер өлеш ассириялеләр, дини нигездә таркалып, төрек солтанаты җәберенә дучар була. Беренче бөтендөнья сугышы елларында алар, әрмәннәр белән беррәттән, Төркия властьлары һәм көрд феодаллары тарафыннан чамасыз күп кырыла. Исән калганнар Якын һәм Урта Көнчыгыш илләренә, Европага, Америкага, Австралиягә тарала. Төрекләр изүенә каршы баш күтәрүдә катнашкан ассириялеләр (безнеңчә — айсорлар) Совет Россиясенә кайткач, алар өчен Әрмәнстанда, Грузиядә, Әзербәйҗанда һәм Краснодар краенда махсус совхозлар оештырыла. 1919 елда ук инде СССРда айсорлар телендә 400 китап һәм дәреслек басыла. «Көнчыгыш йолдызы» дигән газета һәм чит илләрдә 4 журнал чыга. Бөек Ватан сугышы елларында айсорлар Совет Ватанына чын күңелдән бирелгән патриотлар буларак танылалар — аларның бөтен илгә билгеле генераллары һәм Советлар Союзы Геройлары бар.*

*Бу санда безнең мәҗлестәшләребезгә айсор халык иҗатыннан моннан бик күп еллар элек Франциядә һәм Германиядә, Иранда һәм Советлар илендә басылган мәсәлләрдән кайберләренең тәрҗемәсе тәкъдим ителә.*

## ИШӘК БЕЛӘН САНДУГАЧ

Көннәрнең берендә урамнан узганда бер ишәк бакчада сандугач сайравын ишетеп таң кала. Һәм сорый ишәк сандугачтан: «Әйт әле, дускаем, бүген тавышың шундый матур булсын өчен иртән нәрсә ашадың син?» Сандугач әйтә: «Иртәнге ашым минем чык дымы һәм саф һава булды».

Ишәк, үзенең тавышы да сандугачныкы кебек сихерле һәм яңгыравык булуын теләп, чык дымы белән һава күбрәк керсен өчен, зур итеп авыз ача. Бүтән барча ризыктан ул баш тарта. Һәм ахырда җан тәслим кыла.

Бу мәсәлнең мәгънәсе шулдыр: кеше үз табигатенә каршы булган бер нәрсәгә дә омтылмаска тиеш.

## ЛӘТЧӘ БЕЛӘН ИГӘҮ

Бер ләтчә тимер кибетенә барып керә һәм шунда бер игәү күрә. Шуны бик тәмләп ялый башлый. Игәүгә бик каты ышкылган тел яралана һәм каный. Ә ләтчә исә бу кан тимердән чыга бит дип куана гына. Игәүне ялавын дәвам итә ул һәм ахыр чиктә бөтенләй телсез кала.

Бу мәсәлнең мәгънәсе ачык: үзсүзле кешеләр, хаталарын акларга тырыша-тырыша, үзләрен бөтен нәрсәдән мәхрүм итәләр.

## ИКЕ ӘТӘЧ

Ике әтәч талаша башлый. Җиңелгәне ниндидер бер кысан ояга кереп поса, ә җиңгәне биек өй түбәсенә менеп ала да, тамагын яра-яра кычкырып мактана икән.

Мактанчык әтәч бөркет күзенә чалына. Ул өй түбәсенә таш булып атыла да, көчле канат белән сугып имгәтеп, әтәчне эләктереп алып китә.

Бу мәсәл тыйнак булырга өнди: үз-үзеңне чамасыз мактарга, үз көчең белән чамасыз масаерга ярамый.

## ӨЧ ЕЛАН

Ике еланның үзара бик каты сугышканын-көрәшкәнен ерактан карап тора икән берәү. Шул чакны ул шул еланнар янына өченче елан да шуышканын күрә.

«Күрәсең, бусы да нәкъ теге ике елан кебектер, ахры», дип уйлый шул әдәм.

Шулай шул: һәр тинтәк үз ишен эзли.

## ҮГЕЗ ҺӘМ АРЫСЛАН

Бер үгез йоклап яткан арыслан баласын күрә дә бик каты сөзеп аны үтерә. Баласының мәетен күргән арыслан исә тирән кайгыга бата һәм үгезне бик каргый шул чакны.

Арысланны күреп әйтә шунда үгез: «Әгәр синең ул балаң зур арыслан булып үссә, нәкъ үзең шикелле, күпме җәнлек-җанварны ботарлар иде, нихәтле ана балаларын кызганып елар иде».

Әйе, кешеләрнең күпләренә үзләрендәге начар сыйфатларны күрә белмәү хас, әмма алар, син әшәкесең дип, бүтәннәрне үгетләргә бик хирес булалар.

## СЫРХАУ БОЛАН

Бер болан бик каты авырып китеп, тау түбәсеннән үзәнлеккә мәтәлә. Дуслары-иптәшләре аның янына бик еш килеп йөриләр, килгән саен шул үзәнлектәге куе үләнне дә туйганчы ашап китәләр икән.

Болан исә терелеп аякка баса, әмма үләнсез җирдә бик тиз арада ачтан үлә.

Шуны аңларга кирәк: хәлеңә кергән булып кызганыч белдергән күбәүләр сиңа ярдәм итүгә караганда күбрәк зыян гына китерә.

## АУЧЫ БЕЛӘН ЭТ

Үз хуҗасын югалтып кырда адашып йөргән бер этне очрата аучы. Хуҗасын эзләп табарга бер дә ашыкмыйча, табылдык эткә ул күпләп ризык бирергә тырыша.

Һәм әйтә икән эт көннәрнең берендә аучыга:

— Калдыр мине, кит син, синең чамадан тыш кайгыртучанлык мине бик куркыта.

Күптән билгеле нәрсә шул: чиксез игътибарлы затларга ышанмаска кирәк.

## БЕР АРЫСЛАН, ИКЕ ҮГЕЗ

Ике үгез белән көрәшә икән бер арыслан. Тегеләр бик бердәм булып карышканга, үгезләрнең һәркайсы арысланны мөгезгә эләктерә дә эләктерә, ә арыслан дигәнебез каршы көч күрсәтә алмый икән. Шуңа күрә дә ул хәйлә белән эш итәргә була. Бер үгез янына килә дә аның колагына пышылдый: «Әгәр дустыңны яклап авыз ачмасаң, мин сиңа бернинди яманлык эшләмәячәкмен».

Бер үгез арысланның шул вәгъдәсенә ышана, ә арыслан исә аларны, берәм-берәм берсеннән-берсен аерып, ботарлап ташлый: башта берсен, соңыннан икенчесен.

Нәтиҗә шул: әгәр илләр бердәм булсалар — аларны беркем дә басып алалмый. Үзара дошманлашсалар — һичшиксез җиңеләчәкләр һәм юкка чыгачаклар.

## БОЛАН ҺӘМ АУЧЫЛАР

Бер болан бик сусагач чишмәдән су эчәргә килә. Шунда ул суда чагылган үз шәүләсен күрә. Ә күргәне исә аңа ошамый: «Нишләп минем аяклар шулай нечкә һәм ямьсезләр икән?» Аннары ул шул ук шәүләгә карап үзен-үзе юата: «Кара, нинди зур һәм күп тармаклы мөгезле ич мин!»

Көтмәгәндә шул болан аучыларга юлыга. Болан җан-фәрман чабып кача. Тигез кыр буйлап чапканда, аучылар аңардан шактый артта калалар. Ә урман ешлыгына кергәч исә боланның мөгезләре агач ботакларына эләгеп бутала. Шуңа аңа аучылар аткан ук килеп тия.

Әйтә икән шул чакны болан: «Шул кирәк булган мин юләргә! Аякларым нечкә һәм ямьсез дип зарланган идем, ә шул аяклар мине исән калдырдылар бит. Ә шәпләрнең дә шәбе дип мактанган мөгезләрем мине һәлак иттеләр».

Бу очрак безне шуңа өйрәтә: матур күренгән һәр нәрсә мактауга лаек түгел, ә тормышның иң кыен минутларында безне бәладән коткарган нәрсәләр исә — мактаулы һәм кадерле.

## ТӨЛКЕ БЕЛӘН АРЫСЛАН

Капкынга эләккән бер арысланны күргәч, төлке аңа бөтенләй якын килә һәм бик каты кычкырып аны тирги-үгетли башлый. Ә арыслан әйтә икән: «Әгәр бу хәлгә калмаган булсам, син миңа карата моны һич эшли алмас идең...»

Нәтиҗә шул: дөньяның вак-төяк затлары бөек кешеләрне шулай мәсхәрәләргә һәр вакыт һәвәсләр.

## ЭТЛӘР ҺӘМ АРЫСЛАН ТИРЕСЕ

Этләр арыслан тиресе табалар. Шуңа ярсып ташланалар да кисәк-кисәк итеп йолыккалап та ташлыйлар. Шуны күргән бер төлке әйтә икән: «Әгәр арыслан үзе исән булса, сез үз тешләрегезнең аның тырнакларыннан бик күпкә көчсез икәнен сизәр һәм аңлар идегез, әлбәттә...»

Бу мәсәл кайчандыр көчле булган кешеләргә хәзер нәфрәт белән караучы түбән затларга кагыла.

## АУЧЫЛАР, АРЫСЛАН ҺӘМ ТЫЧКАН

Зур җәтмә корып аучылар бер арысланны тоталар. Бер тычкан килеп җәтмәне чәйнәп өзә дә арысланны коткара.

«Тормышта бер кемне дә кимсетмәскә кирәк икән!» дигән нәтиҗәгә килә арыслан.
Мәсәлнең мәгънәсе шул: дәрәҗәле затлар зур бәлаләрдән еш кына бары тик кечкенә һәм билгесез кешеләр ярдәме белән котылып калалар.

## БЕР МАЛАЙ ҺӘМ БЕР ЧАЯН

Кайчандыр бер малай шәһәр стенасы артында бер чикерткә тота. Шуннан бераз соңрак ул сахрада чаян очрата һәм, бу да чикерткә нәселеннәндер дип уйлап, аны кулына ала. Чаян исә аны шул чакны бик каты чага һәм әйтә: «Син мине тотам дип уйладың, ә асылда исә моңача булган бар нәрсәңнән дә мәхрүм калдың».
Нәтиҗә: теге яки бу алымны тормышның һәркайсы очрагында да куллану ярамый.

## БҮРЕ БЕЛӘН АРЫСЛАН

Бер бүре бәрән урлый. Урманга алып кайтып барышлый, арыслан очрап аннан бәрәнне тартып ала. Ризыксыз калган бүре ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән әйтә икән шул чакны:
— Мин тапкан малны болай талап алуың бик сәер бит әле.
— Ә син таланган мал белән аерылышуны югалту дип санама һәм бер дә кызганма...
Әйе, таланган мал каракның үз кулында бик сирәк очракта гына кала. Еш кына исә аның үзен талыйлар.

## ТЫЧКАННАР ҺӘМ МӘЧЕЛӘР

Тычкан халкын мәчеләр чиксез-чамасыз кыра икән. Шул бәладән котылу турында уйлашканда, безнең башлыкларыбыз булырга тиеш дигән нәтиҗәгә киләләр алар. Һәм шундый башлыклар сайлап та куела. Һәркемгә күренеп торсын өчен, аларның башына алтын мөгез дә беркетелә.
Көннәрнең берендә мәчеләр тычканнар өеренә зур һөҗүм ясыйлар. Гади тычканнар үз ояларына качып бик тиз котылалар икән. Ә башлыкларның исә хәле яманрак: аларның алтын мөгезләре ояга кереп качарга комачаулый һәм... аларның барысын да тотып ашыйлар.
Йомгак сүз шул: табигый булмаган һәр кыланыш кешеләргә бары тик зыян китерә һәм аларның һәлакәтенә сәбәпче була.

## КОШЛАР ПАТШАСЫ

Кошлар үзләренә патша сайларга карар кылалар. Тәхет өчен көрәшнек кызганда тавис торып баса да әйтә: «Минем тышкы кыяфәт гүзәллеге бары тик мин генә патша булырга тиеш дигән фикерне раслый».
Аның белән бөтенесе инде килешә язганда гына тавис янына бер карга килә дә әйтә икән: «Ярый ди, мәсәлән, син патша да булдың ди. Әгәр дә ки бөркет һөҗүм итә башласа, ничек саклый алырсың икән безне син?»
Мораль: Үзен саклый алмаган бүтәннәрне яклый алмый.

## КАРТ ӘБИ ҺӘМ ТӨЛКЕ

Тинтәгрәк бер әбинең ишәге була. Шуны ул һәр көннең иртәсендә үлән утлап йөрергә чыгарып җибәрә. Шул басуга көн саен бер төлке килеп чыга һәм ишәккә атланып иртәдән кичкә хәтле чаба икән. Ишәк өйгә арып-талып кайта.

...Күршеләре киңәше белән әби кеше ишәккә сумаладан ияр эшләтә. Шуңа менеп атлангач һәм көндезен кояш кыздыра башлагач, төлке ишәкнең сыртына ябышып кала. Көтүче исә әбигә ишәкне шул төлке белән кайтарып бирә. Кызы белән бергәләп карчык төлкене кыйный башлый.

— Үтергәнче кыйнасаң кыйна, әмма йөземле келәткә генә яба күрмә, әбекәй!— ди төлке.

Ә төлкене барыбер шунда ябалар; ул андагы бөтен йөземне ашап бетерә һәм үзен тагын кыйный башлагач, болай дип ялвара:

— Теләсәң нишләт, әбекәй, әмма тавык кетәгенә япма мине!

«Ә, салкыннан һәм юештән курка икән бу» дип, әби аны юри шунда яба. Төлке андагы барча тавыкларның һәм әтәчнең башына җитә.

Иртән әби кетәкне ачып карыйм дигәндә исә төлке дигәнебез чыга да урман ягына шыла. Ә әби? Йөземсез дә, кош-кортсыз да кала ул. Ник? Ачык авызлы тинтәк булганы өчен.

## АРЫСЛАН ҺӘМ КУЯН

Арысланның, чират буенча, куянны ашар көне җитә.

— Ник болай соңга калып, инде иртәнге аш узгач килдең?

— Мин бирегә бер куян иптәшем белән килә идем, юлда аны бер арыслан тотып ашады һәм шул арыслан сине дә бик яманлап сөйләде. Шуңа күрә соңгардым,— ди куян.

— Әйдә, шул арысланның кая торганын күрсәт әле миңа!

Куян арысланны су тулы тирән баз янына ияртеп килә:

— Менә шунда тора явыз арыслан.

Суга карый да арыслан үз шәүләсен күрә, явыз арысланны ботарларга дип суга сикерә һәм шунда батып үлә.

## ФИЛ ҺӘМ ТЕГЕРМӘНЧЕ

Сахрада адашып бик күп йөргән фил бер тегермәнгә килеп чыга һәм... тегермәнчедән шунда кич кунарга бик каты үтенеп рөхсәт сорый. Тегермәнче кертә килмешәкне. Ә иртән ул әйтә кунакка: «Инде китәргә вакыт бит...» Фил әйтә икән шул чакны: «Кемгә кысан булса, шул китсен, ә миңа биредә дә яхшы».

## АЮ ҺӘМ БҮРӘНӘ

Урман буйлап йөргәндә бер аю бал исе сизә. Бер агач башына карый ул һәм шуңа бау белән бәйләп куелган бүрәнә күрә. Менә башлый. «Бу нәрсә миңа бер дә ошамый», ди аю һәм бүрәнәне үзеннән читкәрәк этмәк була. Бүрәнә исә салмак кына селкенеп ала да аюның янбашына китереп бәрә. Аю аны, ачуланып, тагын көчлерәк итеп этә. Бүрәнә аның башына килеп бәрелә. Тагын этә — бүрәнә аны агач башыннан егылып төшәрлек итеп иңен-башын авырттыра, ахырда исә... бәрелеп, аюның башын яра. Ә агачка бәйләп куелган бүрәнә акыллы кешеләр өчен әле хәзер дә теге балны саклый.

Димәк: көч дигәнең бөтен нәрсәне дә хәл итми!

## БЕР ҮЛӘН ҺӘМ КАНӘФЕР ЧӘЧӘГЕ

Канәфер чәчәкләре арасында бер үлән үсә һәм шул чәчәкләрдән хуш ис ала икән. Шул үләннән сорыйлар: «Нишләп әле синнән шундый шәп ис аңкый?» Әйтә икән үлән: «Канәфер белән дуслаштым, минә нәкъ шуның исе сеңде!»

Чын дуслыкның нәтиҗәсе менә шундый була ул!

## УСАЛЛЫК ӨЧЕН ҖӘЗА

Бер арыслан үлеп ята. Инде йөзтүбән капланган, көчкә сулыш ала. Заманында үзләрен бик каты азаплаган шул җанварга үч итеп аның янына киләләр икән бүтәннәр. Кабан дуңгызы килә дә бик каты тешли, үгез бик каты сөзә, ишәк исә тояклары белән бик каты типкәли. Арыслан хәтта ачудан үлә яза — хәтта ишәк җәзасын да кичерергә кирәк бит...

Мораль: картлыгыңны хөрмәт итсеннәр өчен, яшь чагыңда кешеләргә күбрәк яхшылык эшләргә тырыш.

## БҮРЕ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Бүре белән төлке дуслаша. Бервакыт алар бакчага кереп виноград ашамак булалар.

Төлке ике виноград өзеп ала да үзенең борын тишекләренә китереп куя һәм әйтә бүрегә: «Туганкай, менә күр, мин шул хәтле ашадым ки виноградны, менә ул җимеш инде минем борыным тишекләреннән кире дә чыга башлады. Ә син шул кадәрне ашый аласыңмы?»

Бүре, берни дә шик һәм хәйлә белмичә һәм төлкедән уздырырга теләп, әлбәттә, комсызланып, ашый да ашый икән җимешне.

Төлке исә бакчада чабып-уйнаклап йөри, хуҗа күзенә яхшырак булып күренергә тырыша. Хуҗа күреп алгач һәм аны куа киткәч исә, төлке дигәнебез бүренең нәкъ яныннан узып шыла. Хуҗа исә шунда фәкыйрь бүрене тота һәм аның язмышын үзе теләгәнчә хәл итә.

## ТӨЛКЕ, ҺӨД-ҺӨД, ӘТӘЧ ҺӘМ ЛӘКЛӘК

Бер төлке һөд-һөднең, әтәчнең һәм ләкләкнең ышанычын казанырга тели. Алар ышангач исә ул — күп хатынлы булганы өчен әтәчнең бугазын, башында Сөләйман таҗы йөрткән өчен һөд-һөднең муенын чәйнәп өзә, ә ләкләкне исә төнлә тавышлап кешеләрне борчыганы өчен корбан итә.

Камил Мостафин

# ПАРОДИЯЛӘР

## Оныткамын

Хуш, диңгезем — тыныч култыкларың,
давылларны кичкән кыяларың!..

Вак интриган күзгә карап көлә —
ат перчаткаң! —
булмый атышып...

Роберт Әхмәтҗанов.

Хуш, диңгезем! Китәм! Нигә дисәң,—
юешләнгән капрон күлмәгем...
Яр тапталган...
Никтер оныткамын
монда элек кемнәр йөргәнен.

Күңелгә гел таныш юллар килә,
ә интриган күзгә карап көлә,
тора, каһәр, эшкә катышып.
Пистолетны өйдә калдырганмын,
жалкы бит, әй,—
булмый атышып!

## Ярамый шул...

Ә мин көнлим сине — ят күзләрдән,
Иңнәреңә яткан чал туннан,
Алларыңа алтын чәчен сибеп,
Сер бүлешкән төнге лампаңнан.

Сәҗидә Сөләйманова.

Көнлим сине, көнлим — ят күзләрдән,
Бармагыңны кочкан балдактан,
Ыспай чәчләреңне аралаган
Үзең сатып алган тарактан.

Иңнәреңә яткан туннан көнлим,
Син юына торган сабыннан...
Галстук та, чая кызлар кебек,
Муеныңа әнә сарылган.

Яшерермен сине ят күзләрдән
(Мин хәзергә әле сабырлы),
Тик нишләтим икән шул лампаңны,
Тарагыңны, тунны, балдагыңны
Һәм галстук белән сабынны?!

Атар идем утка, барсын җыеп
Һәм үч итеп сиңа, юләргә!..
...Әйе, шулай итәр идем дә бит,
Ярамый шул — акча түләнгән!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЭШЧЕ СЫЙНЫФЫ ТУРЫНДА ЯҢА КИТАПЛАР

1976—1978 елның шушы тема әсәрләре конкурсын ВЦСПС президиумы һәм СССР Язучылар союзы игълан иткәннәр иде. Күптән түгел аңа йомгак ясалып, бер беренче бүләк Петр Проскурингa («Имя твое» романы), ике икенче бүләк Олесь Гончарга («Берег любви» романы) һәм Аркадий Первенцевка («Гегемон» романы) бирелде. Өч әдип (Кокоулин, Скоп, Мирмухсин) өченче бүләккә лаек булдылар. Кызыксындыру бүләгенең берсен безнең әдибебез Эдуард Касыймов Татарстанның Бондюг химиклары турында язылып, русчага «Чулман — река внуков» исеме белән тәрҗемә ителгән романы өчен алды.

## ДӘРЕСЛЕКЛӘР КАМИЛЛӘШЕР ҺӘМ СТАБИЛЬ БУЛЫРЛАР

Республикабыз Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан китап нәшрияты шул турыдагы мәсьәләне конкрет тикшерделәр. Анда министр В. В. Иванов, профессорлар М. З. Зәкиев һәм Д. Г. Тумашева, КДУ һәм КДПИ укытучылары, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, РСФСР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты галимнәре, педучилище һәм урта мәктәп укытучылары катнашты. Чыгышларда татар телендә аерым дәреслекләрнең сыйфаты анализланды һәм күп кенә эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

## «ВОЛГА» ЖУРНАЛЫ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Унынчы бишьеллыкның зур эшләре һәм казанышларына «Волга» журналы керткән өлеш турында сөйләшү июнь азагында Саратовта үткәрелде. Бу иҗади конференциядә Мәскәүдән, Идел буеның унтугыз өлкә һәм республикаларыннан килгән вәкилләр журнал материалларының сыйфаты һәм аның авторлар белән иҗади элемтәләрен тагын да ныгыту перспективалары турында сөйләделәр. Татарстан язучылары исеменнән анда Мәҗит Рафиков һәм Равил Фәйзуллин чыгыш ясады. Киләсе елда «Волга»ның бер саны бүгенге татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләрен махсус туплап чыгарачак.

## ЯШҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН

Казандагы Яшьләр үзәгендә яшүсмерләр өчен республикада беренче махсус китапханә ачылды. Аның фондында — 30 меңярым том китап, күп төрле исемдәге көндәлек матбугат теркәмәләре, күп санлы диапозитивлар һәм грампластинкалар коллекциясе.

## МАРИ ДУСЛАРЫБЫЗ СЪЕЗДЫ

Йошкар-Олада мари язучыларының бишенче съезды булып узды. Анда күрше республика әдипләренең соңгы биш елдагы иҗаты партия билгеләгән бурычларны хәл итү юнәлешендә, илнең күп милләтле зур әдәбияты үзәненә кушылган агым булып үскәнлеге, җирле һәм үзәк нәшриятларда 150 дән артык китап чыгарулары билгеләп үтелде. Мәскәүдән һәм тугандаш республикалардан килгән әдипләр исә, шул җөмләдән Татарстан язучылары вәкиле Самат Шакир заман темасына язылган һәм төп проблемаларны художестволы хәл итүгә багышланган әсәрләрнең киләчәктә берсенберсе кабатламый торган, тормыш яңалыгын кыю ачышлы итеп, киләчәккә үткенрәк караш белән язылсыннар иде дигән теләк белдереп чыгыш ясадылар.

## УДМУРТИЯДӘ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Инде күптәннән Воткинск заводының пролетар традицияләре булган, Октябрьдан соң исә промышленность һәм авыл хуҗалыгы, фән һәм культура үсешендә гадәттән тыш зур сикереш ясаган удмурт дуслар илендә СССР Язучылар союзы үткәргән совет әдәбияты атналыгында Татарстан әдипләре коллективыннан Гариф Ахунов катнашты.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

20—21 июньдә Уфа шәһәрендә «Урал һәм Идел буе халыкларының әдәби мирас проблемалары һәм бүгенге тормыш» дигән темага региональ фәнни конференция булды. СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы тарих, тел һәм әдәбият институты тарафыннан хәзерләнгән бу конференциягә Казагыстан ССР, Татарстан, Удмурт, Мари, Чуваш, Мордва, Карел автоном республикаларыннан да галимнәр килгән иде. Конференциядә Казан тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәреннән профессор М. Х. Гайнуллин, филология фәннәре кандидатлары Ә. Г. Әхмәдуллин, Ш. Ш. Абилов, М. В. Гайнетдинов, Казан педагогия институты галиме Ф. Хатипов доклад һәм чыгыш ясадылар. Конференциядә катнашучылар арасында туган якларына кайтышлый Уфада туктаган прозаик Әмирхан Еники дә бар иде.

## ТАНЫШ ЯКЛАРДА

Ленинград шагыйре, дистәдән артык шигырь китабы авторы Михаил Сазонов 1942 елда фронтта каты яралангач, Казан госпиталенә озатыла, бирегә аның күзләрен өлешчә булса да күрә торган итеп дәвалыйлар. Аннары ул Казанда слесарь булып эшли һәм поэзия өлкәсендә дә үзенең сәләтен сыный башлый. Күптән түгел шагыйрь яңа китапка материал туплар өчен Татарстанга килде, Казанда һәм КамАЗда булды.

*

* *

Җәй урталарында Казанда булып, илдә күптән танылган кино һәм театр артисты, якташыбыз Раднер Моратов Татарстанда яшь киносөючеләрнең икенче республика слетында эстетик зәвыклы булырга өндәгән матур, бик гыйбрәтле чыгыш ясады. Төрле киностудияләр төрле илләрда төшергән алтмыштан артык фильмда дүрт дистәләп милләт вәкиле рольләрен уйнаган бу оста быел республикабызның Зеленодольск районы «Үрнәк» поселогында төшерелгән «Бәйрәмнең өч көне» исемле нәфис фильмда татар кешесе образын башкарачак.

## ХАЛЫК ХӨРМӘТЕ

Әдәби телебезгә нигез салышучыларның берсе, атаклы шагыйрь Габделжаббар Кандалыйның кабере, мәгълүм булганча, Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы, Иртуган авылы (Иске Кандал) җирендә. Үткән елны шагыйрьнең тууына 180 ел тулу уңае белән «Восход» колхозы идарәсе (председателе Ә. Сафиуллин, партия комитеты секретаре Р. Габбасов) шул кабер өстенә яңа чардуган кордырып, шагыйрьнең исеме язылган гранит таш куйдырды.




## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТАГЫН БЕР МУЗЕЕ

Ул Җиңү көне уңае быел Пермь шәһәренең 70 нче номерлы мәктәбендә ачылды. Үзәк районның мәктәпкә шефлык иткән предприятиеләре аның матур бинасын җиһазлауга күп көч куйганнар. Мусаның яшьлек дуслары, сугышка хәтле үк Пермьдә эшләгән, Мусаның тормышы һәм иҗатын армый-талмый пропагандалаучы Ибраһим һәм Биби ханым Кадыйровлар музей өчен шактый кызыклы яңа экспонатлар тапканнар һәм алар зур осталык белән әзерләнгән. Музей зур җәмәгатьчелек катнашы белән тантаналы төстә ачылды. Анда Ташкенттан филология фәннәре кандидаты, Муса һәм аның көрәштәшләре турында белгеч Исхак Зәбиров та катнаша һәм музейга үзенең кандидатлык диссертациясенең бер данәсен, «Җәлил белән бергә» дигән китабын бүләк итә. Ә Пермь өлкәсенең «Белем» җәмгыяте исә аның Муса батырлыгы һәм үлемсез иҗаты турында чыгышларын хәрби частьта, Эчке эшләр министрлыгы идарәсендә, фармацевтика институтында, елга училищесы һәм хореография училищесы, 5 нче һәм 52 нче номерлы мәктәпләрдә һәм предприятиеләрдә оештырылган, барлыгы 2500 кеше катнашкан аудиторияләрдә үткәрә.

*

* *

Мусага багышлап уздырылган шундый ук зур кичәләрнең берсе Ташкентта М. Әшрәфи исемендәге консерваториянең актлар залында уздырыла. Анда Муса турында

исталекләрен Хәдичә Җәлилова сөйли һәм фән кандидаты, Үзбәкстан Журналистлар союзы премиясе лауреаты Исхак Зәбиров чыгыш ясый.

## КАЗАННАН ЧИТТӘ

*
* *

Төркестан хәрби округының Ташкентта үткәрелгән 60 еллыгы тантанасында шагыйрь Зәки Нури катнашты. «Кичке Ташкент» һәм хәрби округның «Фрунзевец» исемле газеталарда аның хәрби темага шигырьләре басылды.

*
* *

Хабаровск шәһәре китап нәшриятында чыккан «Доблесть поколения» исемле китапта Ленин һәм Дәүләт премияләренә лаек булган шагыйрьләрнең БАМ төзүчеләренә багышланган шигырьләре тупланган. Анда Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» дигән кечкенә поэмасының тәрҗемәсе дә кертелгән.

*
* *

«Поэзия» альманахында (Мәскәү, «Молодая гвардия» нәшрияты, 21 нче чыгарылыш) шагыйрә Мәрзия Фәйзуллинаның русчага Римма Казакова тәрҗемә иткән алты шигыре басылды.

*
* *

Быел Голландиянең Амстердам шәһәрендә дөнья күләмендәге фотокүргәзмә оештырылды. Анда төрле континент фотографларыннан барлыгы 400 рәсем кабул ителде. Шулардан утызы — СССР фотографлары эше иде. Безнең Татарстаннан анда «Азат хатын» журналы фотохәбәрчесе Рифкать Якуповның сабан туе темасына төрле елларда төшерелгән рәсемнәре күрсәтелде. Автор киләчәктә андый сурәтләрне тематик альбом итеп тупларга җыена.

## СОЮЗЫБЫЗНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

*
* *

Лениногорск әдәбият берләшмәсе утырышында язучыларның иҗат активлыгы турында сүз барды. Анда Әдип Маликов, Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов һәм башкалар берләшмә эшенең уңай һәм кимчелекле якларына тукталдылар, яңа әсәрләргә анализ ясадылар.

*
* *

Татарстан радиосыннан Әлмәт әдәби берләшмәсе членнарының чыгышы булды. Берләшмә җитәкчесе Сәҗидә Сөләйманова кереш сүзеннән соң яшь авторлар Роберт Рәкыйпов, Венера Туктарова, Әхтәм Фәхретдинов яңа шигырьләрен укыдылар.

*
* *

Укытучы Таһир Шәмсуаровның яңа шигырьләр кульязмасы тикшерелде. Аның уңай һәм җитешмәгән якларын билгеләп, Ә. Маликов һәм Қ. Булатова заман темасы әсәрләренә күбрәк игътибар итәргә кирәклеген әйттеләр.

*
* *

Лениногорскидан яшь шагыйрь һәм музыкант Разим Вәлиуллин җитәкчелек иткән вокаль квартеты һәм С. Мортазин җитәкләгән бию ансамбле Беренче Бөтенсоюз сәнгать фестивале лауреатлары исемен алганнар иде. Шул ике коллективтан сайлап алынган группа Польшаның Варшава, Краков, Закопане һәм Жешов шәһәрләрендә чыгышлар ясады.

*
* *

Чирмешән районының Урманасты Утәмеш авылы клубында Лениногорск әдәбият берләшмәсе членнары әдәби-музыкаль кичә уздырдылар.

## УКЫТУЧЫЛАР БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

1978 елның июнендә Тольятти шәһәрендә башлангыч мәктәп укытучыларының өлкәара курслары эшендә филология фәннәре кандидаты Гөлчәчәк Әдһәмова катнашты. Ул РСФСРның унөч өлкәсеннән килгән 70 укытучы алдында татар балалар әдәбиятының бүгенге торышы турында сөйләде. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен Татарстан китап нәшриятының 1978 елда бастырып чыгарган китаплары һәм 1979 елга төзелгән планы белән таныштырды.


## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Тарих фәнен үстерүдәге хезмәтләре, нәтиҗәле педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел, 26 июнь Указы нигезендә тарих фәннәре докторы, профессор, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының КПСС тарихы кафедрасы мөдире, «Казан утлары» журналының редколлегия члены **Рәфыйк Измайлович Нәфиковка Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

# КЕШЕ БУЛСАҢ

**АЛМАЗ МОНАСЫЙПОВ**
**музыкасы**

**ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИН**
**шигыре**






Бу дөньяда яшәү җиңел түгел,
Һәр вак-төяк өчен җаның янса,
Намуссызлар, вөҗдансызлар өчен
Үз вөҗданың әгәр газапланса.

Бу дөньяда яшәү җиңел түгел,
Кулсызларның сыңар кулы булса
Аяксызга терәк-таяк булсаң,
Улсызларның газиз,
Улсызларның газиз улы булсаң.

Җиңел түгел, яуда ауганнарның
Әрнеп тынмас яралары булсаң,
Сак белән Сок кебек кавыша алмаган
Ике җанның аралары булсаң.

Бу дөньяда яшәү җиңел түгел,
Йөрәксезләр өчен йөрәк булсаң,
Телен тыйганнарның теле булсаң,
Тик бирәүгә җирдә,
Тик бирәүгә җирдә үрнәк булсаң.

Бу дөньяда яшәү җиңел түгел,
Һәр вак-төяк өчен җаның янса,
Намуссызлар, вөҗдансызлар өчен
Үз вөҗданың әгәр газапланса.

Җиңел түгел, бер дә җиңел түгел
Җиңел түгел яшәү кеше булсаң,
Ләкин кеше башын салса салыр,
Кешелеген барыбер,
Кешелеген барыбер саклап калыр

# *Хөрмәтле укучыбыз!*

Икенче ай инде газета-журналларга язылу бара. Шул уңай белән Сезгә «Казан утлары» журналының 1979 елда нинди әсәрләр бастырып чыгаруы турында хәбәр итәргә телибез.

Һәр елдагыча язучыларыбызның яңа әсәрләренә зур урын биреләчәк.

Атилла Расихның фән кешеләренең хезмәте һәм тормышын чагылдырган «Сынау» исемле романы, Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» дигән тарихи романы, Мирсәй Әмирнең «Үсә төшкәч» дигән автобиографик повесте, Сәҗидә Сөләймәнованың медиклар тормышыннан язылган «Гөлбадран» повесте, Әхсән Баяновның бүгенге авыл кешеләрен сурәтләгән «Аязучан болытлы һава» повесте, Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар», Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Хәтер ярлары» дигән повестьлары, Әмирхан Еники, Рафаил Төхфәтуллин, Диас Вәлиев, Азат Ганиев хикәяләре редакциягә кабул итеп алынды.

«Замандаш» конкурсы дәвам итәчәк.

Поэзия бүлеге Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Зәки Нури, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әдип Маликов, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов һ. б. күп кенә шагыйрьләрнең яңа шигырьләре белән таныштырачак. Поэзия турында сөйләшү дә ел буена дәвам итәчәк.

Публицистик язмаларда һәм очеркларда татар халкының революцион тарихы, бүгенге фидакарь хезмәте чагылачак.

Ватан сугышы батырлыгын сурәтләгән материаллар басылачак.

Сәнгать бүлеге театр, рәсем, музыка сәнгатенә кагылышлы фәнни-популяр мәкаләләр, сәнгать кешеләре турында очерклар, фотодокументлар, истәлекләр әзерли.

Тәнкыйть бүлеге бүгенге татар совет әдәбиятының актуаль мәсьәләләренә багышланган материаллар, язучыларның иҗат портретлары, яңа китапларга күзәтү һ. б. характердагы мәкаләләр тәкъдим итә.

«Халык иҗаты», «Төрлесеннән», «Елмаеп та, көлеп тә», «Мәсәлчеләр мәҗлесе», «Нәниләр дөньясы», «Безнең календарь», «Укучы сүзе», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» дигән рубрикаларда да күп кенә кызыклы материаллар басылачак.

Хөрмәтле укучыбыз!

«Казан утлары» журналына вакытында язылырга онытмагыз. Ул 73210 индексы белән Бөтенсоюз каталогына кертелгән һәм аңа Советлар иленең теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин.

Журналга язылу бәясе елга — 6 сум.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210